ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

11.2010





**Салих Сәйдәшев**
**(1900—1954)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

**11**
**(1057)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---



✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Онытылган агач. *Шигырьләр* ........ 5
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Лотфулла солдат. *Бәян* ........ 10
Нәҗибә САФИНА. Күңел фасыллары. *Шигырьләр* ........ 38
Дамир ГЫЙСМЕТДИН. Божра буйлап. *Бәян* ........ 42

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Ленизa ВӘЛИЕВА. Әй, болыт, кояшны каплама!.. *Шигырьләр* ........ 79

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Батулла. Төнге мәҗлес. *Хикәя* ........ 81

**ФӘН**

Дамир ИСХАКОВ. Татар юлы такыр түгел... ***(Татарның этник тарихы, халыкны исәпкә алу һәм сәясәт)*** ........ 90
“Татар энциклопедиясе” битләреннән ........ 149
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 152

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Аллаһ боерса, мәчет тавына ап-ак карлар явар... ........ 112

**Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары ........ 117

**СӘНГАТЬ**

Рашат НИЗАМИ. Иске Аракчиноның күккә ашуы ........ 136
Әзһәр ШАКИРОВ. Булмас димә, дөнья бу!.. ........ 143

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Аксакаллар мәҗлесеннән ........ 121
“Мин йолдыз түгел, җырчы гына.” ***(Ф. Фәтхинең мәшһүр җырчы Ф. Кудашева белән әңгәмәсе)*** ........ 155
Фирдәвес ХУҖИН. Күкләр шаһит. *Документаль бәян* ........ 160

**АК ҖИЛКӘН**

Разил ВӘЛИЕВ. Бәләкәй Разил ........ 174
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Су елмайгач... *Хикәя* ........ 182
Ким ШАКИРОВ. Капица аткан ук ........ 184

Берлекнең яңа әгъзалары ........ 185
“Казан утлары” архивыннан ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": повести З. ЗАЙНУЛЛИНА "Солдат Лотфулла", Д. ГИСМУТДИНОВА "По кругу", сатирический рассказ Р. БАТУЛЛЫ "Ночная посиделка"; стихи А. ХАЛИМА, Н. САФИНОЙ, Л. ВАЛЕЕВОЙ.
"Наука": Д. ИСХАКОВ. "Этническая история татар, перепись населения и политика" (окон); Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (прод).
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Публицистика": размышления И. Валиуллы о религиозном воспитании;
"К 125-летию Г. Тукая": хронология жизни поэта.
"Искусство": Р. НИЗАМИ. "Вознесение к небу Старого Аракчино"; притчи А. ШАКИРОВА.
"Память": М. УСМАНОВ. "Меджлис аксакалов"; беседа Ф. Фатхи с выдающейся певицей Ф. Кудашевой; Ф. ХУЗИН. "И небо тому свидетель".
"Белый парус": Р. ВАЛЕЕВ. "Маленький Разиль".
"Наш календарь".
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: первый снег; писатель Алмаз ХАМЗИН.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*


"Prose and poetry: novel by Z. ZAYNULLIN "Soldier Lotfulla", D. GISMUTDINOV "To circle", satirical tale by R. BATULLA "Night-sitting"; poems by A. HALIM, N. SAFINA, L. VALEEVA.
"Science": D. ISKHAKOV. "Ethnic history of Tatars, census and politics" (ending); F. GARIPOVA. "History of our villages" (continuation).
Pages from "Tatar Encyclopedia".
"Journalism": Reflections by I. VALIULLA of religious education;
"To 125th anniversary of G. Tukay: chronology of poet's life.
"Art": R. NIZAMI. "Ascension to heaven of Old Arakchino"; parables by A. SHAKIROV.
"Memory": M.USMANOV. "Majlis of aksakals"; conversation of F. Fathi with outstanding singer F. Kudasheva; F. HUZIN. "And sky is witness".
"White Sail": R. VALEEV. "Little Razil".
"Our calendar."
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: first snow; writer Almaz KHAMZIN.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.11.2010, график буенча 1.11 .2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–1563. Тираж 4055.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.



Айдар
Хәлим

# ОНЫТЫЛГАН АГАЧ

## Солылар

*Игенче Рафаэль Сөләймановка*

**Солыларның кысык күзләрендә**
**Чыклар—мөлдерәмә: олылар...**
**«Без чык түгел—үлемтек яшь!»—диеп**
**Яңгыр сорап егълый солылар...**

**Көйде дөнья!.. Көмеш ташкын булып**
**Солым офыкларга акмасмы?**
**Буш сабаклар җиткән кыз-кыркындай,**
**Бөдрә алкаларын такмасмы?**

**Безгә диган яңгыр болыт булып**
**Гүя читкә китеп кышларга,**
**Барып коя кирәкмәгән сазга—**
**Назсыз Псков, Воронежларга!..**

**Без солысыз—атсыз скиф, сармат,**
**Кыпчак, болгар, татар микән без?**
**Ак солыдан кара солы эзләп**
**Банкротлыкка чыккан икән без!..**

**Янды басу!.. Аллаһ!..Бир тамчы дым!..**
**Нәрсә ашатырбыз атларга?!**
**Үзебез—телсез, солы кирәклеген**
**Ничек аңлатырбыз ятларга?**

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар («Милли шигырьләр», «Убить империю», «Татар вакыты», «Тилергән сирень» һ. б.) авторы. ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

Солы җаным!.. Сабый чагым!.. Назым!..
Синең өчен янып көймәсәм:
Башкаларга бераз охшар идем,
Бу кадәр дә сине сөймәсәм!..

Солы!.. Солы!.. Атның милли ашы!.
Димәк, милли ашы татарның.
Чәйнәлмичә, без исән калырбыз
Хәтта карынында атларның...

## Көзге урманда

*Каләмдәшем Рәшит Юнысов истәлегенә*

Шыбыр-шыбыр яңгыр. Лач-лоч киләм.
Өзелмәгән яфрак шәбәргән.
Чабылган үләннең төпләреннән
Кояш яшел курпы җибәргән.

«Алар мине нигә күрәлмиләр?!—
Дим.—Буарлар иде кушкуллап.
Ә-әй, чукынмаслармы!»
Әнә, ничек
Җирдән сулар сытыла лычкылдап.

Йөрәк «Көрәш!» диде. Мин көрәштем.
Берьялгызым калып кыйналдым.
Башкалар май-данда коенганда
Мин мәйданда канга буялдым.

Нәрсәгә ирештем? Булдырдыммы?
(Булдыралмау белән тотылдым!)
Булдырганнар «көрәшче» күкрәген
Орден лентасына тутырды...

Табигатьтән бары мәгънә табам!
Шул көч давыллана күземдә.
Ярый, ул бар, юкса, шушы курпы
Сыман черер идем үзем дә...

Күңел сизә: кояш ташлар юнып
Чакма чага океан артында.
Минем өчен ал факел кабыза
Аллаһының иман шартында...

## Онытылган агач

Түгел имән, каен, юкә яки алмагач,
Ачыклыкта, юлдан читкә атлагач,
Утыра бер мәһабәт онытылган агач.

Кәүсәсе кырлы, сырлы-сырлы,
Яфраклары нурлы, җырлы-җырлы,
Астында—җиләс, салкында—җылы-җылы.

Киң ябалдашлы, күләгәсе астында
Юлчылар ял итә, сабыйлар уйный,
Ул гына ял итми, уйнамый—уйлый да уйлый.

Пенсия-хаерхаһ алмас, ашыгып-кичегеп килмәс,
Башкалар кимсетсәләр, колагына да элмәс.
Аңардан көлсәләр, үзе һич тә көлмәс.

Беркем белми-күрми, беркемгә кирәкми,
Һәркемне ял иттерә, ашата-эчертә—бүләкли,
Шундый киң күңелле, шундый зур йөрәкле.

...Түгел имән, каен, юкә яки алмагач,
Ачыклыкта, юлдан читкә атлаган.
Утыра бер мәһабәт онытылган агач—
Искә алыр кешесе дә калмаган.

## Кәркәлем

Нигез корсаң да, каторжан,
Качып-посып, чокырга,
Тотынгансың, тезең чәнчеп,
«Иман шартын» укырга!..

Кичеп гасырлар иманлы,
Инде килеп, бүгендә
Догасыз калуыңа мин
Рәнҗеш йөртәм күңелдә!..

Юкка коелмый бу зарлар.
Юкка түгелми бу яшь.
Канлы таулар арасыннан
Бер балкып чыгар кояш.

И минем каккан казыгым,
И минем авылкаем!
И «Баллы Елга»м балыннан
Балланган каенкаем!..

## Ярсыма, йөрәк

Ярсыма, йөрәк, ярсыма,
Ярсыма елга кебек.
Китәсең бер көнгә, елга
Түгел—
Гомергә кебек.

Ярсыма, йөрәк, ярсыма,
Яшәдең алданмыйча.
Карачкыларны маяк дип,
Ялганга ялганмыйча.

Ярсыма, йөрәк, ярсыма
Дошманнар карашыннан

Танылалмый китүеңә
Милләтең тарафыннан.

Бетмәбез әле, үтмәбез,
Милләт бер шөһрәт татыр.
Бер килеп акбүз атында
Болгари дәүләт кайтыр.

## Вокзалда табылган шигырь

«Сара!..
Синең бу хыянәттән соң
Язалмадым язар хатымны.
Аракыда мин үземне түгел,
Юдым акчарлактай атымны...

Авыл түгел—давыл көтә сине.
Урамыңда—зилзил-ураган.
Бәгырькәең, кайнар камчы сымак,
Канлы яра белән уралган.

Син чыгарга миңа теләмәдең,
Инде үкенечләрдән ташып чык.
Диңгез котырганда дулкын какса,
Минем ат ялынаябышып чык...»

## Сүгенә белмәүче агач

Яфракларын миллион колак итеп
Борган да бу агач як-якка,
Моң тыңлаучы Җан Иясе булып
Катып калган басып аякка.

Кешем, агач та бит—Аллаһ заты.
Син агач алдында сүгенмә!
Агач миллион ел сүгенмәде,
Сүгенмичә яши бүген дә...

И Адәмзат!.. Аңа сүгенүләрең
Барып җитсә, ниләр кичәрсең?
Таңда сине ташлап, китеп барса,
Яшеллектән башка нишләрсең?

Ул гакылсыз, әмма сүгенә белми,
Син гакыллы, сүгенә беләсең.
Агач җырын тыңлый белмәсәң дә,
Тиле кебек көлә беләсең...

## Фрегат

Фил аксөягеннән уелган ат,
Тоякларын ташлап киң ифрат,

Диңгез гизә... Ат дигәнем икән
Җилкән кергән кораб-фрегат.

Ул күк күкрәгенә йолдыз сибә,
Аса-палас ачыла күкләрдән.
Бәхетсез—тик бәхтен таба бары
Күкне йолдыз белән чүпләүдән.

Юк, фрегат түгел, читкә этеп
Дөнья малын, вак көн кирәген,
Илен эзләп, океан аша чаба
Бу—минем җан, минем йөрәгем.

## Аллаһы Тәгаләгә

Татар азатлыгы өчен
Үләргә әзер идем.
Мөстәкыйльлек корбанына
Иң камил нәзер идем.

Актылар сак сулар озак!...
Аллаһым, инде килеп,
Бирдең гомер, бирми безгә
Дәүләти мөстәкыйльлек..,

## Көзге юлдан кичке манзаралар

Нократ суы куерып тонган.
Югалган парахутлар.
Саркылып кына тирбәлә
Кичке зәңгәрдә утлар.

Нигәдер җырлыйсым килә,
Еларга кирәк, бәлки.
Бабайлардан калган малны
Туздырып беттек тәки...


Яшәү шушы була микән,
Йөрәкне телә-телә?
Безнең тирән катламнардан
Гырылдау ишетелә.

Нигәдер җырлыйсым килә,
Каләмне уйга салып.
Йолдызга атасы килә
Йөрәкне—ертып алып.

Су өсте кинәт тетрәнде
Божрадан божра калкып:
Браконьерлар ятьмәсеннән
Ычкынды олы балык...

Мин әле исән, теремен,
Тәшәккүр, үтте каза.
Каза күрә күрмәгез, дип,
Шушы шигъремне язам.

*2009–2010 еллар*



Зәки
Зәйнуллин

# ЛОТФУЛЛА СОЛДАТ

БӘЯН

1907 елның июль азаклары иде... Көннәрнең берсендә Эстәрлебаш авылы никрутларын ак патшаның солдат хезмәтенә озаттылар...

Эстәрледән тугыз олау белән утыз ике никрут Себер тимер юлының Әкчүн стансасына чыкты. Жамали староста белән Гафур писер никрутлар белән хушлаштылар.

—Ярар, егетләр! Ак патшага әйбәт хезмәт итеп, туган якка исән-имин әйләнеп кайтырга язсын!

Арбалар буйлап үтеп егетләрнең кулларын кысып чыктылар.

—Күрешергә язсын исән-имин кайтып!

Әкчүн стансасында аларны поезд вагонына төяделәр.

Уфада атна буена кандала ашатып яткач, бер кичне, алты никруттан торган команданы Лысак фамилияле унтер-офицер Уфа тимер юл вокзалына алып төшеп вагоннарга утыртты да, Харьков каласына алып китте. Алты никрут арасында Лотфулла Зәйнуллин белән Карагыш авылыннан мишәр егете Кәшшаф Гималетдинов та бар иде. Калган дүртесе—урыслар.

Ике тәүлек дигәндә Харьковка барып төштеләр. Тимер юлда, хезмәт урыннарына үтеп барган никрутларны стансаларда ашату оештырылган икән. Беренче иртәне үк балчык кәсагә салып биргән кәбестәдән пешерелгән ашны Кәшшаф кулындагы агач кашык белән бутап карады да, янында утырып ашый башлаган Лотфулланың бөеренә терсәге белән төртте:

—Лотфулла! Бу кәбестә шулпасының ите дә бар бит. Әллә теге тырышып йөгерә торган хайванныкы инде?

Әйткәнен аңлап бетермичә, Лотфулла ашавыннан туктап Кәшшафка карады:

—Нинди тырышып йөгерә торган хайванны сөйлисең син?

—Без, мишәрләр, дуңгызны шулай тырышып йөгерә торган хайван дибез

---

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН (1933)—*язучы, галим, техник фәннәр докторы; «Полковникны озату», «Ник ямансу бу күзләр?», «Агыйделнең аръягында...» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

бит. Йөгерә башласа бик тә тырыша бит инде ул йөгерергә. Коръән безгә аны ашауны тыйган бит.

—Аша биргәнне! Урыс хезмәтендә бит син хәзер. Урыста солдатлыкта. Әсир төшкән мөселман кебек без хәзер. Нәрсә бирсәләр, шуның белән тукланырга тиеш. Әсирлектә чучка ите ашау гөнаһ саналмый. Синең белән минем кебек урыс солдаты булган мөселманга, ул әсирлек белән бертигез. Котылып кайткач ашарбыз елкы итен, казылыкны вә һәм дә сарык итен. Аша биргәннәрен.

—Син еппәрәсең генә. Әллә моңарчы да син ул нәстәнең итен ашаганың бар идеме?

—Күрше нимес Мердер алпавытта ел ярым ялчылыкта эшләгән идем мин. Шунда ашаттылар миңа дуңгызның итен дә, салосын да...

Кәшшафетдин тәүлектән артык ач барганнан соң гына, җирәнеп кенә булса да, урысның щи дигән ашының башта шулпасын гына эчте. Харьковка килеп җитеп, кызыл кирпечтән Холодная Гора дигән урында салынган өч катлы солдат казармасында атнага якын яшәгәч, урыс никрутларыннан калмастан, урысның чучка итеннән һәм кәбестәдән пешерелгән ашын, үзләреннән дә тизрәк ашап бетерергә өйрәнгән иде инде...

Харьковта тагын поезд вагонына төяделәр дә, даңгыр-доңгыр китереп, селкетә-селкетә алып та киттеләр.

—Кырымга! Керчь каласына!—диде унтер-офицер Лысак.—Хезмәтегез Керчь каласыннан унбиш чакрымда диңгез ярына салынган крепостьта булачак. Ул крепость Кара диңгез белән Азов диңгезе кушылган җирдә, Керчь бугазында урнашкан. Яр артиллериясе крепосты ул. Ике йөз еллар чамасы элегрәк төрекләр салган крепость ул.

Кәшшафетдин Лотфуллага пышылдады:

—Нәстә була ул татарча моның крипыс дигәне?

—Кальганы урыслар крипыс диләр. Ике диңгез кушылган җирдә яр артиллериясен куярга ясалган булырга тиеш. Диңгездән барган карабларга ата торган урын булырга ошаган...

Солдат хезмәтенә, Кырымның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан Керчь кальгасына барып эләккән татар егете Лотфулла Зәйнуллинның кайсы җирләрдә хәрби булганын яхшырак аңлау өчен Кырым ярымутравы һәм Кырым ханлыгы, аның тарихы турында беразмәгълүмат биреп үтик.

Татар кешесе буларак та һәм үзешчән тарихчы буларак та бер тарихи мәсьәләне аңлап бетерә алмыйча һәм аны чишә дә алмыйча бик озак еллар чишәргә тырышып яшәдем мин. Һәм... 1990 елның декабрь аенда, шул мәсьәләне чишәргә миңа ике Кырым татары ярдәм итте. Ай-Петри тавы астында, Ялта—Севастополь автоюлы кырында, кышкы әче салкында, тәмәке басуына «самозахват» ясап кереп авыл сала башлаган татарлар иде алар! Ул авыл хәзер Кырымдагы иң матур авылларның берсе. Ай-Петри тавы астында ул авыл. Ай-Петрине урыслар Ай-Бөдрәне үзгәртеп атаганнар. Башы бөдрә аның. Ә инде турыдан диңгез ярына төшсәң, анда Караиз исемле бик матур курорт урнашкан.

Ринат Аблаев һәм Әмир Мәҗитов исемле иде ул татар егетләре.

Ә мин чишә алмаган мәсьәлә менә мондый. Урыста бөек патша булган Петр I Воронеж каласында диңгез кораблары төзү өчен бик зур верфьлар оештырган. Максаты—Кара диңгезгә чыгу һәм шундагы җирләрне урыс дәүләтенеке итү. Чынлап та, Воронежда кораблар төзиләр һәм көньякка зур поход оештырып, Азов һәм Кара диңгезләрен, шундагы җирләрне яулап, Русия итү башлана. Тарихта бар мәгълүмат буенча Петр I Азов крепостен алуга ирешә. Һәм...

Штурм белән алган Азов кальгасын шартлатып җимереп, туздырып...

Кара һәм Азов диңгезләрен яулап алуны ташлап Русиясенә гаскәре белән кире кайтып китә Петр. Кара һәм Азов диңгезләрен һәм шундагы җирләрне басып алу сугышларын туктата. Ни өчен туктата?

Русиядән күпкә көчле булган Швециягә каршы сугыш башлап, егерме елдан артык сугышып, аны җиңеп карел-финнар җиренә Санкт-Петербург кальгасын салган, Балтыйк диңгезенә чыгуга ирешкән. Зур җиңү! Ә ни өчен Азов кальгасын алгач... ташлап Русиягә кайтып китә! Ә ул бит Петр I! Гади урыс патшасы гына түгел. Ул һәрвакыт үзенең максатына ирешү өчен бер нәрсә алдында да туктап тормастан, күп югалтулар аша да барган да барган. Тик алга гына һәм чит җирләрне яулап алырга! Сугыша-сугыша Русиянең барлык халыкларын хәерчелеккә, бөлгенлеккә төшереп, бик күпләрен сугышларга тыгып юк иткән. Һәм күп җирләрне яулап алгач, иң күп фаҗигане Петр I татарларга китергән.

Кырымлы дуслар белән сөйләшкәндә шундый сорау бирдем мин аларга.

—Ни өчен Петр I Азов кальгасын алгач, Төркия белән сугышуын туктатып, яулап алган җирләрне ташлап, Азов кальгасын җир белән тигезләп, җимереп кайтып киткән. Һәм Кара диңгезгә, Азов диңгезенә башкача чыгарга омтылмаган. Ни өчен?

Алар сөйләгән сүз минем өчен көтмәгәндә янымда гына зур авиабомба шартлагандай булды. Бу турыда менә язып утырам. Һәм мин язганны укыган татарларның күпчелеге мине очраткач бер үк сорауны бирәчәк:

—Син язуын язгансың ла ул, ә синең шушы язганыңа документың бармы? Документың булмаса, синең болай язарга хакың юк.

Куликово сугышы турында Русиянең бер генә документы да юк. Хәтта Куликово Поле дигән урыны да юк, анда казып тапкан бер генә кылычы да, ук башы да юк, тимер кисәге дә юк. «Побили татарина Мамая» дип урыслар алты йөз елдан артык шапырыналар. Мин хөрмәт иткән язучы Марсель Галиев бар. Миңа искитмәле бер фикер әйтте ул. Шуны түкмичәчми язам һәм мин язганнан соң ул Марсель Галиев әйтеменә әвереләчәк. Менә ул җөмлә:

—Зәки абый! Берәр кеше турында мактап язсаң, безнең татар синнән сораячак: «Шулай дип мактап язгансың. Шулай дип язарга синең документың бармы? Ә инде менә син берәрсе турында яманлап, ямьсез иттереп язсаң, синнән берәү дә документ сорамаячак. Безнең татар, әгәр син урыска ошамаслык итеп язсаң, сине бетереп туктый. Куркак без!» Һәм Марсельныкы дөрес.

Менә мин Петр I турында язам һәм күпчелек татар бу язганны кабул итмәячәк. Безнең татарның күпчелеге куркуыннан, үзенә-үзе файда да чыгара алмый дөнья йөзендә!

Мин, ни өчен Петр I башкача Кара диңгезгә чыгарга тырышмаган дигән сорауга, һич тә көтмәгәнне сөйләделәр. Елмайдылар: «Бар ул турыда документ! Петр I нең Кара диңгез ярларыннан гаскәре белән сугышны туктатып кайтып китүенең сәбәбе бар һәм ул бик зурдан. Без ул турыда беләбез.»

Азов кальгасын алганнан соң Петр I сугышны киңәйтеп, тагын да ныграк итеп һөҗүмнәрен оештыра. Вә ләкин, һич көтмәгәндә сугышны туктатып, башкача көньякка килеп тә карамый.

Эш шунда: Кырым татарлары төнге операция оештырып, разведка мәгълүматларын файдаланып, Петр I патшаны төнлә чатырыннан урлыйлар. Атларга атланып килеп, төнлә белән һөҗүм итеп! Һәм Петр I не әсир итеп Кырымга алып кайтып китәләр. Бакчасарайга барган чакта Алмалык исемле бик матур һәм зур авыл бар. Шунда яшереп тоталар урыс патшасын

жир астындагы таш савытта. Ике айдан артык. Урыслар Кырым ханына киләләр, «күпме телисез шул кадәр алтын-көмеш бирәбез, патшабызны азат итегез!»—диләр. Кырым ханының җавабы кыска:

—Юк. Алтыныгыз да, байлыгыгыз да кирәкми. Үз кулы белән язып, үзенең мөһерен сугып, Төркиягә дә, Кырымга да беркайчан каршы сугышмаячакмын, Кара һәм Азов диңгезләренә башкача басып алырга килмим дип безгә документ бирсен. Шул документны эшләсә, без аны бернинди алтынсыз да бирәбез сезгә. Алып кайтып китегез. Сезнең ул патшагызның шуннан соң безгә кирәге юк. Үзегезгә булсын! Әгәр дә инде шундый документны Петр I эшләмәсә, язмаса, кул куймаса, мөһерен басмаса, без аның башын чабып, сез урысларга тапшырырбыз. Гәүдәсен дә, башын да аерым аерым итеп!

Урыслар әйтеп карыйлар:

—Алай иткәнче сез аны Төркия солтанына тапшырыгыз!

Әмма ханның җавабы кыска була:

—Шушы көнгә кадәр без, татарлар, бер генә әсирне дә Төркиягә бирмәдек! Сатуын сатабыз әсирләрне базарларда, анысы була торган эш. Сез дә шөгыльләнәсез андый сәүдә белән. Ә Петр I не без беркемгә дә бирмәячәкбез дә, сатмаячакбыз да. Башкача монда килеп йөрмәгез. Безнең шартны Петр үтәсә, үзебез илтеп бирербез аны сезгә!..

Һәм Петр I, Кырым ханының шартына буйсынып, үз кулы белән язып, мөһерен сугып, Кырым татарларына шундый кәгазьне тоттырган, тапшырган.

Сорыйм егетләрдән:

—Белмисезме, ул документның язмышы ничек икән бүген? Бар микән ул бүген дә?

Миндә дә татар каны бит: «документыгыз бармы???»—дим!

Икәүләшеп баш селкиләр, елмаеп җавап бирәләр:

—Бар андый документ бүген дә. Стамбулда үзәк архивта саклана. Аны күргән, укыган галимнәр бар Кырым татарларыннан. Тик Советлар Союзыннан, урыстан төрекләр бүген дә бик нык куркалар. Документның үзен дә, копиясен да бирмиләр безгә. Бөек Петр I нең бу бит дөнья мәсхәрәсе!!! Мәсхәрә бит бөтен Жир шарына!—Кырым татарлары Петр Великийны әсир итеп урлап алып киткәннәр төнлә белән чатырыннан. Төнлә белән. Һәм алтын да алмыйча, бушка чыгарып җибәргәннәр: артына типкән кебек итеп. «Бар кайтып кит Русиянә! Башкача монда киләсе булма!»

Русия соңрак, Әби патша заманында, Кырымны яулап алмады, алдалап Русиягә кушты.

Риза Фәхретдиновның «Асар» әсәреннән алынган фикерне дә китерик әле монда. «Бик күп цивилизацияләнгән илләрнең тарихлары мифлар, риваятьләр, легендалар, телдән телгә күчеп килгән имеш-мимешләр, кабер ташларындагы мәгълүматлар, кәгазь кисәкләрендә теркәлгәннәр буенча языла. Күп вакытта вак-төяк тә бай тарихи мәгълүматлар бирә. Хакимият тик үз файдасына язган архив документлары белән чын тарих язылмый беркайчан да...»

1768—1774 елларда Төркия белән Русия арасында барган сугыш туктатыла. Ул сугыш Русиянең җиңүе белән тәмамлана. Петр I башкара алмаган Кара һәм Азов диңгезләрен яулап алуны Әби патша—Екатерина II башкарып куя. Болгариядә, Силистр исемле каладан ерак түгел Көчек-Кайнажар исемле авылда Русия белән Төркия арасында солых төзелә. Бу 1774 елның 10 июль көне була. Керчь, Яңа Кала, Кинбург крепостьларын Русиягә бирә Төркия һәм Кавказдагы Кабарда җирләре тоташы белән Русия карамагына күчә.

Кара һәм Азов диңгезләре бугазлары Русия өчен ачык дип игълан ителә. Тик әле диңгезләр үзләре Русия карамагына бирелмиләр...

«1783 елда Кырым Русиягә кушыла!!!»

Барлык тарихи мәгълүматларда Кырымның Русиягә кушылуы турында тик шушы җөмлә генә бар һәм... Кырымда барган сугышларның берсендә яшь офицер Михаил Кутузовның яраланып сыңар күз белән генә калганы турында фактлар гына язылган. Башкача Кырымны яулап алу турында бер тарихи факт та юк. Ни өчен?

Кырымның Русия тарафыннан йотылуында иң гаепле кеше—соңгы Кырым ханы. Ул миллион алтынга кызыгып комсызлык күрсәтүе аркасында Кырым ханлыгын югалта. Урыслар ханга берничә миллион алтын акча тәкъдим итеп, Төркия белән сугыш барган чакта Кырымга, вакытлыча дип урыс гаскәрен кертүгә ирешәләр. Солых буенча Төркия белән сугыш тәмамлануга урыс гаскәре Кырымнан чыгып китәргә тиеш була. Хан булып ханнар да ахмаклык эшләүгә сәләтле була икән! Исең китәр! Хан бит ул!

1774 елда Төркия белән сугыш тәмамлана. Ә урыс гаскәре сугыш беткәч Кырымнан чыкмый һәм чыгарга уйламый да! Урыслар—Кырымда, ә Кырым белән Гәрәйләрдән булган хан һаман идарә итәргә тырыша. Кырым татарлары төзелгән солых буенча урысларның Кырымнан чыгып китүләрен таләп итә башлыйлар. Менә шул баш күтәргән Кырым татарлары белән бәрелештә татар Котдус нәселеннән булган Михаил Кутузов күзен югалта. Әби патша боерыгы белән, Кырымдагы барлык гаскәрләр белән командалык итәргә, тотылган Пугачевны Самара каласыннан Мәскәүгә сак астында тимер читлек эченә утыртып, бикләп алып кайткан Александр Суворов җибәрелә. Соңрак «бөек полководец» итәләр Суворовны урыс патшалары. Суворов та—татар морзалары нәселеннән чыккан шәхес. Искиткеч тырышлык һәм ерткычлык белән урысның яулап алу сәясәтен уздырган ул.

Урысларның төзелгән солыхны үтәп Кырымнан чыгып китүләрен таләп итү—сугышчан, көрәшчән Кырым татарларының урысларга каршы коралы кузгалышы башлана. Суворов командалыгында урыс гаскәрләре татар авылларына басып кереп, дүрт йөздән артык авыл муллаларын Кырымның Алупка дигән шәһәренә җыялар. Һәм 1782 елның җәендә шул муллаларны, Суворов боерыгы буенча, муеннарына таш бәйләп, Кара диңгезгә батырып үтерәләр. Чөнки урыска каршы торуны муллалар оештырган була. Кырым халкы куркып, баш күтәрмичә, тынып кала. Кырымның соңгы ханы үзенең башкаласы Бахчасарайны ташлап, чит илгә—Франциягә—эмиграциягә чыгып китә. Һәм атаклы Кырым ханнары Гәрәйләр нәселе Парижда юкка чыгып бетә, югала, ханлыгыннан мәхрүм кала. Ул нәселнең юк-бар очлары Парижда әле дә булса бар бугай.

Кырымны «тынычландырган» Суворов Санкт-Петербургтан яңа боерык ала: «Кырымнан гаскәрең белән чыгып, Кара һәм Каспий диңгезләренең Кавказ тауларының төньягында урнашкан далалар буенча үтеп, аннан соң Әстерханнан алып Самара каласына кадәр Идел-Суның (урысларның булачак «Великая Волга»сы) ике яры буйлап гаскәр белән үтеп, нугайларның шундагы барлык авылларын, анда яшәүчеләрне тоташ юк итәргә!» Русиягә, Кырым ханының һәм Казан ханлыгының союздашы, аркадашы булган нугайларны халык буларак Суворов гаскәре юк итеп, 1782 елда зур поход белән үтә.

1783 елда Кырым Русиягә кушылды дип патшабикә указы игълан ителә. Петр «Великий»ны кумир итеп яшәгән Иосиф Сталин 1944 елның май аенда Кырымнан сөргенгә озатып, «Кырымны басурман татарлардан азат итә». Татарлар бүген дә үз илләре Кырымга кайта алмыйча җәфа чигә. Ата-

бабадан калган туган туфракка «самозахват» ясап кайтырга тырышалар. Урыс белән хохол үзләре дә эшли белмиләр Кырым жирендә, эшчән, тырыш татарны да кайтармыйлар Кырымга—«собака на сене» алар бүген дә Кырым жирендә!

Керчь кальгасын 1722—1730 елларда Төркия карары белән салганнар. Диварларны салу өчен ташны җир астыннан Әче Мөшнә дигән урыннан чыгарганнар. Дивар салу өчен кулланылган ул таш ятмасы җир астында 40—60 метр тирәнлектә 15—20 метр калынлыкта ята икән. Тик ул җир астында чагында таш булып катмаган, ә балчык хәлендәрәк һәм үзе йомшак икән. Таш чыгаручылар шул йомшак таш-балчыкны кисү өчен ясалган эре тешле, ике тоткалы махсус корыч пычкылар кулланып, эре-эре шакмаклы итеп җир астында кисеп бүлгәләгәннәр. Ике тәгәрмәчле арбага җигелгән атлар ярдәмендә җир өстенә чыгарганнар. Шунда ташларны берсе өстенә берсен тезеп, биек итеп әрдәнәләп өйгәннәр. Җир өстенә чыгарылып, өелеп куелган шул дүрткелле йомшаклар һавада ташка әйләнгәннәр. 10—15 көн узуга ул йомшак ташлар чын таш булып катканнар. Яңа чыккан шул йомшак ташларны суда җебетеп балчык ясаганнар. Һәм шул каткан ташлар арасына әлеге балчыкны җәеп кальга крепостен өйгәннәр. Дивар биеклеге14—16 метрга җиткән, ә диварның калынлыгы 5—6 метр иттереп ясалган. Төрекләргә Керчь һәм Яңа кала кальгаларын салуда французларның кальга төзүче белгече Вобан дигән француз җитәкчелек иткән. Кальга төзелеп беткәч, диварлары калкып чыккач, калып эченә ике катлы итеп яр артиллериясе пушкалары утыртылган. Русиядә яр артиллериясе орудиеләре XIX гасырда гына барлыкка килә. Урыслар Балтыйк, Кара һәм Азов диңгезләре ярларына чыгып, Керчь, Яңа кала кальгаларын Төркиядән тартып алганнан соң гына. Шул кальгалардан үрнәк алып Русия үзенең дә яр кальгаларын сала башлый. Тик ничек кенә тырышсалар да, яр артиллериясе өчен урыслар салган кальгалар төрекләр салган кальгалар дәрәҗәсенә җитә алмый.

Салынган кальгаларны яр артиллериясе пушкалары белән коралландыралар. 1907 елда яр кальгаларына куелган пушкаларны күрсәтеп китик һәм шуңа түбәндәге таблицаны бирик.

| Калибр [д'юйм] | Үрнәк | Снаряд массасы [кг] | Ату ераклыгы [км] | Ату/мин |
|---|---|---|---|---|
| 12 | 1892 | 331,3 | 22,8 | 1/3 |
| 11 | 1877 | 249,5 | 12,4 | 1/3 |
| 10 | 1892 | 224,9 | 20,5 | 1/2 |
| 9 | 1877 | 126,0 | 10,67 | 1/3 |
| 6 | 1891 | 47,0 | 13,2 | 3/1 |
| 4,7 | 1891 | 20,4 | 13,9 | 3/1 |

...Эреле-ваклы тимер юл стансаларында азлап йәисә озаклап туктап тора-тора, поезд көньякка карап барды да барды. Тәүлек ярым узгач, Кырымга килеп кереп, поезд Керчь дигән каланың тимер юл вокзалында туктады. Вагоннан төшкән алты никрутка унтер-офицер капчык һәм төен-тартмаларын күтәртте дә, җәяүләп шәһәр аша кояш баешы ягына алып чыгып китте. Мишәр егете Кәшшафетдин хатын-кызга тыныч кына карап бара торганнардан түгел иде, ахрысы:

—Карале, Лотфулла! Мондагы, бу яклардагы хатын-кызлар диюем, Харкыф каласыннан ук чамалап киләм, безнең мишәр хатын-кызларына

караганда симезрәк дә, юанраклар да бит әй. Төс ягыннан безнекеләргә тартым үзләре. Чәчләре дә кара, күзләре дә кара да коңгырт, йөзләре дә ак та, ал да... Ай-һай, безнең татар егетләре булгандыр бу җирләрдә диюем. Безнең татар катышлы бит болар бар да...

Ике сәгатьтән артыграк кабаланмый гына тәпиләгәч, Керчь каласын чыгып, таш юл белән киттеләр. Тагын өч сәгатьтән артыграк юл үткәч, алда кара төстәге биек таш дивар белән уратып алынган Керчь кальгасы күренде. Моңарчы зур калаларны да, хәрби кальгаларны да күрмәгән ике татар егете, биек таш диварга карап, өнсез калып атлады. Кальга дивары биек тә, мәһабәт тә булып, үзенә хәрби хезмәткә килгәннәрне бик горур кыяфәттә каршы ала иде. «Берничә елыгыз минем кальга эчендә үтәчәк!» дигәндәй, Керчь каласы ягына караган ике тимер капкасы бар икән.

Киң, биек тимер капкаларның икесенең дә уң ягында бер кеше сыярлык кына итеп тимер ишек ясалган. Ишек яңагындагы чылбырга эленгән тимер таяк белән унтер-офицер Лысак берничә тапкыр ишеккә сукты. Тимер кеЛәле итеп ясалган кечкенә тишекнең капкачы эчке якка ачылды. Анда бөтерелеп өскә карап торган җирән мыеклы кызыл бит күренде:

—Крепость дежурныена хәбәр ит! Унтер-офицер Лысак, яңа солдатлар белән кайтып җитте. Алты кеше,—диде Лысак.

Ишектәге капкач ябылды. Бераз торгач ишек ачыла башлады.

—Керегез!—диде кылыч таккан штыксыз карабин тоткан жандарм ишек ача-ача.—Дежуркага узарга боерык бирделәр сезгә.

Ике катлы итеп кызыл кирпечтән салган йорт янына килеп җиттеләр. Штаб бинасы икән. Икешәрләп шеренгага тезеп, никрутларны йөзләре белән штабка каратып бастырды да, унтер-офицер Лысак бина эченә кереп китте. Кулындагы кара төстәге чүпрәк сумкада никрутларга Уфада ук тутырылган хөкүмәт кәгазьләре иде. Күп тә узмады, сул беләгенә кызыл таккан дежур офицер белән Лысак кире чыкты. Дежурный тавыш-тынсыз басып торган алты никрутны, ике кулын артына куйган килеш урап, карап чыкты. Барысы да озын гәүдәле, нык бәдәнле, авылларда күп эшләп, чыныгып үскән көчле егетләр иде.

—Яхшы, Николай Николаевич! Казармага алып кит. Капитан Бульонны беләсеңме?

—Беләм. Озын буйлы, сакал-мыеклы.

—Шул. Тап шул Бульонны, белгәч... Болар алтысы да аның батареясына. Бүген үк мунча кертсен, солдат киеменә киендерсен. Аңлашылдымы?

—Так точно, Ваше благородие!

—Аңлашылса, үтә!

Капитан Бульон белән мунчага кадәр дә, солдатча киенгәндә дә очраша алмадылар. Барлык мәшәкатьләрне дә Бульонның батареясындагы Каргалов фамилияле поручик эшләде. Батарея фельдфебеле ярдәмендә алты яңа солдат мунчага да бардылар, юындылар да, солдат формасын да киделәр. Мунчада барлык җирләрендәге чәч-йоннарын кырып алдылар. Батарея каптинармусы ярдәмендә таманлап итекләрне, солдат киемнәрен киделәр. Кызык та, күнелле дә булып чыкты солдатча киенү. Чабаталарын, ямаулы чалбар, казакиен салып ташлап солдатча киенгәч, Лотфулла чибәрләнеп китте. Зәңгәр күзләре тагын да матурланып, зәңгәрләнеп, йөзе алсуланып, азрак түгәрәкләнеп киткәндәй булды. Анардан көчек кебек калмыйча йөргән Кәшшафетдин солдатча киенгәч, бераз каушый төште ахрысы—дәшмәс булды.

—Син нәрсә, Кәшшафетдин, дәшмисең? Әллә шүрли төштең инде?

Мишәр кабаланмый гына янында басып торган урыс солдатларына карап алды. Мунчадан чыккач, кальга эчендә мунча алдында басып торалар иде.

Кәшшафетдин кальганың дивары аша ераккка карап каткан иде.

—Карале, Лотфулла, дингез дигәне шушы була микәнни? И-и-әй! Харап бит, әй! Икенче яры юк бит монын!

Лотфулла Кәшшаф кулын сузып күрсәткән якка карады. Андаа-а-а!!!

Кальганың биек дивары артында күз күреме җиргә кадәр иксез-чиксез булып зәңгәр төстәге су даласы җәйрәп ята. Тау-ташлы көньяк Уралдан килгән ике татар егете мондый тигез булып таралган киң су матурлыгын күргәннәре юк иде әле. Су өстеннән кальгага таба искән җил, ак башлы кечкенә дулкыннар куа һәм шул куылган дулкыннар, салмак кына итеп ниндидер, мона кадәр ишетелмәгән дәһшәтле дингез тавышы чыгарып, табигатьтә бик тә куәтле, көчле сулык барын аңлаталар. Күктә ак болытлар йөзә, ә дингез аша ерак-еракта күгелҗемләнеп ниндидер ак башлы таулар күренә кебек. Фельдфебель солдатларның дингезгә караганнарын чамалап, әйтеп куйды:

—Кавказ таулары анда! Дингезнең теге ягында диюем.

Кальга таш диварының дүрт почмагында дүрт капкасы бар икән. Керчь каласы ягына—ике киң зур капка. Дингез ягындагы почмакларда ярның ике ягына караган тагын ике биек капка бар. Калага караган капкаларга терәп салынган будкаларда кергән-чыкканны тикшереп тора торган, зәңгәр төсле хәрби кием кигән, мыеклы жандармнар утыра. Болар инде крепость капкаларын һәм кергән-чыкканны саклаучылар, тикшерүчеләр. Андый җаваплы эшне гади солдатка тапшырып булмый бит инде.

Керчь кальгасы дивары дингез суына терәп салынган. Кала ягында да таштан салынган, дингез һәм һава тәэсиреннән каралган биек, калын дивар. Соңрак, хезмәт итә торгач беленде, диварның биеклеге 15—18 метр, ә калынлыгы 5—6 метр икән. Дүрткелләнеп салынган диварның һәр ягының озынлыгы 300 метр чамасы.

Кала ягына караган дивар почмакларында ике биек тимер капка, ә дингезгә таба төшкән ике дивар почмагында тагын ике капка. Капкалар дүртесе дә сары төстәге кирпечтән бизәкләп салынган. Дингезгә караган капкалар башына наводчиклар урнаша торган тәрәзәле ике будка ясалган. Пушкалардан атулар белән җитәкчелекне шул будкаларда урнашкан команда башлыклары—артиллерия офицерлары башкара икән. Кальга эчендәге һәрберсе алтышар пушкадан торган ике батарея белән, дингез ягындагы капкалар башына урнашкан шул ике КПдан командалык итәләр.

Ярны саклаучы Керчь крепосте зур һәм дәһшәтле иде. Урынны да уңышлы сайлаганнар. Азов дингезе белән Кара дингез кушылган урында, Ак Борын дип аталган Керчь каласы ягыннан дингезгә чыгып торган ярымутрауда урнашкан ул кальга. Кавказ ягына кадәр 5—6 чакрым киңлектә Керчь бугазы җәелеп ята.

Керчь крепостен Төркия солтаны салдырган. Керчь крепостендагы платформага утыртылып, дингез бугазына караган озын көпшәле пушкалар да, аларны кул көче белән хәрәкәтләндерә торган «рычаг»лы, «шестерня»лы механизмнар да Лотфулла өчен тәүге көннәрдә аңлый алмаслык, «урыс абзый» төзегән катлаулы һәм серле «техника һәм механизмнар» иде. Рычагка тотынып 12 калибрлы пушка утырган платформаны әйләндерү әллә ни авыр түгел икән. Бар механизмнар да җайланган, көйләнгән, майланган. Азрак көчәнсәләр, платформаны дүрт кеше урынына икәү дә әйләндерә ала. Хезмәт итә торгач, солдатлар, офицерлар белән аралашып Лотфулла бер нәрсәне аңлады: пушка утырган платформа аны ике кеше әйләндерергә итеп ясалган икән. Тик дүрт кеше куярга булганнар. Бәрелеш вакытында ике кеше һәлак булса да, әйләндерердәй икесе калса, шул җитә икән. Тик ул «рычажниклар» барысы да таза һәм көчле булырга тиешләр. Урысча

укый-яза белүнең «рычажник»ка кирәге юк. Тик көче булсын: «Сила есть, ума не надо!» дигән урыс әйтеме бәлки шушы яр артиллериясе белән бергә тугандыр. Аны кем белсен инде, бер Ходайдан башка.

Яңа солдатларны ике көннән хезмәт урыннарына бүлделәр. Лотфулла белән Кәшшафетдинне һәм тагын алты яңа солдатны крепость уртасында урнашкан унике пушкалы бастион эченә алып кerделәр дә, баса торган урыны киң һәм тишекле итеп ясалган бормалы, тимер баскычтан җир астына алып төшеп киттеләр. Аларны алып төшүче унтер-офицер «господин фейерверкер» дип атала икән, шуның билгесе итеп погоннарына буйга, бер бармактан азрак киңлектә кызыл тасма такканнар. Фамилиясе Савченко, үзе хохол икән...

Алар платформа астындагы киң, тәбәнәк түшәмле бер түгәрәк зур бүлмәгә төштеләр. Тәрәзәләре юк. Вә ләкин бүлмә үзе якты. Диварлар сары кирпечтән, идән таштан. Диварларда аралары 7—8 метр булыр электр лампалары яна. Уртада тимер калай белән тоташ диярлек ябылган, пушкалы платформаны әйләндерергә ясалган махсус тимер шестернялардан, тәгәрмәчләрдән, трослардан торган механизм урнаштырылган.

Фейерверкер Савченко механизм каршына сигез яңа солдатны бер шеренгага тезде дә, кыска гына нотык әйтте.

—Сезнең каршыгызда пушкалы платформаны әйләндерер өчен ясалган механизм тора. Ул—«поворотный механизм пушки» дип атала. Һәм ул пушка рычаглар ярдәмендә, дүрт солдат көче белән әйләндерелә. Сез инде менә шул пушканы платформасы белән бергә әйләндерүче солдат хезмәтен үтәячәксез. Инде белегез, сез, солдатлар, шушы «поворотный механизм» базында дүрт ел пушкалы платформаны әйләндереп, Бөек Русиянең ак патшасына тугрылыклы хезмәт итәргә тиеш буласыз һәм итәчәксез.

Алмашлап итек башына һәм үкчәсенә баскалап алды да дәвам итте:

—Механизмны кирәк чакта ике якка да әйләндереп була. Дошман корабле кайсы якка йөзсә, шул якка әйләндерелә.

Мактанып та китте:

—Безнең Керчь крепосте Русиянең яр крепостьлары арасында үзенең тиз һәм төз атуы белән иң алдынгыларның берсе булып тора. Эһ-һем, эһ-һем! Кайбер маневрлар вакытында гына, бик сирәк булса да, безнен крепостьны Балтыйк дингезендә урнашкан Кронштадт һәм Красная Горка крепостьлары гына уза ала...

Йөзенә аз гына сизелерлек мәсхәрәле елмаю чыкты:

—Анысы да... исегездә тотыгыз, анысы да, өстә утырган артиллериянең иң зур начанствосы шулай булырга тиеш диеп карар кылган чакта. Купчелегенең малайлары... эһ-һем, эһ-һем... генерал малайлары баш калага якын шул крепостьларда хезмәт итәләр.

Шеренгада басып торган солдатлар аша карап кычкырды:

—Денис-со-ов!

Арттагы дивар ишеге ачылды. Аннан таза гәүдәле солдат күренде:

—Слушаюс-сь господин фейерверкер!

—Дүрт «рычажникны» чыгар монда.

Ишектән дүрт солдат каты атлап килеп чыктылар.

—Командуй, Денисов, на поворот платформы!

Денисов команда бирде:

—Взять рычаги! Установить их!

Дүрт солдат, «поворотный механизм»ның дүрт ягында дивар янында идәндә яткан тимер төрбәдән ясалган махсус башлы дүрт рычагны кулларына алып, «поворотный механизм»да ясалган тишеккә тыктылар. Һәр рычаг өч метрлы иде. Дүртесе дә бер-бер артлы телгә килделәр.

—Рычаг № 1 к работе готов!

—№ 2 к работе готов!

—№ 3 к работе готов!

—Рычаг № 4 к работе готов!

Фейерверкер команда бирде:

—Мин «Бер, ике, өч! Башладык» дигәч этәргә тотынабыз. Бер! Ике! Өч! Башладык!

Ныклап өйрәтелгәннәр иде солдатлар. «Башладык!» дигәч, «Поворотный механизм»ны әйләндерергә тотындылар. Фейерверкерның командасыннан бердәм кузгалдылар. Кабаланмый гына «рычажниклар» дүртесе бер кеше кебек хәрәкәт итәләр—атлаулары да бер ритмда. Ике мәртәбә әйләнгәч, фейерверкер яңа команда бирде:

—Тормози-и! Останови-и!

Дүрт солдат гәүдәләрен артка таба биреп, рычагка ике куллап ябышкан хәлдә, әйләнгән пушкалы платформаны туктата башладылар. Бер минут тирәсе үтүгә, платформа туктады. Тагын фейерверкер командасы ишетелде:

—Выходи-и на другую сторону!

Берничә секунд үтүгә «рычажниклар»дан җавап килде:

—«Рычаг № 1»—на другой стороне!

—«Рычаг № 2»—на другой стороне!

—«Рычаг № 3»—на другой стороне!

—«Рычаг № 4»—на другой стороне!

—Бер! Ике! Өч! Башладык!

Дүрт солдат көче белән пушкалы платформа икенче якка әйләнә башлады. Ике мәртәбә «механизм поворота» янында йөреп әйләнгәч, фейерверкер «рычажниклар»ны туктатты.

—Тормози-и! Останови!

Механизм туктагач, фейерверкер аны әйләнми торган итеп бикләп куйды да команда бирде:

—Рычагларны алып дивар буендагы ояларына куярга! Барыгыз да өскә күтәрелегез!

Бу команда механизм әйләндергәннәр өчен генә иде. Шеренгада тавыштынсыз гына басып «рычажник»ларның эшләгәннәрен карап торган яңа солдатларга таба борылды:

—Күрдегезме инде үзегезне нәрсә көткәнен?

Солдатларның берсе дә дәшмәде:

—Мин инде бу крепостьта унҗиде ел хезмәт итәм, унсигезенче елга китте. Сезнең өчен авыр эш түгел. Әлегә сугыш юк. Дошман корабльләре крепость алдында күренмиләр. Өйрәнүләр, атулар, платформа әйләндерүләр тәүлегенә иң күбе ике, өч сәгать бара. Иң авыры, киеренкелеге Санкт-Петербургтан безне тикшерергә берәр комиссия килеп эшләсә йәисә инде берәр генерал, адмирал килсә. Анда инде үзебезнең кем икәнлекне күрсәтү өчен икешәр-өчәр тәүлек йокламыйча буксирларга трос белән тагылган баржа-мишеньнарга атарга кирәк, үзебезнең осталыкны, ата белүне күрсәтергә туры килә. Андый чакларда сездән нәрсә таләп ителә соң?

Беренчедән: кирәк якка, ату белән җитәкчелек иткән офицер биргән командага буйсынып, ул кушкан тизлек белән механизмны әйләндерү.

Икенчедән: ату белән җитәкчелек иткән офицер биргән командага буйсынып, платформаны кыска вакытта туктатырга һәм кирәк тизлектә кире якка бора башларга. Аяклар белән каршы торып платформаны туктатырга! Үзегез атлаган түгәрәккә, идәнгә карагыз!

Бар да идәнгә карадылар.

—Күрәсезме, идәнгә цементлап кыргый яссы ташлар катырылган. Башка урыннардагы кебек, идән сезнең атлап этә торган урында шома түгел. Платформаны әйләндергәндә йәисә туктатырга тырышканда аяк шумасын өчен ул.

Идәндә, чыннан да, «рычажник»лар платформа әйләндереп атлап йөргән түгәрәк бер метр киңлек тау ташы белән каплап катырып җәелгән иде.

Икенче көнне яңа солдатларны ант итүгә әзерләү башланды. Чи мишәр авылыннан чыккан Кәшшафетдин берничә генә сүз урысча белә иде:

—Вада, хлиб, валинки, ширст, рубел, вудка...

Лотфулла аңардан көлде:

—Күп белмәсәң дә урыс сүзләрен, «вудкасын» откансың икән әле.

—Әй-лә! Әти белән Федоровка базарына барган идек пима сатарга. Биш ел чамасы узды инде аңа. Шунда бер урыс карап торган безнең пима сатканны. Сатыр бетерергә бер генә пар хатыннар пимасы калгач, әти атны җигеп килергә дип китте. Шунда бер таза урыс килеп минем күлмәк якасыннан борып алды да, кәзәкинең эчке кесәсенә акча янына тыгыла сул кулы белән. Пышылдый миңа: «Динга дай! Вудка надо!»—ди. Динганың нәрсә икәнен беләм инде. «Динга» ди инде бу да. Татар сүзе «тәңкә» бит инде. Безнең, татарлар, кебек акчаны шулай ди бит урыслар. Ә «вудка»ның нәрсә икәнен белмим бит инде.

—Бирдеңме?

—Нишләп мин сасы урыска акча бирим ди. Сул кул белән моның минем яканы бөтереп тоткан кулыннан эләктердем дә, беләзектән кысам теге кулны. Сул кулы эчке кесәгә кереп җитә язган иде инде. Туктады теге сул кул минем кесәгә үрмәләүдән. Ә мин кысам тегенең уң кулын. Беләзегеннән. Ике күзе акаеп, ике якка кыйшая башлады урысның. Ә мин кысыпмы кысам тегенең кулын. Ә кул шәп тегенең, зур. Күзләре алара, төсләрен югалта башладылар. Күгәрә башлады урысым. Тик теге сул кулын һаман алмый әле бу. Шуннан мин ныграк итеп кысам тегенең кулын беләзегеннән, Шартлый башлады теге урыс кулының сөяге. Чыгарды урыс сул кулын минем түш кесәсе яныннан. Ябышты бит шул сул кул белән минем бугазга. Мин иякне аскарак идем дә, бугазны яшерәм, бирмим тегеңәргә. Кыстым тек тыстым моның уң кулын. Күм-күмгәк булды моның йөзе, ә борыны ап-ак булып агарды. Гырлый башлады бу. Сүз әйтергә маташа, бугазыннан «хр-хр» дигән аваздан башка бер нинди тавыш чыкмый. Чүктереп җиргә хәтле күтенә утырттым мин моны. Үзем дә чүгәләдем янына. Карага манган киндер күлмәк, шуның өстеннән кызгылтрак чикмән кигән бу. Кулын җибәреп чикмән якасыннан тотып торгыздым да моны, арты белән әйләндереп уң аякның тезе белән бик ныклап чәпәдем тегенең күтенә. Берәү сыер сатып тора икән—китте бу очып кереп сыер аяклары арасына. Куркуыннан, ахрысы, сыер да моңа берне өстәде арт аягы белән. Ята урыс «ах» та «ух» килеп. Мукәйләгән, тора алмый азаплана. Маржасы булды, ахрысы, бер хатын килеп «Антуша да, Антуша»,—дип торгызып, читкә алып китте тегене.

Берничә көн узгач, узып барганда куна кергән әтинең таныш биларус, «шабра»ларыннан сорадым, нәстә ул «вудка», дип. Аракы икән, каһәр...

Кәшшаф көлде:

—Шул сүз истә калды, баштан чыкмый инде менә, «вудка» да «вудка».

—Эчкәнең бармы соң син аны?

—Аллам сакласын. Федоровка базарында күргәләдем мин исерек чуашларны. Алар бит кеше түгел эчкәч. Хәтта чуаш та түгел инде ул. Чучка тек чучка инде.

Ант итәргә әзерлек алып барганда патша галиҗәнаплары Николай II кызларының исемен белү мәҗбүри икән. Янып-пешеп, күзләрен йомып,

барлык дөньясын онытып, утырган урынында пышылдап та, кычкырып та Лотфулла гарәп хәрефләре белән язып тоттырган кызлар исемен кабатлый да кабатлый Кәшшафетдин:

—Аначтасия, Ульга, Мария...

Кызлар белән бергә патшаның кече улын да кушып жибәрә:— Ликчей...

Күзен ачып үзенә үзе карап алган кебек итә дә, тагын күзләрен йомып тотына:

—Аначтачия, Аначтачия, Аначтачия...

Озак кына дәшмичә алга-артка селкенеп утыра да тагын тотына:

—Ликчей, Ульга, Ульга, Ульга, Ликчей, Ликчей...

Уф Алла! Аначтачия! Аначтачия!

Өч көн буе ятласа да, бер генә исемне дә хәтерендә калдыра алмады. Һәм... янды!

«Патша кызларының исемен ятлаулар ничек барганны» тикшерергә ул көнне капитан Бульон үзе кергән иде. Алдында тезелеп утырган солдатларны үзе утырган өстәл янына чыгарып «белемнәрен» тикшерде.

—Сорокин!

—Я!

—Выдь сюда!

Солдат итек табаны белән идәнгә «строевой шаг» белән сугып «Пермяк соленые уши» (казармада алган кушамат!) Сорокин өстәл янына чыгып басты. Бульон сорау бирде:

—Безнең императрицаның исеме ничек?

—Александра Федоровна Романова.

—Молодец Сорокин!

—Рад стараться!

—Так! Тәхет мирасчысының исеме кем?

—Царевич Алексей.

—Ничә яшь инде аңа?

—Икесе тулып әле өчкә генә киткән.

—Молодец! Утыр!

—Рад стараться!

Бульон алдында утырган яшь солдатларга зур игътибар белән биреп карый: «Кемне чакырырга?»

—Рядовой Гималетдинов!

Куркуыннан шунда ук агара башлаган «рядовой Гималетдинов» сикереп тора.

—Монда чыгыгыз!

Лотфулла пышылдый:

—Сиңа чыгарга куша.

Кәшшаф чыгып баса. Дәшми.

—Чыкканыңны доложить ит!

Кәшшаф таптанып тора да «урысчалатып» телгә килә:

—Маяныкы твояныкын не панимай, гаспадин капитан. Татарски бит маяныкы.

Бульон урыныннан торып баса. Үз гомерендә капитанның «гололобый татаринны» беренче күрүе иде. Солдатка якынрак килде:

—Как, как? Повтори.

Лотфулла урыныннан ярдәмгә килә:

—Кабатла, ди, сиңа.

—Пжалста! Маяныкы тваяныкын не панимай бит татарски бит маяныкы.

—Та-ак! Значит, «татарский?»

—Татарски.

—Ладно? Син, милок миңа патшаның зур кызының исемен әйт әле?

Кәшшафетдин кызарып чыкты, тик капитанның нәрсә сораганын ул аңламады да. Шулай да җавапсыз калмаска уйлады, ахрысы.

—Знайт низнайт, маяныкы гаспадинка...

Шул мәлдә һич көтелмәгән хәл була. Капитан Бульон йодрыклап солдатның сул як яңагына бар көче белән китереп сукты. Кәшшафетдин диварга барып бәрелде.

—Мамай, вонючий! Мая, твоя!!! Рожа татарская, не мытая! Хәзер мин сиңа патша кызларының исемнәрен йодрык белән өйрәтәчәкмен. Кил!

Солдатлар утырган яктан урысчалап, кычкырып дәштеләр:

—Сезнең солдатны кыйнарга бер хакыгыз да юк.

Капитан Бульон тавыш килгән якка кискен борылды. Анда солдат Лотфулла Зәйнуллин басып тора иде. Ул Бульонның күзенә туп-туры карады:

—Нигә сугасыз аңа?

—Урыс телен белми бит. Ишетмисезмени, патша кызының исемен дә белми.

—Татар бит ул. Урысны күргәне дә юк. Өйрәнер әле казармада яши-яши.

Бульон кыза башлады. Зәйнуллинга боерды:

—Кил минем янга!

Лотфулла строевой адым белән капитан янына килеп туктап, доклад ясады:

—Ваше благородие! Рядовой Зәйнуллин Сезнең боерык буенча килде.

Доклад бетеп өлгермәде, Бульон кизәнеп Лотфуллага сукты...

—Адвокат табылган... мать! Мә тагын берне!

Сукты. Тик Лотфулла аның кулын һавада тотып алды, суктырмады. Каерылган беләкне аз гына кулларында кысып тотты да җибәрде. Акрын гына янаулы тавыш белән әйтте:

—Мин синнән Гималетдиновны да, үземне дә кыйнатмаячакмын. Исегездә калдырыгыз, капитан әфәнде, без аның белән татарлар...

Ике көн узгач, рядовой Зәйнуллин полк командиры кабинетына керә торган ишек төбендә утыра иде. Кереп килгән полк командирын күреп солдат аягына басты, честь бирде. Полковник туктады, сорады:

—Сез миңамы?

—Так точно! Сезгә! Рядовой Зәйнуллин.

—Бер минуттан керегез.

Кереп китте.

Әйткән вакыт узган кебек булгач, Лотфулла ишек шакыды:

—Ваше Высокоблагородие! Разрешите войти?

—Прошу.

Солдат өч адым атлады да, честь биреп, доклад ясады.

—Ваше высокородие! Рядовой Зайнуллин капитан Бульон өстеннән жалу белән килде.

—Капитан Бульон өстеннән?

—Так точно!

—Тыңлыйм сезне.

—Патша кызының исемен белмәгән, урыс телен начар белгән өчен капитан Бульон рядовой Гималетдиновның яңагына сукты. Мин солдатны яклап сүз әйткән идем, миңа да бер мәртәбә сукты. Икенчегә сукканда кулын тотып алып суктырмадым. Минем Сезгә үтенечем бар.

—Нинди үтенеч?

—Кыйнамасын безне. Без—татарлар! Әгәр безгә сугудан туктамаса, капитан өчен дә, үзем өчен дә эш начар булып бетәчәк.

—Һм!—диде полковник.—Бу синең әйткәнең янаумы, куркытумы?

Лотфулла нәрсә сөйлисен алдан ук уйлап, башына салып кергән иде. Җавап тиз булды:

—Янау да, куркыту да түгел. Мин сезне алдан белеп торсын дип әйтергә кердем. Әгәр дә капитан Бульон миңа, йәисә Гималетдиновка тагын бер сукса, мин аны артиллерийский тесак белән чәнчеп үтерәм. Шул гына.

Яр артиллериясендә һәрбер солдат кыска гына, тик гади хәнҗәрдән азрак озынрак артиллерия тесагы белән коралланган. Дары тутырылган ниндидер капчыкны кисеп тишәр өчен. Ул һәрчак бил каешында, сул якта агач кын эченә тыккан хәлдә асылынып тора.

—Капитанны үтерсәң Зәйнуллин каторгага элэгәсең бит!

—Мин үземнең каторгага китәсемне беләм. Бер кайтмасам, бер кайтырмын. Ләкин мин аңардан дустымны да, үземне дә кыйнатмаячакмын.

—Һм! Тик торганнан проблема бит монда. Бер сукканнан үлмәгәнсең бит, Зәйнуллин. Түзәргә кирәк.

—Никак нет, господин полковник. Эш түзүдә түгел. Ә җанны мәсхәрәләүдә.

—Да-а!?! Җанны-ы?!!

—Так точно! Җанны!

Сул кулы белән чибәр мыегын сыпыргалап, уйланып торды полковник. Урыныннан торды да ике кулын артка куеп, Лотфулла яныннан үтеп, ишек төбендә борынды, тагын өстәле янына килде. Солдатка таба борылды.

—Аңларсыңмы икән мин әйткәнне, Зәйнуллин? Капитан Бульон иң оста артиллеристларның берсе. Порт-Артур крепостенда японнарга каршы ябык позицияләрдә пушкадан атуны беренчеләрдән булып оештырган офицер-артиллерист. Икәү булганнар алар анда беренчеләрдән. Икенчесе, аның дусты капитан Александр Колчак. Анысы нәсел ягыннан чыгышы белән татар. Тик телен оныткан, татарча ике җыр гына белә икән.

Капитан Бульон да, капитан Колчак та японда әсир булганнар. Русиягә кайтканнарына әле ел да юк. Контужен булган ул каты. Шунлыктан үзен-үзе онытып, кулларына ирек биргәли шул. Аның белән сөйләшү булгалады инде. Тик ярдәме тимәде. Түз инде син, Зәйнуллин.

—Никак нет, господин полковник. Түзә алмыйм. Кыйналмыйм мин аңардан.

Икесе дә бераз дәшми тордылар.

Лотфулла урынында кузгалып куйды:

—Сез безне Гыймалетдинов белән икебезне дә башка гарнизонга күчерегез, господин полковник. Бульон миңа тагын сукса, азагы хәтәр булачак. Ә капитан Бульонга минем киңәшне әйтегез—ярдәм итәчәк ул.

—Нинди киңәш икән, әйтеп кара.

—Кыза башлап кулы кычыта башласа, эчтән генә «унга кадәр» санасын. Теләсә. Шул ун санны мин татарча сүзләр белән аңа язып тоттырырмын. Татарча санасын.

Полковник кызыксынып елмайды:

—Ә ни өчен татарча инде, русча түгел. Әллә сихыры күбрәкме татарча санаса?

—Юк! Сихыры юк. Урысча бит үз телендә була. Шунлыктан баш мие эшләр-эшләмәс кенә катнаша санауда. Баш урысча санауны яхшы белә бит, һәм баш мие санауга катнашмый да диярлек. Ә болай санау, татарча булгач, татар сүзләрен искә төшерергә кирәк һәм ми эшли, уйлый. Татарча унга

кадәр санаганчы, кулының кычытуы да басыла. Хуҗасы да тынычлана.

—Бик кызык нәрсә сөйләдең бит әле син. Каян беләсең моны, ә, Зәйнуллин?

—Мин дә кызу холыклы. Малай чакта тик торганнан берничә тапкыр сугышып киткәнем бар иде. Үзем башлап. Берсендә казыклар белән җирдә тәгәрәтеп кыйнадылар. Шуннан әни өйрәтте чуашча унга кадәр санарга. Кыза башлаганда инде.

—Ярдәм итәме?

—Капитан Бульон миңа берне суккач мин чуашчалап саный башлаган идем инде.

—Капитан Бульон сине үзенә чакырып алыр. Син татарчалап бердән алып унга кадәр кабаланмый гына, ачык итеп, аңа әйтеп санарсың. Ул сүз белән урысчалатып язып алыр син әйткәнне. Ятлар. Һәм сиңа кычкырып әйтеп унга кадәр санар. Ялгыш җирен син төзәтеп тагын яздырырсың.

Кыска гына итеп көлде:

—Өйрәнсен әле хохол баласы татарча санарга.

Торып чыкты өстәл артыннан:

—Әгәр татарча санау да ярдәм итмәсә, капитан сугышудан туктамаса, мин сезне күрше батареяга күчерермен. Икегезне дә. Сез, татарлар, таза, көчле егетләрсез («Джигиты» диде полковник!) Тәртибегез дә бик әйбәт. Аракы да эчмисез. Мондый тырыш, тәртипле солдатларны һич кенә дә кулдан ычкындырырга ярамый. Үзебезнең гарнизонда үтәр хезмәтегез.

Көтелмәгән сорау бирде:

—Ашау ничек, җитәме?

—Так точно! Башта җитми иде, хәзер инде ипи артып та кала башлады.

—Күп каламы?

—Өйлә ашында мин килгән чакта дүрт телем ашый идем. Хәзер өчәү дә җитә.

—Ә дуңгыз итенә карашыгыз ничек? Коръән тыя бит сезне аны ашаудан. Ашамыйсызмы?

—Коръән мөселманга өч очракта дуңгыз итеп ашауны гөнаһ санамый.

Полковник кызыксынды:

—Нинди очраклар алар, миңа да әйт әле?

—Беренчесе, мөселман булмаган чит илгә барып эләгеп, анда мөселман суйган ит булмаса һәм суярга мөмкинлек булмаса. Үз илендә мөселман суймаган сыер итеп ашау да гонаһ. Ә чит илдә Коръән мөселман суймаганны ашауны гонаһ санамый. Дуңгыз итен дә. Икенчесе, карабка утырып диңгез кичкәндә. Ашарга дуңгыз итеннән башка ризык булмаса. Шулай ук мөселман суйган ит булмаса. Өченчесе инде, мөселман булмаган башка илгә әсир булып төшкәндә. Шул өч очрак.

—Син бит хәрби хезмәтне әйтмәдең.

—Хәрби хезмәттә булу, башка мөселман булмаган халыкка әсирлеккә төшү белән бер дәрәҗәдә санала. Безнең ак падишаһ христиан динендә бит. Шунлыктан безнең аңа хезмәт итү әсирлектә булу белән бер дәрәҗәдә санала.

—Ала-ай!—дип гаҗәпләнде полковник.—Катлаулы һәм акыллы сезнең мөселман дине. Мин бернәрсә дә белмим икән әле ул турыда.

Ул кулы белән солдатның беләгенә акрын гына сукты.

—Килештек дип уйлыйм мин Зәйнуллин синең белән. Килештек. Икегез дә яхшы хезмәт итегез, мин сезне җәберләргә беркемгә дә ирек бирмәм. Булдымы?

—Так точно, Ваше Высокородие!

—Бар. Хезмәт ит. Гималетдиновка өйрәт инде син патша кызларының исемнәрен. Өйрәнсен. Авылына кайткач мактаныр. Үзләрен күрмәсәм дә, мин патша кызларының өчесенең дә исемнәрен беләм дип. Бар! Рөхсәт сиңа китәргә.

...Керчь крепостена килеп ай, ай ярым вакыт үтүгә авылны, туганнарын, әти-әнисен, авыл тирәсендәге эреле-ваклы тауларны, елга буйларын, еракта күгелҗемләнеп күренгән Байгара, Кайраклы, Күремтә тауларын Лотфулла үлепләр сагына башлады. Тауларда, далаларда үскән татар баласының дүрт биек таш дивар эченә, сандык эченә салган кебек бикләнгән, йөрәге сыкрап, башы энке-менке килә иде. Хезмәте әйбәт бара яр артиллериясе рядовое Лотфулла Зәйнуллинның. Ашау-эчү әйбәт. Тәүлегенә өч кадак ипи бирәләр. Итле щи, борщ, галушка ашаталар. Икенчегә дип кисәкле ит, ботка, итальян спагеттисы дигән ак челәүчәнгә охшаган, иң ялкау татар хатыны кискән бодай токмачыннан да юанрак, тәлинкә эчендә шуып торган бер ризык бирәләр. Иптәш хохол солдатлары аны итальян макароны диләр. Тәме әллә нәрсә түгел дә, тик үзе болай әйбәт кенә ашала. Сигез яшеннән байларда бозау көтүе көтәргә чыгып, егерме бер яше тулып, солдатка киткәнче батраклыкта йөргән һәм ялчылыкта нәрсә бирсәләр шуны ашап өйрәнгән Лотфуллага солдат ашы байлар гына ашаган аш булып тоелды. Тазарып, түгәрәкләнеп, алсу йөзле чибәр егеткә әйләнеп китте Лотфулла. Тик менә сагынула-ар!..

Бер төнне Лотфулла казарма эчендә дневальный иде. Солдат халкы хырлап, саташып йоклый. Диңгез ягыннан алсуланып таң атып килә. Аз гына яктыра төшкән тышкы яктан казарма эченә сай гына аклык сибелә башлады. Үзеннән соң тумбочка янына басып торырга тиешле Тищук фамилияле украин егетен уятты.

—Тор! Синең смена хәзер.

Тищук киенеп, тумбочка янына баскач, Лотфулла йөрәге сыкрауга чыдый алмыйча, казарма алдына чыкты.

Тышта тып-тын. Җил дә юк. Диңгез дә тын һәм крепость диварының теге ягында диңгез, горур булып ятуын белә. Тик йоклаган дию пәрие кебек, диңгез дә, сирәк-мирәк «пу-уф» дигәнрәк тонык кына аваз чыгарып куя. Гүя ул да, йоклаган чагында да, тын ала инде.

«Һава алмаштырып» крепость ишегалдында байтак басып торды Лотфулла. Инде керергә дип борылган иде, дивар тышыннан казарма башына үрмәләгән тимер баскычка күзе төште. Башына кергән уйдан арына алмыйча, баскычтан казарма башына менеп китте. Казарма өч катлы булып, түбәсе кыек итеп тимер белән ябылган. Чормадан түбә башына чыгар өчен ясалган ишекне ачып, Лотфулла казарма башына чыкты. Сакланып кына, калай түбәдә таеп китмәскә тырышып, өй башын япкан тимер калайның тавышын чыгармыйча кыек белән төтен чыга торган кирпеч морҗа янына күтәрелде. Морҗа, кирпечтән сырлап, асты ярты кирпечкә чыгып торган итеп салынган. Лотфулла шул чыгып торган кирпечкә артын терәп утырды да, килгән ягына, кояш чыгышына карап тынып калды...

Дөнья тып-тын...

Крепостьның эчендә дә, тышында да шылт иткән тавыш та юк. Утырган урыныннан артта, унбиш чакрымда урнашкан Керчь каласының тавышы крепость янына килеп җитми. Тик сирәк-сирәк кенә, таң белән уянып, диңгез яры буйлап арлы-бирле йөреп үзләренә төрле бөҗәк-кортлар эзләүче озын борынлы кошларның «чжык-чжык» дигәнрәк тавыш чыгарып куюлары гына ишетелгәләде. Ул озын борынлы кошлар туган яклардагы кулик кошка да, пибик дигән шулай ук озын борынлы, тик бик тә чуар каурыйлы кошларга ошаганнар ошавын. Тик бу кош алардан зуррак, гәүдәсе озынрак,

аяклары да ярыйсы гына озын. Тик никадәр матур булмасыннар, безнең куликларга, пибикләргә матурлык ягыннан житә алмыйлар инде...

Алда, крепостьның биек диварының теге ягында иксез-чиксез, бернинди үлчәмгә дә сыеп бетми торган каракучкылланып, зәңгәр дингез жәелеп ята. Крепость утырган Ак Борын яры уң якка таба 1,5—2,0 чакрым чамасы сузыла да, аннан уң якка кереп китеп күренмәскә әйләнә. Яр сул якка ташлы кыялар булып 6—7 чакрым чамасына сузыла, аннары Керчь бугазының 4 чакрым чамасындагы иң тар жиренә барып житеп, биек кенә таш кыя ясап ала да, Азов дингезе ягына, аның яры булып кереп китә. Ул урынны Камыш Борын дип йөртәләр бугай. Һәм анда Кырым—Кавказ ярларын тоташтырып зур дингез паромы йөри диләр. Дөрестер, бик тә аяз көннәрдә ул паром күренеп кала. Утырган казарма башыннан Керчь бугазы аша туп-туры карасаң, бугазның теге ягында Кавказ таулары күренә. Әтисенең әнисе, дию пәриләре турында әкиятләр сөйләгәндә ул тауларны Каф таулары дип, жен-пәриләрнең туган илләре анда, балам, дип сөйли торган иде. Инде менә авылда туып-үскән Балта Зәйнетдин улы батрак Лотфулла шул жен-пәриләр, диюләр туып үсә торган Каф тауларын Кырым дигән жирдән—солдат казармасы башыннан—карап утыра. Күз күремендә 7—8 чакрым бардыр.

Лотфулла кызыл төстәге офыкка, һавада каралып күренгән тауларга карап күңеле белән, йөрәге белән, башы, барлык вөжүде белән туган ягына кайтып киткән. Әйтерсең лә инде ул авылы Эстәрлегә кайткан да, Байгара Тау ягыннан чыгып килгән кызыл кояшны карарга исәпләп авыл каршысындагы Зират тавы башына менеп утырган. Казарма артында түгел, ә Зират тау астында Керчь крепосте дивары түгел, ә авыл зиратының коймасы сузылган. Кырым Керче крепосте казармасы башында утырган егет Байгара тау артыннан акрын гына, вә ләкин туктамыйча, табигать матурлыгын күрсәтеп күтәрелеп чыгып килгән зур кояшның әлегә тик читен генә күрә. Менә ул кояш кыйпылчыгы тау түбәсеннән өскәрәк күтәрелә, зурая, һавага менә башлый. Күтәрелгән саен кырыннан, читеннән азлап кына, кызыллыгы алсу төскә алмашына, кыйпылчык зурая, чын кояшка әверелә. Тагын азрак күтәрелгәч, кояшның өске кырына куе сары төс керә һәм кояш һавага үрмәләгән саен ул төс киңәеп сарыланганнан сарылана бара. Кояш чыга гына башлаган мизгелдә, зират эченә иртә яздан очып килеп, оя корып, бала чыгарып яшәгән Ходайның иң асыл кошы булган сандугачлар берәм-сәрәм генә тавыш биреп сайрарга тотына. Кояш Байгара Тау артыннан яртылаш күтәрелгәндә зират эчендә сайраган сандугачларның исәбе-хисабы юк. Күпләп-күпләп моңаялар, сайрыйлар. Зират эче, бу дөньядан мәңгелеккә китеп, инде нужа-михнәтләрдән арынып туган жир туфрагындагы каберләргә, үзләре дә туфракка әйләнергә дип яткан Ходай бәндәләренең жан-рухларын тынычландырып сандугач сайраулары белән тула. Лотфулла өчен сандугачлар—гади кошлар түгел. Сандугачларда бу дөньядан киткән асыл кешеләрнең жаннары урнашкандыр дип уйлый ул. Усал, явыз кешеләрнеке түгел. Алар башкаларга изгелек эшли белмиләр, моңаеп аларга сайрау житкермиләр. Чөнки алар жир йөзендә явыз булганнар.

Зират эченә мәдрәсә мөдәррисе Харис мәхдүм Тархан Тукаев заманында утыртылган, инде бик тә юанайган биек карагай башына кәккүк килеп куна. Берәр кошчыкның оясына үзенең күкәен яшереп кенә куеп килгән ахрысы. Баскан ботагында боргаланып, сикергәләп ала да, жир йөзендә нужа-михнәткуар күпләп күрергә дип туган, ике аягына баскан Ходай әрвахларының йөрәгенә моң белән сагыш сала:

—Кәк-кү-үк! Кәк-кү-үк!

Бала да чыгара белми торган чуардан киенгән бу җилбәзәкнең сандугач кошныкы кебек йөрәк моңы да юк, җыры да юк, сайрый да белми. Ә шул җинел холыклы коштан чыккан тавыш—«кәккүге» моңлы кешенең генә түгел, җаны белән явыз булган бәндәләрнең дә күнелен кузгата, йөрәкләренә сагыш сала, нечкә күнеллеләренең күзенә яшь китерә. Бу якты дөньяга Ходай бәндәсенең Вакытлыча гына килгәнлеген исенә төшерә. Онытма, китәсең син дә бу дөньядан!

Лотфулла яхшы белә—Эстәрлебаш зиратындагы кебек сагышлы итеп тавыш биргән кәккүкләр башка бер генә җирдә дә, бер генә зиратта да юк. Мәдрәсәдә укыганда Зарифулла хәлфә әйткән дөрес ул: «Ир бәхете күрмәгән, балаларын инсафлы итеп үстерә алмаган, нужа-михнәттән иртә картаеп җыр-моңны да онытып, күзләренең нуры сүнгән бәхетсез хатын-кызлар җанынннан бар иткән ул кәккүк кошны Ходай тәгалә! Ул кош җырлый, сайрый белми, ә тавышында аның моң, сагыш сандугач сайравыннан күбрәк һәм тирәнрәк. Шул сагыштан, нужа-михнәттән бала чыгару сәләтен дә югалткан кош ул—кәккүк! Балалар! Сез кәккүк тавышын ишетсәгез кая гына китеп барсагыз да, нәрсә генә эшләсәгез дә, «бисмиллагызны» укыгыз, Ходайга Кәккүк кошны бар иткән өчен рәхмәтегезне җиткерегез! Нужа-михнәт, хәерчелектә дөнья көткән хатын-кызның оҗмахта булуын теләгез! Ходайның иң сагышлы кошы ул, Кәккүк! Аңарда хатын-кыз җаны!»

Кырым ярымутравында, Ак Борында салынган кальга эчендәге казарма башында төтен морҗасына аркасын терәп утырган арсландай таза гәүдәле егет, туган ягын, туган җирен, туган авылы, туганнарын сагынып елый, сагышлана иде...

Бу 1908 елның май ае башлары иде. Өч көн узгач, татар солдаты Лотфулла Зәйнуллин казарма эчендә өч хохол солдаты белән низагка кереп, чак-чак артиллерия тесагына тотынмыйча калды.

Ул солдатлар Таврия дигән Кырым ярымутравыннан чыккач төньяккарак сузылып киткән даладан иделәр. Сөйләшкән чакта еш кына Аскания-Нова дигән, немец алпавытлары Фальцфайннар яшәгән оҗмах кебек матур урынны искә алып сөйлиләр иде. Өч солдатның берсенең әтисе шул немецләрдә бакчачы булып эшли икән. Шул дала Тавриясеннән әтиләре парлап үгез җигеп Кырымга тозга дип килгән. Кырымның төньягындагы Сиваш дигән сазлыклы урында, корырак елны тозны, тишекләнгән тимер көрәк белән, су сай урыннардан көрәкләп алып була икән. Тозга килгәннәр салынкы мыеклы хохол агайлар һәм бер уңайдан урыс патшасы хезмәтендәге «хлопецләрен» дә күреп, хәлләрен белеп кайтырга дип, Сивашка керер алдыннан, Керчь крепостена килгәннәр.

Крепостьның Керчь каласына караган капканы чыгып, юл белән бер чакрым барсаң, ике зур кыя таш арасыннан чылтырып Ходай биргән салкын сулы чишмә чыгып агып ята. Парлап җигелгән үгезләрен тугарып Таврияда килгән өч хохол шул чишмә янында кундылар. Тирә-якта үгезләренә җитәрлек аз-маз үлән дә үсеп чыккан икән. Слава Богу!

Өч украин солдатын полк командиры боерыгы белән аталары янына төнгелеккә җибәрделәр. Кояш баеп килгән чакта чишмә ягыннан берничә ир тавышы бергә кушылып җырлаган украин җыры ишетелә башлады:

Распрягайте хлопцы кони
Да лягайте почивать
А я пиду в сад зеленый
В саду криниченку попать.

Крепость ишегалдында тәмәке тартып утырганнар арасыннан «Пермяк

соленые уши» көнчелек тулы тавыш бирде:

—И-эх! Нигә Пермь яклары Таврия далаларында түгел икән. Мин дә бүген йөзәр идем горилкада.

Башкалар да, күңелсез генә елмаешып, төнге йокыга ятарга дип кереп киттеләр...

Икенче көнне кояш чыгу белән украин солдатларының әтиләре тозга дип Сиваш сазлыгы ягына, үгезләрен «цоб-цоби» дип кабаланмый гына куалап китеп бардылар.

Шул көнне кичке алтыдан соң дневальный булып рядовой Зәйнуллин казармадагы тумбочка янына басты. Ярты сәгать чамасы узгач, бүген иртән әтиләре киткән өч хохол егете бастионнан казармага кайтып керделәр. Ятак урыннары янында бераз «мыдыр-мыдыр» килеп сөйләшеп утырдылар да, нәрсәгәдер шатланып көлештеләр. Берсе торып каптеркага китте. Озак та үтмәде, солдат капчыгы күтәреп иптәшләре янына кире килде. Капчыктан ике украин ипие һәм ике зур кисәк чучка мае—сало чыгарды. Салоның һәр кисәге 3—4 кило чамасы. Караватның ике ягына тезелеп утырдылар. Берсе артиллерия тесагы белән ипи кисте, икенчесе сало телә иде. Сало кискәне тик кенә утырган өченчесенә карап, елмаеп нәрсәдер әйтте. Лотфулла «татарин» дигәнне ишеткән кебек булды. Тик әһәмият бирмәде.

Хохолның берсе торды да дневальный басып торган якка арты белән басты. Һәм иелә төшеп нәрсәдер алды да, Лотфуллага таба килә башлады. Хохолның култык астында бербөтен зур түгәрәк, кабартып пешергән хохол икмәге, икенче кулында зур сало кисәге иде. Көлгән күзләрен дневальный булып басып торган Лотфулладан алмастан янына килеп җитте. Бер адым кала гына туктады. Беләге белән биленә кысып тоткан зур икмәкне дневальный тумбочкасына куйды. Шикәр кебек ап-ак салоны икмәк өстенә салды.

—Тебе, Магометанину, подарок от нас, от хохлов. Кушай на здоровье чушка сало. Тебе чушка сало. Магометанину! Ешь!

Зур уң кулы белән шапылдатып Лотфулланың сул кулбашына сукты да, иптәшләре янына китте.

—Туктале, син!—диде Лотфулла.—Бик зур бит бу сало кисәге. Тоташы белән миңамени инде?

—Әййе. Бүләк сиңа. Аша. Сиңа. Аша. Тоташы белән синеке.

Иптәшләре янына барып җиткәч, өчәүләшеп казарма тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп тавыш чыгара-чыгара кычкырып көлделәр. Берсе, яшь бәреп чыккан күзен җиңе белән сөртә-сөртә, әйтеп ташлады:

—Ешь, мусульманин! Твой Аллах на том свете тебя на скворode будет жарить как это сало. Ешь, пока здесь и живой!

Лотфулла дөньяларын онытып көлгән өч хохолга елмаймаска тырышып карап алды да, кыныннан тесакны тартып чыгарды. Бисмилласын әйтмичә генә зур, түгәрәк ипидән калын итеп «кибән башы» кисеп алды. Аннан соң бармактан калынрак итеп ап-ак салоны зур кисәктән тесак белән кисеп аерды да, «кибән башы»ның киселгән ягына куйды. Тумбочканы ачты да, калган ипи белән салоның зур кисәген тумбочка эченә тыгып, аның ишеген япты. Ипи белән салоны ике куллап тотты да авызына капты. Ап-ак, таза тешләре белән ипиле салоны зур гына итеп тешләп өзеп аерды да, чәйни башлады. Ятаклары янында утырган өч хохол тып-тын булдылар. Көлешү, сөйләшү тукталды. Үзләре генә ишетелерлек итеп, акрын гына сөйләшә башладылар. Бераз гына вакыт узгач, сало белән ипине биргән Мыкола тумбочка янына килде. Күзләре йөгергәли, бите кызарып чыккан иде.

—Калган ипи белән салоны кире бир, чукындырылмаган морда. Бир исән чагында.

Лотфулла чәйнәгәнен йотты да, җавап бирде:

—Мин бит син хохолдан сорадым, бик зур бит бу сало, барысы да миңамы дип. Син бит салоны тоташы белән минеке диден. Бүләк диден. Ә бүләкне кире сорамыйлар. Әйдә, гулэй моннан. Алдыннан артың матур.

—Ах син татарская морда! Мин синеме!—Уң кулын йодрыклап сугарга кизәнде хохол.

Ә Лотфулла хохолның ике күз арасына, үзенә малай чагында дәү әтисе Әбү Нәгыйм өйрәткән татар ысулы белән китереп «чәпәде». Уч төбе белән. Хохол идән буйлап 3—4 метр очты. Сикереп торды да акырып җибәрде:

—Татарин үтерә мине! Татари-и-ин!

Ятак янында баскан ике иптәше тумбочка янына ташланды.

Лотфулла сул кулына алган ипи белән салоны дневальный тумбочкасы өстенә куйды да, бил каешының сул ягында асылынып торган агач кыннан артиллерия тесагын тартып чыгарды. Аякларын азрак аерып басты. Ул бик тыныч иде:

—Килегез! Берәмләп килсәгез дә ярый, өчегез бергә килсәгез дә ярый. Өчегезнен үлеме дә татар кулыннан булыр. Ну!

Ыргылганнарның берсе туктады. Ыңгырашып идәндә яткан Мыколага торырга ярдәм итте. Бер-берсенә карашып алдылар да, өчесе бер булып кыска-кыска гына атлап дневальныйга якынлаша башладылар. Мыкола сул кулы белән борынын каплап тоткан—анын бармаклары арасыннан кан ага иде. Кулындагы тесак белән Лотфулла беренче итеп уртадагы хохолның корсагын ярырга ниятләде. Хохол бил каешын ятакка элеп куйган, тесак каеш пряжкасына тимәячәк. Хохоллар ташлану ноктасына килеп җиттеләр дигәндә, алар артында тавыш ишетелде:

—Нинди ызгыш монда? Туктагыз!

Өч хохол артында ике кулын артка куйган капитан Бульон басып тора иде. Өч солдат та «Смирно!» бастылар. Бульон аларга бик җентекләп карады да Мыколадан сорады:

—Нәрсә булды сина? Кем сукты?

—Татарин Зәйнуллин, господин капитан. Татарин сукты!

—Татарин? Нәрсә өчен?

—Без аңа үртәп кенә көлергә уйлап чучка салосы биргән идек аша дип. Ул бит мусульманин. Ашамас диеп уйлаган идек. Кисеп алды да ашый да башлады. Мин кире алырга иткән идем, миңа йодрыклап «чәпәде».

Капитан елмайган күзләрен Лотфуллага күчерде дә сорады. Соравында кызыксыну иде.

—Син, Зәйнуллин, сало ашыйсынмыни? Син бит мусульман, татар. Ә?

—Господин капитан! Мин 19 яшьтә чагымда бездән өч чакрымда яшәгән боярин немец Мердер264 имениесендә балта белән эшләп, абзарлар салышкан идем. Ул да бездән көләргә уйлап сало ашарга биргән иде. Без, сигез татар, ашадык та бетердек.

Тумбочканы ачты.

—Менә салолары. Сезнең алда бирәм кире, алсыннар. Миңа кирәге бер тиен. Берсе алды инде миннән. Сез кермәсәгез, бетерә идем мин аларны. Алсыннар «бүләкләрен»...

—Бүләк диделәрмени?

—Әййе.

—Суя иденме, Зәйнуллин?

—Суя идем, господин капитан. Мин бит аларның Аллалары булган яһүдидән чыккан Христосларына тимим. Тимәсеннәр минем динемә.

—Ала-ай!—диде Бульон.—Еврей дисен. Христос бит минем дә Аллам.

—Мин әйттем бит инде, сезнең Христоска тимим дип. Һәркемнең үз Алласы.

Мыкола капитанга мөрәҗәгать итеп:

—Господин капитан! Сало белән ипине алып китәргә рөхсәт итегез.

Бульон елмайды:

—Бүләкне кире алмыйлар, Галдун. Кире алмыйлар. Бирмә, Зәйнуллин. Ашап бетер. Үзең генә булдыра алмасаң, урыс иптәшләреңне сыйла.

Өч хохолга борылды.

—Мин дә сезнең кебек украинец. Хохол. Тик беркайчан башка милләтләрдән көлгәнем, аларны мыскыллаганым юк. Тагын бер мәртәбә Зәйнуллиннан көлсәгез, йәисә үч алырга уйласагыз, сезнең өчегезне дә киркәчә утыртырмын мин. Гауптвахтага!

Казармага кайткан солдатлар арасыннан Лотфулла «Пермяк соленые уши»ны чакырып алды. Елмаеп сорады:

—Сало ашыйсың киләме?

—Килә дисәм, нәрсә әйтерсең?

Лотфулла дневальный тумбочкасын ачты.

—Тот, Семен! Сало сиңа. Ашагыз дусларың белән..

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, биш урыс солдаты бер ятакны уратып утырып хохоллар «бүләк иткән» ипи белән салы кисәген юк иттеләр—ашап бетерделәр. Көлешеп Лотфуллага рәхмәт әйттеләр.

—Ну и татарин! Каян алган бу кадәр шәп салоны? Татарда да чучка салосы була икән. Рәхмәт сиңа, Зәйнуллин.

—Исәнлеккә!—диде Лотфулла елмаеп.

Шул очрактан соң өч украин солдаты татар солдаты Зәйнуллиннан башкача беркайчан көлмәделәр һәм аңарга бер генә начарлык та эшләмәделәр. Бергә хезмәт иткән соңгы ике елда бер-берсенә мөнәсәбәтләре ярдәм итүгә һәм солдат дуслыгына күчкән иде инде...

...Таза гәүдәле, юан беләкле ике татар егетен снарядларны чокырдан пушкалар янына күтәрә торган лебедкалар әйләндерергә куйдылар. Бер ай чамасы лебедка әйләндергәч, Лотфулланың солдат язмышы кинәт үзгәрде. Кичен ул Андрей Козубенко дигән хохол солдатының әйтеп торуын хат итеп язып утыра иде. Хохол укый да, яза да белми. Шулай булса да таза, көчле хохол егетен әлеге шул снарядны пушка янына күтәртә торган лебедка әйләндерергә өйрәтәләр иде. Хохолның күпсанлы туган-тумачаларына, агай-энесенә сәлам язып бетереп киләләр иде, аларга эндәшкән тавыш ишетелде.

—Нәрсә эшлисез монда?

Батарея командиры капитан Бульон икән. Икесе дә торып «смирно»га басып каттылар.

—Өйгә хат язабыз,—диде Козубенко.

—Әллә үзең яза белмисеңме?—дип сорады капитан?

—Юк. Грамотам юк минем. Укый да, яза да белмим.

Бульон Лотфуллага карады.

—Зәйнуллин! Синең русча белемең бармыни? Хатны русча язасың бит.

—Так точно. Русча. Дүрт кыш рус мәктәбендә укыдым мин.

—Каладамы?

—Юк, үзебезнең авылда.

—Ул рус авылы идемени?

—Юк, татар авылы. Анда дүртьеллык рус школасы бар. Шунда укыдым мин.

—Татар авылындамы?

—Так точно.

—Арифметиканы да беләсеңме?

—Беләм, дүрт гамәлне дә беләм. Гади һәм десятичная дробьны да беләм. Процентны да.

—Әнә ничек икән. Ярар, яз хатны. Мин синең турыда полк командирына хәбәр итим әле. Синең бит наводчик булырга белемең житәрлек. Әгәр полк командиры карар кылса, наводчиклыкка риза буласыңмы?

Лотфулла аз гына уйланып торды да, җавап кайтарды:

—Прицельны өйрәнеп булырмы икән? Бик тә катлаулы бит ул.

Бульон елмайды:

—Аның катлаулы икәнен син каян беләсең инде, ә?

—Наводчиклар күрсәттеләр.

Икенче көнне рядовой Зәйнуллин «во фронт» басып полк командиры полковник Тимофеев кабинетында тора иде. Полковник кызыксынган күзләрен солдатка текәде.

—Менә капитан Бульон синең дүртьеллык русча белемең бар, ди. Дөресме?

—Дөрес. Тик минем ул дүрт ел укыганга документым юк.

—Ни өчен?

—Авылдагы Тархан Тукаев бирдермәде. Мине учитель Байишев Казанга учительская школага җибәрергә теләгән иде. Тукаев каршы төште.

—Нилектән?

—Казанда укып руска әйләнеп кайта ул дип.

—Дурак ул Тархан. Дурак.

Лотфулла дәшмәде.

Полковник бармаклары белән тыкырдатып өстәл тактасына суккалап алды да сорады:

—Наводчик булырга телисеңме, Зәйнуллин?

—Воля ваша, Ваше Высокородие? Ничек боерасыз бит!

—Яхшы. Бүгеннән алып полкның наводчиклар командасына керү турында мин язма рәвештә боерык бирәм. Аның начальнигы капитан Ростунов. Беләсең бит аны?

—Так точно. Жирән сакал, мыеклы.

—Ул японнарга каршы Порт-Артурда сугышкан. Шунда яраланган. Владивосток госпиталендә дәваланганнан соң безнең крепостька хезмәткә җибәрелгән. Пушкадан атарга өйрәнерсең. Сынау биргәч, аена биш тәңкә акча түли башларбыз. Аңламаган урыннар булса, сораулар туса, капитан Бульон да ярдәм итәр. Ишеттеңме, Николай Николаевич.

—Так точно, Ваше Благородие. Ишеттем.

Шул көннән соң рядовой Зәйнуллин чокырдан снарядлар күтәреп менгерә торган лебедканың һәм лафетка утыртылган пушканың механизмнарын әйләндерүдән азат ителеп, наводчиклар төркеменә беркетелде.

Капитан Ростунов йомшак холыклы һәм бик тә мәрхәмәтле кеше булып чыкты. Барлык солдатларга һәм унтер-офицерларга да «Сез» дип дәшә, фельдфебельләргә исеме, әтисенең исеме белән зурлап дәшеп сөйләшә.

Кальга эчендә ике катлы итеп урнаштырылган алтышар зур пушкадан торган ике батарея төзелгән. Кальга эчендә 12 калибрлы алты пушка батарея булып урнашкан. Шулар өстенә 10 калибрлы тагын алты пушка утыртылган. Уникесе дә казенный яктан (пушканың арты) корыла һәм төтенсез дары кулланып атыла. Шул 12 зур калибрлы пушкалардан башка алардан илле метрга уң якта 6 калибрлы япа-ялгыз тагын бер пушка утыртылган. Ул пушка снарядының авырлыгы 47 килограмм—өч потка якын, 13 чакрым ераклыкка ата. Һәм ул пушка крепостьта артиллеристларны атарга өйрәтү өчен кулланыла. «Учебная пушка» дип атыйлар. Аның прицелы зур калибрлы, егерме ике чакрымга ата торган пушканыкы кебек зурдан эшләнгән.

Шунлыктан сөсәү, ату принциплары барысы да зур пушканыкыннан аерылмый. Өйрәтү, күнегүләр шул «учебная пушка»да бара.

...Лотфулла наводчиклыкка күчкәннән соң дүрт ай чамасы узгач, Кәшшафетдинның пушка атканда авызын ачарга оныткannan, ике колагының да пәрдәләре шартлап, ул бик каты саңгыраулана. Севастополь дингез госпиталендә ай ярым дәваланып ята да, табиб комиссиясенең «не годен к строевой службе в Российской армии» дигән карары белән үзенең мишәр авылына кайтып китә. Хезмәт итүе бер елга да тулмаган иде. Иртәгә китәсе көнне броня белән өсте капланган ике катлы батареядан ерак түгел бер эскәмиядә утырып байтак сөйләштеләр. Лотфулла дустына өч тәңкә акча чыгарып бирде:

—Кайтышлый, юл унае бит, Эстәрлегә кереп әтигә биреп кит.

Кәшшафетдин акчаны алып түш кесәсенә сала.

—Ярар, Лотфулла, тапшырырмын. Кайтам бит инде.

Әллә ни сөйләшер сүзләр юк иде. Чөнки берсе баш белән дә һәм йөрәге белән дә инде туган авылында, ә икенчесе тагын өч елдан артыкка Керчь кальгасында урыс патшасының солдат хезмәтендә торып кала. Кәшшафетдин хушлашырга дип кулын бирде дә, пышылдап диярлек әйтте:

—Син дә, Лотфулла, минем кебек пушка аткан чакта авызыңны ачма. Сине дә җибәрерләр колакларың ишетмәс булгач...

Лотфулла аптыравын яшерә алмыйча мишәр дустына карады. Башын селкеде:

—Юк, Кәшфи! Мин эшли алмыйм андыйны. Гомерем буе колаксыз саңгырау булып яши алмыйм мин. Минем өчен язгы тургайның сайравын бер мәртәбә генә булса да тыңлау үзе бер гомер ул. Юк! Хуш! Исән-сау кайтып җит. Мин солдаттан кайткач барырмын әле сине эзләп. Йөрешербез дуслар булып.

Аерылыштылар. Тик дуслыклары өзелмәде. Кәшшафетдин гомере буена киез итекләр басып кәсеп итте. Эстәрледән 15 чакрымдагы Карагыш исемле мишәр авылында, атнасына 4—5 кием киез итек басып, Эстәрле базарына шимбә базарына сатарга күтәреп килеп, Лотфуллада куна торган булды. 1930 елда дусты Лотфулла ярдәме белән «кулак булып» озатылудан котылып кала алды.

1981 елда Кәшшафетдин бабайга 95 яшь тулды. Ә минем әти 1965 елда 79 яшендә бу дөньядан китте. Мин Кәшшаф бабайны күрәсем килеп Карагош авылына киттем. Кәшшафетдин бабайның әбисе дә исән, үзе дә исән. Тик бик нык картайган, йончыган иде инде алар. Улы Нурый белән килене Зөләл (Дәрдеменд нәселеннән) карый иде аларны.

Бабай да, әби дә ап-актан, саф-чиста итеп киендерелгән.

Икесен дә аерым бүлмәдән җитәкләп алып чыгып утырттылар. Нурый абый минем кем икәнне аңлатырга тырышып кычкырып-кычкырып әтисенә байтак әйтеп маташты. Тик бабай аңламады ахрысы. Әһәмияте булмады. Чәй эчәргә утырыштык. Нурый абый сөйли:

—Безнең ишегалды аркылы авыл инеше ага. Мин шуны будым да корбан балыклары җибәрдем. Буа ярында эскәмия бар. Көн җылы булса, шунда алып чыгып утыртабыз әтине. Балыклар йөзгәнне икешәр-өчәр сәгать карап утыра. Өйлә чәен эчә дә тагын «прогулкага» чыгып утыра. Аллага шөкер, күзләре әйбәт күрә. Бу юлы умарта корты янындагы икенче эскәмиягә утыртабыз. Тагын утыра шунда кортларның умарта эченә кергәннәрен, чыкканнарын, очканнарын карап. Тимиләр кортлар, чакмыйлар. Алар да өйрәнделәр әтигә.

Килене Зөләл апа үзенекен өсти:

—Бик күңелле алар белән яшәве. Дүрт бала үстердек—бар да читтә, төрле

калаларда яшиләр. Кунакка кайтып-китеп кенә йөриләр оныклар белән. Әти белән әни безгә хәзер балаларыбыздан да артык. Холык ягы белән икесе дә сабый балалар кебек инде алар. Үзләре бик тә сабыр.

Күрдем. Утырдым. Чәй эчтек. Китәргә дип Кәшшафетдин бабай белән хушлашам. Кочаклыйм азрак. Көтмәгәндә карлыкканрак тавыш белән акрын гына итеп әйтеп куймасмы.

—Кирч крипычы. Капитан Бульон. Лотфулланың төпчек улы бит син.

Күкрәктә йөрәк янына жылы йөгерә: таныды бит! Керчь кальгасы—Кәшшаф бабайның солдат хезмәте, әти—солдат дусты. Ә батарея капитаны Бульонны исендә тотуның да сәбәбе бар. Капитан рядовой Кәшшафетдин Гималетдиновны урысча әйткәнне анламаган өчен йодрыклап сугып, берничә мәртәбә «урыс теле анларга» өйрәткән. Бульон Кәшшаф бабай хәтерендә йодрыклы капитан булып үлгәнче исендә калган...

Әтиемнең солдат дусты Кәшшаф бабай, улы Нурый, килене Зөләл карамагында тагын өч ел яшәп, 98 яшендә бу дөньядан мәнгелеккә китте. Бик оста пима басучы, зур куллы, киң урынлы саңгырау бабай иде. Карагыш мишәр авылында жирләнгән. Урыны ожмахта булсын инде. Аллаһы әкбәр!

...Өч айга якын Лотфулла Зәйнуллин наводчиклык һөнәренә өйрәнә. Николай Каммозев дигән Тверь карелы өйрәтә аны наводчик һөнәренә. Башта Каммозев бер кәгазь битенә пушка атканнан соң чыгып очкан снаряд траекториясен төшерә. Снарядның очу траекториясе көянтә кебегрәк кәкре була икән. Һәм аның еракка очуы снарядның пушка стволыннан чыккан тизлегеннән, көпшәнең озынлыгыннан һәм горизонтка карата нинди почмак ясап күтәреп куюыннан тора икән.

Николай Лотфуллага елмаеп карый:

—Әйдә, һавага чыгыйк. Мин сина снарядның очкан юлын—траекториясен күрсәтәм.

Чыгалар. Николай, булачак наводчикны крепостьның Керчь каласы ягына караган дивар янына бастыра. Кулына бик зурдан булмаган бер таш ала. Аны кулында сикерткәли дә, Лотфуллага күрсәтә:

—Менә бу таш—снаряд ди. Мин кулны аска салындырып артка бирәм дә, кулны өскә селтәп ташны һавага ыргытам.

Николай селтәнеп ташны һавага ыргыта. Лотфулла карап торган якта тып-тын яткан зәңгәр төстәге дингез иде. Шул зәңгәр төстә ташның очканы бик ачык күренә иде. Ташны бер ыргытуда ук Лотфулла «траектория полета снаряда» дигән сүзләрне аңлап ала. Алай ик-ән! «Траектория» икән таш очуы да. Һәм снаряд аткач һавадан туп-туры очмый икән—ул «траектория» буенча оча икән.

Кәшшафетдин кайтып киткәннән соң, Керчь кальгасы артиллерия гарнизонында Лотфулла татарлардан үзе генә торып калды. Урысча ярыйсы гына сукалаганнан, аларча укый-яза белгәч, инде наводчиклыкка күчеп, «прицел», «траектория», «учреждение», «перелет», «недолет» дигән артиллерия терминнарын өйрәнеп, аларның мәгънәләренә төшенеп, Лотфулла белем һәм һөнәр ягыннан бик нык үзгәрә башлады. Капитан Ростунов өйрәткән пушка серләренә төшенеп, «учебная пушка»дан ата башладылар. Пушка янына чыгып, аңа тотыныр алдыннан Лотфулла атнадан артык пушканың прицелын өйрәнде. Дингезгә караган ун як капка башына салынган һәм «Будка прицела» дип аталган кирпеч бина эчендә «Дальномер», «Угломер», «Панорама» дип аталган бик тә катлаулы—атканда туры тидерер өчен траекторияне исәпләп чыгарыр өчен кулланыла торган артиллерия приборлары куелган. Наводчик булачак ярыйсы гына белемле жиде яна солдатка капитан Ростунов шул приборларның төзелешен сөйләде

һәм исәп-хисап уздырыр өчен алар белән ничек эш итәргә кирәклекне бик җентекләп күрсәтте. Солдатларны берәм-берәм шул дальномер, угломерлар, панорама артына утыртып исәп-хисап ясатты, аларның башын эшләтте, хисаплатты.

Тәүге атна-ун көндә Лотфуллага бик авыр булды. Авылда тархан Гадкадыйр Тукаевның дүрт үгез җигелгән ике агач тәгәрмәчле тимер сабаныннан башка «механизм һәм прибор» күрмәгән, татардан чыккан ялчы егетнең, заманы өчен иң алдынгы пушкалар һәм механизмнар белән коралланган Яр артиллериясе крепостена хәрби хезмәткә килеп эләгеп, наводчиклыкка өйрәнә башлавы үзе бер могҗиза иде.

Дуңгыз ите белән килеп чыккан ыгы-зыгыдан соң капитан Бульон рядовой Зәйнуллинны пушка урнашкан, томаланган зур «Орудейное помещение» дип йөртелгән махсус бүлмәгә алып керде. Орудие кормасындагы диварга беркетелгән бер тимер ишекне ачты. Анда кечкенә бүлмә күренде. Бу—капитан Бульонның кабинеты иде:

—Кер, Зәйнуллин! Утыр! Сөйләшик!

Утырыштылар. Бульон үзенең эш өстәле артына кереп утырды. Бүлмәдә тәрәзәләр юк. Һава алмаштырыр өчен аш тәлинкәсе зурлыктагы, тышка—диңгез ягына чыга торган түгәрәк бер тишек кенә бар. Өстәлнең сул ягында бернечә бүлектән торган агач шкаф. Китаплар куяр өчен махсус ясалган ахрысы. Бүлекләргә төрле калынлыктагы, төрле зурлыктагы китаплар тезеп куелган. Капитан күнеллеләнгән коңгырт күзләре белән өстәлнең уң ягында басып торган Лотфуллага карады. Азрак кына елмайды да, сүз башлады:

—Менә нәрсә, Зәйнуллин. Полк командирына син минем өстән жалу белән кергәнсең икән.

Нәрсәдер әйтергә теләгән Лотфулланы сул кулын азрак күтәрә биреп туктатты.

—Утыр менә шушы урындыкка.

Солдатны утыртты.

—Соңрак әйтерсең сүзенне. Мине тыңла башта. Әйдә, без синең белән килешү төзик сүз белән. Башкача бер-беребезгә кул күтәрмик. Мин үзем бик үк начар кеше түгелмен. Тик Порт-Артурда физически да, психологик-мораль яктан да бик нык ватылдым, изелдем мин. Шуңа әсирлектәге түбәнсетүләр дә өстәлде...

Дәшмичә, өстәл өстенә карап уйланып торды. Елмайды:

—Полковник миңа әйтте синең тәкъдимне.

—Син миңа әйтеп тор, мин татарча бердән унга кадәр сүзләр белән саннарны язып алыйм. Син полковникка әйткән метод эффективно булырга ошый. Баш миен эшләтә бит, чыннан да. Татар сүзләрен искә төшерергә тырышып, мидә киеренкелек тудыра. Әйдә, әйт, мин язам.

Алдына кәгазь салып, кулына каләм алды.

Лотфулла башлады.

—Урысча «один» или «единица». Татарча—«бер».

—Как, как?

—Урыс телендә йомшак «е» авазы юк. Безнеңчә «бер», «через «е» говорится: «бер».

Дальше, «два»—урысча, татарча—«ике»...

...

Соңгысы—«десять». Татарча «ун». Иң жинеле инде монысы—«ун».

—Ун! Ярар,—диде Бульон.—Син, Зәйнуллин, әйдә, бердән унга кадәр кабаланмый гына һәрбер авазны ачык итеп әйтеп санап чык.

Лотфулла санарга тотынды:

—Бер, ике, өч,... тугыз, ун.

—Тугыз, ун! Так, так! Тугыз, ун! Хорошо! Тугыз, ун! Ну-ка, тагын бер тапкыр сана әле.

—Була ул. Бер, ике,... тугыз, ун.

—Һм! Тугыз, ун! Тугыз, ун. Бик матурдыр сезнең телегез, ә, Зәйнуллин?

—Андый матур тел башкача юк, господин капитан. Ә жырла-ар искиткеч!..

Азрак икеләнеп торды да, өстәде:

—Сезгә ярарга тырыша Зәйнуллин дип уйлый күрмәгез. Татар жырлары белән сезнең украин жырлары гына ярыша алалар. Тик сезнең жырлар да, безнең татар жырларына житешә алмыйлар.

—Син каян беләсең безнең украин жырларын?

—Кичке аштан соң крепость ишегалдындагы юан тирәк төбендә украин солдатлары жыелып жырлыйлар. Күпләр алар—егермегә якын. Иллә дә жырлары матур инде!

Капитан Бульон татар сүзләре белән «бердән—унга» кадәр саннарны язып алганнан соң, бер генә очракта да рядовой Зәйнуллинга сугу түгел, авыр сүз дә әйтмәс булды. Шулай да солдатларга ике-өч тапкыр сукты. Берничә ай үтүгә, капитан Бульон солдатларга сугудан бөтенләй туктады. Тагын байтак көннәр үткәч, каршына честь биреп «строевой шаг» белән атлап килгән рядовой Зәйнуллинны полк командиры туктатты:

—Остановись, Зайнуллин! Хезмәт ничек бара?

—Яхшы, господин полковник!

—Пушкадан атасыңмы? Тидерәсеңме?

—Атам! Тидерәм! Капитан Ростунов бик риза миннән. Рәхмәт сезгә!

—Капитан Бульон өчен сиңа рәхмәт, Зәйнуллин. Син өйрәткән унга кадәр татарча санау белән ул бит, чын-чынлап төзәлеп килә. Баш авыртуы да ныклап кимеде ди. Төсе дә яхшы якка үзгәрде аның. Рәхмәт сиңа.

—Әйбәт, алай булгач, господин полковник.

—Әйе, әйбәт.

Бульонның хәлен аңлатты.

—Өч баласы бар аның. Зурысына сигез генә яшь. Гимназиянең беренче сыйныфына укырга китте. Ә кечкенәсе өч айлык кына. Капитан каты авырып китсә, ул балаларны карарга башка кеше юк.

—Бәлки ярдәм кирәктер.

—Син ничек ярдәм итә аласың инде аңа, солдат?

—Нигә ярдәм итмәскә, ди. Мичкә ягар өчен утын кисәргә, ярырга, ташырга. Бәлки йорт эшләре бардыр. Аннан бит мин бик яхшы балта остасы да...

—Эшләргә денщигы бар аның. Рәхмәт сүзеңә. Хуш.

Честь бирде дә, полковник китеп барды.

Ә өч көн узгач рядовой Лотфулла Зәйнуллинны каравылда торганда килеп чыккан вакыйга өчен гауптвахтага утырттылар.

Разводящий унтер-офицер Озеров аны постка алып барып, сакка куйды. Сакчы ул сакчы инде. Кулда, патроны патронникка жибәрелгән кыска артиллерия карабины. Бил каешында—тесак, өстә—шинель, аякта—итек, башта—козырексез түгәрәк «блин». Йөр постта, кара, тыңла, берәүне дә якын жибәрмә. Тик разводящий белән сак начальнигын гына кертергә ярый постка.

Төнге сәгать бер үтеп, вакыт икенчегә киткән иде. Склад алдында гына, тонык кына булып бер генә электр лампасы яна. Ә биш-алты метр читтәрәк исә дөм-караңгы, бернәрсә дә күренми. Өстәвенә, сентябрь төне болытлы, жилле һәм юеш. Янгыры юк, тик Кавказ ягыннан диңгез аша искән салкын

җил күп итеп дым алып килә. Җил сөякләргә кадәр үтеп, тундыра. Җил тавышыннан башка бер ят тавыш та юк иде. Алмашынырга байтак вакыт бардыр әле—сәгатьтән артыграк дип уйлады часовой. «Туңдыра башлады, ә җылынам дип йөгерергә ярамый. Часовой бит». Шул уйларны өзеп складның уң ягында, тәбәнәк кенә итеп чәнечкеле тимерчыбык сузган якта, кемнеңдер мышный-мышный пост ягына килгәне ишетелде. Часовой муенын суза биреп, колакларын торгызып, тыңлады. Чыннан да, берәү постка керең килә. Үзе мышный, үзенең аяк тавышлары да ишетелгәндәй була өстәвенә. Часовой «Устав артиллерийской службы»ны исенә төшерде:

—Стой! Кто идет?!

Теге һаман килә бит! Җавап бирмичә һаман мышнап килүен белә. Үзе төн караңгылыгында күренми дә бит әле ул. Тагын бер кычкырды Лотфулла:

—Стой! Кто идет?!

Җавап тагын юк.

Устав таләп иткәнчә икенче төрле итеп кычкырды:

—Стой! Стрелять буду!

Туктарга уйламый да, «мышный-мышный» килә һаман.

—Стой! Стрелять буду!

Тавыш килгән җиргә чамалап карабинын төзәде дә, часовой карабин курогына басты. Гарнизон тынлыгын бозып ату тавышы яңгырады. Аткан якта ыңгырашкан тавыш чыгарып зур гәүдәле берәү җиргә ауды. Мышнау да, атлау да тукталды. Карабинны яңадан корып, аткан ягыннан күзләрен алмыйча, нәрсәдер ишетергә тырышып катып калды. Тирә-як тып-тын иде.

Арттан, каравыл бинасы ягыннан, йөгергән аяк тавышлары ишетелде. Ике солдат ияртеп разводящий унтер-офицер Озеров караңгыдан килеп чыкты.

—Нәрсә булды? Кемгә аттың?

—Кем икәнен күрмәдем. Әнә берәү теге яктан постка керең килә иде. Мышнаганы, атлаганы ишетелде. Кычкырып карадым: «Стой! Кто идет!», «Стой! Стрелять буду!» Ә ул һаман керең килә. Тавышка карап бер аткан идем—егылды бугай. Керүдән дә туктады, кире дә китмәде. Инде мышнамый да. Киткәне дә ишетелмәде. Барыгыз, карагыз! Миңа посттан китәргә ярамый!

Бер солдатны сакчы янында калдырып, икенчесен үзе белән ияртеп, унтер-офицер Озеров, Лотфулла күрсәткән якка китте. Аз гына вакыт узгандыр, Озеров кычкыра:

—Зәйнуллин! Самсоновны үз урыныңа калдырып тор. Монда кил.

Барып җитәргә ике-өч адым кала, Озеров Лотфуллага, чиләк белән салкын су койган кебек итеп, «яңалык» әйтте:

—Син бит, дурак, полк командирының сыерын атып үтергәнсең. Идиот! Нишләтә инде ул безне иртәгә иртән? Ә?

Лотфулла җилкәсен генә җыерды:

—Белмим. Нәрсә эшләтсә дә эшләтер. Мин караңгыда күрмәдем ул сыерны.

—Полк командирына сөйләрсең боларны. Әйдә, киттек! Мин сине посттан алам. Самсонов кала синең урынга.

Каравыл бинасына кайттылар. Каравыл начальнигы разводящий докладын тыңлап бетерде дә, посттан алынган рядовой Зәйнуллинга боерык бирде:

—Карабиныңның патроннарын ал. Патронташка сал да өстәлгә куй. Карабиныңны пирамидага урнаштыр. Бил каешыңны, чалбар каешыңны икесен дә сал, өстәлгә куй. Кесәңдәге барлык нәрсәләрне өстәлгә бушат.

Кульяулыгыңны гына калдыр... Булса.

Господин полковник сине иртәгә сыерын аткан өчен нәрсә эшләтер? Белмим. Ләкин башыңнан сыйпамас дип уйлыйм мин. Ә хәзергә, иртән полк командирына доклад ясаганчы, мин сине гауптвахтага утыртам! Һәм син инде аннан 15—20 тәүлексез чыкмассың дип уйлыйм.

Кырыйдарак басып торган унтер-офицер Озеровка ымлады:

—Ябып куй гауптвахтага, аерым камерага! Хәзер үк.

Озеров Лотфулланы гауптвахтаның бер генә сәкеле камерасына япты да, чыгып ишекне шалтор-шолтыр китереп бикләп алды.

«Бирде, Ходай! «Гауптвахта» дигәннәрен дә күрдек... Урыс патшасына хезмәт итә-итә, безнең татар башына тагын ниләр төшәр?»

Чишенеп тормады, итекләрен генә салып идәнгә куйды да, сәкегә менеп ятты. Мендәр, юрган кебек нәрсәләр юк инде ул. Тик ике иске шинель генә диварда эленеп тора иде. Үзенең шинелен баш очына салды. Теге иске шинельләрнең берсен астына җәйде, икенчесен өстенә ябынды. Гапкадыйр Мәгъзүмгә яз көннәрендә сабанда йөргәндәге сыңар мөгезле кызыллы-аклы зур үгез күз алдына килде. Арыса буразнага ята иде дә, күпме кыйнасаң да тормый иде. «Бармы икән әле дә! Шулай арыса, бүген дә ятамы икән?»

Үгезне исенә төшереп елмайды. «Ходай кушмаган эш булмас әле!» дип бисмилласын укыды да, тирән йокыга талды...

*Дәвамы киләсе санда*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Нәҗибә
Сафина

# КҮҢЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ

***

**Дөньяның сары сагышка**
**баткан мәлләре—көзме?**
**Бәгырьләргә ачы итеп**
**кадалганнары—сүзме?**

**Кайсылары ачырактыр,**
**көзге җилме, сүзләрме?**
**Авыр, авырдан да авыр—**
**мөлдерәмә күзләрме?!**

**Дөньяның моңнарга баткан**
**бар әле язгы мәле!**
**Каеннардан шуып төшкән**
**кыш ябындырган шәле...**

**Көзнең сагышлары ачы,**
**моңнары тирән язның.**
**Авыр, авырдан да авыр**
**табышы ялгыз казның.**

**Дөньяның моңга-сагышка**
**баткан мәлләре авыр.**
**Ул—кеше гомерләрендә**
**назларсыз үткән дәвер.**

## Көзге урман

**Шәрә тирәкләр гаскәре**
**Сары диңгездә йөзә.**
**Төйнәлгән бөреләр инде**
**Кышның сулышын сизә.**

Нәҗибә САФИНА—*шагыйрә, публицист, «Таң кошы», «Без—шигырь, тормыш—проза», «Кан хәтере» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Соңгы яфраклар җилсез дә
«Келт»итеп өзеләләр.
Соңламыйк китәргә диеп,
Кошлар да тезеләләр.

Гөмбә ташый әле керпе,
Тиен куыштан карый.
Яфраксыз тирәк чирүен
Салкын җил генә тарый.

## Умырзая белән сөйләшү

—Умырзая! Сиңа дәшәм:
Син ник кыска гомерле?—
—Вакыт белән санамыйлар
Гөл илендә гомерне.

—Умырзая! Син ни өчен
Салкын язда туасың?—
—Кайсы бала белә икән
Кайсы мәлдә туасын...

—Умырзая! Ә ни өчен
Калмыйсың җылы җәйгә?—
—Мин—умырзая, хисләрне
Тота алганга бәйдә...

## Сөю качса

Синсез килмәс инде бу Яңа ел,
Туктап калыр Вакыт,—
Дигән идем, җанга шакып китте
Бер адашкан шатлык!

Әй, кузгалды күктә ак болытлар,
Коелалар карлар.
Иңнәренә ап-ак карлар төяп,
Сөенешә парлар.

Алар өчен бар да шатлык кына,
Хәтта үткән Вакыт...
Сөю качса, җанга керә алмый,
Елап йөри шатлык.

## Әлегә башкача шул

Бу дөньядан кеше булып китәм,
Мин ни булып кабат кайтырмын?
Мин, мөгаен, җирнең бу йөзенә
Бер калкулык булып ятармын...

Ул калкулык үсәр дә тау булыр,
Кыя үсеп чыгар ташлардан:
Җан-ташларны буйсындырмак булып,
Югарыга үрли башлардар...

Чәлпәрәмә тагы таш кителер,
Кеше тагы түбән тәгәрәр.
Күтәреләм диеп төшүләрнең
Бәһаләрен белсәкме әгәр...—

Без беркайчан таулар булмас идек,
Җаннар катмас иде таш булып.
Кеше бер дә ләззәт тапмас иде
Кеше башларына баш булып...

***

Буучыга алтын кирәк,
Буылганга—һава.
Алтын сулап яшәп булмый:
Буучы да ава....—
Тау кадәр алтын булалмый
Бер әҗәлдән дәва.

***

Акылы белән югары
Түбәндәрәк тора...—
Хикмәт нидә икәнлеген
Тамырлардан сора.

***

Бала туа, тибрәтергә җыр кирәк.
Ә бераздан тәпи басар җир кирәк.
Кеше китә, озатырга—дога-җыр,
Кирәк—Мәңгегә баш салыр соңгы җир.

***

Дөнья—фани, җан—мәңгелек,
яралса...
Агартырга мөмкин түгел,
каралса.

***

Изге анам, Туган җирем,
Туган телем, Туган ил,—
Кешем, шул рухи дүрт саның
Исән булса, бәхет шул.

***

Оран салдым, көтеп тордым—
аваз кайтмады.
Әллә аваз да баш салыр
урын тапмады?

***

Дөньяга әйтсәң үз сүзең—
Ачачак сиңа йөзен.
Дөньяга каш җыерсаң,
Аш түгел, таш җыярсың.

***

**Йөрәк ритмнан язса,**
**Яшәү бетә.**
**Яшәү шигырь түгел диеп,**
**Йә, кем әйтә?**

***

**Икәүдән икәү—бер өйдә**
**Җырласалар ике көйгә,**
**Төпсез дәрья эчендә дә**
**Комга терәлә көймә.**

***

**Җанында кабынса**
**Чын шигырь очкыны,**
**Яндырып бетерер**
**Гамьсезлек юшкынын.**

## Яшьләргә

**Ашыкмагыз китәргә.**
**Алда язлар, сезгә кала**
**Дөньяны гөл итәргә.**

***

**Хыяллары биегрәк**
**Булган кешенең**
**Вак-гөяк гөнаһы булмый**
**Кылган эшенең...**

***

**Тирәкләр—тартылган**
**гитара.**
**Кешеләр шунда да**
**битараф...**

***

**Тарих—күк баскычы.**
**Ә тел—җан ачкычы.**

## Чын яшәү өчен

**Бернәрсә дә кирәк түгел,**
**Кирәк ярату гына:**
**Хисләреңне бар дөньяга**
**Сөеп тарату гына.**

***

**Карьера**
**вөҗданны каера.**
**Карьера**
**халыктан аера.**



Дамир
Гыйсметдин

# БОЖРА БУЙЛАП

БӘЯН

Поезд, тизлекне арттыра-арттыра, Мәскәү ягына җилдерә. Җәйге көн бераз сүрелгән, вагонда җиләс... Ачык ишек, тәрәзәдән поезд тәгәрмәчләре текелдәве ишетелә. Ходайның рәхмәте, Марат дүрт урынлы купеда берүзе генә бара. Күрәсең, бу чорда халык әле дәррәү чемоданнарга ябышмаган. Май гына бит әле!.. Шөкер, сәфәрләр унды дип әйтеп була. Күз алдына янә Киевның манзаралары килеп басты. Үзе монда утырса да, Маратның күңеле, әле генә елашып-җырлашып аерылган эчкерсез милләттәшләре белән, Киев вокзалында калды... Биредәге татарлар милли җыр бәйгесен юкка гына каштаннар чәчәк аткан иң матур чорга куймаганнар. Тарихи шәһәр, мәһабәт биналар, күз явын алырлык алтын манаралар, купшы чиркәүләр...

Афәрин! Чал Днепр өстендә ике көн рәттән татар-төрек моңнары яңгырап торды. Бер-берсен сагынган, җырга-моңга сусаган халык җәелеп китеп бәйрәм итте. Фестивальне оештыручылар, рәхмәт төшкерләре, илленең өстенә чыккан Марат Сабиров кебек, дөнья гизеп, мунча ташы кебек шомарган журналистны да шаккатырды. Димәк, яши әле татар! Казаннан еракта да... Хәтта чит илләрдә дә...

...Ачык купеда кинәт «ирләр, рәхим итегез!» фасонында киенгән утыз яшьләр тирәсендә мөлаем хатын-кыз пәйда булды. Аның кулында эчемлек-ашамлыклар төялгән зәңгәр пластик кәрҗин иде.

—Исәнмесез! Сезнең ашарыгызга да, эчәрегезгә дә җитәрлек икән, тик безнең ризыктан да авыз итегез инде! Безгә дә бит план тутырырга кирәк!..—Шул сүзләрдән соң буфетчы хатын, күзләрен шаян уйнатып, кыска итәкләрен төзәткәләгән булып аларны тагын да күтәрә төште һәм Маратның каршына ук кереп утырды. Авыз суларыңны китерерлек тыгыз ботлар тагын да ачылды, үз-үзен бик иркен тоткан сөйкемле ханым-туташ нәрсәдер туктаусыз сөйләнде...

Дамир ГЫЙСМЕТДИН (1949)—*шагыйрь һәм прозаик; «Әйтсәм әйтим», «Атта да, тәртәдә дә», «Өметсез шайтан», «Кая ашыгырга?..» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Матур ак тешләр... Юка, зәңгәр, ярымачык майка астыннан сыешмый, бәреп чыгарга торган ике тулы зур алмалы түш, кояш нурларын мул сеңдергән тән, шоколад исе аңкып торган куе, аксыл-сары чәчләр, зифа гәүдә, төз аяклар... Маратны шайтан кытыклап алгандай булды. Гөнаһка кертә бит, пумала баш! Әшен яхшы белә, шельма! Шунда әсәрләнеп китә язган Марат тиз генә үз-үзен кулга алды. Очраган бер чибәргә мөкиббән китсәң—тирәнгә кереп батырсың, Сабиров!.. Чая хатын ул арада, үзенчә гөрли-гөрли, өстәлдә торган затлы эчемлекләрдән авыз итәргә дә, берничә шәлперәйгән апельсинны пассажирга яхшы бәһадән шуытып калдырырга да өлгерде.

—Ну, ярар,—диде сәүдә кешесе, ниһаять, урыныннан күтәрелеп.—Сез бик күркәм адәм, турысын әйтим: күңелемә хуш килдегез... Күреп торам, бераз алҗыгансыз да... Сезгә минә минем назлы куллар житми!—дип официантка кыз кинәт Маратка сарылып, тыгыз түшләре белән ышкылып, куллары белән аның чал кергән чәчләрен сыйпап алды. Ир затын янә ток суккандай булды.— Берүзеңә күңелсездер дә... Кыскасы, абзыкай, мин Харьковтан соң таможняны узгач, сиңа кунакка киләм...Үзеңне кеше итәрмен... Чао! Ишегеңне бикләмә!..

Пассажир, мондый көтелмәгән тәкъдимне ничек кабул итәргә белмичә:

—Ярый, ярый,—дип буфетчы ханымны елмаеп озатып калды.

...Поезд яшел урманнар, күлләр, нинди дер бәләкәй һәм зур станцияләрне артта калдыра-калдыра, Мәскәү ягына элдертә бирде. Эх, жегетләр, заманалар—баганалар... Әйтергә кирәк, гомер кояш баешына авышкан дәвердә, кеше ялгыз калдымы, уйлана башлый. Бигрәк тә ир халкы... Иң тирән уйланулар Маратны нишләптер менә шул поездга утыргач билəп ала. Уй-фикерләр кайларга гына алып китми... Үткәннәр, яшь чаклар, киләчәк... Сораулар—җаваплар, табышмаклар, хатирәләр... Гомер уза, ә безләрдән нәрсә кала соң? Нинди эзләр, нинди гамәлләр?.. Безнең заман кешеләрен яңа буыннар ничек искә алыр? Безләргә бит хөкүмәт карарлары белән һәйкәлләр куймаслар...

...Тәгәрмәчләр келтер-келтер тәгәри дә тәгәри, уй-фикерләр йомгагы сүтелә дә сүтелә...Әйе, Марат еш кына яшәүнең мәгънәсе, дөньяның кайдан килеп, кайларга баруы хакында бик житди уйлана. Кайчагында кирәгеннән дә артык! Ә бит кеше үзе дә табигатьнең серле сандыгында сакланган табышмакларның берсе.

Заманында кайсыдыр редакция кушуы буенча Марат бер танылган галим белән бик кызыклы әңгәмә корган иде. Аның фикеренчә, кеше—бу дөньяның иң зур сере. Галим-голәмә киләчәктә дә адәмнең асылына төшенә алмаячак. Ул чакта мөхтәрәм профессор һәр кешедә дүрт кеше яши дигән фикерен алга сөргән иде. Янәсе, Ходай Тәгалә кешене дүрт сүрүдән (энергиядән) дәрман туплап яраткан. Кешенең бер сүрүе уттан (утта вакыт энергиясе), икенчесе—җилдән, өченчесе—судан, дүртенчесе—җирдән. Гыйлем иясе үзенең теориясен шул дәрәҗәдә мавыгып, хисләнеп, һәвәсләнеп сөйләгәнгә күрә, аны ни туктатып, ни бүлдереп, ни төпченеп тору мөмкин түгел иде. Марат ул чакта ике кесә блокнотын язып тутырды. Профессор Вакыт дөньясын, Эфир дөньясын, Су дөньясын, Тыгыз дөньяны бергә бәйләп, яшәүнең асылын үзенчәлекле мантыйк калыбына, нинди дер формулага салып аңлатырга тырышты. Әйе, һәр акыл иясенең үз дөнъясы бар. Күп очракта ул—бик чуар фикерләрдән торган ифрат катлаулы, каршылыклы, хикмәтле виртуаль дөнья. Аны аңлау—гади нәрсә түгел, җәмәгать! Күпләр өчен ул чытырманлы урманнарга компассыз бару белән бер.

Ә профессорга килгәндә, аның монологын йорты каршындагы колачлы

имәнне кинәт яшен сугу гына туктатты. Тәрәзәләр зыңгылдап китте, җир чайкалып алды.

Марат, каударланып, ишек-тәрәзәләрне яба башлады. Ә профессор, киресенчә, күзлеген салып, залдагы зур тәрәзәне шыр ачып җибәрде, кулларын офыкка төбәде һәм нииндидер канәгатьләнү белән:

—Менә бу, ичмасам, көч! Нинди тылсым! Энергетика!.. Курыкмагыз, яшь дустым! Без—Хак Тәгаләнең бер кисәкчеге.—Кинәт урысчага күчеп—Сужденному утонуть—молния не страшна!—дип кычкырды.

Балачактан күк күкрәүләрдән, яшеннән шүрләп калган Марат, авыз эченнән генә белгән догаларын укыды. Соңрак табигать тынычланып, елмаеп кояш чыккач, интервью дәвам итте. Гыйлем иясе дөнья серләрен чиште дә чиште.

—...Ходай кодрәте белән адәмнең энергетик дәрманы яшерелгән һәм аңа гади акыл ирешә алмый... Кешеләргә бер-берсенә сихер яки психик энергетика аша тәэсир итүне өйрәтергә ярамый. Кәтигәрически! Бу, яшь дустым, куркыныч... Недопустимо!

Аура, карма, энергетика, эчке акыл белән аралашу, үзеңнең ихтыярың белән идарә итәргә өйрәнү омтылышы—мондый әкәмәтләр белән кызыксыну-мавыгу Маратта әнә шул яшеннән дә курыкмый торган акыл иясе белән сөйләшкәч башланды...

Берничә ел элек Төркиянең иң матур җиренә—Урта диңгез буена ялга баргач та Марат бик сәер хаста сыман нәрсә кичерде. Ул чын мәгънәсендә авыру да түгел иде. Көндезләрен юмарт кояш астында, гел үзенчә гөрләп-шаулап торган диңгез буенда рәхәтләнеп ял итәсең, йөзәсең, дөньяның тәмен, гүзәллеген тоеп ләззәтләнәсең, ә төннәрен—йоклый алмый интегәсең ... Нишләптер шундый җәннәти җирдә Маратның йокысы качты. Әйтерсең лә, нииндидер җанкисәр сине төннәрен бимазалый башлый. Кайчандыр, белепме-белмичәме кылган гөнаһлы гамәлләрең искә төшә. Йә тиктомалдан яшәү-үлем турында уйланасың, йә ярты юлда калган эшләр, йә вакытның ифрат тиз үтүенә борчылып, таңга кадәр керфек какмый әсәрләнеп чыгасың. Бераз гына черем иткән арада да әллә нинди шомлы, хәвефле төшләр күреп, шабыр тиргә батып уянасың.

Ә бит бу хәлләр тикмәгә генә булмаган. Казанга кайткач та Маратка кайгылы хәбәр ирештерделәр: Розалия юл казасына эләккән... Ике атна хастаханәдә аңсыз яткач, фани дөньядан китеп тә барган. Менә бит ул дөньяның хикмәте!.. Казанда булган аяныччлы хәл ерак Анталиядә ял иткән Маратны, димәк, юкка гына бимазаламаган... Нәкъ ике атна!.. Һай, Розалия җаным, үкенечле булган икән язмышларың!.. Марат бу гөнаһлы мәхәббәтнең трагедия белән тәмамланачагын сиземли иде шул. Ә бит Розалия очрашкан саен:

—Мин, Марат лачынкаем, бәхетле!—дип әз генә булса да керфек чылатып ала иде...

—Үзең бәхетле, дисең, үзең тиктомалдан тагын почыкланасың!

—И-и, бигрәк беркатлы инде син... Җитмәсә ә-әле журналист, психолог, бокс-борын! Кеше холкына ачкыч табучы, имеш! Беләсең килсә, хатын-кызның күз яшьләре керфек очында гына эленеп тора ул! Без шундый инде: җил иссә дә, кояш балкыса да яулык чылатабыз... Мин бәхетле, җаныем, син булганга... Шуңа шатланам... Януларым-көюләрем дә сиңа бәйле... Сине югалтудан куркам мин...

Сизенгәндер сөйгән җан... Әйе, Марат белән алар соңрак очраштылар шул. Гөнаһлы мәхәббәт булды ул. Марат та гаиләле, Розалия дә—балдакланган аккош. Нишлисең, шулай килеп чыкты инде...

Марат беркайчан да хатын-кызлар артыннан исәрләнеп, башын югалтып

йөрмәде. Юк, бу ниндидер тәкәбберлек түгел, ә егетнен үз кагыйдәсе иде. Гәрчә анын кебек, ягъни туганда ук фәрештәләр һәрьяклап үпкән сөйкемле ир-егетнең толым ияләренә өстәнрәк каравы дөньялыкта сирәк очрый торган нәрсә түгел. Монда эш башкада иде. Маратка әтисе үсмер чактан ук әйтә килде: «Хатын-кызлар артыннан башынны югалтып йөрмә. Ир иткән дә хатын, жир иткән дә... Алар белән сак бул! Бернәрсәне онытма: бирим дигән колына—чыгарып куяр юлына! Сиңа дигәне —сиңа булыр, беркая да китмәс.. Аларның артларыннан селәгәенне агызып йөгерергә кирәкми!..»

Теләсә-теләмәсә дә, шул киңәшләр Маратның башына нык сеңгән иде. Житмәсә, атай бу мәсьәләләрдә үзе дә сыната торган кешеләрдән түгел.

...Күз явын алырлык чибәр Розалия белән алар Казанның иске аэропортында августның жилле-яңгырлы бер көнендә очраштылар. Бөгелмә рейсы ике сәгатькә тоткарлангач, Марат тамак ялгап алырга дип ресторанга керде, буш өстәл артына утырды. Бердәнбер клиент булгангамыдыр, официант озак көттермәде. Ул елларда жәмәгать туклану челтәренең абруе ишек сакчысы, официант, администратор кебек гади хезмәткәрләргә нык бәйле иде. Алар сине ресторанга йә бөтенләй якын жибәрмәскә, йә кичәге котлетны ашатырга, йә милиция чакыртып айныткычка озатырга да күп сорамыйлар иде. Шуңа да биредә тормыш күбрәк язылмаган кагыйдәләр нигезендә бара. Һәм ресторанда эшләгән швейцар, официант кебек адәм белән танышлык йөртү кешенең яшәвен беркүпме жиңеләйтә дә иде.

Сәвит чорында кафе-рестораннарда, гадәттә, буш урыннар булмый иде. Булган очракта да кешеләрнең аерым-аерым өстәл артына утыруларын нишләптер бик өнәмиләр иде. Әллә ресторан хезмәткәрләре артык адым ясарга теләмәгән, әллә сәвит кешесен коллективтан аеруны хуп күрмәгәннәр...

Шул арада кинәт ресторан яктырып киткәндәй булды. Залга, төз-төз басып, алиһәдәй жан иясе килеп кермәсенме?! Кыяфәте, буй-сыны, кигән киемнәре, үз-үзен тотышы чибәркәйнең, чыннан да, гади генә адәм затыннан түгеллеген раслап тора иде. Официант, озак уйланырга ирек бирмичә:

—Молодой человек, можно я посажу эту девушку рядом с Вами?— диде.

Калфаклы кызның мондый соравы Маратка бөтенләй урынсыз, сәер тоелды.

—Әлбәттә!..

Танышу өчен моннан да кулай форсат буламы инде тагын, жегетләр!

Марат бу гамәлне, әлбәттә, күкләр тарафыннан тәгаенләнгән дип кабул итте. Һәм ялгышмады.

Алар бәләкәй самолетта бергә очтылар. Юл газабын бүлешкән кешеләр бик тиз уртак тел таба. Марат белән Розалия ачыктан-ачык сөйләшеп, танышып киттеләр. Очкыч һава «чокыр»ларына эләккәндә Розалия «һай!» дип кайнар кулы белән Маратның кулына ябыша, бите белән иненә елыша... Курка, янәсе... Житмәсә, кинәт һава үзгәреп, көчле жил чыккач, очкыч беркүпме болытлы күктә кәгазь уенчык кебек бөтерелә башлады. Розалия күзләрен йомып, Маратка чытырдап ябышты. Анын кайнар сулышы, тыгыз күкрәкләре, язгы шомырт чәчәкләре исе аңкып торган куе коңгырт чәчләре юлдашын тәмам исерткән иде. Марат очкычнын бу халәттә озаграк интегүенә бер дә каршы түгел иде. Бераздан, ничектер исән калган самолет, Бөгелмә урынына Бигешкә төшеп утырды. Розалиянең Чаллыда таныш-белешләре булмаганга, Марат якташы, буйдак Хәлилгә шылтыратты. Ул өендә булып чыкты. Күп тә үтмәде, Казан кунаклары Хәлилнең ике бүлмәле фатирына кайтып төштеләр. Марат бу уңайлыкны да күкләр тарафыннан

фатихаланган гамәлдер дип кабул итте.

Танышу-күрешү хөрмәтенә бер-ике рюмка күтәргәч, Марат фатир хуҗасының Розалиядән күзен алмавына игътибар итте. Аңлашыла ки, үз гомерендә әллә күпме хатын-кыз күргән Хәлил бу юлы кәртинкәләрдән төшкән илаһи затка чын-чынлап мөкиббән киткән иде. Ничек тә булса Розалиягә ошарга тырышып, ни генә эшләмәде бу кичтә чәчләренә чал төшкән буйдак. Фокуслар да күрсәтеп карады, яттан шигырьләр сөйләде, анекдот-мәзәкләр сипте. Ләкин Розалия, әллә әдәп саклап, әллә тыйнаклык күрсәтеп, Хәлилнең бу кыланышларын елмаеп кабул итсә дә, аның Маратка әледән-әле серле караш ташлап алулары: «Соң син кайчан талантларыңны күрсәтәсең, дустым?»—дигәнне аңлата кебек иде. Марат түзмәде:

—Хәлил дус, ялгышмасам, заманында синдә баян да бар иде кебек?—дип сорап куйды. Хәлил бер мәлгә югалып калды, чөнки баян инде ничә ел шкафта тик ята. Ник дисәң, баян, кем әйтмешли, аның өчен тумаган... Ә бәлки ул баян өчен яралмагандыр... Ара-тирә Марат бу якларга барып чыккач кына, шкафтагы инструментка җан иңә, ул телгә килә иде.

Ә инде Маратның итәгенә менеп кунаклагач сипте баян моңнарны. Җитмәсә, Розалия дә җырга-моңга хирыс кеше икән... Ул Маратка кушылып, үзенең моңлы тавышы белән халык көйләрен башкаргач, Хәлил бераз боегып калды. Юк инде, юк, аңа Ходай мондый талант бирмәгән!.. Марат җилкәләрен сикертә-сикертә, инструментның бөтен мөмкинлеген кысып чыгарды. Аннары аягүрә басып, үзе яраткан «Олы юлның тузаны»н бик моңлы, суза-суза, елатырлык итеп җырлап, чыгышына матур нокта куйды. Розалиянең зур кара күзләре дымланган иде. Ул кул чабып Марат янына килде һәм аны ихластан үбеп алды. Бу мизгелдә аның ялтыраган күзләре сокланудан тагын да матуррак күренәләр, янәсе, мин, бәгърем, сине шундый талантлыдыр дип уйлаган идем шул...

Ә Хәлил мондый борылышны көтмәгән иде. Күз явын алырлык гүзәл Розалияне күргәч, ул бүген үк, шушы кичтән калмыйча, ничәмә еллар чишәлмәгән мәсьәләне хәл итәргә карар кылды. Нокта куярга—вәссәлам! Әйе, бер белмәгән хатын-кыз, бәлкем яраткан кешесе дә бардыр... Ну бит чәнечкесе йөрәкнең иң уртасына кереп кадалды! Менә шулдыр инде ул бер күрүдә гашыйк булу дигәннәре!.. Маратка нәрсәгә гыйшык-мыйшык уйнарга?! Менә дигән хатыны, баласы бар... Атлаган саен хатын-кызлар аның муенына асылынырга гына тора. Юк, бу юлы Хәлил чигенмәскә тиеш! Марат аңлар!..

Мәҗлес тәмамланыр алдыннан Хәлил, Розалиягә савыт-сабаны җыештырырга ярдәм итәргә кушты да, Маратны балконга чакырды.

Сүзне ничек башларга белми азаплангач, Хәлил кулын селтәп, турысын ярып салды:

—Әйт дөресен, сиңа бит Розалия чираттагы уенчык кына, шулай бит?!

—Турысын әйтим—мин дә аңар гашыйк булдым... Тик, Хәлил дустым, хатыным, бала турында сөйләп вакыт уздырма...

—Йә, шулай ди... Дальше что?!

—Вакыт күрсәтер...

Хәлил, кабынып китеп, Маратның изүенә ябышты:

—Син яхшы беләсең: кырык тула бит миңа! Төпләнергә телим! Туйдым бу ялгызлыктан, зимагурлыктан!..

Марат Хәлилнең кулларыннан ычкынып:

—Тынычлан!—дип кычкырды.—Бу дусларча сөйләшү түгел! Гафу, без, алайса, кунакханәгә китәбез!..

—Калдыр син Розалияне! Алла хакы өчен! Мәңге бурычлы булырмын!.. Калдыр! Син табарсың! Син—чибәр, син әнә нинди талантлы... журналист! Калдыр!..

Кызып киткән ике дус балкон ишегенең ачылып китүен дә, бүлмәгә Розалиянең чыгып басуын да сизми калганнар иде.

Марат Розалияне күреп:

—Син барысын да ишеттенме?—дип сорады.

Югалып калган кыз әкрен генә: «Әйе!»—дип пышылдады.

—Алайса, үз сүзенне өздереп әйт! Монда хәлләр шундый...

Хәлил шул мизгелдә Розалия каршына тезләнде:

—Мин сине яратам, Розалия, мин иртәгә үк язылышырга әзер!.. Син—минем соңгы көймәм!..

Марат нишләргә белмичә, йөзен чытып: «Мәнә сиңа бесплатный тамаша «Хәлил—Розалиябану!»—дип кенә әйтәлде.

Ниһаять, гауга чыганагы да телгә килде:

—Сез икегез дә менә дигән ир-егетләр!.. Ләкин... Мин кияүгә чыгалмыйм бит!

Хәлил аягына торып басты:

—Ә нигә?!

—Чөнки мин инде кияүдә!

Бүлмәдә тынлык урнашты. Беренче булып Хәлил телгә килде:

—Булса соң! Это не имеет значения! Һәрхәлдә минем өчен...

—Ә Марат синең өчен?—дип сорады кинәт Розалия, юлдашының күзләренә туры карап.

—Миңа да барыбер... Минем йокы килә, иптәшләр, сәгать төнге ике бит инде!..

Килеп туган хәл шахмат уенында еш очрый торган патны хәтерләтә иде. Марат Розалиянең бер бүлмәгә кереп ялгызы гына йоклавына каршы түгел иде. Башын югалта язган Хәлил бу очракта күрәләтә кунак кызын тотып көчләмәс бит инде!

Ләкин Хәлил көтелмәгәндә:

—Дустым, сез беркая да китмисез!—диде кинәт, фатир ачкычларын өстәлгә чыгарып салып.—Мин башны югалта язганмын... Гафу үтенәм... Онытa язганмын: сез бит кунаклар... Ял итегез... Тыныч йокы...

Хәлил элгечтән җиңел курткасын алып, тиз генә фатирдан чыгып китте.

—Бигүк яхшы булмады әле бу!..—диде Марат, балконга таба атлап.

Розалия Маратның юлына каршы чыкты.

—Кирәкми, Марат... Ул барысын да аңлады...

—Бөтен бәла синең чибәрлегеңдә , Розалия туташ!

Кыз, гаепсез сабый кебек, кара күзләрен тутырып юлдашына карады. Янәсе, ул бит аның гаебе түгел... Розалия түземлеген җуеп, Маратка килеп сарылды. Һәм кулы белән диварны капшап, утны сүндерде. Шул кичтә ике йөрәктә башка ут кабынды. Алар бу халәтнең ничек, нәрсә белән һәм кайчан бетәсен белмиләр иде...

***

Розалия белән Марат бер-берсен шашып яраттылар. Ул елларда аларның телефон аша әйтелгән мәхәббәт сүзләрен язып барып нәшер итсәң, «Кыйссаи Йосыф» китабы калынлыгындагы һәм иң мөһиме—шуның кебек үк йотлыгып укыла торган бер басма пәйда булыр иде. Ә инде һәр очрашуның онытылмас, ләззәтле вә кайнар мизгелләрен тасвирлар өчен атаклы Мопассан каләме кирәк булыр иде. Тик бу гыйшык тарихы ни хәтле мавыктыргыч булса, ул шул ук дәрәҗәдә мажаралы, мәшәкатьле һәм хәтәр иде. Чөнки гашыйклар, инде мәгълүм булганча, икесе дә башка кешеләр белән никахта иделәр. Сугышка кергәч—ярасыз булмый, дия иде Маратның бер танышы. Шул

чорларда яшь журналист ике ут арасында бик озак бәргәләнде. Бер яктан—инсафлы хатыны Сәриясе, гаилә... Икенче яктан, Марат өчен текә кыядан да сикерергә әзер торган, сөюдән шашкан сөйкемле сөяк—Розалиясе. Сәрия кебек акыллы, иманлы, тугрылыклы, тырыш хатынны Марат берничек тә ташлый алмый иде. Ни әйтсәң дә, алар хатыны белән бер-берсен аңлап, яратып, хөрмәт итеп гомер кичерәләр иде. Сәрия иренең еш кына чит-ят хатын-кыз исләренә төренеп кайтуына карамастан, «мужикның һәр кайсы шундый инде аның»—дип үз-үзен тынычландыра торган иде. Малын таба, өйгә кайтара, эчеп-тузып йөрми, балаларны ярата. Сәрия шуна да бик риза иде. Марат та хәләлен аңлап, юкка-барга тавыш чыгармады. Шуңа «ужымга» керер алдыннан ул һәр тапкыр хатынын ишандырыр өчен бирәр мантыйклы, ышандырырлык сәбәп уйлап табырга мәҗбүр иде. Шул ук вакытта Розалиясен дә югалтасы килмәде. Ләкин тормышны белми-аңламый торып үзеннән күпкә олы ир уртасына кияүгә сикереп чыккан яшь хатын-кызның дуамаллыгы да шактый гына җайсыз хәлләр тудыра иде. Җитмәсә, Розалиянең хәләл ире Галим Сабирович, шактый җылы урынны биләгәнгә, шәһәр түрәләре арасында абруйлы кешеләрдән санала иде. Сәвит чорында бит әле аның әхлак милициясе вазыйфасын башкарган партком-райкомнары да гаилә сагында тора иде. Гыйшык-мыйшык хәлләре еш кына партия оешмаларының җыелышларында көн тәртибенә әледән-әле куелып тора иде. Уракка төшү, савымнарны арттыру, дуңгыз үрчетү планнары белән беррәттән, уставтан тайпылган коммунистларның персональ эшләрен тикшерү—партия органнарының көндәлек шөгыле иде. Партия һәр коммунистның ничек яшәвен, кай тарафларда нинди гамәлләр кылып йөрүе белән кызыксынып тора иде. Бу дәвердә аноним хатларны бик теләп тикшерәләр иде. Парткомиссияләрнең эшен шул исемсез хатлар булмаса, күз алдына да китерергә мөмкин түгел иде. Сәясәттән читләшеп партия әгъзалары да бераз урлашалар, печтик алдашалар, ара-тирә салгалыйлар, әз-мәз сулга да йөриләр иде. Ягъни, бу җәһәттән алар халыктан аерылмаска тырыша иде. Җитәкче иптәшләр өчен мондый рәхәтләрне чит-ят кеше күрмәгән һәм белмәгән махсус урыннарда оештыралар иде. Ләкин чорына күрә шигаре дә бар иде: барысын да эшли аласың—тик эләкмә. Эләксән—беттен! Гаеп, агайне, үзеңдә!

Марат еш кына үзен миналар кырында хәрәкәт иткән кебек хис итә иде. Чөнки партия билетын йөрткәнен ул һәрвакыт истә тотарга тиеш! Онытса—башкалар искә төшерәчәк! Совет армиясендә хезмәт иткәндә замполит коткысына бирелеп коммунистлар сафына кергән сержант Сабиров, нигездә, партия кушканча эшләргә һәм яшәргә тырыша иде. Партия уставы бит ул—библиянең кыскартылган бер шәкеле—анда гел игелекле, иманлы гамәлләр кылу фарыз ителгән. Әйе, хатын-кызлар, дуслар белән ара-тирә җыелышып, устав кагыйдәләрен бозгаларга туры килгәләде. «Ансыз—дөнья сансыз!»—дия иде бер тәҗрибәле коммунист. Һәр рәхәтнең зәхмәте дигәндәй, тотылмаса да Галим Сабирович Розалиясенең тугрылыклы Пенелопа түгеллеген сизенә иде бугай. Ләкин яшь хатынның шаярулары чамасыз булмавына да шөкрана кылып яши иде кебек ул. Хатынының рияланып йөрүенә еш кына игътибар итми, күрмәмешкә салына иде. Иң мөһиме—кеше арасында рисвай калмаска! Анысын, Аллага шөкер, Розалиясе үзе дә аңлый булса кирәк. Шуңа да Галим Сабирович гаиләдә юкка-барга савыт-саба шалтыратуны хуп күрмәде. Киресенчә, кайчакта бераз театр уйнаштырып, хатынына: «Син дигәндә—аяк идәндә!»—дип хөрмәт күрсәтә, очындыра торган булды. Кием-салым, акча, ялга бару кебек масрафлар, кыскасы, Розалиясе өчен мондый «вак-төяк» һич тә җәлке түгел!.. Исән-сау булсын да бергә яшәсен генә!..

Әнә теге Казан аэропортында танышкан көнне Розалиянен унбиш мең акчасы булган. Кайгыртучан ире Бөгелмәдәге райпотребсоюз рәисе белән сөйләшеп, хатынына «Жигули» алырга акча биргән. Мәгълүм ки, һава хәлләре, көтелмәгән очрашулар бу планнарга төзәтмә кертте.

Хәлилнең фатирында искиткеч ләззәтле төн уздыргач, Розалия үзенең Бөгелмәгә машина алырга баруы хакында әйтте. Марат бу хәтле зур акча белән ялгыз сәяхәт итүне бер дә өнәмәде. Барыбер аңа да Бөгелмәгә барасы бар. Шуңа бу мәшәкатьле эштә Марат бернинди мәнфәгатьсез, ихластан ярдәм кулын сузарга булды. Иртән торып, чәйләр эчеп утырганда, ишектә кинәт кыңгырау чылтырады.

Ишек ачылып китүгә коридорга иң әүвәл яман исләр аңкып керде. Аннары дөммә исерек Хәлил һәм аны өченче катка сөйрәп менгән ике салмыш ир-егет пәйда булды. Бу компания фатир хуҗасын коридор идәненә сузып салды да берни әйтми чыгып та китте.

Марат нәрсәдер мыгырдаган, адәм сыйфатын җуйган Хәлилне бүлмәгә сөйрәп кереп түшәккә яткырды, яңакларына суккалап, селкетеп карады, ботинкаларын салдырды. Аннары «моның белән эш пешмәс—айнысын,»—дип кухняга Розалия янына чыкты. Ул өстәл артында акча пачкаларын барлап утыра иде.

Марат аны арттан кочаклап алды:

—Нәрсә, миллионерша, дебет-кредит, сальдо-бульдо килеп чыгамы?

Розалия бераз уңайсызланып:

—Лачыным, монда биш мең җитми...—диде.

Гомерендә кулына биш йөз сумнан артык акча тотмаган Марат өстәл тулы банкнотларны күреп югалып калды.

—Яхшырак сана... Кем алсын аны?!

Кинәт Хәлил йоклый торган бүлмәдән берьюлы атлар кешнәвен, пычкылар чыжлавын, тагын әллә нинди җен-пәриләр котыруын хәтерләткән авазлар ишетелә башлады.

Марат Хәлил түләүсез концерт куйган бүлмәгә ымлап күрсәтте:

—Бәлкем, ул... Тукта, карыйм әле...

Марат әкрен генә баскалап Хәлил янына килде, аның курткасын салдырырга тырышканда кинәт идәнгә бер пачка акча «шап» итеп килеп төште.

—Менә сиңа, фокусник!.. Синекедер инде бу—сана!

Розалия кыюсыз гына кызыл унлыкларны чутлый башлады.

—Бер мене җитми...

—Кайдадыр проматал, опилка баш!..

Маратка бик җайсыз иде. Булса—шундук үзенекен чыгарып бирер иде дә бит!.. Вәт син аны, дус булып йөри бит тагын, кесә карагы! Салган баштандыр инде...

—Әйдә матурым, киттек Бөгелмәгә, берәр нәрсә уйлап табарбыз әле...

Бу машина сатып алу тарихы юкка гына шулай мәшәкатьле, мажаралы башланмагандыр ул... Әй, машина, машина, житә кеше башына, дип тикмәгә генә әйтмиләр бит!

Марат шул хәлләрдән соң Хәлил белән аралашмады. Шәрекътагы мәкальдәгечә: ун тапкыр яхшылык итү—бер кат начар гамәл кылырга форсат бирми...

Тик болары олы юлның тузанына күмелеп, онытыла башлаган хәлләр булса, ә менә автомобиль казасында Розалия белән бергә Хәлилнең дә элагүе бигрәк көтелмәгән нәрсә булып чыкты. Ничек алар икесе бер машинада барганнар, нигә руль артында утырган Хәлилгә бернәрсә дә булмаган? Әйтерсең лә, ул Маратның Төркиягә ялга китүен генә көтеп торган! Хәер,

соңгы вакытта Розалия белән аралар суына башлаган иде инде...

Үлем-китем, җеназаларны Марат яшьтән үк күңеленә бик авыр ала торган хисле кеше буларак, соңгы юлга якын туганнарны, дус-ишләрне озатуда гына катнаша иде. Әлбәттә, Розалия белән хушлашырга килде. Халык байтак җыелган. Сентябрьнең коры кояшлы көнендә Маратның бәгырькәен татар зиратындагы сары балчыклы кабергә индерделәр. Сөю, сәгадәт, гүзәллек өчен яратылган бу сөйкемле Хода бәндәсе фани дөньяда аз гына яшәп тә, кемнәрнедер бәхетле итеп, кайсын көнләштереп, үпкәләттереп кинәт бакыйлыкка китеп барды. Әлбәттә, бу фаҗигале язмыш якыннарының да, дусларының да йөрәген телеп китте. Әнә үсмерләрчә тартылган улы, кайгыдан картаеп, бөкрәеп калган, җирән чәчләре күкселләнеп киткән Галим Сабирович, чат әнисенә охшаган, матур кара тутлы, почык борынлы кызы, матәм чарасына күпләп җыелып килгән дус-ишләре, иптәш кызлары. Көтелмәгән бәла, трагедия барысын да бер мәйданчыкка җыйган. Әйе, зиратта гына адәм баласы туктап кала, бер мәлгә тормыш куунын, мал җыюның мәгънәсезлеге турында уйлана. Кәфенлекнең кесәсе юк: дөньяга ничек киләбез, шулай китәбез... Зираттан шундый уйлар белән кайтып барганда Маратны Розалиянең иптәш кызы, сердәше Гөлчирә куып тотты.

«Маратик!—дип пышылдады ул, аның колагына.—Бүген сиңа әйтмичә булдыралмыйм... Розалиянең Мәрзиясе синнән бит аның!.. Күрдеңме, тач син бит!..»

Шул вакытта аяк астында җир чайкалып киткәндәй булды, шабырдатып салкын яңгыр коя, тирә-юньдәге агачлар айкала-чайкала башлады. Әйтерсең лә, Маратның эчендәге халәте тышка бәреп чыкты.

...—Моны син бел дә мин бел... Кайчан да булса әйтерсең, бәлкем... Анысын үзең карарсың...

Бу көтелмәгән хәбәр аяктан бәреп егарлык булса да, Марат үз-үзен кулга алырга тырышты. Бер-ике сүз белән Гөлчирә авариянең кайда, ничек булуын, рульдәге Хәлилнең беренче мәлгә машинадан төшеп, кан эчендә яткан Розалиягә беренче ярдәм итмичә, качып китүе хакында да сөйләде. Аннары гаебен таныган имеш... Тик эш узган бит...

—Җаһил кеше инде, валлаһи! Синең белән очрашмый башлагач ук ябышты инде ул аңа... Ләкин Розалия аны яратмады. Якын җибәрмәде... Бәлкем, морадына ирешәлми аптырагач «миңа да, башкага да булмасын!»—дип каза ясагандыр. Һай, кара эчле адәм ул, мин сиңа әйтим!.. Кабереңянәшә булмасын!.. Ярый, мин киттем... Ирем килә... Без Галим Сабировичлар белән гаилә дуслары бит... Хуш...

Менә сиңа мә! Мәрзия—безнең уртак мәхәббәт җимеше!.. Розалия җаный, ник соң моны миннән яшерден?!

...Эх, Розалия, Розалия!.. Бу сәер юл фаҗигасен казыргамы-юкмы? Милициядә, прокуратурада таныш-белешләр бар барын. Кемең ул сиңа, дип төпченсәләр—кәртләрне ачырга кирәк булачак... Аларны Марат тирән яшергән иде. Галим Сабирович, әлбәттә, эшне үзе дә болай гына калдырмас... Аңа да хакыйкатьне белергә кирәк. Бернәрсә ачык: бу кабахәтлекне кылган Хәлилне дуслар исемлегеннән кичекмәстән сызып ташларга! Бүген үк һәм мәңгегә!..

Марат сиздермичә генә кеше йөрмәгән сукмактан трамвай тукталышына таба китте.

***

Поезд алга чаба да, чаба... Гүя, ул «Яшьлек» станцасына якыная бара. Хатирәләр поезд тәрәзәсеннән, экрандагы мавыктыргыч фильм кадрлары

кебек, бер-бер артлы күренеп ала. Ниләр генә узмаган башкайлардан!..

Менә ул онытылмас еллар... Сугыштан соң туган, ачлы-туклы, ыштансыз үскән авыл балалары. Әтиләре фронттан кайтмаган булсалар, бу затлар якты дөньяга тумаслар да иде. Ә аларның балалары... Оныклары... Әтиләрне, һичшиксез, Ходай үзе саклаган. Монда зур бер мәгънә ята. Гомер чылбыры өзелмәгән! Ә бит сугышта йөргән солдатны Газраил һәр почмакта көтеп торган.

Маратның әтисе Мифтах, сирәк-мирәк кенә фронтовой граммнарны тоткач, кичләрен ишле гаиләсен җыеп, сугышта күргәннәре хакында бик мавыктыргыч иттереп, кайчак иртәнгә кадәр сөйли торган иде. Әлбәттә, бу якын тарихка сәяхәт балалар өчен дә бик кызык, гыйбрәтле була, Мифтахның үзенә дә ниндидер канәгатьләнү бирә иде.

Сугышта бер хата, ялгыш адым, югалып калу бик кыйммәткә төшкән: андый адәмнәр беренче чиратта кырылганнар.

...Мифтах Сабиров меңләгән сугыш чакрымнарын санитар машинада яралыларны алгы сызыктан тылга ташып уздырган. Гади шофер булса да, нинди генә аяныч хәлләргә юлыкмаган, илен, дусларын сатмаган, исән-сау туган авылына әйләнеп кайткан! Әфисәр погоннарын киеп. Маладис! Марат аның белән горурлана иде. Балачакта ул елларда «безнекеләргә» һәм «немесләргә» бүленеп нинди генә зур «хәрби операцияләр» уздырмады авыл малайлары! Разведчиклар, танкистлар, матрослар немес «окопларына» сиздермичә бәреп кереп, ничәмә «тел» алып кайттылар... Сугыш киноларын карап, икенче көнне үк авыл малайлары Жуков, Малиновский, Рокоссовский булып, таяк атка атланып, Сталинград, Кавказ, Берлиннарга барып җитәләр иде. Ләкин иң кадерлесе—күкрәкләре орден-медаль белән тулган әтиләре сугыш турында сөйләгәндә бу балалар авызларын ачып тыңлыйлар, ихластан горурланалар иде. «Минем әти фәлән булган, минем абый—танкист, бабай—матрос, безнеке—очучы»,—дип малайлар авылдан киткән һәрбер сугышчының тарихын яхшы беләләр иде. Илгә килгән зур кайгының эзләре дә тирән булгандыр, күрәсең...

Марат әтисенең сугышта күргән маҗараларын бүген дә яхшы хәтерли. Шулай берзаман ул бомбежкага эләгә. Андый чакта солдат, кая туры килә—шунда кереп поса бит инде. Монда уйлап, урын сайлап торыш юк. Сугышчыларның күбесе куак-агачлар арасында утырган зур бер бинага таба йөгерә. Янәсе, шунда гына әҗәлдән котылып була... Мифтах исә машинасын арыш кырына туктатып, янәшәдә генә торган «ЗИС» астына кереп йөзтүбән каплана. Фашист очкычлары, халыкара килешүләргә карамастан, санитар машиналарына да һөҗүм иткәннәр. Ләкин бу юлы бомбалар солдатлар күпләп җыелган теге зур бинаны һәм куе бакчаны җир белән тигезлиләр. Ниһаять, очкычлар офыкка кереп югалгач, Мифтах «ЗИС» астыннан чыгып, аның кузовына күз ташлый. Йә, Ходай! Машинага шыплап снаряд төягәннәр икән! Бер бомба кыйпылчыгы эләксә дә, Мифтах туп-туры җәһәннәмгә очкан булыр иде. Менә шулай, еш кына сугышта кеше гомерен галиҗәнап язмыш, очраклы хәлләр саклап калган...

...Күп тә үтмәде, купега янә кемдер шакыды. Бу юлы да ишектә буфет хезмәткәре пәйда булды. Тик монысы тагын да яшьрәк, чибәррәк, ә күкрәкләре күпкә ачыграк һәм итәкләре ир затларын нык дулкынландырырлык кыска иде. Ул кулындагы ашамлыклар һәм эчемлекләр тутырган кәрҗинкәсен өстәлгә куеп, серле елмайды һәм үзенең ниятләрен, кинаяләп тормыйча, турыдан-туры ярып салды.. Монысы да план белән бергә шәхси мәсьәләләрен хәл итәргә кергән икән. Марат, янә акча янчыгын чыгарып, ресторан файдасы өчен генә бер-ике апельсин алды, ә буфетчы кыз, кыстатмый гына бер рюмка коньякны әйләндереп куйды һәм «Харьковтан соң күрешербез!»—дип күз

кысып, купедан чыгып та китте.

Эх, бу хатын-кызлар!.. Соңгы елларда аларның тәртибе, үз-үзләрен тотышы, әхлагы кемнедер гаҗәпләндерсә дә, Маратны бер дә шаккатырмый иде. Казанда да, Рәсәйнең башка шәһәрләрендә дә, чит илләрдә дә мондый ягымлы «күбәләкләр» атлаган саен очрап тора.

Әнә, кайбер өлкән сыйныфларда укучы кызлар инша язганда «Син кем булырга телисең?»—дигән сорауга—«Фахишә!»—дип горурланып, бер дә икеләнмичә җавап бирәләр икән. Кем әйтмешли, барып җиттек!

Әйе, хатын-кызларны кичке урамнарга озакка сузылган реформалар, акча кытлыгы, ягъни хөкүмәт үзе төртеп чыгарды. Ә мондый үтә табышлы кәсепне бик тиз генә «текәләр» үз кулына алды. Үлемсез мафия бу юлы да отышта калды. Кызларын да, клиентларын да таптылар, җиңгәчәйләр йортларын да, салон-сауналарын да ясап куйдылар. Кыскасы, поезд күптән китеп барды, ә җәмгыять һаман бәхәсләшә, рөхсәт итәргәме-итмәскәме бу четрекле бизнесны?! Ара-тирә урамнардан, кунакханәләрдән кыска итәклеләрне милициягә төяп алып китәләр китүен. Ләкин эш штраф түләү һәм погонлы кешеләргә тән рәхәте күрсәтү белән тәмамлана... Бартер: без—сезгә, сез—безгә! Җенси пожарны сүндерергә машина да, су да кирәкми. Аның өчен хатын-кыз белән ирнең теләге һәм акча гына кирәк!.. Ә калганы ике арада, уртак түшәктә хәл ителә..

***

Сугыштан кайткан яшь әфисәр Мифтах Сабиров авылның иң чибәр кызы Миңлегөлне бик тиз күреп ала һәм тимерне кызуында суга. Янгырлы октябрь сиңа җылы җәй ае түгел. Төннәрен йолдыз санап тормаганнар, киләчәккә хыяллар корып, болыннарны урап йөрмәгәннәр... Хәер, андый чакта гашыйкларга табигатьнең яңгыры да, фасылы да, давылы да, фронтовиклар әйтмешли, нипочум булган. Әби-бабайлар да сайланып-сатулашып тормаганнар, авыл сәвите дә тиешле имзаларны җәһәт кенә җыеп, пичәтне чәпеп куйган. Туй-фәләннәр уздырып торыш булмаган—чамалар сыек: җыелышып бераз чәйләгән-майлаганнар дә эше бетте, кодагый. Авылда чираттагы сәвит гаиләсе пәйда булган.

—Һай, бигрәк хәерче дә заманга туры килде безнең яшьлек!—дип искә ала иде үткәннәрне Маратның әнисе.—Кышка керсәң, кияргә кием табалмыйсың, язга чыксаң, ашарга ипи бетә... Ләкин без әтиең белән икәү барыбер бәхетле идек...

***

...Поезд янә кайсыдыр станциядә туктады. Вагонга таможня хезмәткәрләре, чик сакчылары керделәр. Бәйләнерлек нәрсә табылмады. Тикшерәсен—тикшереп, ишекләрне шалтыр-шолтыр ябып, чыгып киттеләр. Марат та купены бикләп, йокларга ятты...

Иртән ул уянганда вагон буйлап пассажирлар арлы-бирле йөри, радиодан көчле музыка яңгырый иде. Димәк, торырга вакыт. Кырынып, юынып бераз тамак ялгап алгач, кичәге өзелгән уйлар, хатирәләр аны янә биләп алды. Ләкин ачык купеда кәрҗин тоткан буфетчы хатынның олырагы пәйда булып, Маратны хыялый дөньядан мәшәкатьле чынбарлыкка кайтарды. Яшь ханымның укасы коелган иде.

—Ник сез миңа төнлә ишек ачмадыгыз?—диде ул иренен турсайтып.—Бөтен планнарымны боздыгыз!..

—Мин бик арыган идем, каты йоклап киткәнмен, ишетмәдем, гафу итегез...

—Слабак!—дип мыгырданды буфетчы хатын.—Мужчина так не

поступает!—диде һәм купеның ишеген «шалт» иттереп ябып, китеп барды.

Марат бу ханымның нинди планнарын бозганын аңлап, эченнән генә елмаеп куйды. Димәк, тиздән икенче кәрҗинкәле кыз да килеп җитәчәк...

Күп тә үтмәде, аның юравы юш килде. Яшьрәк хатынның планнары һәм аппетиты тагын да зуррактан булган, күрәсең. Үпкәсе йөзендә ярылып ята иде.

—Вы вчера меня о-очень подвели!—диде ул, кашларын усал җыерып.—Ну вы—оригинал... Обещали всем сразу: и моей подружке, и мне... Вообщем, кинули обеих. Взрослые люди так не поступают!

—Гафу итегез, кичә мин бик арыган идем...—диде Марат.—Әйдәгез, мин сездән тагын ике апельсин, бер пепси алам. И полный расчет!

Кыз бераз йомшара төшеп, товарларын сатты һәм дәшми генә чыгып китте. Ярый әле болар белән исәп-хисап кыска булды. Югыйсә, бик кыйммәткә төшәрләр иде... Шайтан белгәнме, аларның артында кемнәр торганын!..

Гомер буена нинди генә очрашуларга тап булмыйсың! Журналист язмышы—мосафирлыкта. Хәрәкәттә—бәрәкәт. Поездлар, очкычлар, машиналар, паромнар, көймәләр, кораблар... Нинди генә рәвештә хәрәкәт итми каләм иясе? Әле сәяхәт ул —эшнең башы гына. Кайткач, тәэсирләрне, фикерләрне, фактларны бер дисбегә тезеп, адәм баласы йотлыгып укый торган әсәр язу—төп максат. Кайчак килеп чыга, ә кайчак—юк. Кәрзингә язган чаклар да булгалый...

Марат хатирәләр чылбырын ялгап, тагын «Үсмерчак» тукталышына кайтып төште. Кемнедер шашып сөйдеме ул, сөймәдеме? Әлбәттә, булды андый хәлләр. Хәер, ул чакта да, соңрак та аңа хатын-кызлар игътибар итәләр иде. Авылда язылмаган гадәт буенча яшьләрне ешрак имеш-мимешләр кавыштыра. Имештер, фәлән егет фәлән кызга өйләнә икән... Булып чыкмас... Бәлешләре пешмәс... Әнкәсенә карап кызын сайла дигәннәрме? Хәбирә кызы белән Самат малае бер-берсенә көн белән төн кебек мач килә... Ә менә Гамил—Рамилә бер ботакка кунып сайрасалар—авылны таң калдырырлар иде... Ә югары оч Сәлиме Бола урамы Нәсимәсе белән юкка вакыт уздырып, ботинка туздырып йөри...

...Марат та хатын-кыз затын ярата. Алар бит табышмаклы, серле халык... Кайсы белән сөйләшкәләп, кайсы белән кулын тотып, кочаклашкан, үбешкән чаклар да булгалады. Ләкин яшьлектә күнелгә уелып калганнары күп түгел. Әйе, Яшь Тирәктә югары очта яшәгән Галия шундыйлардан иде. Бер карасаң, әллә нәрсәсе дә юк кебек, ләкин зирәклеге, тыйнаклыгы, пөхтәлеге, эчке нуры һәм матур җырлавы белән үзенә магнит кебек тартып тора. Гаҗәп, шундый әүлиянең янында бүген беркем дә юк. Егетләр беренче мәлгә артыннан көтүләре белән йөргәннәр. Ләкин Галиянең кулын да тоталмыйча 180 градуска борылып кайтып китәргә мәҗбүр булганнар. Кызның дарысы бик коры икән. Шуннан соң авыл кавалерлары кул селтәгәннәр. Ә Маратның инде тирә-юньдә гармунчы, спортчы буларак танылып килгән чагы. Кыз халкы алтыннан бакырны аера белә ул! Озата барса, берәү дә Маратка дорфаланып тормас иде әле...Кулын тотып кына калмас, битеннән генә булса да «пәп» итеп кайтыр. Ул да әхлаклы заманда зур бер җинүгә тиң! Сүз генә куш! Һәм язның бер кичендә Марат тәвәккәлләде: Галияне өенә озата китте. Тәүге көрешү нәтиҗәле тәмамланды: егет кирәкле сүзләрен дә тапты, кызның йомшак кайнар кулларын тотып, киләсе көрешүне тәгаенләп кайтты. Хәер, кем башкача булыр дип уйлаган соң! Гармун белән уртак тел тапкан егет, кызларның йөрәгенә иң кыска юлны тапмасын ди!

Әлбәттә, авылда гармунда сыздыручы егетләр тагын да бар иде. Иң осталарыннан Мараттан дүрт-биш яшькә өлкәнрәк Магаз булгандыр. Чәче дундырыклы суганны хәтерләткән бу ләпәшкә борынлы, шадра битле, урта буйлы адәм затына базар көнне сәлам да бирмичә узып китәр иден, билләһи газыйм! Ә кулына гармун алса—һәркемнең игътибары анарда. Таланты бармак очларында! Кайдадыр махсус укып та кайткан оста баянчы еш кына авылдан китеп югала иде. Хәер, моның сәбәбен якташлары яхшы белә. Магаз бераз «төшереп» алган җирдә берәр мөгез чыкмый калмый. Кемдер каршы, кыек-мыеграк сүз ычкындырса, Магазның җен-пәриләре кузгала һәм ул озак уйлап тормый, йә рәшәткәгә, йә курага ябыша. Нәтиҗәдә эш милиция белән тәмамлана, җанҗалчыны алып китәләр дә явыз хулиганлык өчен бер-ике елны чәпиләр.

«Кем сукты—Магаз сукты!» Милициягә дә әллә ни мәшәкатьләнәсе юк: рецидивист гаепле, шуның белән эш бетте-китте!

Авыл эшләрендә Магаз әллә ни катнашмаса да, һәвәскәрләр концертын аңардан башка күзаллап булмый. Әтисе «Төрмәчедән ерак тор!»—дип, җае чыккан саен Маратның колагына тукып торды.

—Әти, мин бит аның кырына гармунда уйнарга өйрәнер өчен генә барам,—дия торган иде Марат. Улының яхшы гармунчы булып китүен бик теләсә дә, ата кеше тальянкадан гайресен алып бирәлмәде. Күрәсең, Мифтах гаиләнең такыр акчасын кысып кына тоткандыр. Йә өйрәнгәне дә бик җиткән дип уйлагандыр. Концертларда, мәҗлесләрдә әнә ничек сыздыра. Тагын нәрсә кирәк!

Шулай да сигезенче класста укый башлагач, җәй көнне колхозда стажерлыкта йөргән өчен Маратка шактый хезмәт хакы язганнар иде. Акчаны кәнсәләрдән Мифтах үзе барып алды.

—Маладис улым, расхутлар бик күп, чуаштан сугымга ат та аласы бар... Бик вакытлы булды бу...

Ә Минлегөл улының ике рәтле гармун сатып алырга хыялланганын яхшы белә иде. Күрәсең, иренең колагына да бер генә тапкыр пышылдамагандыр. Инде карлар явар алдыннан әнисе улына шыпырт кына илле сумны тоттырды: «Тәүзыйх абыең гармунын сата икән. Барып кара, ошаса—алырсың. Акча турында атаңа әйтми тор...»

Һай, Маратның шатлыгын күрсәгез иде! Тәүзыйх абыйның алтын белән йөгерткән шәмәхә шуйский двухрәткесе бит әле ул! И-и, әни, бәгырькәй, маладисның маладисы! Сөйләшеп тә куйган, рәхмәт төшкере!

Марат шул ук көнне гармунлы булды. Соңрак Тәүзыйх абыйның шәмәхә двухрәткәсендә ул әллә нинди конкурсларда катнашып, әллә нинди дипломнар, бүләкләргә ия булды. Дөресен әйткәндә, мактарга саран Магаз да яшүсмер гармунчының үзеннән калышмавын яшермәде. «Двухрәткәдә Марат—Фәйзулла Туишев, ә баянда мин—Марс Макаров!»—дия иде ул. Ул чорда Яшь Тирәктә гармун модада иде. Маратның модада эше юк, бөтен хыялы—баянда шәп итеп уйнарга өйрәнү. Тальянка—хромка—баян. Боларның беренчесе—башлангыч мәктәп, икенчесе—урта, өченчесе—институтка тиң иде. Кыскасы, Магаз иректә чакта һәр көннең кадерен белергә, файдаланып калырга кирәк! Әйе, аны Магаздагы дуамаллык, юкка-барга кызып китүләр, хакыйкать эзләүләре, милицене, влачны күрәлмәү, сүгү кебек нәрсәләре һич кенә дә кызыксындырмады. Матур дөньяны тимер рәшәткәле тәрәзәләр аша гына күзәтү Маратның планнарына керми иде.

Ничектер шулай бер зур кичәдән соң клубтан яңа «Тульский» баян югалганлыгы мәгълүм булды. Баштанрак клуб мөдире Даһия апа үзе тикшеренүләр уздырып караган, ләкин музыка коралының эзенә төшә алмагач, милициягә барган. Погонлы егетләр эшне кызуында тотып,

авылга килеп төштеләр. Концерттан соң баянда Марат та, Магаз да һәм күрше авыл егетләре дә уйнаганнар икән. Магазның өенә тенту белән кергәннәр—табалмаганнар. Маратны да силсәвиткә чакырттылар. Сорау алдылар. Марат кичәдән соң шактый салган Магазны өенә кайтарып, хатыны кулына тапшырып калдырды. Аннары Галияне озата киткән иде. Сөйгәнен бу эшләрдә бутамас өчен ул «мин концерттан соң кызлар янына киттем»—дип язды.

—Кемнәр ул? Нинди кызлар?—дип бик төпченсәләр дә Марат Галиянен исемен яңгыратмады. Ләкин гаепне тикшерүчеләр тагын Магазга аудара башладылар. Өендә менә дигән ике концерт баяны булган Магазга колхоз баяны ни пычагыма кирәк соң ул?!. Милиценең мантыйгы башкачарак булып чыкты. Баянны Магаз ике поллитрга кемгәдер сатып җибәргән, имеш. Берничә шаһит та табылган. Бу хәлләрдән соң Марат әтисенә ялынды. Абруйлы кеше, сүзе үтә. Күрәләтә гаепсез кешене төрмәгә тыгалар бит!

Мифтах бу эшнең нечкәлекләренә кереп торырга теләмәде. Аныңча, бер дөрес юл, ул да булса —Магаздан баланнын ераграк торуы!

Марат бу хәлләрне әтисенә житкерүенә бик үкенде.

—Ярар, алайса!—дип ул ишекне каты итеп ябып, өйдән чыгып китте.

Миннегөл иренең холкын яхшы белгәнгә, тынычрак тавыш белән:

—Мифтах, Маратның шундый чагы, бик каты бәрелмә инде син аңа!.. Биздерергә булдырасың...—дип әйтеп куйды.

Еш кына гаиләдә ата—баш, ана—муен дип йөрсәләр дә, дарылары бик тиз кабынучан Сабировлар, вакыт узгач суынып, мәгънәле бер уртак фикергә киләләр иде. Һәм мондый очракларда, әлбәттә, бар нәрсәне үзенең мәрхәмәтле йөрәге аша уздырган Минлегөлнең бер акыллы киңәше, кыстырып куйган мәгънәле сүзе хәлне дөрес бәяләргә, максатка туры юл табарга ярдәм итә иде.

Марат ничек булса да югалган гармунны табарга тиеш иде. Һәм ул аны тапты.

Сорка тавы дип аталган чирәмле-күлле матур бер җирдә. Мәҗлес корып, гармуннар белән утырган компаниядә берәү колхоз баянын бимазалый иде. Күнел ачуда, беркетмәләр теле белән әйткәндә, шулай ук шәһәрдән кайтканнарга охшаган ике пумала баш кызый, ара-тирә район үзәгендә күренгәләгән күрше авылдан көрәшче Сибай бар иде. Дөресен әйткәндә, бу чуар төркем биредәге гүзәл табигать гармониясенә бер тамчы да тәңгәл килми иде.

Сибай Маратны таныды булса кирәк:

—Әйдә, брат түрдән уз!—дип кирәк чамасы кулын сузды.—Ишеткәнем бар...Штангист, баянист... Давай тартып җибәр әле безненчә, мишәрцә!

Гармунны бимазалаган төссез мишәр егете уйнавын туктатып, баянны салдырыр-салдырмас килеш Маратка таба атлады. Ләкин шул мизгелдә бу гамәлгә шайтан килеп кысылгандай булды: исерек гармунчы ничектер сөрлегеп китеп, баяны белән бергә «гөп» итеп җиргә ауды. Әле генә кәеф-сафа корып, шаулашып утырган пикник әгъзалары бер мәлгә сүзсез калдылар. Сибай коллектив хуҗалыкка тигән зыян турында сөйләп тормады, кемнәрнеңдер аналарын искә алып, ватык баянны кочып нишләргә белми утырган мәҗлестәшен сүгеп атты.

Марат шулчак сүзгә кушылды:

—Сибай, ә бит баян—колхоз милке! Мин сез урлап китеп ваткан инструмент өчен җавап бирергә җыенмыйм!

—Баян күпме тора?—дип сорады кинәт Сибай, Маратка төбәлеп.

Марат аның чын бәһасен үзе дә белми иде. Шуңа якынча саннарны атады.

Сибай шартларга җитә язды:

—Син нәстә, пацан, охренел, да?!

Марат бу эшнең милициягә барып җиткәнен, тирә-юньдә кырыслыгы, усаллыгы, төрмәче булуы белән дан тоткан Магазның язмышына бәйле икәнен әйткәч кенә Сибай әйләнеп төште.

—Шулаймыни?..Так бы сказал! Магаза могут повязать?.. Монысы нацар!..—Аннары теге пешмәгән егеткә борылып:

—Баянны алып китәбез. Йә төзәтәбез как новый... Йә, бөтен нәсел-нәсәбәң белән зыелып, яңаны аласыз. Атаң—спикулянт! Ике көн срук!.. Тот бишне, штангист!.. Магазга привет от Сибая!..—дип кычкырды.

Бу баян тарихы Маратның зиһенендә янә бер гыйбрәтле эз калдырды. Әллә нинди авыр, көтелмәгән, куркыныч, буталчык хәлләрдә дә югалып калмаска, каударланмаска, үз-үзеңне чын ирләрчә тотарга, чигенмәскә кирәк!

Мәктәптә уку күп вакытны алса да, үзешчән сәнгатьтә катнашуны,сәхнәгә чыгып, үзеңнең сәләтеңне күрсәтүне, мәйданда гер, йә штанга күтәрүне Марат чын егетлек дип саный иде. Моны нинди төрмә романтикасы белән чагыштырып булсын ди!

Кырык яшенә җитеп ир-кияү күрмәгән Даһия апа концерт-спектакль оештыруда тиңдәшсез иде. Сәхнәгә теләсә кемне менгезми. Хәтта тискәре геройларны уйнау да азып-тузып, эчеп-исереп йөргән ир-атларга тәтемәде. Шуңа да, бәлкем, Даһия апаны авыл халкы хөрмәт иткәндер. Күрәсең, ул үзенең шәхси тормышына кул селтәп, күңел җылысын тулаем яраткан эшенә багышлагандыр. Соңрак милли-мәдәни чараларда шактый кайнаган Марат күзлегеннән Даһия апаның артистлыгы беркатлы булып күренсә дә, ул елларда халык бу чаралардан соң берничә көн шау-гөр килә иде.

Марат ул концертларны яхшы хәтерли. Баштан сельпо ярдәме белән бертөрле киенгән һәвәскәрләр хор белән «Туган ил» җырын башкара. Чөнки сәвит чорында туган ил, партияне мактап җырлау, шигырь сөйләү—мөселманга намазны Коръәннең Фатиха сүрәсе белән башлап җибәрүе кебек фарыз иде. Аннары «Утыр әле яннарыма» кебегрәк берәр җыр яңгырый, зал җанланып китә. Яхшы хор «Каз канатын», әгәр дә тамашачылар аннан соң да уянып китмәсәләр, репертуардагы «Дүдәк-дүдәк, бак-бак-бак»ны әйттереп бирә. Аннары кем ничек булдыра инде. Арада бераз гына салмыш башкаручылар да очрый, чөнки авыл егетләре андый вакытта көмешкәне бераз җибәрсәң, тавыш та көчлерәк чыга, сәхнәдәге тарсыну да бетеп куя, диләр иде.

Концертларда Маратның икенче рольдән беренче рольгә күчеп йөрүләре, әйткәнебезчә, Магазның җинаять кодексын бозуына бәйле була иде. Нәкъ чыгарылыш имтиханнары алдыннан Сабан туйлары башланган көннәрдә Магаз чираттагы берәүнең авыз-борынын җимереп, кабат тимер рәшәткәле йортка ике еллык командировкага китеп барды. Әйе, бу көтелмәгән хәл Маратның шәхси планнарын боза язды. Җитмәсә, ул авыл җәмәгатьчелегенә бик кирәк кеше булып чыкты. Даһия апа район Сабан туенда концертлар куярга ниятләнеп йөри иде. Аңлашыла ки, төп баянчы тиз генә кайтмаслык якларга китү сәбәпле, бөтен ышаныч Маратта иде. Физкультура укытучысы Мөкатдәс абыйның да иң көчле штангычыларның берсе Марат Сабировны Сабан туе чемпионы итеп күрү биелгы планнарында кызыл кара белән тамгаланып куелган иде. Яшерен-батырын түгел, бу хыял Маратның үзен дә бик җылыта, һәвәсләндерә иде. Чөнки ике ел дәвамында тимер-томыр күтәреп, штанга белән җитди шөгыльләнгәнгә, аңа авылда гына түгел, районда тиңдәшләр юк иде кебек. Әйе, бик кирәк иде ул җиңү Маратка! Мәскәүдән журналлар

яздырып алып, мускулларны үстерә, көчне арттыра торган төрле күнегүләрне ул жиде кат тиргә бата-бата, кат-кат, ел буена даими ясап килде. Уку һәм физик күнегүләр! Бу яшәү рәвешенә әверелде. Бөтен халык алдында район Сабан туенда катнашып, 17 яшьлек үсмергә иң көчле егет исемен дәгъвалау өчен, мин сезгә әйтим, кимендә батыр йөрәкле, тәвәккәл булырга кирәк! Менә шуннан соң без синең белән сөйләшеп карарбыз, Малик!

Бу тормышта уннан-сулга бәргәләнеп, үз урынын таба алмаган унтугыз яшьлек, армиягә китмәгән Малик нишләптер Маратны күралмый һәм аны, жае чыккан саен, тукмаклый иде. Гадәттә, Маликнын сөякчел йодрыкларын Маратка бию кичәләреннән соң, кызлар китеп, егетләр таралып өлгермәгән чакларда тоярга туры килә иде. Соңрак Марат бу кабахәтнең бөтен халык алдында йодрык уйнатуының сәбәбенә төшенде. Колагына аю баскан, житмәсә, ифрат сөйкемсез, алагаем кәкре борынлы, кеше белән аралаша белмәгән Маликны кызлар да үз итмиләр иде. Ә бөтен яктан килгән, талантлы гармунчыны бары тик йодрык ярдәмендә генә түбәнсетеп була бит! Менә шуңа да Марат үзенең мускулларын чыныктырды, көч туплады. Һәрьяклап үз-үзен терсәк сугышына әзерләде. Тик Малик санашыр вакыт житкәч кенә каядыр китеп олакты. Әйтерсең лә, сизенгән, кабахәт! Маратның борчылуыннан йокылары качты. Гүя тамакта нindидер төер утыра иде... Авылда Малик армиягә киткән дигән сүзләр ишетелгәләде. Берәүләр аны ветеринария институтына имтихан биргән дип тә сөйләделәр. Кайчан да булса бер кайтыр әле, бәдбәхет! Анысы да монысы— Марат очрашуга һәрьяклап әзер иде... Һәм, ниһаять, санашу сәгате сукты!

Жәйнең матур бер кичендә клубта бихисап кеше жыелып, яшьләр бик зур тамаша оештырдылар. Барысы да рәхәтләнеп биеделәр, ял иттеләр. Әлбәттә, Марат кичәнең бизәге дә, үзәге дә булды. Медицина документларын биреп Казаннан кайткан Галия дә ул кичәдә үзен бик бәхетле хис итте. Гашыйклар серле карашлары белән бик тиз аңлаштылар. Парлы биюгә чыккач, Марат, тирә-юньдәгеләргә сиздермичә генә, ике сүз белән кызның колагына очрашу сәгатен житкерде. Галия егетнең тыгыз мускулларына бармакларын батырып: «Аңладым!»—дип пышылдады. Очрашу урыны, гадәттәгечә, Галияләр йортыннан ерак түгел, Яшь Тирәктә һәркемгә мәгълүм йөз еллык имән янында... Ләкин кичә тәмамланыр алдыннан гына бер төркем яшьтәшләре арасында Малик пәйда булды! Шулчак Маратның бөтен планнары чәлпәрәмә килде. Әйе, Галия бик мөһим... Бәлкем, бүген хәлиткеч аңлашу да булыр иде... Ләкин Малик кайткан бит! Ничек аны ычкындырасың! Юк, Марат бу форсатны күптән көтә! Малик яшьләрнең тарала башлавын күреп, дуслары белән клубның ишегалдына юнәлде. Марат та тиз генә шунда йөгереп чыкты. Гадәттәгечә, сугыш чукмары озын сөякчел кулларын алга сузып Маратка ташланды. Егетләр читкәрәк тайпылып, бакчаның бер почмагында мәйдан сыманрак урын барлыкка килде. Марат арыслан кебек сикереп, көндәшен ике кулы белән бар көченә кысып, югары чөерде. Аннары чәбәләнгән дошманын һавада тотып алып жиргә томырды. Әллә көтелмәгән дорфалыктан, әллә Маратның шул хәтле көч-нәфрәт белән алып сыптыруыннан Малик, ах-вах килеп, жирдә озак ятты. Мондый финалны күреп, аның дуслары да дәшми генә бер читтә тордылар. Ниһаять, Малик авырткан жирләрен уа-уа торып басты. Шунда гына Марат коры тавыш белән: »Исеңдә тот, адәм актыгы, бу синең миңа соңгы һөжүмең булды, аңладыңмы?!..»—дип кычкырды.

Менә шул хәлләрдән соң Малик Изахов авылдан әллә кая китеп тә

югалды. Шулай итеп Марат беренче дошманы белән исәп-хисапны өзде.

***

Чувашстан якларында Сабан туйлары бераз үзгәчәрәк уза. Маратлар үскән чорда иксез-чиксез Рәсәйдә җир кытлыгы булган, күрәсең. Хәтта Сабан туе мәйданнарын сөреп, ул дәвердә авылларны берләштерү галәмәтен уздырдылар. Гомер-гомергә үз көнен үзе күргән Яшь Тирәкне чуаш авыллары белән кушып, бер уртак колхоз ясап куйдылар. Мондый берләшү чуаш милләтенә нинди өстенлекләр биргәндер—әйтүе кыен, ә менә, нигездә, ислам йолаларын тотып яшәгән татарлар шайтан суы-көмешкә белән күбрәк мавыга башлады. Татар сабантуйларын чуаш акатуйлары белән бергә уздыру гадәткә керде. Яшь Тирәктә халык гомер-гомергә ярышып эшләде. Үз колхозы булган чорда беренче бригада белән икенчесе бил алыша иде. Кем кемне? Бу кагыйдә кырларда-ындырларда гына түгел, сабантуй мәйданнарында, гомумән, яшәү рәвешенә дә үтеп кергән иде. Яңа колхоз оешкач, ярышулар чуаш-татар арасында зуррак мәйданнарда уза торган иде. Чуаш арасында яшәгәнгә, татар өчен һәр җиңү монда аеруча зур мәгънәгә ия. Кечкенә генә татар авылыннан чыккан Чуашстан, Татарстан чемпионнары исемен искә алып һәр татар күкрәк сугарга ярата иде. Беренче укытучысы Мөкатдәс абый үзе дә җәй җиттеме—велосипед ярышларыннан кайтып керми. Ә инде эчү-тарту, хәмер спортчыга бөтенләй ят нәрсә. Эчтеңме—мәйданга якын килмә! Йә, Бола буена барып ят, йә печәнлеккә кайтып йокла! Черкиләр белән көрәш!

Ә Марат үсмер чакта авыл Сабан туенда малайлар да, бабайлар да тиргә батып, ихластан көрәштеләр, йөгерделәр. Халык алдында, Сабантуй мәйданында галәбә тоту, җиңү яулау—онытылмас вакыйга. Ә инде бер прәнкә, исле сабын бирсәләр бала-чаганың башы күкләргә тия иде.

Ул елны Марат та беренче тапкыр район Сабан туенда катнашты. Халык күп җыелган иде. Төп ярышта исә штанга күтәрүчеләр көч сынашты. Унҗиде яшьлек Марат Сабиров әле унберенче сыйныфны гына тәмамлаган иде. Штанга күтәрү буенча иң симез абзыйлар арасында чандыр гәүдәле Маратны күреп, ярышны алып баручы кызгылт, тәпәч борынлы җирән судья, башын чайкап, елмаеп куйды. Янәсе, дохляк, бер үпкәң белән кая тыгыласың!..

Бөтен спортчыларны бер командага җыйдылар. «Сез барыгыз да көчле, әйдәгез башлагыз! Кем күбрәк күтәрә—шул җиңә!»—дип штангычыларны мәйданга чакырдылар. Штанганы өскә чөялмәгәннәр тәкеренеп мәйданнан чыгып китә бардылар. Ә бер-ике симез абый 80 килограммны бер-бер артлы күтәреп, мәйдан тирәсендәге халыкның алкышларын яулады.

—Марат Сабиров, «Яшь Тирәк», штангада туксан кило!—диде судья, тагын да кызара төшкән борынын чигелгән чуаш сөлгесенә чумырып. Марат: «Пропускаю»,—дигәч, мәйдан гөжләп алды. Туксан килоны симез дәгъвачыларның икесе дә күкрәктән ары төртә алмады. Ә Марат исә беренче чыгуында ук туксан бишне асат кына өскә чөйде. Мәйдан: «Маладис! Давай тагын!»—дип татарча кычкырды.

Туксан биштән соң штангага тагын биш килолы беленнәр өстәлде. Дәгъвачылар арасында Марат һәм тазарак бер чуаш егете генә калды. Шәмәхәләнә барган тәпәч борын беренче булып штангага Маратны чыгарды. Моңа хәтле бер центнерны Сабиров Чабаксарда республика беренчелегендә күтәргән иде күтәрүен. Ләкин ул чакта ике судья кызыл лампа кабызды һәм чемпионлыкка юлны яптылар. Янәсе, атлет кулларын тиешлечә турайтмады... Шуңа Марат йөз килолы штанга янына чыкканда ниндидер дулкынлану кичерде. Моны Мөкатдәс абый шундук сизеп алды булса кирәк:

—Каушама, энекәш! Син җиңәсең!—дип тынычландырды ул.

Халык арасыннан кемдер: «Марат—син чемпион!»—дип кычкырды. Әйе, монысы—Галия иде. Иң кирәк чакта кайтып төшкән бит! Маладис! Марат йөзләгән кеше арасында сирень бәйләме тоткан Галияне бик тиз күреп алды. Болай булгач инде Җир шарының үзен күтәреп куярсың, валлаһи!

Сынатмаска! Марат ныклы адымнар белән мәйдан уртасына атлады. Ул кайбер спортчылар кебек үзен эчтән кыздырмады, дулкынланып нәтиҗәне көткән халыкның нервысында уйнап тормады. Штанганы җирдән кубарып алды да иплән кенә күкрәгенә салды. Аннары бөтен көчен биреп, «Э-эх» дип җитез генә өскә чөереп, кулларында берничә секунд тотып торды.

—Вес взят!—дигән командадан соң, Марат аны ниндидер бер ачулану катнаш канәгатьләнү белән җиргә ташлады. Штанга чирәмгә беленнәре белән тирән кереп батты. Мәйданның бер өлеше шатлыктан дәррәү кул чапты, ә икенчесе сызгыра башлады. Ак күлмәктән киенгән нечкә билле Галия хуш исле чәчәк бәйләмен иясенә тапшырды һәм тиз генә Маратның битенә кайнар иреннәрен тидерде. Моны күреп мәйдан янә бер гөжләп алды һәм яшьләрне алкышларга күмде. Ул арада тәпәч борын ике ярдәмчесенең җиргә баткан штанганы чыгаралмыйча азаплануын күреп, сыбызгысын чыелдатты:

—Юрамас[1]! Нильза! Пульше так ни китать!

Ниһаять, штанганы такыр җиргә тәгәрәтеп чыгардылар. Бу юлы мәйданга чуаш егете чыкты. Халык бер мизгелгә тынып калды. Кем җинә?! Безнекеме, әллә... Штанга янә өскә очты. Тик ул чуаш егете белән бергә чайкала башлады. Һәм бер мизгелдән атлетның кулыннан төшеп китеп, янә чирәм җиргә кереп батты. Мәйдан «Эх!»—дип уфтанып алды.

—У тибя ещо адин падхуд!—диде судья бармаклары белән шәмәхә борынын бимазалап.

Тик җинү җилләре бу юлы да чуаш егетенең тегермәненә исмәде. Ул штанганы күкрәгеннән ары күтәрә алмады. Марат исә тагын ике белен өстәтеп, йөз дә ун килолы штангага таба юнәлде. Мондый авырлыкны ул гомерендә беренче тапкыр күтәрергә ниятләнде. Меңләгән күзләр мәйданга төбәлгән. Авылдашлар, классташлар, туганнар, дулкынланудан үзен кая куярга белмәгән әтисе—барысы да Маратның җинүен көтәләр. Алай гына түгел—аяк терәп таләп итәләр! Әнә горурлануы, мәхәббәте йөзләренә чыккан Галия... Җинәргә!

Маратка үз гомерендә Җину тәмен төрле мәйданнарда күп тапкырлар татырга насыйп булды. Ләкин беренче җину, тәүге мәхәббәт кебек үк күзәнәкләренә сеңеп калган татлы мизгелләр беркайчан да онытылмый! Ул чакта Марат Сабан туена нокта куйды. Әле ниндиен! Бу юлы татары да, чуашы да яшь пәхлеванга кинәнеп кул чаптылар. Якташлары —татарлар яңа чемпионның гаярьлегендә үзләренең дә өлешләрен тоеп, һәр чатта мактаныштылар, тел шартлаттылар. Мәйданны татар үзешчәннәре басып алды. Китте җыр, китте бию! Чуашлар бер мәлгә югалып, боегып калды. Ләкин дошманлашу булмады. «Бүген татар бәйрәм итә!»—дип кайсылары кызыксынып читтә басып торсалар, икенчеләре татарларга кушылып җырлый-бии башладылар. Чөнки ике халык та бер-берсен яхшы аңлый иде.

Акчаны кысып кына тоткан әтисе, ниһаять, Маратка велосипед белән баян алып бирде. Хәер, башка яшьтиләргә андый бәхет бер-ике ел элек тәтегән иде. Шул ук кичтә Марат тагын бер күптән көткән дәү бүләккә ия булды. Аh, Галия, кем уйлаган сине шул хәтле хисле, мәхәббәтле, төрек локомы кебек татлы булырсың дип! Кыскасы, яшьләр, әйтерсең лә кайчандыр кулдан ычкынган бөтен форсатны берьюлы файдаланырга

[1] Ярамый! (чуашча)

омтылып, таңга хәтле сөю ялкынында яндылар...

***

Дөресен әйткәндә, авылның сигезеллык мәктәбендә белем бирү һәм тәрбия эше заманына күрә яхшы куелган иде. Һәрбер укытучы, кем әйтмешли үз урынында, белемле һәм таләпчән. Монда шалтай-балтайны җене сөймәгән, һәр эшне тәртип белән җиренә җиткереп алып барырга яраткан фронтовик Мифтах Сабировның да өлеше зурдан иде.

Дөньялар үзгәрә... Яшь Тирәктә беренче класска быел ике бала кергән... Кайчандыр мәчет урынына салынган ике катлы мәктәп бинасында манара торгызып гыйбадәтханә ачканнар. Тарих кабатлана. Урта буын намазга утыра башлаган. Арада яшьләре дә бар. Бирсен Ходай!

Ә янәшәдә, иске мәктәпкә терәлеп икенче бер корылма моңаеп утыра: монысының кирпеч диварлары гына салынган. Акча юклыктан төзелми калган яңа мәктәп бинасы ул. Төрле милләтләргә Ельцин чорында күрсәтелә башлаган хөрмәткә һәйкәлдер дә бу. Бәлки, аны мәктәп директоры Мифтах Сабировның үҗәтлеген, тырышлыгын сурәтләгән ядкәр дип атаргадыр? Яңа мәктәп салдырам дип, Мәскәү, Чабаксар юлларын күп таптады бит ул! Баксаң, гомерләр узып та киткән. Милли мәгариф тарафдары заманаларның кинәт үзгәрүенә гаҗәпләнми. Мифтахны хәзер күбрәк гомер кояшының офык артына тәгәрәве гарьләндерә иде. Вакытны йөгәнләп булмый шул! Туксан елга якын гомер бер мизгел кебек—үтте дә китте. Кайбер иң мөһим, иң мәгънәле эшләрне Мифтах Сабиров шундый озын гомер яшәп тә гамәлгә ашыра алмый калды!.. Кызганыч, әлбәттә... Ләкин нигә үкенергә?! Табигый хәлләр! Һәрнәрсә хәрәкәттә, һаман үзгәреп тора. Берәүләр килә, берәүләр китә... Буыннар алмаша. Тормыш дәвам итә...Тик менә кабахәт ялгызлык җанны бимазалый! Аннан гына дәва юк! Ун ел элек бергә гомер иткән сөекле Миңлегөле кинәт вафат булгач, Мифтах иң авыр сынауга—ялгызлыкка дучар булды. Шул хәтле ишле гаиләдән авылда Сабировлардан берәнбер кеше—сиксәнгә якынлашып килгән Мифтах үзе генә утырып калды. Гомер буе хатынының иркәсендә яшәгән ир-атка ялгызлык дигән коточкыч нәрсәне колыннан татырга туры килде. Картлык көнендә аш пешерергә дә, бакча эшләрен карарга да, идән юарга да—һәммәсенә дә өйрәнде Мифтах. Тик ялгызлыкка гына күнә алмады. Марат кайчак уйлап та куя: бәлкем Ходай Мифтахны: «Хатыныңны исән чакта тиешенчә бәяли алмадың, хәзер инде менә татып кара ялгызлык афәтен»,—дип яшәтә дә яшәтәдер. Бу турыда шактый уйлангач, Марат кыска гына шигырь дә язып куйды:

Бола суы нишләп шулай моңсу ага,  
Дулкыннары гүя яраларга кага...  
Кеше китә—тик җырлары гына кала...  
Исәннәрне сәфәр көтә, дәшә кала,  
Хуш, авылым! Текә ярда әткәй кала,  
Бөтен сагыш, әйтерсең лә, аңа кала...

***

...Поезд тагын ниндидер станциядә туктады. Русия җирлеге башланды бугай... Сөйләшүләр, нигездә, бөек Толстой телендә. Әлбәттә, замана телләрне дә читләтеп үтмәде. Вак-төякләре ассимиляция тегермәненә эләгеп, инкыйраз корбаны булып тарихта калды. Миллионлаган халык сөйләшкән татар теле дә бу афәтнең упкыны читендә тора. Шәһәр җирлегендә ана телебез язгы кар сыман бик тиз эреп юкка чыга бара. Алласызлык чорында шайтан таягы шикелле чәчәк ата башлаган катнаш никахлардан татарча

белмәгән ничәмә буын туып-үсеп балигъ булды. Маратның туган тел, милләт, мәдәният турында уйлана башласа, кан басымы уйнаклый иде. Милләттә акыл ияләре җитәрлек, ләкин «без коммунизмга урыс теле аша киләчәкбез»,—дип тукылдап торган илдә кемнәр сиңа ана теленә ябышып ятсын?! Телне бер көндә генә өйрәтеп тә, югалтып та булмый. Тик вакыт татар файдасына эшләми. Башка милләтләр бәрабәренә башлап сәвит халкын әвәләделәр. Бүген әлеге каһәр суккан тегермән йөзләгән милләтне россиянлыларга әйләндерә. Бу кемгә кирәк?!

Әнә Финляндиядә көн күргән меңгә якын нижгар кавемен генә ал. Чит мохиттә ике гасыр яшәп тә, үз телләрен, диннәрен, гореф-гадәтләрен саклап калганнар. Дин һәм гаилә—ике төп багана. Суоми татарлары телне саклауны дин нигезенә салып дөрес эшләгәннәр, күрәсең. Анда көчле мәхәллә яшәп килә: аның каршында тел, дин курслары булдырганнар, яшьләр һәм спорт оешмаларын, балалар өчен җәйге лагерь (камп) төзегәннәр. Өстәвенә, рәхмәт төшкере, Финляндия хөкүмәте татар азчылыгына һәртөрле ярдәм күрсәтә. Һәр елны Хельсинкидагы татар мәхәлләсенә хөрмәт күрсәтеп Финляндиянең иң беренче кешесе—президенты килә! Ә Европа шурасында милли азчылык комиссиясендә Финляндиядән татар кешесе вәкилчелек итә...

Маратның андагы милләттәшләр арасында таныш-белешләре шактый иде. Ельцин хакимият иткән чорда аңар Суоми татарлары белән бергә уртак эшләр башкарырга туры килде. Скандинавия илләренә еш кына сәяхәт тә итә иде. Алар кирәге чыкканда Маратка шылтыраталар иде. Ничек, имештер, хәлләр?

«Шөкер, эшләп ятабыз...»

«Сез эшлисезме, әллә ятасызмы?..»

Андагы халыкның менталитеты, үз-үзен тотуында, аралашуында, кыскасы, телендә ачык чагыла. Безнең җирлектә сөйләшү, гадәттә, төгәл рәвештә бармый. Ничек яшибез—шулай сөйләшәбез... Без эшләп ятабыз, эшләп утырабыз, эшләп йөрибез... Ә алар фәкать эшлиләр. Мөгаен, шуңа да башкача яшиләр.

Фин ягында гомер иткән милләттәшләребезгә: «Төшке аштан соң очрашырбыз»,—дип карагыз әле. Аларның шундук күзләре шакмаклана. Төшке аштан соң ул—кайчан? Сездән, һичшиксез, очрашуның төгәл вакытын төпченәчәкләр. Әбәзәтелни! Бу капитализм шартларында канга сеңгән төгәллек, үз сүзеңдә тору, вакытның кадерен һәм бәясен белү. Хәер, соңгы елларда безнең халык та мондый «вак-төякләргә» игътибар итә башлады булса кирәк... Ә кая барасың?!.

Шул ук Киевны гына ал. Марат анда берничә тапкыр булды. Барган саен гаҗәпләнеп кайта иде. Украина ун-унбиш ел элек үзен бәйсез дәүләт итеп игълан итсә дә, Киев, нигездә, урысча сөйләшә иде. Телеканалларда да москальләр теле хакимлек итә. Ниһаять, соңгы баруында Марат бу вәзгыятьнең кискен үзгәрүен күрде. Урамнарда, оешмаларда, кунакханәләрдә, рестораннарда украинча исәнләшү һәм сөйләшү гадәткә керә башлаган. Марат бу сәфәрендә татар проблемалары турында сөйләшер өчен Милләт мәсьәләләре буенча министр белән күреште. Карап торырга бу әфәнде йә яхүд, йә урыс милләтеннән кебек иде. Шулай да министр, ватып-җимереп, украинча сөйләште. Әңгәмә башында: «Гафу итегез, мин сезнең белән безнең дәүләт телендә сөйләшәчәкмен!»—дип белдерде һәм янына тәрҗемәчене утыртты. Монысы Марат өчен иде. Әңгәмә украин телендә барды. Мондый тәртип биредәге барлык хакимият даирәләренә дә үтеп кергән иде. Телевидениенең күпчелек каналлары да украинча сөйләшә башлаганнар.

Марат Татарстандагы хәлләрне искә төшереп утырды. Журналист халкы еш кына милли мәсьәләләрне тирәнтен аңлап бетерми—каләмгә ябыша, суверенитет, ике теллелек, кануннар, программалар турында «тиеш-кирәк» дип ачынып-һәвәсләнеп яза. Ләкин эшнең асылына төшенеп тору юк. Журналистның мантыйгы нигездә «без булдырабыз!» дип кәпрәюгә кайтып кала.Ә бит шырпы тартмасы кебек гади бер хакыйкать бар: милләтне, телне бары тик мөстәкыйль дәүләт кенә саклап кала...

***

Бу юлы вагонга шактый кеше кереп тулды. Күп тә үтмәде, Маратның купесында да бер пассажир пәйда булды. Шакмаклы кәчтүн кигән, житмеш яшьләр тирәсендәге урыс дәдәсе «Волга-Волга» комедиясендә бюрократ ролен башкарган артист Игорь Ильинскийга ике тамчы су кебек охшаган иде. Маратка бу адәмнең йөзе нишләптер бик таныш тоелды. Кайда күрешкән иде соң әле ул бу абзый белән?!.. Шактый азаплангач, баш миенең кайсыдыр бер почмагыннан, ниһаять, хәбәр килде: »Мәскәү-Тула» поезды! Французлар әйтмешли, бу дежавю иде. Утыз еллап гомер узса да, абзыкай үзгәрмәгән... ...Әйе, шик юк, бу библияне яттан белүче, үткер телле адәм! Марат аңа заманында Тулага әбисен озатып барган чакта тап булган иде.

Мәктәпне тәмамлаган чак. Әтисе Маратка: «Әбиеңне Тулага, Рәхилә апаңнарга илтеп кайтырга кирәк. Минем эшләрем күп... Сиңа да дөньяга чыга башларга вакыт...»

Марат мондый жаваплы эшкә үзен әзер дип саный иде. Авыл егете булса да, урысчасы яхшы, беләге нык, белем дә—11 класс! Нигә еракларда яшәп яткан газиз апаларын барып сөендермәскә? Житмәсә, әбисе дә кызларын сагына. «Как-никак» бер ел өйдән дә чыкканы юк. Саваплы гамәл!..

Киттеләр. Мәскәүгә ансат кына барып житкәч, Тула поездына утырдылар. Менә шунда очраштылар да инде алар. Бу абзыйның бөтен вагонга библияне пропагандалап баруын ике сәгать буе тыңлап торгач, әле генә комсомолга кергән Марат Сабиров түзмәде—бу дин тарафдары белән идеологик бәхәскә керергә булды.

—Дин халыкның башын әйләндерер өчен уйлап табылган әфьюн!

Бер мәлгә вагон ниндидер яшь шалканның авызыннан яңгыраган марксистик фикерне ишеткәч, тынып вә сагаеп калды. Чөнки заманасы шундыйрак иде. Кулына библия тоткан, сыек житен чәчен артка тараган абзый бәхәскә керергә ашыкмады. Ул комсомол егетнең һәр сәвит кешесенә мәгълүм атеистик шигарен көлемсерәп кабул итте. Аннары, кинәт библиясен ябып:

—Сез, яшь дустым, коммунизмга ышанасызмы?—дип сорады.

—Әлбәттә!—дип жавап бирде Марат, һич тә икеләнмичә.

—Менә бит!—диде ул, елмаеп.—Сез коммунизм булырмы-юкмы—белмисез, әмма партия программасын укып, аңа ышанасыз. Мин дә библиядә язылган ахирәтнең барлыгын белмим, ләкин ихластан ышанам... Бу очракта, дустым, без икебез дә берди түгелме?

Әбисе русча анламаса да, бәхәснең яхшыга бетмәячәген тоемлап, Маратка татарча дәште:

—Улым-жаным, зинһар, бәхәсләшмә кәферләр белән!—дип ялварды. Яшь атеист та мәктәп белеме генә төпле бәхәс алып барырга форсат бирмәвен анлап, әбисе янына кайтып утырды. Ул нык гарьләнсә дә үз-үзенә гыйбрәтле нәтиҗә ясады. Тиешле белемең булмаган килеш беркайчан да бәхәскә кермә!.. Зур сабак!..

Тулага барып житкәч, теге диндар адәмне кара кәчтүнле ике жидти кеше вагон төбендә каршы алды һәм култыклап, каядыр алып та киттеләр. Күп

тә үтмәде, Марат янына да милиция хезмәткәре килеп житте.

—Успокой свою бабушку, пусть немного подождет. А ты ненадолго пойдешь свидетелем...

Вокзал нәчәлнигe бүлмәсендә утырган ике яшь егет диндар абзыйдан сорау алып, протокол тутырып утыралар иде.

—Садись, комсомолец! А ты, между прочим, молодец, не растерялся...— диде борыны боксерларныкы сыман кәкрерәге, эчкә баткан төссез күзләрен Маратка төбәп. Бу адәмнең галәмәт зур колаклары баш сөягенә ике яктан жилем белән ябыштырып куелган сыман күренә иде.

—Не наш человек, ты Андреев! Не наш... Опять за старое?! Откуда библию взял? Где кстати, она? Куда ты ее спрятал, Андреев?!.

Абзый берни дәшмичә, тыныч кына утыра бирде. Ул арада бүлмәдәге вәзгыять борчулы вә киеренке төсмер ала башлады. Допрос алучыларның нервылары тартә тәжесе кебек тартылган иде. Марат вагонда библияне үз күзләре белән күрсә дә, аның кинәт югалуын криминал дип бәяләнүне күнеле белән кабул итмәде. Аңа калса, кеше теләсә нинди китап укый ала. Инквизиция заманалары түгел ич! Һәркемнең шәхси эше! Шулай да ул сизенә иде: библиянең булу-булмавы һәм кай тарафта юкка чыгуы бу очракта диндар абзыйның язмышын хәл итәргә бик мөмкин иде.

—Мин, шәхсән, библияне күрмәдем, иптәшләр!..

Абзыйны тоткарлаган вәкаләтле кешеләр аптырап Маратка төбәлделәр. Зур колаклының тешен шыгырдатуы ишетелде. Әле генә комплиментка ия булган яшь атеистка мөнәсәбәт кинәт үзгәрергә мөмкин иде.

—Ну ведь религиозную пропаганду он вел!

—Да, мы с ним спорили...Это был диспут... Товарищи, меня бабушка старая там ждёт... У нас вот-вот автобус на Щёкино уходит, товарищи!..

—Черт с ним!—диде ниһаять дәү колаклы оперативник, ишек төбендә басып торган милиционерга борылып.—Пусть подпишет протокол и уматывает! Отпусти комсомольца! Введи других свидетелей... Где Малик Салатов?

Маратның аркасына салкын тир бәреп чыкты, буыннары йомшарды. Ул арада ишектә яңа шаһитләр күренде. Йә Ходай! Беренчеләрдән булып бүлмәгә ныклы адымнар белән Малик атлап керде. Күрәсең, ул монда беренче тапкыр гына түгел. Кайдан килеп?! Ничек?! Ул нинди шаһит булсын! Вагонда аның эзе дә юк иде бит! Фамилиясе дә Салатов түгел, Изахов... Бик сәер! Ләкин бу мизгелдә Маратның бөтен теләге әлеге шомлы һәм тынчу бүлмәдән тизрәк чыгып ычкыну иде. Шөкер, Малик авылдашын әллә күрмәде, әллә танымады. Марат ул арада «выжт» итеп бүлмәдән чыгып шылды. Инде тәмам борчуга төшкән әбисен эзләп тапты.

—Әйдә, әбекәй, догаларыңны укы, тизрәк ычкынырга кирәк моннан!— дип каударланды онык. Алар кирәкле автобуска өлгерделәр. Шулчак Марат тагын бер гыйбрәтле кагыйдәне мыегына чорнап куйды. Кешене батырырга жиңел, ләкин ярдәм итәргә —ай-һай!..

***

Өч дистә ел узган очрашуны искә төшереп, диндар абзый белән бик гапләшәсе килсә дә, Марат беренче булып сүз башларга кыймады. Ләкин юлдаш үзе озак паузаларны өнәмәгән кеше булып чыкты.

—Сез кай яклардан, мөхтәрәм әфәнде?—дип кызыксынды урыс агае, колагын Маратка таба борып. Күрәсең, ишетүе чамалы иде.

—Мин үзем Казаннан. Журналист. Киевта командировкада булдым...

—Киев ошадымы сезгә?

Марат жавап бирергә өлгермәде, абзый үзенекен тезеп китте. Бераз

кычкырыбрак ул Киевта сәвит заманында ике мәртәбә кулга алынуын, төрмәдә утырып чыгуын, шәһәрнең тарихын, православ чиркәүнең Украина җирлегендә авыр көн күрүен озак вә озын итеп сөйләде. Болары Маратка бик кызык булмаса да, ул телдәр абзыйны бүлдерми генә тыңлап утырды. Беравыкка туктап калгач, Марат әңгәмәдәшенә үзен күптән бимазалаган сорауны бирде:

—Сезнең фамилиягез Андреев түгелме?

Бу сөаль Ильинскийга охшаш кешене аптырашка калдырды. Аның йөзе бер мәлгә сорыланып калды. Ул озын сөякле бармаклары белән купедагы өстәлдә барабан партиясен уйната башлады. «Дулкынлана!»—дигән нәтиҗә ясады Марат.

—Гафу итегез, без сезнең белән таныш түгел кебек...

—Утыз ел элек без сезнең белән бергә Тулага поездда барган идек... Сез әле бөтен вагонга библияне укып бардыгыз... Хәтерлисезме, аннан соң сезне Тула вокзалында КГБ хезмәткәрләре кулга алды?..

Ни ачык кеше шул мизгелдә күзгә күренеп үз-үзенә ябылды.

—Сез ялгышасыз, әфәнде... Мине кем беләндер бутыйсыз!..

Маратның һич кенә дә ялгышасы килми иде. Ул Туладагы очрашуның башка мизгелләрен дә искә төшереп, Андреевның телен чишәргә тырышты. Ләкин әңгәмәдәш купе читенәрәк кучеп утырды һәм авызына йозак элеп куйгандай булды. Маратка бу кешенең кинәт үз-үзенә бикләнүе һич кенә дә аңлашылмады. Монда мантыйк юк иде. Дөньялар үзгәреп, күпме сулар аккан, диндар адәмнәрнең тоталитар чорда влач тарафыннан җәберләнгәннәре, киресенчә, хәзер күкрәк киереп, мактанып йөри.

Ә бу адәм... Бәлкем, чынлап та, Марат бутыйдыр? Кызганыч, Маратка ул вакыйгаларның нәрсә белән тәмамланганын бик тә беләсе килә иде. Ярый, нишләп тә булмый. Марат бу юлы библия турында да тәфсилләбрәк сүз куертырга әзер иде, югыйсә... Бутаган тек бутаган... Ә күңел барыбер ышанмый. Бәлкем, заманында үзенең дөньяга карашы, дин тотуы аркасында бу адәм житәрлек михнәт кичергәндер. Бәлкем, аны җәберләп, тәүбәгә китергәннәрдер. Дөнья катлаулы нәрсә бит ул!..

Кондуктор киләсе станцаны игълан иткәч, урыс агае сумкаларын җыештыра башлады. Марат үзенең үҗәтлеген танып, юлдашыннан гафу үтенде.

Инде купе ишеген ачар алдыннан Ильинскийга охшаган абзый бер мәлгә тукталып, уйланып алды. Аннары кинәт Маратның колагына иелеп:

—Вы зря извиняетесь... Я тот самый Андреев. Я вспомнил... Спасибо Вам. ...Вы тогда меня здорово выручили... Только запомните, у нас ничего не изменилось! Прощайте!—диде һәм тиз генә купедан чыгып китте...

Уйлап карале син, нинди күрешү! Мондый фактны журналист гомер буе эзли бит! Җәл, төпле сөйләшү генә булмады. Ә бит Изахов-Салатовны Андреев, мөгаен, яхшы истә калдыргандыр. Чөнки Маратның иманы камил иде: мәкерле авылдашы, теләсә нинди ялган белән Андреевны батырырга КГБга нык ярдәм иткәндер әле. Һәм Андреев-Ильинский, бәлкем, бу хакта Маратка сөйләп биргән булыр иде дә...

***

Ә Марат тагын күзләрен йомып, уйга талды.

Поезд чаба да чаба... Ул бу җирдә яшәүче кешеләрне ташый. Баксаң, тимер тәгәрмәчле машина пассажирларны төрле яклардан бер үк маршрут буенча алып бара. Поезд-гомер машинасы. Әйе, бара да бара ул. Безгә хәтле дә йөргән, бездән соң да тәгәри. Юлаучылар кемнендер тарафыннан билгеләнгән станциядә һәм сәгатьтә төшеп калалар, ә поезд хәрәкәтен

дәвам итә. Тормыш вокзалларына ул үз вакытында һәм бик төгәл килеп җитә. «Балачак», «Үсмер чор», «Яшьлек» станцияләре... Аннан бик тиз «Өлгергән», »Җитлеккән» тукталышлары... Сизми дә каласың—«Картлык»ка килеп керәсең... Аннары—соңгы тукталыш... Поезд ахыр чиктә «Әҗәлгә» сәяхәт итә... Пассажирларны соңгы тукталышка, ягъни «Әҗәл» станцасына төшерә дә бoжра буйлап «Балачак»ка җилдертә. Һәм янадан юлга чыга. Поезд һаман хәрәкәттә...

Марат әҗәл турында уйламаска тырышты. Монысы котылгысыз. Өлгерербез әле... Бер борынгы акыл иясе әйткән бит: «Мин барда үлем юк, үлем килгәч мин юк.» Бу хакта уйламаска гына кирәк!

Ярый әле, дөньяда күңел дигән гаҗәп нәрсә бар! Аның канатына утырып тарихка да, киләчәккә дә, якын арага да, ерак космоска да хәрәкәт итә аласың! Тик без таможняны әле узмаганбыз һәм мона хәтле беркем дә бернинди кыңгыр-мыңгыр хилаф гамәлләрне башкармый һәм мөмкин хәтле үзен тыныч тотарга тырыша. Бер кило героин кыстырып баручысы да, нормадан күбрәк горилка, йә башка нindидер контрабандный товар алып кайтучысы да...

***

Әй, яшь чаклар, яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар;
Саламнан тәртә каерып,
Чикерткә җиккән чаклар...

Маратның әнисе үзенең яшьлеген искә төшергәндә шулайрак такмаклый иде. Әйе, үсмер чакларда ниләр генә кылмаганбыз! Бәлкем, чикерткә дә җиккәнбездер... Тик ул көннәр бик еракта, нindидер таулар, урман-сулар артында, җил-давылларда, зәңгәр томаннарда адашып калган...

Ул чорда Марат яшьтәшләренә түгел, өлкәнрәк кызларга гашыйк була иде. Ләкин мәхәббәт мәсьәләсендә өлгергән кызлар астан өскә, ягъни үсмерләргә түгел, зуррак егетләргә карый. Нишләргә кала?.. Кинолардагы геройларга мөкиббән китү, андагы чибәркәйләрне фантазияңдә иркәләп-сөю, алар белән бергә булу—һәрбер мыексыз үсмернең татлы шөгыле ул.

Шулай килеп чыкты ки, Марат гомер буе үзе күз салган кызларга хисләрен сиздермәскә тырыша иде. Шактый кыен нәрсә ул «маскировка» дигәннәре. Ләкин мәхәббәтеңне сиздермәү, каударланмау, кәртләрне вакытыннан алда ачмау ахыр чиктә максатка ирешүнең иң кыска юлы. Ул үсмер чактан ук күңеле белән сизенә иде: хатын-кыз мәхәббәтен яулар өчен үз-үзеңне күрсәтә белергә кирәк. Марат күзе төшкән кызны ихластан ярата, аңа бик тә игътибарлы булырга омтыла иде. Ул сөю дөньясын башта романтик рәвештә хыялында кора һәм шул сюжет буенча баруны мәхкуль күрә иде. Чынбарлыкта исә хыялый калыптагысы ул уйлаганча булмый да иде. Ләкин Марат Сабиров һәр гамәлен үлчәп, хатын-кыз белән араларны дөрес корырга тырыша иде. Егет булсаң—егет бул! Аның тиз арада танылып, барысын да шаккаттырасы килә иде. Шул максатка омтылу әзме-күпме матурлыкны бәяләргә өйрәтте, музыкага, җырга, спортка тартты. Кирәк чакта театрын да уйныйсың, клоун да булып кыланасың, биисең дә, җырлыйсың да. Вариантлар күп. Камиллеккә талпыну, кешеләрнең психологиясен өйрәнү, алар белән дөрес мөнәсәбәтләр кору үзе бер сәнгать! Марат балачактан бирле адәми затларның холкын өйрәнә, кызыксына, үзенең күңелендә аларның рәсем-портретларын ясый иде. Һәм еш кына андый шәхесләрдән гыйбрәт ала иде. Кеше дигән кроссвордны һәр көн чишәргә туры килә бит!

Ул заманнарда Яшь Тирәктән Мәскәүгә китеп урнашкан авылдашларның балалары җәйге каникулга кайталар иде. Бу үзенә күрә гамьсез авыл тормышына нииндидер яңалык, төрлелек кертә иде. Алар, нигездә, Маратның яшьтәшләре, ягъни унике-ундүрт яшьлек үсмерләр иде.

60 нчы еллар—авылларда сугыштан соңгы бала-чагаларның күтәрелеп килгән чагы. Алар кояш белән торып ат җигәләр, салам тарттыралар, тирес ташыйлар, утын яралар, тагын әллә нәрсәләр майтаралар иде. Менә шул балалар, эштә каешланып, вакытыннан алда җитлегеп балигъ булып китәргә мәҗбүрләр иде. Моны аларның үз-үзләрен тотышларыннан да, сөйләшүләреннән дә күреп була иде. Ә башкаладан кайткан үсмерләрнең бар кайгысы—су коену, кояшта кызыну, балык тоту, кичләрен клубка йөрү. Хөрәсәннәр! Аларга рәхәт!.. Тик бик тырышлары гына бәрәңге бакчасын утыйлар, чишмәдән су алып кайталар, әби-бабайларының вак-төяк йомышларын башкаралар.

Мәскәүдән кайтучылар арасында Маратның иң сагынып, көтеп алганы Растин бабайның оныгы—кара тутлы, чандыр, күзләре шомырттай янып торган, бик сөйкемле, исеме җисеменә туры килгән Гөлшат. Хәер, Гөлшатны бер Марат кына түгел, авылдагы башка яшь җилкәнчекләр дә зарыгып көтеп тора. Кыскасы, Мәскәү чибәркәе артыннан егетләр дәррәү чабалар иде. Ул баштарак ярым шәһәрчә сүзләр кыстырып, ә җәй ахырында инде бөтенләй татарча сөйләшеп, тотышы белән дә, эшчәнлеге илә дә авыл кызларыннан бер нәрсәсе белән дә аерылмый иде. Шунысы кызык: егетләр каникулның беренче яртысында Гөлшат артыннан көтүе белән чапсалар, җәй ахырында бу ажиотаж бераз кими иде. Растин бабайның тынгысыз көннәре, төнге нәүбәтләре нәкъ менә шул чибәр оныгы кайтып төшкән чорда башлана. Аның кечкенә генә алма бакчасы шәһәр кызы Гөлшатның йөрәген яуларга дәгъвачылар белән сугыш кырына әйләнә. Көчләр тигез түгел: беръяктан—мәхәббәткә исергән таза-йомры авыл егетләре, икенче яктан—шәхси милекне, ягъни алма, алмагачларны, каралты-кураны һәм, әлбәттә, яраткан оныгын көтеп, саклап поста торучы кыска тәртә белән коралланган сугыш инвалиды. Резервта тагын бер хәрәкәтчән корал—Растин бабайның чуваштан ияреп кайткан «Банзай» атлы йокламас усал эте бар. Койма башыннан йөргән Хәлилләрнең тактикасы яшь чибәркәйне клуб белән Растин бабайның йорты арасында тотып алу. Һич булмаса, капканы һәм абзар ишекләрен блокировать итү. Гадәттә төнге нәүбәтләр егетләргә уңыш китерми. Чөнки Гөлшат Мәскәүдән кайткан мәлгә еш кына партизан сукмакларыннан йөри. Маратның апасы Гөлнур белән аларга кайта. Растин бабайның йорты Маратлар белән күрше генә. Ә инде нинди батыр йөрәкле булсалар да, егетләр мәктәп директоры Мифтахның йортын урап узарга мәҗбүр. Дарысы да кызу, район белән элемтәләре дә яхшы... Кыскасы, мондый очракларда отышта Марат кала иде. Кунак кызы очрашуга үзе өйгә килә. Таң атканчы сөйләшүләр, беренче үбешүләр лапастагы печәнлектә апасы йоклап киткән чакларда булды да инде...

Марат аңлый: Гөлнур аның беренче мәхәббәт белән дөрләвен сизенә иде. Гөлшат үзе дә ыспай авыл егетләрен янга калдырып, яшьтәше, унбишне генә тутырган Маратны яратты бит! Очрашулар көндезләрен дә килеп чыга. Гөлнур белән Гөлшат бик килештерәләр, уртак серләре байтак. Әлеге дә баягы кое да үзенең ролен уйный. Гөлшат еш кына Маратларның коесына суга керә. Җүләр генә мондый форсатны ычкындырырга мөмкин! Андый чакта Марат бер мизгелдә кое янында пәйда була. Чын егет кеше кызлардан чиләк күтәрттерәме соң инде?! Шту син!.. Су алганда кичке планнар тәгаенләнә. Кунак кызын Сабировлар еш кына чәйгә дә чакыралар иде. Мондый форсатлардан файдаланган Маратның башы күккә тигәндәй

йөри. Шулай да бу самими мәхәббәтнең юлында бер киртә бар иде барын. Нишләптер Гөлшатны Маратның әбисе яратмый иде. Дөресрәге, Мәскәү кызы анын саруын кайната иде. Чөнки ул Гөлшатнын нәсел-нәсәбәсен бик яхшы белгәнгә, алардан ерак торыгыз, дип гел чәпчи иде. Имештер, анасы хәмер белән мавыга, әтисе дә шундыйрак, кыскасы, әхлакый яктан дөрес кешеләр түгел... Бу дәлилләр Маратның гакылына барып житми, йөрәгендәге гыйшык утында каен тузы кебек «гөлт» итеп янып бетә иде. Әби—әби инде ул! Аңлап та житкермәскә мөмкин. Монда бит әле иртәгә өйләнергә жыенган кеше юк! Миңнегөл исә үсмер улынын хисләрен аңлап, бу самими мөнәсәбәтләргә һич кенә дә каршы килмәде, кысылмады. Әлбәттә, ул үсмерлектә дуслашып йөргән бала-чаганың гыйшык-мыйшык уеннарының ни дәрәжәдә житди икәнен яхшы аңлагандыр. Көндезләрен әбисе еш кына кунакларга киткәндә Гөлшат, Гөлнур һәм, әлбәттә, Марат өйдә рәхәтләнеп күнел ачалар иде. Патефон, радио уйнаталар, сүзләргә нindидер ижекләр кушып, башкаларга аңлашылмый торган телдә сөйләшә иделәр. Мәсәлән, Гөлшат Маратка: «Миснин сиснине яснаратам!»—ди. Сөйгәне шундук: «Миснин дә сиснине өснезелеп яснаратам!»—дип жавап кайтара. Андый аралашулар, серле елмаюлар, бергә уйнаулар, тау башына барып чәчәк, жиләк жыюлар... Аннары зарыгып кич житкәнен көтүләр... Марат, гармунчы булганга, аны зурраклар яшьләр жыелган жирдән башка үсмерләрне куган кебек йә колагын борып, йә артларына тибеп кайтарып жибәрмиләр иде. Чөнки гармунчы—һәрчак кирәкле кишер яфрагы. Шул ук вакытта кичә тәмамлангач, кызларны ауларга чыккан өлкәнрәк арыслан-юлбарслар вак-төяк жанварларны чината-чината куып жибәрәләр иде. Монда инде гармунчы да, биюче дә—барысына да бер метла. «Барыгыз, маңкагызны агызып йөрмәгез, чабаклар, югыйсә, әнкәгез эзләп килер!..» Ә Гөлшат белән Марат төнге маршрутны көндез үк сөйләшеп куйган...

Булган ул беренче мәхәббәт, Марат Мифтахович, булган! Аның күп нечкәлекләре инде онтылган. Тик яшел болыннардан чәчәк жыеп, сөйгәненә бүләк итүләр хәтердә. Урман, елга, бал исләрен сеңдергән букетларга мең төрле мәгънә салына. Шуңа да аны иясенә бүләк иткәч, саклап, кадерләп тоталар. Менә шушы эчкерсез, самими сөю хисләрен тирәнтен татыган ике йөрәк вакыт көзгә алышкач, елаша-елаша аерылышалар иде. Аннары Мәскәү белән Яшь Тирәк арасында «Лети с приветом, вернись с ответом!» дип пичәтләнгән сөю хатлары йөри башлый ...

Бу вакыйгалардан соң байтак гомер узгач,Марат, армиядән кайту белән, Мәскәү якларына барып чыкты. Һәм Гөлшатны эзләп тапты. Кызганыч, аның әнисе вафат булган, ә бер энекәше төрмәдә утыра иде. Житмәсә, язмыш Маратның беренче мәхәббәтен шундагы бер урыс белән бәйләгән икән. Нindидер жинаятьләр кылып, анысы да тимер рәшәткәле йортка эләккән. Мәскәүгә килеп күрешкәч, Марат Гөлшатның башы шатлыктан түшәмгә тияр дип уйлаган иде, ләкин алай булып чыкмады. Әйе, башына матур ак шәл бөркәнгән Гөлшат, күп еллар үтсә дә, табигать биргән гүзәллеген, нәфислеген жуймаган иде. Тик бу инде бөтенләй башка, үз эченә ябылган хатын-кыз иде. Ул Маратны үз фатирына алып кайтты. «Мин хәзер үзем генә яшим,»—диде Гөлшат, кемгәдер үпкәләгән сыман. Авыл хәлләре турында да әллә ни төпченеп тормады. «Ишеттем, Гөлнур кияүгә чыккан... Ике баласы бар икән... Мин шат. Сәламемне житкер...» Кунак егете туган яклар, Растин бабай хакында бер-ике жөмлә өстәп куйды. Сөйләшү бәйләнмәде. Гөлшатның фатирына кергәч, Марат андагы фәкыйрьлекне күреп хәйран калды. Бүлмәләр пөхтә булса да, бер пыяла шкаф, сигарет төпчекләреннән көйрәп, уелып беткән, озынча агач өстәл, бер-ике ярымватык урындыктан гайре жиһаз күзгә чалынмады. Чәйнек

кайнап чыккач, Гөлшат кайдандыр ике пыяла стакан, шикәр кабын чыгарып өстәл әзерли башлады. Шул мизгелдә Маратны тетрәндергәне—Гөлшатның башындагы матур шәлен салып, өстәлгә эскәтер урнына җәеп куюы булды!.. Кунакның үзе белән кучтәнәчләре дә, тәүге мәхәббәте белән көрешүне билгеләп үтәргә дип алынган яхшы шәрабы да бар иде. Ләкин шәл-эскәтер җәелгән озын өстәл артында да озак утырмадылар. Сөйләшү тагын килеп чыкмады. Әйтерсең лә, озын агач өстәл кайчандыр бер-беренә гашыйк булган ике кешене упкын кебек мәңгелеккә аерган. Алар агымсуның ярларында басып калган Сак белән Сокны хәтерләтә иде. Күрәсең, Гөлшат бик авыр хәлдә яшәгән, бу төрмәдә утыручы энекәше дә, яраткан дусты да аның бөтен җелеген суырганнар. Бер дистә ел элек хыял канатларында очкан, самими тәүге мәхәббәт кичергән ике бәхетле яшүсмерне инде берни дә бәйләми иде...

Шуннан күпмедер вакыт узгач, Маратның энекәше Илшат авылдан Казанга килеп чыкты. Мәктәпне тәмамлап, абыйсы янына урнашырга килгән. Авыл хәбәрләре турында сөйләшкәндә Илшат кинәт әйтеп куймасынмы:

—Абый, күптән түгел Растин бабайларга Мәскәүдән Гөлшат апа кайтып төшкән иде. Үзе генә...

—Йә, шуннан?..

—Ул миңа Мәскәүгә җибәрерсең дип бер хат тапшырды... Хаты ябыштырылмаган да... Менә...

Маратның гомерендә дә кеше хатларын укыганы булмады. Ләкин бу юлы пичәтләнмәгән конвертта нидер, үзе өчен бик мөһим хәбәр барын тоемлады.

—Пичәтләмәгән дисеңме? Йә, укы, алайса. Бәлкем, безгә дә ирештерергә теләгәндер...

Илшат русча хатны тырыша-тырыша укыды. Гөлшатның җанкисәге Викторга язылган мәктүбендә ярдәмчел Сабировлар гаиләсенә рәхмәтләр юлланган, авылда яшәгән туганнары турында ниндидер сүзләр әйтелгән иде. Марат соңгы бер-ике җөмләгә аеруча игътибар итте. «Сөеклем, мәхәббәтем минем... Бары тик сине генә яратам. Көтәм...» Ләкин болары Маратка түгел, ә төрмәдән башы чыкмаган урыска адресланган иде.

—Житте!—дип кычкырды энекәшенә Марат.—Миңа барысы да аңлашылды! Мин дә Сәрия апаңны бик яратам!..

***

Авыл, әти-әни, туганнар, Бола елгасы... Зөяләргә, аннары Иделләргә таба чаптыра-чаптыра ага ул. Шул авылны бизәп торган елганы хәзер ничек кенә мәсхәрәләмиләр! Крахмал ширкәтләре, дуңгыз фермалары, ашлама, солярка складлары, гади адәми затлар—һәркайсы үзенең пычрагын, калдыгын, чүбен сүзсез аккан Болага ташлый. Шуннан соң аның ярларына «Саклан, зараза!»—дигән шигарь элеп, якын бармыйлар дип уйлыйсызмы?! Юк шул, адәм баласының холкы хикмәтле: ул үзе пычраткан суга тартыла. Шунда коена да, балыгын да тота, насос куеп, бакчасына Боланың суын да сиптерә. Елга татар белән чуаш арасында гайре рәсми чик булып та тора. Кышларын ике ярда яшәгән бала-чага, үсмерләр ара-тирә аяусыз милләтара «сугышлар» алып бара. Гадәттә, «җиһат» беренче кан пәйда булу белән туктала. Кайсы милләтнең көчлерәк икәне имгәтүләр, баш ярулар кебек рәхимсез гамәлләр белән саналмый. Монда сугышчыларның саны һәм кинәт хәрәкәт итүләре, йодрыкларның житезлеге тактик өстенлек бирә. «Ура» кычкырып, боз өстеннән күрше ярга кысып чыгарган, ягъни «дошманны» чигенергә мәҗбүр иткән як җиңә...

Язларын ярларыннан ташып, дуамалланып аккан Бола ешрак чуаш пиччәләрен, ара-тирә көмешкә белән мавыккан татар абзыйларын да Зөягә агызып китә. Тик бу Боланың күргән рәнжешләре өчен адәмгә бармак янавы гына әле. Яшь Тирәкнең аскы урамнарын язын ташыган йөгәнсез Бола һәр елны текә ярларын уеп, ихаталарга, йортларга якыная бара. Менә монысы куркыныч! Ләкин бүген авылда ул хакта уйлаучы юк кебек—адәмдә яшәү кайгысы. Ә Бола өчен чуаш кайгыртсын!.. Ничек язган—шулай булыр... Хәлләр болай барса, Бола ун-унбиш елдан астагы урамнарны юып, калкулыктагы зиратка да килеп җитәр... Ә анысы татарныкы бит анын!..

Марат, җае чыккан саен, авылга кайтып, балачакларны, үсмер чорларны искә төшереп, хисләнеп, йөрәкнең януларын басып, хәтер янартып килә иде. Озак кайтмый торсаң, хәттә чуаш пиччәләре, җингиләре сагындыра башлый.

Хәзер инде авылга кайткач, зиратны әйләнеп кайту Маратнын иң тәүге гамәленә әверелде. Изге җаннар ахирәткә иртә һәм кинәт китәләр: әнисе Миңлегөл, энекәшләре Камил, Илшат, Рәмис янәшә яталар. Бакыйлыкта якын кешеләр торган саен ишәя, ә фани дөньяда азая бара. Шундый монсу диалектика. Авылдан Казанга китер алдыннан Марат һәр кат ихатаны әйләнеп чыга. Кайсыдыр ишектән башына ак шәлен ураган әнисе килеп чыгар да юл догасын укыр кебек тоела аңа...

***

Ул елны Марат Сәрия белән Кавказга ялга китте. Бер-ике атна үткәч Кисловодскига энекәше Илшат белән Лилия дә килеп төште. Кавказ тауларында бергәләп төрле экскурсияләргә, кафе-рестораннарга, шашлыкларга кинәнеп йөрделәр: кайда җәяү, каядыр машина белән. Кисловодски тирәсендәге атаклы тауларга менеп, анда истәлеккә төсле тасмалар бәйләп калдыргач, бер матур көнне Домбайга сәяхәт кылдылар.

...Иксез-чиксез таулар, кыялардан шаулап аккан салкын шарлавыклар, шифалы һәм кинәт үзгәрүчән һава. Бормалы юллар, тирән упкыннар, гаҗәеп яшел, куе урманнар. Әйтерсең лә, ошбу табигатьнең гүзәллеген һәм кырыслыгын, таулардан ыргылып аккан елгаларның тизлеген кайнар канлы кавказлылар үзләренә сеңдергән...

Таулы юллардан машина Домбай якларына элдертә. Инде Кисловодск күптән арттa калды. Борылмалы серпантин юллар сәяхәтчеләрне Зур Кавказ сыртына күтәрә. Машинаның гына түгел, анда утырганнарның да тыны кысыла. Кыялы юлдан барганда ешрак өскә карыйсың. Шулай да вакыт-вакыт түбәнгә күз саласы килә. Ә карасаң... Андагы куркыныч гүзәллек, теләсәң-теләмәсәң дә, хәтергә мәңгегә сеңеп калыр сыман...

Сабировларның юлдашы—карачай егете Рәшит, яшь чакларын искә төшерә-төшерә, биредәге берән-сәрән урнашкан авыл-шәһәрләр турында сөйли.

Кырыс чырайлы, шат күңелле бу ир уртасы карачай халкынын фаҗигале язмышын тик бер тамчы гына татып өлгергән икән.

—Мин Казахстан далаларында тудым гына... Биредә таулар арасында үстем,—ди Рәшит ничектер горурланып.—Турысын әйтим: миңа повезло...

Карачай теле безгә дә аңлаешлы икән. Аңлашылмаганнарын Рәшит русчага күчеп аңлата. Ничек соң әле тау егете әллә кайлардагы Казахстан далаларында туган?

—Ярый әле миңа анда туарга гына насыйп булган. Ә бит халкым шунда, сөргендә дистәләгән еллар газап чиккән,—ди Рәшит, тирән сулап.

Әйе, рәхимсез рәвештә илдән сөрелгән кардәшләребез хакында без

нәрсә беләбез соң? Бар белгәнебез рәсми пропаганда тарафыннан уйлап чыгарылган бер җөмләгә сыя: фашистларга сатылган кырым татарларын, чичән, карачайларны һ.б. Кавказ халыкларын сугыш бетәр-бетмәс Урта Азиягә сөргәннәр...

Ә бит бу җәберләнгән милләтләрне яклап, шул ук елларда чит илдә яшәүче кешеләр, бигрәк тә галимнәр, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкырганнар. Тик бер илдә—Совет илендә генә аларны ишетүче булмаган. Уйлап кара: Норвегиядә яшәүче бер галим дистәләгән документларга таянып, карачай халкының сөргендә булган фаҗигале язмышын төпләп өйрәнә, китаплар яза, рәнҗетелгәннәрне яклап чыга, советларны геноцидта гаепли.

Рәшит кавказлыларны ерак сөргәнгә төяп озату өчен НКВДның зур гаскәри операцияләр уздыруы хакында сөйләде. Җирле халыкка җыенырга нибары бер сәгать вакыт бирелгән. Кулга йә бер сумка, йә бер төенчек кенә алырга рөхсәт ителгән. Халыкны хайван ташый торган вагоннарга төяп, ерак сөргенгә алып китәләр. Күпләр өчен бу соңгы сәяхәт була...

Ниһаять, 1957 нче елда хөкүмәт нахакка рәнҗетелгән халыкларга туган җирләренә кайтырга рөхсәт итә.

Кызыклы әңгәмә юлны кыскарта диләр. Сәяхәтчеләр, гапләшә-сөйләшә Кавказның гүзәл җиренә—аның җәүһәре Домбайга якынлаштылар. Юл читендә үсеп утырган чыршы-наратлардан шифалы һава аңкып тора, тирәюньдә без белмәгән кошлар сайрый. Аска төшкән саен, таулар биегәеп кала сыман. Аларның түбәләрендә ак шәлъяулыкны хәтерләткән кар катламнары күренгәли. Шул чак машина кинәт тизлеген югалтып «тып» итеп туктап калды. Сул яктан выжылдап, бер-бер артлы унлап милиция машинасы узып китте.

—Бу ни хәл? Болар кемнәр, кая бара?—дип кызыксынды Илшат шофердан.

—Черкесск шәһәренә Дудаев килергә тиеш дигәннәр иде. Шул түгелме икән?..

Дудаев! Нишләп йөри ул бу якларда?! Югыйсә, Россия газеталары язуынча, Дудаев Грозный шәһәреннән беркая да чыгып-китеп йөрми, шунда посып ята.

Домбайдагы табигатькә ничек кенә гаҗәпләнеп-сокланып йөрсәк тә, чечен генералы Маратның күнеленнән чыкмады. Илшат та бу шәүкәтле шәхесне бик күрергә тели иде. Сораша-белешә торгач, шунысы да мәгълүм булды: Чечен президенты Карачай халкының корылтаена юл тоткан икән...

Берничә сәгатьтән Домбай тауларының гүзәллеген, биредәге халыкның кунакчыллыгын ихластан тоеп, Сабировлар Кисловодскига таба кайту юлына чыкты. Көн кичкә авышкан иде. Черкесск шәһәрендә бина таба алмаганга күрә корылтайның урамда уздырылуы, рәсми хакимият вәкилләренең анда катнашмавы, әмма бу җыенда Дудаевның ялкынлы чыгыш ясавы хакында хәбәр тиз таралды. Шулай килеп чыкты ки, Маратларның микроавтобусы чечен генералы кавалькадасының артыннан, аның эзенә бастырып барды. Рәшит тә Татарстаннан килгән дусларын батыр йөрәкле генерал белән таныштыру теләгеннән кавказлыларча дөрләп яна иде. Вәгъдә—иман!..

Ул арада караңгы төшә башлады. Озак та үтми, Маратларның машинасы халык күпләп җыелган ниндидер бер җиргә тукталды. Монда бәйрәмнең төп исе тауларга-үзәннәргә таралган иде. Бер яктан кавказлыларның бер урында тик утыртмый торган музыкасы, барабан сугулары, икенче яктан төрле телләрдә сөйләшкән халык, борыннарны кытыклаган шашлык исе...

Бернича сәгать элек юлда очраган милиция машиналары да шунда. Димәк, Дудаев биредә! Тиздән Рәшит әфәнденең «разведка»сы өстәмә мәгълүмат китерде: Дудаев һәм аның министрлары карачай халык вәкилләре белән елга буендагы кафеда чәйләп утыралар икән. Шулчак Маратның башында Чечен президенты белән очрашып, интервью алу нияте туды.

Бу теләкне, Илшат белән Рәшит тә хупладылар. Хатыннар чечен хәрбиләре белән эш итүгә теше-тырнаклары белән каршы чыкты. Ләкин төрки халыкларда баш муен белән озак сөйләшеп тормый. Ирләр «эшне» кызу тоттылар. Елга буенда җыелган жирле халык вәкилләре татар кардәшләренә бик теләп ярдәм иттеләр. Өч кешелек делегация кафега таба юл алды. Ләкин автомат тоткан сакчылар каршыга чыкты. Озатып баручыларның:

«Бу әфәнделәр Татарстан журналистлары»,—дигән сүзе юлларны ачты. Әмма бернича метр узгач, делегация каршында кара кием кигән таза егетләр пәйда булды. Болары автомат, рация белән коралланганнар иде. Инде кафега биш-ун метр калгач, электр уты яктысында каршыга янә дүрт-биш сакчы чыкты. Болары кәчтүм-чалбар, модалы җәйге күлмәкләрдән иде, ләкин баштан-аяк коралланганнар. Сакчылар, төпченә-төпченә, төрле сораулар бирделәр.

Татарстан журналистлары... Берсе, елмаебрак: «КГБдан түгелме соң?»—дип шаяртып алды. Вәзгыяте шундый бит!.. Генерал Дудаев кебек көрәшче йөз елга бер туа! Аның гомерен ничек сакламыйсың! Бу җидти кешеләр арасында мәзәк сүз әйтергә нигәдер тел әйләнмәде. Ул арада Дудаевның тән сакчылары кунакларны кафеның ихатасына алып керделәр. Банкет барган зур бүлмәнең ярымачык ишеге төбендә чал чәчле бер хәрби: «Сизгә бираз бикләмәк кирәк!»—дип ымлап, агач эскәмиягә күрсәтте. Баш сакчы билгеләгән урынга утыргач, журналистлар банкет залыннан тиешле фәрман көтә башладылар. «Татарстанда ничек яшисез?», «Татарлар—зур милләт, сез җиңәчәксез!», «Бездән сәламнәр әйтегез!»—диештеләр ихата эчендә җыелышкан сакчы егетләр.

Ниһаять, өстәл башлыгы соңгы тостны игълан итте булса кирәк. Кафедан «Азатлык!»,» Бәйсез Ичкерия!», »Генерал Дудаев шәрәфенә!» дигән сүзләр яңгырады. Шул мизгелдә ишек ачылды һәм инде түземлекләрен жуя башланган кунакларны кафега чакырдылар. Банкет залында унбишләп кеше, чечен вәкилләре, балкарлар, хужалар—карачайлар бар иде. Араларында чал чәчле бер урыс кешесе дә күренде. Аңа аерым игътибар вә хөрмәт күрсәтелүе сизелеп тора иде. Бу сөрелгән халыкларны яклаучы рус галимнәренең берсе икән.

Ниһаять, Марат белән Илшат Президент Җәүһәр Дудаевка якынлашты һәм аларны таныштырдылар. Бераз алгарак чыккан Марат:

—Бу очракта сезнең белән интервьюны Мюнхендагы татар-башкорт «Азатлык» радиосы өчен алам,—диде.

—Бик яхшы,—диде Президент йомшак куллары белән кунакларның кулларын кысып. Бу чандыр гәүдәле, мыеклы, эшләпә кигән кешенең әкрен, әмма үз-үзенә нык ышанып сөйләгән сүзеннән, тыныч йөзеннән ниндидер аңлый алмаслык эчке бер көч һәм үзенә җәлеп итә торган аура балкып тора иде. Кемнәрдер автограф алган арада, абыйлы-энекәш өстәл артына утырдылар. Алар артына ике яктан автомат тоткан егетләр кереп басты. Ялда булганга күрә, Маратның кулында кечкенә генә бер блокнот һәм кемнәндер алып торган ручка бар иде. Сораулар күптән уйланып, әзерләнеп куелган иде инде.

—Рәхим итегез!—диде Дудаев, Маратка ымлап.

—Сезнең бирегә килүегезнең максаты нидән гыйбарәт?

—Мине карачай халкының корылтаена делегат итеп сайладылар. Килмичә булдыра алмадым. Язмышыбыз уртак, динебез бер... Бүген безгә берләшергә кирәк!

—Корылтай ничек узды?

—Без Россия хөкүмәтенең милли мәсьәләләрдә элеккеге империячыл сәясәт алып баруын күреп торабыз. Тик биредәге җирле администрация корылтайга шул хәтле ачык каршылык күрсәтер дип уйламаган идем. Делегатларга—кунакханәләрдә урын, корылтай уздырырга зал бирмәгәннәр, утны өзгәннәр!.. Тик андамы соң эш?! Корылтай узды, карачай халкының иң акыллы, иң батыр уллары хәрәкәт башында.—Ул янында басып торган кунакларга ымлап күрсәтте.—Халык янә бер тапкыр үзенең бәйсезлеген ачыктан-ачык игълан итте.

—Сез Татарстан хөкүмәте белән элемтәдә торасызмы?

—Әлегә юк, кызганыч, без сезнең Президентыгыз белән очраша алмадык. Мондый эшләрдә телефоннан аралашу гына нәтиҗә бирми. Татарстан җитәкчеләренә йөзебез ачык. Бүген үк очрашырга әзербез. Әлбәттә, алар да шундый теләк белдерсә.

—Чечен республикасы Россия белән алга таба нинди мөнәсәбәтләр корыр?

—Без тулы бәйсезлек өчен көрәшәчәкбез. Без һәр халык үз язмышын үзе сайларга, билгеләргә тиеш, дибез. Мәскәү әлегә бу хакыйкатьне аңламый һәм аңларга теләми дә. Шуңа без инде үзәк хакимияткә ышанмыйбыз. Алардан мәрхәмәт көтмибез.

—Россия телевидениесеннән еш кына: «Грозныйда Дудаевка каршы оппозиция берләшә, Республикада эшләр харап,»—дип оран салалар. Бу хакмы?

—Билгеле инде, безнең сүзләр дә, сәясәт тә, хәрәкәт тә Мәскәүгә ошамый. Милли азчылык турында уйдырма тарату үзен демократик дип игълан иткән Россия газеталары һәм телевидениесенең бүген төп эшенә әверелде. Бездә андый оешкан оппозиция юк. Төрлечә фикерләү бар. Бу—табигый нәрсә. Без аның өчен беркемне дә эзәрлекләмибез.

—Сез үзегезнең язмышыгыз өчен борчыласызмы?

—Юк. Мин инде күптән беркемнән дә курыкмыйм. Алладан башка, әлбәттә. Азатлык өчен көрәшү—иң авыр юл. Әле беркемгә дә азатлыкны китереп биргәннәре юк...

Шушы сүзләрдән соң Маратка генерал ярдәмчеләре интервьюны тәмамларга кирәк, вакыт бетте, дип ишарәләде.

Әңгәмәнең тәмамлануын сизеп, тирә-юньдәге кунаклар ашыга-ашыга кесәләреннән кәгазьләр, блокнотлар чыгарып генералдан автограф алырга керештеләр. Рәшит әфәнде дә Җәүһәр Дудаевка үзенең автомобиль йөртү таныклыгын сузды. Күрәсең, башка нәрсәсе табылмаган. Мин аңа әкрен генә терсәк белән төрттем. Янәсе, нишлисең, син бит Рәсәй җирлегендә яшисең. Туктатып интектерерләр үзеңне...

—Ә-ә, юк , киресенчә, алар безгә честь биреп калачаклар. Ул бит Дудаев имзасы!..

Генерал, ниһаять, автографлар өләшеп бетерде һәм урыныннан кузгалды.

—Беләсезме, Татарстан Россиянең йөрәгендә, аннан бик күп нәрсә тора. Онытмагыз, бирешмәгез, алданмагыз. Ә без—тау халкы. Без хәтәр сукмаклардан йөрергә өйрәнгән. Без артка чигенмәбез. Барыгызга да күп сәлам!

Дудаев хөрмәт белән кунакларның кулын кысты. Сакчылар Казан вәкилләрен микроавтобуска хәтле озатып куйдылар. Хатыннары елашып,

югала язган ирләрен кочаклап алдылар. Исән-имин икәннәренә ифрат шатландылар. Ул арада Дудаев командасы юлга чыкты. Тауларга куе томан төшкән иде.

—Һай, ничек кайтырбыз?..

Дудаев машиналары «выжт» итеп күздән югалды. Тик Рәшитнен микроавтобусы урныннан кузгалмады. Чөнки юлда бер генә нәрсә дә күренми иде .Куе томан. Унда—упкын, сулда—кыя, алда—күренми торган тар гына юл. Барып кара!

—Ничек соң әле Дудаев мондый тизлек белән китеп барды,—дип гаҗәпләнде Марат.

—Ул бит—Җәүһәр!—дип горурланып җавап бирде Рәшит...

***

Чираттагы станция, чираттагы пассажирлар. Тимер юл хезмәткәрләре, әйтерсең лә, Маратның купесына махсус рәвештә хикмәтле кешеләрне сайлап, утыртып баралар. Әйтергә кирәк, проводник та, яшь кенә маржа да Маратка артык игътибар итә кебек тоелды. Купены кирәксә-кирәкмәсә дә юып-себереп чыга, чәйен китерә, елмаеп кына сөйләшә. Бу юлы купега өстенә гади генә шакмаклы күлмәк кигән, чем кара күзле, очлы бөркет борынлы кавказлыга охшаган бер адәм килеп керде. Аның күзләре бик сагышлы, борчылулары йөзенә чыккан иде.

—Сез әзериме?—дип сорады Марат, танышырга теләп.

—Юк, мин—чечен!

—Хуп, мин дә мөселман... Татар... Казаннан—Марат.

Кавказлы бераз йомшарып:

—Әссәламәгаләйкем, мин Әмир булам...

Сөйләшеп киттеләр. Тәгәрмәчләр көенә Марат әкрен генә бернечә ел элек Домбай якларына кылган сәяхәтләрен искә алды. Чеченнның милли көрәшчесе инде һәлак булган генерал Дудаев белән очрашуны журналист кулына сирәк эләгә торган бәхет кошы дип тәфсилләп сөйләде.

Маратның бу хикәятен тыңлап торган Әмирнең күзләре тагын да монсулана төште. Ул, гафу үтенеп, тамбурга тәмәке тартырга чыгып керде. Күпмедер дәшми баргач, чечен кардәш сөйләп җибәрде:

—Сез, мөселман кардәшем, Җәүһәрне идеаллаштырасыз... Монысы сезнеңчә. Ельцин, Дудаев... Бәйсезлек... Ул чакларда мин дә шулай һәвәсләнеп йөрдем. Ләкин Россия—Чечня сугышы ул хәтле рәхимсез, канлы булыр дип уйламаган идем! Уйлап кара, кардәшем, ул сугыш минем яраткан хатынымны, өч баламны, биш ир туганымны юк итте!..—Әмирнең күзендә яшьләр күренде.—Миңа нишләргә?! Ничек яшәргә, әйт, кардәшем! Газиз балаларым, туганнарым, хатыным һәр төн төшемә керә!.. Мин аларны сагынам. Беләсеңме, туганкай, мин хәзер үткәннәр белән генә яшим! Мин, кардәшем, яшәүнең бернинди мәгънәсен күрмим!.. Менә күрше купеда бер ир белән хатын бара. Минемчә, алар да татарлар. Тәмәке тартырга чыккач, ул кеше миңа беләсезме нәрсә ди?!

Марат Әмирнең күзләренә төбәлде. Чечен кешесе аның колагына иелеп, пышылдады:

—Бу поездга Харьковта өстәмә бер вагон такканнар. Анда командировкадан кайтып килүче утызлап хәрби бара икән...

—Шуннан?—дип сорады Марат, кызыксынуын тыялмыйча.

Әмир тагын да якынрак иелеп:

«Менә тот та шартлат үзләрен! Кровная месть будет!»—ди бу адәм. Уйлап карагыз, бер белмәгән кешегә, курыкмый-нитми, дистәләгән җан иясен юк итәргә куша...

Марат туалетка барганда күрше купедан бер таныш кешенең чыкканын күргәндәй булган иде. Ләкин абайламый калды. Кем булды соң әле ул?!

Әмир тирән сулап куйды.

—Әйе, чечен икән—террорист, чечен икән—үч ала... Беләм, безнең халык белән Рәсәйдә хәттә бишектәге сабыйларны куркыталар. Ләкин минем беркайчан да кешегә кул күтәргәнем булмады! Аңлыйсызмы, бу зур гөнаһ!.. Андый гамәл минем иманыма, динемә, холкыма туры килми... Ул хәрбиләр дә бит кемнеңдер балалары. Без барыбыз да Алла тарафыннан яратылган җаннар. Барыбыз да Алла каршына барабыз. Шунда һәркем җавап тота, тиешле җәзасын ала. Шул исәптән канлы Рәсәй-Чечен сугышын башлаучылар да...

—Ул сугышта җиңүчеләр дә!—дип өстәде Марат.

Чечен кешесенең ихластан сөйләгәненә Марат инана иде. Ул биштәреннән үзенең соңгы җыентыгын алып, имзалап Әмиргә тапшырды.

—Кайчан да булса укырсыз. Монда төрле язмалар бар. Шул исәптән Дудаев белән очрашу турында да...

—Рәхмәт кардәшем!.. Ярый, мин тартып керим әле...

Марат бушап калган купе буйлап йөренә башлады. Кем икән соң ул провокатор?! Күпмедер вакыттан соң купе ишегең шакыдылар.

—Әйе, рәхим итегез!

Ишек кинәт ачылып, анда колга сыман озын буйлы, кәкре борынлы, шактый май җыйган Малик күренде. Шулай дип уйлаган иде шул аны Марат!

—Вот и встретились земляки!—диде ул ыржаеп һәм Маратка сөякчел кулларын сузды.

—Исәнмесез!—диде битараф кына Марат.

—Чеченцу книгу подарил, а мне, земляку, жалко...

Кай арада Әмирнең кулындагы китапны күреп тә өлгергән очлы күз! Хәл-әхвәл сорау юк, аңа китап давай!

—Ә бит мин үзем генә тигел!—дип дәвам итте Малик, бераз каударланып. Һәм башын ишектән тыгып,—Галия, пади сюда! Сматри кто здесь едит! Пулный сурприз!..

Шул ук минутта купега чәчләре агарган, шактый картайган, битләре җыерчыкланган, авылчарак киенгән Галия килеп керде. Әнекәчем, кайчандыр Марат яратып, илһамланып, бергә хыяллар корып йөргән матур чәчкә, синме бу!

—Рәхим ит, Галия! Нинди күрешү!..

Утырыштылар.

—Сез соң кайдан, кая?

Галия Маликка күз сирпеп алды. Сөйлимме-юкмы? Тегесе башын селекте.

—Без Харьковка кызыбыз янына барган идек. Ул бирәдә укыды... Институт тәмамлады. Монда кияүгә чыкты...

Сүзгә кинәт Малик та кушылды:

—Ә мин сине не забыл, шельма,—диде ул авызын кыйшайтып.—Теге вакытта клуб бакчасында чүт имгәтмәдең!.. Учти, мин злапамятни, Сабиров!

Галия бу сүзләрне ишетмәгәндәй:

—Марат, авылга кайтканың бармы?

—Кайтып торабыз... Ә сез кайда яшисез соң?

Галия янә иренә күз сирпеп алды.

—Без? Без ни... Мәскәүдә...

Әлбәттә, сөйләшүнең рәте-путе булмады. Малик кебек тоз күз ыржаеп

утырганда нинди сөйләшү булсын ди. Тагын бер-ике кәлимә сүз әйтешкәч, барысы да тынып калды. Купега тончыктыргыч тәмәке исләре ияртеп Әмир кайтты. Малик Мараттан янә китабын даулады.

—Бүләк итмәсәң, дай почитать, жмут!..

Марат Әмиргә ымлап:

—Миндә калмады...Соңгысын аңар бүләк иттем.

Әмир Маликның кырмавык кебек ябышуын теләми, китапны чыгарып бирде.

—Почитайте, потом вернете...

Чечен кешесе Мәскәүгә ниндидер кәгазьләр артыннан бара икән. Төгәлрәге, Русия җирлегендә мәхкәмәләрнең бусагаларын таптап та унай нәтиҗә булмагач, ул эшне Страсбургка күчерергә йөри икән. Йорт-җирләрен җимергән өчен Рәсәй хакимиятләреннән компенсацияне фәкать шул Аурупа мәхкәмәсе аша алып була икән. Исән кешегә кайдадыр вә нәрсәгәдер яшәргә дә кирәк бит әле!..

Поезд Мәскәүгә якыная башлады. Матур күлләр, урманнарга терәлеп өчәр катлы шәп кәтиҗләр салынган. Рәсәйнең бөтен байлыгын туплаган Мәскәү һәм аның тирәсе—галәмәт зур акча капчыгы. Биредә миллионнар-миллиардлар. Монда ис китәрлек манзара-мажаралар баскан саен. Башкалада һәрнәрсә сатыла. Җан да, тән дә, мал да... Тик бернәрсәдән генә, хаттә череп чыккан байлар да котыла алмый. Әйе, әҗәлдән! Ә поезд һәркемне шунда илтә...

Юллар алҗыта. Атна-ун көн узгач, хатын, балалар, ике гүзәл чәчкә кебек онык төшкә керә башлый. Авылны, туган-тумачаны, Казанны, дус-ишләрне сагына башлыйсың. Һәрхәлдә, Марат татарча җырларлык хәлгә килгән иде инде. Чит-ят җирләрдә атна-ун көннән соң, Маратның кычкырып җырлыйсы килә башлый. Татарча. Йә, кунакханәдә, йә берәр кеше йөрмәгән башка урында «Олы юлның тузанын» сузып-сузып җырлагач, күңелләр бушап кала, сагынулар бераз басыла...

***

Ниһаять, поезд Мәскәүгә килеп туктады. Марат белән Әмир саубуллашырга җыенганда гына купега ике таза, кырыс йөзле, цивилни киенгән ир-егет килеп керделәр. Ниндидер кызыл документ күрсәтеп, фамилияләрне төпчинделәр.

Марат үзенең документларын күрсәтеп:

—Нәрсә булды, әфәнделәр?!—дип сорады.

—Тыныч кына безнең белән барасыз. Ә анда барысын да аңлатырлар...

Тәҗрибәле журналист Сабиров бу эшнең асылына бик тиз төшенде. Монда әлеге дә баягы Маликның озын куллары уйнаганы көн кебек ачык иде. Мәскәүгә җитәрәк Изахов-Салатовларның саубуллашмый-нитми сәер генә югалулары да шул хакта сөйли иде. Димәк, Маратка һәм чечен кардәшенә үзләренең дөя түгел икәнен исбатларга туры киләчәк.

Озак барырга да туры килмәде. Ишекләрендә бернинди язулар күренмәгән офиста ниндидер пүнәтәйләр катнашында Маратның һәм Әмирнең сумкаларын җентекләп тикшерделәр. Журналистның биштәрендә шикле нәрсәләр табылмады. Ә менә Әмирнең кәгазь тулы сумкасыннан кинәт өстәлгә кул гранатасы тәгәрәп килеп төште. Тентүчеләр «ах!» иткән булып тиз генә протокол сырлый башладылар.

Шулчак тентү барган бүлмәгә дәү гәүдәле, алагаем колаклары баш сөягенә ябышып торган, чал чәчле, калын кашлы полковник килеп керде. Туладагы кыгыбышникларның берсе бит бу! Андый колакларны онытып

буламы соң?!

—Продолжайте, товарищи... Кто из вас тут журналист?

—Мин,—диде Марат, бу көтелмәгән очрашуга гаҗәпләнеп.

—Пройдем ко мне.

Допроска охшап торган бу сөйләшүдән шунысы мәгълүм булды: Марат Сабиров күптән чечен террористлары белән таныш, бу хакта аның Дудаев белән очрашуы һәм аны уңай герой итеп үзенең китабында чагылдыруы дәлилләп тора... Әмиргә дип имзаланган китап өстәлдә ята иде.

Ә инде террорист Әмир Кулаевка килгәндә, бары уяу гражданнарның вакытында хәбәр итүе аркасында гына «Киев-Мәскәү» поездында теракт булмый калган...

Әлбәттә, Марат полковникка китап турында да, үзенең Чечен мәсьәләсенә карашы, Әмирнең аянычлы язмышы турында белгәнен сөйләп бирде. Чеченның биштәреннән табылган кул гранатасы уңаеннан да Марат үзенең дәлилләрен китерде. Мәскәүгә берүк вагонда кайткан Салатов дигән кешенең провокатор булуы, әлеге гранатаның Кулаевның биштәренә соңгы мизгелдә шул кеше тарафыннан салынганын версия итеп сөйләп бирде. Рус хәрбиләре барган вагонны шартлатырга тәкъдим итүче дә Салатов икәнен бәян итте. Ләкин бу фаразлар чынга охшап торсалар да, дәлилләр сай иде.

—Сез Салатовны кайдан беләсез?!

—Без аның белән бер авылдан...

—По-онятно-о... Разберемся,—дип полковник өстәлдәге төймәгә басты. Ишектә бер яшь хәрби күренде.—Уведите в пятую!

—Сез, иптәш полковник, гранатадан бармак эзләрен алыгыз! Экспертиза ясагыз! Барсы да ачыкланыр...—дип кенә әйтә алды Марат.

—Не учите нас работать!—дип кычкырып калды полковник тупас тавыш белән.

Менә шулай, Сабиров, гомереңдә күрмәгән төрмәгә дә эләктең. Әле ярый кулга алганчы, Гамил энекәшенә шалтыратып өлгергән иде. «Әгәр дә минем белән берәр хәл булса, Мәскәүдәге фәлән гәҗиттә зур урында эшләүче фәлән кешегә мөрәҗәгать ит. Без заманында бергә укыган идек,»—дип әйтеп куйган иде.

Террористларга теләктәшлек күрсәткән өчен дип кулга алынган Маратны өч көннән соң иреккә чыгардылар. Абруйлы гәҗиттә эшләүче сабакташы көчле адвокат җибәргән иде. Гаепләүләрнең нигезсез булуын ул гына исбатлый алды. Ни әйтмә, таныш-белешләрең булмаса, мич башында ятып та Себер китәсең икән бит!

Марат азат ителүгә Әмирне төрмәдән чыгарыр өчен бөтен көчен, тәҗрибәсен, таныш-белешләрен җикте. Зур инстанцияләргә шикаятьләр юллады. Мәскәүнең демократик гәҗитләренә мөрәҗәгать язды, тавыш куптарды. Хәттә ачлык игълан итәргә җыенган иде. Провокатор Салатовның чын йөзен ачып, ул сыенган иминлек органнарына хат тапшырды. Ахыр чиктә Әмир Кулаевның эшен яптылар. Бу хакта Әмир үзе Маратка шалтыратып рәхмәтләр укыды. Залимлекне, явызлыкны тулы касәсе белән эчкән, төрле яклап типкәләнгән, рәнҗетелгән кешене иреккә чыгару аерым мәгънәгә ия иде. Бу—намус эше иде! Монда югарыдагы бөек көчләр дә ярдәм итте булса кирәк. Гадәттә, мондый яла белән япкан кешеләрне аклау меңгә бер генә очрый.

Мәскәүдәге эшләрне ахырына җиткереп, Марат Казан вокзалына төште, «Татарстан» поездына билет алды. Берничә сәгатьтән ул тагын юлда иде. Казан поездына утырганчы ук, үзенне яртылаш өйдә кебек хис итә башлыйсың. Туган телдә сөйләшүләр дә, вокзалдагы йөк ташучы

мишәрләрнең сүгенүләре дә, әллә ничә ел күрешмәгән таныш-белешләрне очрату да кәефне күтәрә. Чөнки туган җирне сагынып төрле шәһәр-илләрдән кайткан сәфәриләрнең һәркайсы бертөрлерәк фикерле: үзебезнең Казаннан да матур җир юк... Туган туфракка кан да тарта, җан да...

Маратның бу юлы сәяхәте маҗаралы, мәшәкатьле булса да, бик мәгънәле, гыйбрәтле килеп чыкты. Монда уйланырлык та, язырлык та нәрсәләр җитәрлек. Баш миендәге шүрлеккә барсын да ипләп кенә тезеп куясы, тәртипкә саласы, анализлыйсы, аннары язу өстәле артына утырасы...

Купега кереп урын алгач та Марат янә Галияне искә төшерде. Әйе, көтмәгәндә аны йөрәктән Сәрия бәреп чыгарды. Армиягә китәр алдыннан ул кунак егете рәвешендә Мәскәүдәге дусты Наил белән анын авылына кайтты. Биек тау астында урнашкан бәләкәй татар авылынын табигате искиткеч матур, чишмәләрендәге суларын эчеп туялмаслык, ә кешеләре гади, искиткеч самими тоелды ул чакта Маратка. Кичен клубка бардылар. Яшьләр күп иде. Араларында Казаннан кайтучылары да бар. Нәкъ шул кичтә Марат Казаннан кайткан Сәрия исемле кунак кызын күреп таң калды. Моңа хәтле булган очрашулар, гыйшык-мыйшыклар шул мизгелдә күнелдән зур дулкын белән юылып, гаип булды. Армиягә киткәнче Сәрия белән һәр көн диярлек очрашып тордылар. Мәхәббәт уты торган саен көчлерәк яна-дөрли иде. Айрылышу минутлары әллә нинди гарасатны хәтерләтә иде... Солдаттан кайткач та, гыйшыкның температурасы бер генә бүлемгә дә сүрелмәгән булып чыкты. Бу—чын мәхәббәт иде! Сөйгән җаннарны инде бердәнбер юл—никахлашу һәм ЗАГСка барып балдаклашу көтә иде...

Әлбәттә, бу очракта Маратны армиядән көтеп алган Галия читтә калды. Нишлисең бит?! Тормышта шулай килеп чыга... Икегә ярылып булмый, сәвит чорында берничә хатынга өйләнү турында уйларга да ярамый. Ул бит хәзер генә модага кереп бара... Галия җанкай, Маратның кинәт өйләнгәнен ишеткәч, мендәрләренә байтак күз яше түккәндер. Шулай да анын холкы йомшаклардан булмаган, күрәсең. Галия сиздермичә генә Маратның тормышыннан бөтенләй югалды. Ә бик беләсе килә: яшьли сөйгән ярның язмышы ничек булды икән? Нишләп соң әле ул чәчкә кебек, менә дигән хатын-кыз шайтан таягы Маликка кияүгә чыккан?!

Маратта тоемлау, интуиция ише нәрсә шактый көчле. Бу юлы да ул күнеле белән сизенә иде: Галия анын юлында кабат очрарга тиеш. Һичшиксез! Бу китап ахырына хәтле укылмаган. Монда бик күп сораулар калган... Шундый уйлар белән Марат ресторанга китте. Анда кеше күп түгел иде. Вагон тәрәзәсенә карап уйланып барган Маратка кинәт кемдер: «Мөмкинме?»—дип эндәште.

Марат сискәнеп китте. Анын каршында Галия басып тора иде. Күзенә күренә мәллә?!

—Әйдә, Галия, рәхим ит! Мин нәкъ синең турыда уйлап утыра идем...

Галия соңгы очрашудан соң үзен ничектер иркенрәк тота, бу юлы яшьлектәге таныш билгеләр дә күбрәк сакланган кебек тоелды. Авылдашының йөзендә нининдер нур балкый иде. Өске иреннең бер читендә урнашкан миңе әллә кайдан күзгә чалынып, түгәрәк йөзендәге гүзәллеккә билгесез рәссам тарафыннан куелган нокта сыман кабул ителә иде.

—Мин бик сөендем сине күргәч!—диде Галия Маратка сыенып. Ир-егетнең тәне буйлап ләззәтле тойгы чемердәтеп узды. Әйтерсең лә, шул хәтле гомер узмаган да...

Озак сөйләштеләр алар. Күп нәрсәләр ачыкланды. Үпкәләүләр дә байтак җыелган...

Әйе, Марат өйләнгәч тә Галия бик озак бәргәләнгән. Хәттә үз-үзенә кул салуга барып җиткән. Аннары, бөтен дөньясына кул селтәп, тормыш

дулкыннарында йомычка кебек йөзгән. Нәкъ шул чакта аны Малик эзләп тапкан. Имгәтелгән психика, буш йөрәк, битараф күңелне яулап алырга күп кирәкме соң?! Бер дә яратмаган кешегә кияүгә чыккан. Менә инде ничәмә ел шушы үз аяклары белән кергән тәмугъта азаплана.

—Әллә ничек булды минем язмыш...—диде Галия уйчан гына, чал чәчләрен төзәткәләп.—Марат, мин нык картайганмы?..

Марат үзен бу үкенечле язмышның төп сәбәпчесе итеп тойды:

—Кичерәлсәң—кичер мине, Галия...

—Нишлисең—миңа шулай язгандыр инде... Тик хәзер мине ул җаһил белән бернәрсә дә бәйләми... Мин аннан киттем. Бесповоротно!..

Маратның һәм чечен Әмирнең «җинаять» эше уңай тәмамлануда Галиянең дә өлеше зур булган икән. Ул шаһит буларак, адвокатларга Маликның провокатор икәнен фаш итәргә ярдәм иткән, рәхмәт төшкере!..

—Дөресен әйтим, сезгә каршы кылган кәбәхатлеге мине тетрәндерде. Ул поездга бит Киевта ук утырган. Миңа Харьковтан билет алган иде. Аны бит тегендә официанткалары да, проводнигы да белә. Синең һәр адымыңны күзәтеп, Маликка хәбәр итеп барганнар...

Маратның гаҗәпләнүе чиксез иде.

—Димәк, вагондагы хатын-кызлар да аларның кеше...

Галия авызына ике бармагын куйды. Янәсе, сүзләрне үлчәбрәк сөйлик.

—Кыскасы, болары минем өчен соңгы тамчы булды...

...Поезд Казанга таба җилдертә. Менә инде Свияжск станциясен узып, Идел күперенә килеп керделәр. Төне буе керфек какмый, сөйләшеп чыккан Марат белән Галиянең сүзләре һаман да бетмәгән. Инде таң аткан. Тәрәзәдән бөек елга манзарасы ачык күренә: көзге дулкыннар күбекләнә-күбекләнә диңгезгә таба ага, томанлы офыкта нindидер зур көймәләрнең кара шәүләләре каядыр шуыша, яр буенда тынгысыз балыкчылар соңгы учакларны сүндерә. Шулчак радио Мәскәүдән яңалыкларны бирә башлады: «Мәскәү—Санкт-Петербург» тиз йөрешле поезды зур казага дучар булган. Һәлак булучылар да бар... Каза террорчыларның гамәле булырга мөмкин...» Бу хәбәрне сагаебрак тыңлап торган Галия:

— Беләсеңме, Марат, майор Салатов-Изахов та кичә шул поезд белән Питерга киткән иде,—дип уйчан гына әйтеп куйды...



Лениза
Вәлиева

# ӘЙ, БОЛЫТ, КОЯШНЫ КАПЛАМА!..

* * *

**«Һәркемнең бәхете—кулында»...—**
**Йомарлыйм бар көчкә учыма.**
**«Бәхет ул—пыяла, уала»...—**
**Кан белән укмашып коела.**
**«Дөньяда залимнәр табыла.**
**Ерактадыр диеп уйлама»...—**
**Дус диган, шатланып, ярама,**
**Каерып учымны, тоз сала.**
**«Ышаныч сүнми ул, гел яна.**
**Көч тап тик, үткәнгә карама»...—**
**Таң булып, өметем яңара...**
**Әй, болыт, кояшны каплама!**

## Үз-үземә өч киңәш

*Акыл:*
**Иң күтәрмәс йөккә кулың сузма—**
**Сыгылырсың;**
**Ярты юлга хәтта җиталмичә**
**Егылырсың;**
**Бармак төртеп көләр үткән-сүткән—**
**Җиңелерсең;**
**Иң татлы һәм бөек хыялыңны**
**Җимерерсең...**
**Соң түгел бит. Уйла!**

*Йөрәк:*
**Еллар аша борылып караганда**
**Үкенерсең;**
**Алмый киткән чиксез авыр йөккә**
**Үрелерсең;**

---

Лениза ВӘЛИЕВА—*шагыйрә; «Диңгездә йолдыз коена» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

Хаталандым, кичер, зинһар, диеп
Үтенерсең,
Тик соң булыр. Үз рухыңны шулай
Үтерерсең...
Инде сайла.

*Каләм:*
Иңнәр хәлсез дисәң әгәр, көчле
Йөрәгең бар.
Юллар чиксез озын. Куркакка тик
Офыклар тар.
Тел сөяксез. Бәндә сөйләр. Ә син
Үз юлың яр.
Әмма мине ихлас ният белән
Кулыңа ал.
Чигенмә, бар!

## Әниемә

Сүзгә сыймас бер йомарлам хисем,
Кулларыма алып, учка кысам.
Таралыр да вакланыр дип куркам,
Аңлатырга әгәр аваз салсам.
Сүз кирәкми, сүзләр артык, көчсез,
Бәһасе юк хискә лаек түгел...
Әйтмәсәм дә, шиксез, аңлар, беләм,
Һәрнәрсәгә сизгер даһи күңел.
Алыш-биреш шаулап барган заман
Теш кайраучы түбән җаннар тулы.
Адәм түгел, бәндә бүген күпләр
Һәм буталган иман, ялган юлы...
Ә син һаман шундый пакь күңелле,
Бар ваклыктан өстен Алиһәдәй.
Тез чүктерәм бөтен авырлыкны
Көч бирүче кешем барда синдәй.
Сүз табалмам әмма, кичер, әни!
Кысам бары хисне кулларымда.
Сиңа дигән иң кадерле бүләк—
Бер йомарлам бәхет учларымда.

* * *

*Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз...*
Дәрдемәнд

Таулар күчәр, комнар китәр, бетәр эз...
Һәрнәрсәнең була чиге—бәхәссез.
Гасырларны кичәр әмма шигъри сүз.
Шагыйрь җаны—киләчәккә баккан күз—
Алдан сизәр дөнья шавын, көн гамен,
Кайсы җилләр җибәргәнен ил ямен.
... Заман башка, имеш... Ялган! Һаман шул:
Акыл түгел, мәртәбәдә—көчле кул.
Хакыйкать бит һәрвакытта соңара,
Тузан һаман уйган эзләрне сара...
Тик баш имә, зинһар, рухым, сынма, түз!
Тарих төпкеленнән беркөн калкыр Сүз!

## Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Батулла

# ТӨНГЕ МӘҖЛЕС

ХИКӘЯ

Илдә ачлык хөкем сөргәндә, кешеләр йөзәрләп ачтан үлгәндә, шешенеп үлмәс өчен бәндәләр агулы арыш ашап, меңәрләп кырылганда халыклар атасы Иосиф Виссарионович Сталинның Мәскәү янындагы җәйлек йортында төнге мәҗлес кызганнан-кыза бара иде.

Дәстарханда ниләр генә юк! Ит, бал-майны әйтәсеме? Анда кыздырылган мәрсин балыклары, кызыл-кара уылдыкның исәбе-кадере юк, кемдер үз өлешенә куелган күркә ите өстенә тәмәкесен басып сүндергән. Каганович зур кисәк бозау итен аяк астына төшергән дә, аны иелеп алырга иренеп, итне эчкәрәк  тибеп маташа. Кайсысыдыр банан кабыгын аяк астына ташлаган.

Кинәт почмак куышындагы кечкенә оркестр тантаналы көй уйнарга тотынды. Бу—аягүрә бастырып кыздырылган чучканың табынга чыгасын аңлата иде. Менә НКВД тарафыннан сайлап алынган яшь-гүзәл кызлар бер-бер артлы залга чыга башладылар. Һәр төпсәдә кызыл төскә кергән бер чучка, чучканың авызында  яшел салат яфрагы. Чучка китерүче хезмәтче кызларның берсе идәндәге банан кабыгына басып, таеп егылды, тирә-якка дөге, макарон чәчелде. Кызның итәге ачылып китте. Һәм кыздырылган чучка баласы кызның ялангач ботлары арасына төште. Әйтерсең дә егылган кыз чучка баласы тудырып ята. Кемдер аты-юлы белән сүгенде, кайсылары эче катып көлә башлады.

Табын янында бөтен политбюро, Мәркәзи комитет (ЦК). Һәр урындык ияле. Ләкин һәр мәҗлес саен өстәл тирәли куелган урындыкларның өчесе буш кала килә,  соңарган берәр кеше шул буш урынга утыра калса, Сталин кара көя,  грузинча нидер мыгырданып:

—Мондарием мокла датви! Ац-хара, тахо маца!—дип куя.

Буш урыннарга утырырга ярамаганлыгын бөтен политбюро белә һәм беркем дә ул урынга утырырга җөрьәт итми.

Мәҗлес ахырына таба Сталин һәрвакыт ипи йомшагыннан түгәрәк ясап, шул өч буш урынга ата, ипи ядрәсен урындыкка тигерсә елмая, тигерә алмаса, үзенчә сүгенә иде.

—Мокла датви!

Берия аның ни әйткәнен аңлый: сунарчы аюны атып үтерде! ди иде Сталин. Кем ул сунарчы? Сталин үземе? Кем ул аю?

Сталинның ни өчен өч урынны буш тотканын берсе дә белми, хәтта бөек шымчы, җанкыяр Берия дә белми иде.

Сталин ул өч урын кемнәрнеке һәм ни өчен аларның урыны буш икәнен яхшы белә.

«Ленинны мин сызланудан коткардым,—дип уйлый Сталин.—Горькийны да үпкә авыруыннан азат иттем, аларның җәфаланганнарын күрүе бик тә кызганыч иде: Ленинга өч өлеш морфий, Горькийга бер конфет җитте».

Сталинның кан дошманнары Троцкий, Бухарин, Зиновьевлар... Алары әллә ни түгел иде. Бухарин белән Зиновьевны ул монда, Лубянкада аткарачак. Троцкийны Мексикада чүкетәчәк. Ләкин алардан да куркынычраклары бар иде.

Беренче буш урын Кировныкы. Мәрхүм Киров (беркатлы адәм) ЦК секретарьлыгына булган яшерен сайлауда үзе җыйган тавышларның Сталинныкыннан күбрәк икәнен белгәч, киңәш сорарга дип Сталин янына керде.

—Слюшай, Сережа! Зачим ани тебе, отдай мне!—дип, Сталин Киров тавышларын да үзенә алган иде.

Сергей Миронович һичкарусыз үз тавышларын Сталинга сонды. Бу серне бер Киров кына белә иде һәм ул,бердәнбер шаһит буларак, шәһид китте. Аның урыны буш тора.

Ипи валчыклары беткәч, Сталин Киров урындыгына карбыз кабыгы ата башлады.

Икенче буш урын татар юлбашчысы Вахитовныкы иде. Аһ, шул татар мәсьәләсе! Татарлар күп, татарлар белемле, татарлар актив. Ул чакта Сталин әле беркем дә түгел. Ләкин ул шахмат тактасына бар фигураларны да чыгарып куйган. Вахитов мәһабәт, белемле, затлы-зыялы нәселле татар. Сталин аны кара мыеклы, чандыр, озын буйлы, белемле татар булганы өчен сөймәде. Вахитов исән чакта Сталинга юллар ябылачак иде. Ленин Вахитовны Сталинга караганда якынрак күрә, аңа ышана иде. Казанга ак чехлар кергәч, Сталин яшертен генә үз кешесен Казанга юллады. Яшерен агент Вахитовның башын кисеп, Мәскәүгә алып кайтып, Сталинга тапшырды дигән имеш-мимешләр йөри.

Карбыз кабыклары Вахитов урынына өелә башлады. Имеш, Сталин Вахитовның баш сөяген алтын белән тышлатып, шәраб касәсе ясаткан икән. Хәзер цинандали шәрабы салып эчә торган кадеһнең эчендә, имеш, Вахитовның баш сөяге.

Аһ, шул милли мәсьәлә! Татарлар хокук таләп итәләр. Әнә, беркөнне Сталин янына Кырым татарларыннан, башкортлардан, мишәрләрдән аерым-аерым делегацияләр килгән. Һәр берсе үзенә аерым республика, аерым милләт буларак, дәүләт сорый. Керәшененә чаклы: мин аерым милләт, безгә дә дәүләт кирәк, ди.

Сталин күп уйланды бу турыда. Чыннан да, әллә соң барысына да автономия өләшергәме? Аерым милләт булып, кыр талашып бетсеннәр шунда. Әгәр дә Сталин аларның һәрберсенә аерым-аерым дәүләт бирсә, эш харап. Аларның телләре уртак, мишәренең аерым обкомы, керәшеннең аерым обкомы, аерым фәннәр академиясе, аерым театрлары булып, бер татар халкының җиде берәмлеге: Кырым АССР, Керәшен АССР, Башкорт АССР, Мишәр АССР, Татар АССР, Типтәр АССР, Нугай АССР булыр иде. Слишком жирно будет для татарвы.

—Мишәр, керәшен дигән милләт юк!—диде Сталин.—Мишәре дә, башкорты да, керәшене дә халыкча, шулар бөтенесе бер татар халкын тәшкил итә. Россиядә урыстан кала иң күп халык татарлар булачак.

Вакламыйк без татарларны. Бердәм халык булсыннар!

Шаккаттылар татарлар Сталинның бу сүзләренә! Нинди алдан күрүчәнлек, нинди киң күңеллелек, халыклар атасы татарлар турында кайгырта, аларны бердәм итеп, олы милләт итеп күрергә тели!

Һәм делегацияләр берләшеп:

—Яшәсен халыклар атасы бөек Сталин!—- дип зәңрләнгәнче акырдылар.

Татарларны исенә төшергәч, Сталин елмайды. Бу елмаю: өттем татарларны, дигәнне аңлата иде.

Өченче урын Солтангалиевнеке. Бусы тегеләренә караганда да куәтле шәхес иде. Озын гәүдәле, төз, укымышлы Солтангалиевне беренче күрүдә үк Сталин ошатмады. Ленин вафатыннан соң советлар илендәге канлы еллар әнә шул Солтангалиевтән башланды да. Солтангалиевкә бәйләгән булып, Сталин татарның аңын, башын, тарихын, әдбиятын, музыкасын кисеп ташлады. Соловки, Себер, Магадан лагерьлары татар зыялылары белән шыгрым тулды.

Сталин Солтангалиев урындыгына әстерхан чикләвеге кабыкларын ата башлады. Өч урындыкны да чүпләп тутыргач, халыклар атасы алдындагы цинандалины үз кадеһенә коеп, куе мыегы аша сөзеп кенә бер-ике йотым шәраб эчеп куйды, ул да мәҗлестәгеләр дә шактый кыза бара иде.

Төнге мәҗлестә яһүде дә, хахулы да, урысы да, грузины да—бар да бар, ләкин татар гына юк иде. Татарларның урыны буш тора. Әллә соң Шәехзадә Бабич әүлия булганмы? Ул бу турыда 1916 елда ук иблис турындагы поэмасында язды лабаса.

Һәр шәһәрдән, һәр авылдан—карьядан,
Бар да килгән, бер дә килми калмаган;
Бар да килгән, хатын, кыз, карты, яше,
Тик мөселман җеннәреннән башкасы.

Шул сәгать чуклар, флаглар торгызып,
Һәр флагка: «Яшә, иблис!»—- дип язып,
Әллә нинди зур барабаннар кагып.
Быргы, торба һәм сыбызгылар сызгыртып,
Кызларыннан «марсельезалар» җырлатып
Ду килеп мәркәз урамнан йөрделәр...

Хуҗаның уң ягында бөтен сугышларда да оттырган, булдыксыз, ләкин Сталин кулыннан маршал дәрәҗәсе алган Ворошилов, сул тарафында ике күзен дүрт итеп, дошманын чагарга әзерләнгән зәһәрле җылан—Берия, атка атланып, кылыч айкап, танкларга каршы халыкны үлемгә күтәргән кеше, аракы чөмергән саен күпереп торган мыегын учы белән туктаусыз сыпыра-сыпыра маршал Буденный утыра. Каганович та затлы коньягын уртлап-уртлап куя да, өстәл астындагы ит кисәгенә тибеп-тибеп ала, кызык булмаса да көлә, кызганыч булмаса да җылап алгалый иде. Хрущев иң аргы башта, ул кызыл чигешле ак күлмәгенең якасына кереп бетә язган, һорилкага үрелгәндә киң җиңе чөгендер салатына кереп-кереп чыга. Аның моңа исе китми, һорилканы эчкәч, җиңендәге чөгендер измәсен ялап, суырып куя.

—Микита!—дип кычкырды Хуҗа.

—Слушаюсь, Иосиф Виссарионович!—дип Хрущев аягына калкып, буен сындырды.

—Давай нам гопака!—диде Хуҗа.

Оркестр гопак көен суза, Хрущев хәлдән тайганчы гопаклый. Сталин

елмая. Аh, Сталинның елмаюы! Аны кем генә сурәтләп бирә алыр икән? Хрущев әлсери, аның биюне дәвам итү мөмкинлеге төкәнгәнен Сталин бик яхшы белә, ләкин юри туктатмый. Бу юлы Хрущев үз хәленең мөшкел икәнен сизеп:

—Арыдым, Ио ... сиф... Висс...

Сталин һаман елмая. Аh, ул елмаю! Кызыктан түгел, бию ошаганнан түгел, Хрушевны ул сөйми, сөймәсә дә мәҗлесенә чакыра. Хрущевны ул аксыл чырайлы, кашсыз йөзендә төк чыккан миңнәре күп булганга сөйми, ни урыс, ни хахул, ни кацап булганына күрә ул аны яратмый иде.

—Прадалжай!—диде Хуҗа.

Ләкин Хурщев дәвам итә алмады, урынына барып егылды. Сталинның иблис елмаюы юкка чыкты, ул:

—Ял ит!—диде.

Хрущев урындыгына җайлашып азапланганда Сталинның кырыс тавышы ишетелде:

—Пад столом отдыхай!

Хрущев һич карусыз өстәл астына кереп утырды.

Сталинның кычкырып көлгәнен берәүнең дә күргәне булмады. Хәтта милләттәшләре Берия белән Орджоникидзе алдында да ул көлмәс. Ләкин төнге типтерешләрнең азагына таба ул бераз җеби төшә һәм кызык уеннар уйлап чыгара торган иде. Әйтик, салаттагы чөгендер шакмагын алып, берәрсенең чыраена чәпәү дисеңме! Бервакыт кычкырып көлә башлагач, Ворошиловның ерык авызын тозлы кыяр белән томалап куйган иде. Тын океан селедкасы белән берәрсенең яңагына чабу дисеңме, барысы да Хуҗаның бу уенына түзә, кызык булмаса да көлә иде.

Шулчак Хуҗа төчкерде, бөтен ЦК бердән:

—Сәламәтлек телибез!—дип кычкырды. Өстәл астыннан Хрущевның:

—Яшәсен бөек Сталин!—дип чинаганы ишетелде.

—Чык, Микитка!—диде дә, Хуҗа тагын төчкерде.

Ул уң кулы белән битен каплады, озак кына имән бармагы белән борынын каезлап маташты, аннан нидер тартып алып, ике бармагы белән әвәли башлады. Борын кәрәзе ядрәгә әверелде.

Хрущев өстәл астыннан чыгып үз урынына утырды, ул уңайсыз елмая, авызын ерып көләргә маташа. Шулчак Сталин борын ядрәсен Хрущев тарафына чиертеп җибәрде, ядрә Хрущевның ачык авызына керде-китте. Никита Сергеевич тончыкты, йөткерергә тотынды, барысы да шаркылдап көлә башлады, Сталин да беренче тапкыр кычкырып көлә иде. Ах, аның көлүе! Цинандалидан бүртенгән чыраенда иблис чаткылары уйнап алды, аның мыек очлары да зәһәр көлүгә манчылган иде. Мыек астыннан ямьсез тешләре күренде, бу көлү түгел иде, бу мәкернең ыржаюы иде. Берия сизенде: мондый ыржаюдан соң Хуҗадан миһербан көтмә. Бу чыннан да шулай булып чыкты. Сталинның ерык авызы шундук йомылды, мыек очлары үз урынына кайтты. Ул кәбестә салаты өстендәге зәйтүн орлыгын алды, орлыкны Каганович тарафына ыргытты, Каганович очып килгән зәйтүнне һавада чакта ук авызы белән тотып, чәйни башлады. Лазарьның эквилибристлыгына ЦК таң калды. Алкышлар яңгырады. Ләкин Хуҗа көлмәде. Иосиф Виссарионович Кагановичны яһүдлеге өчен күрә алмый иде.

Сталин тамак кырды, мәҗлес шым булды.

—Мин!—диде Хуҗа шом тулы аваз белән.—Сезне айгылдап көлеп утырыр өчен җыймадым бүген...

Бөтен ЦК кинәт айныды.

—Иллә ачлык!—диде Сталин салмак кына.

Аның бу салмаклыгында менләгән вулкан ята иде.

—Балалар сынык ипигә тилмерә! Ә сез монда тыгынасыз. Лыкынганчы эчәсез! Өч кеше туенырлык итне өстәл астында типкәләп йөртәсез!

Бу мизгелдә: бомба төшсен иде бу йорт өстенә дип теләгәннәр аз булмагандыр. Дәһшәтле башлам иде бу.

—Ни өчен мин әйткәннәр үтәлмәде?..

ЦК дәшми, Политбюро авызын йомып, икенче урыннан тын алып утыра. Шомлы тынлыкта Сталинның салмак-дәһшәтле тавышы ишетелде.

—Ни өчен сез дәүләтне талап, халыкны алдап, тәккә ашап ятасыз, әрәмтамаклар!.. —диде Хужа.

Башлар өстәлдәге ашалып бетмәгән чөгә балыклары өстенә иелгән. Каганович пеләшен каплар өчен чигә чәчен озын үстереп, шәрә урыннарны капларга тырышкан, әмма юеш чәч ишелеп, балык ризыгына төшкән, Кагановичның пеләше ялтырап тора иде. Ворошиловның башы янтаеп, дингез кәбестәсе салатына яткан. Хрущевның башы пеләш түгел түгелен, ләкин аның аксыл чәче ерактан күренми, Хрушев та пеләш сыман. Бөтен Политбюро чәчсез иде.

Иелгән башлар түбәсенә карап алганнан соң, Сталин дәвам итте:

—Кемнең кем булуына карамастан, партийныймы ул, партиясезме, хәрби кешеме, гражданскиймы, Советлар Союзы Героемы, үлемгә хөкем ителәчәк!

Шулчак Хрущев аягүрә басып, яшелле-күкле аваз чыгарып:

—Яшәсен иптәш Сталин! Яшәсен гадел Хужабыз!—дип кычкырды да башын янә өстәлгә салды. Әйтерсең лә ул җәллад балтасына башын куйды.

Сталин канәгатьсез генә Хрущев тарафына карап алды да дәвам итте:

—Җинаятьчеләрдән алынган байлык халык файдасына күчерелергә тиеш.

Тагын тынлык. Сталин салмак атлап, өстәлне әйләнеп чыкты. Гасырга бәрабәр мизгел иде бу.

—Ни өчен шәһәргә икмәк килеп җитмәде?—диде Салин—- Ни өчен халык ачыга ? Кем гаепле?

Берия тамак кырды:

—Кхым, иптәш Сталин!—диде күзлекле җылан.—- Икмәкне игенчеләр әзерләргә тиеш иде.

—Кайда ул иген өчен җаваплы кеше, кабахәт?—дип кычкырды Сталин.

Берия Хрущев тарафына ымлады.

—Мин җаваплы идем, иптәш Сталин?—диде Хрущев.

—Ни өчен халык ач калды? Җавап бир, әрәмтамак!

—Сез кушкан буенча икмәк вакытында өлгерде, иптәш Сталин...—дип башлады Хрущев.—Сез боергач, җир быел мул уныш бирде, шөкер. Көшелләрдә икмәк бурсый. Тау-тау ипи чери, Мәскәүгә озатырга дип тутырылган капчыклар янгыр астында калып, кыза башлады.

Сталин учы белән өстәлгә сукты, Хрущев тотлыгып туктады.

—Бу кешенең мал-мөлкәтен алып, үзен атарга!—диде Сталин.

Хрушев юан гәүдәсенә кире пропорциональ, нечкә тавыш белән җылый башлады:

—Иптәш Сталин,—- диде бичара.—Икмәкне бездән кәрван килеп алырга тиеш иде. Без көттек, һаман көтәбез, кәрваннар һаман юк. Бездән икмәк сорап килүче булмады.

—Кем транспорт башлыгы? Кем кәрваннарны әзерләргә тиеш иде?—диде Сталин янаулы тавыш белән.

Берия Микоянгаияк какты. Микоян калыкты. Микоянның борыны бөтен йөзен каплаган иде.

—Икмәк ташучы кәрваннарны мин әзерләргә тиеш идем,—диде Анастас.

—Кушылган буенча син шәһәргә бирәр йөк икмәк китерттеңме?

—Юк, Иосиф Виссарионович!—диде Микоян.

Сталин Микоянны әрмән булганы өчен яратмый иде.

—Мал-туарын алып, Микоянны хәзер үк атарга!

Бу әмерне ишеткәч, Анастасның болай да озын борыны тагын да салына төште, борын аның авызын каплады.

—Иптәш Сталин,—диде Микоян, ләкин әрмән борын сүзләрне тышка чыгармый иде, Микоян уң кулы белән борынын бер кырга кыйгайтып, тавышын иреккә чыгарды:—Иптәш Сталин! Сигез йөз дөя, мең алаша, өч йөз ишәк, ун состав йөк машиналары әзерләттем. Өч мең чыбылдык, унбиш мең капчык суктырдым. Тутырып куйдык. Ләкин сазлык аша юл салынмаган. Кешеләр басма аша йөри, басмага бер дөя керсә, суга бата. Мин икмәкне суга сала идем. Сез урман аша таш юл салырга боердыгыз. Без шул юл төзелгәнен көтеп ятабыз. Юл салынып беткәч, чапкын килеп миңа хәбәр итәргә тиеш иде. Кәрван көтте, чапкын килмәде.

—Чапкын?—диде Сталин. —Кем ул чапкын?

Берия Буденныйга төртте. Буденный калыкты:

—Мин ул, иптәш Сталин.—диде маршал.—Мин гаепле түгел, таш юл салынып беткәч кенә мин юлга чыгарга тиеш идем. Юл әле салына да башламаган.

—Кем җавалы таш юл өчен?—диде дәһшәтле Хуҗа.

Берия әйтте:

—Орджоникидзе!—диде.

Мыегына ияреп Орджоникидзе аягына басты да:

—Минем гаебем юк, Иосиф Виссарионович!—диде.

Сталин-Джугашвили Берия белән Орджоникидзены грузин булганнары өчен яратмый иде. Чөнки аларның икесенең дә фамилияләре артында «швили» кушымчасы юк иде.

Сталин өстәлне ураганнан соң, табын буйлый арлы-бирле йөренә башлады, төребкәсенә «Алтын руно» тәмәкесе төяргә тотынды. Шырпы сызып төребкәсен кабызды, бер-ике суырып алды да әйтте:

—Ә кем гаепле соң монда? —- диде.—Кем? Дәүләтме бу, әллә бер-бер кыргыйлар җәмгыятеме? Кем халык турында кайгыртыр? Әйт, Серго, кайсыдыр ки, син Орджоникидзе!

—Таудан таш кисәргә миңа кушылган иде. Ташны кисәр өчен кеше кирәк, эшче куллар кирәк. Ташчылар сорап, мин Ворошиловка бардым. Сталинның әмере бар, дидем. Ләкин маршал Ворошилов миңа бер генә солдат та бирмәде. Сталин түгел, Ленин үзе килсә дә бер солдат та бирмим, диде.

Ворошиловның ирен өстенә ябыштырылган мыек кисәге борын тишегенә кереп китә язды. Ул куырылып килде дә күкрәге белән өстәлгә ятты. Хуҗа Ворошиловны урыс булганы өчен сөйми иде.

Сталин төребкәсенең сабы белән Ворошилов тарафына төртеп:

—Кабахәт син, Климентий!—диде.

Ворошилов торып үрә катты.

—Син—- ворошило! Ворошиш-ворошиш да доворошишься! Синен күтенә шило, Ворошилов! Әмеремне үтәмәгән кешене Колыма көткәнен син белмисенмени, Ефримыч? Серго ялганлыймы?

—Дөрес әйтә Серго,—диде Ворошилов.—Мин шулай дип әйттем.

Сталин төребкәсен Воршиловның башына сугып кага башлады, кайнар көл Ворошиловның пеләш башына коела, ул нишләргә белми, үрсәләнә, чәбәләнә.

—Асарга! Буарга! Тереләй күмәргә Ворошиловны!—дип кычкырды Хужа.

Ворошилов кайнар көлне сыпырып төшерде дә аракыда чылатылган тастымал белән башын каплады. Аның чырае сызланудан битәр катыргыга китү куркусыннан сытылган иде.

—Иптәш Сталин!—диде Ворошилов.—Ышанычлы милләттәшең Берия миңа яшерен боерык китерде. Бер генә сакчыны да, бер генә солдатны да таш кисәргә алмаска. Сталинга һөҗүм әзерләнә, диде. Аны сакчысыз калдырырга ярамый, диде.

—Лаврентий!—диде Хужа.

Бериянең бөкшәйгән гәүдәсе калыкты.

—Синең арканда икмәк килеп җитмәгән! Сине атарга хөкем итәм! Хәзер үк!—диде Сталин.

—Иосиф Виссарионович,—- диде Берия.—Мин шундый боерык бирдем, дөрес. Чөнки мин: сезнең җанны сакларга алынган кеше. Әгәр дә солдатларны таш кисәргә алып, сезне саксыз калдырсам, илебез генералиссимуссыз кала иде.

Сталин урынына утырды, ул уйда иде:

—Алайса, кем гаепле соң, кемне атарга?—диде ул үзалдына:—- Минеме? Халыкның ач калуында мин гаепле булып чыгам. Мине атыгыз! Әмерем шул!

—Сез гаепле түгел, Иосиф Виссарионович!—диде Берия.—Сезне үтерү куркынычы булмаса, һичшиксез, мин гаскәрне тауга таш кисәргә юллаган була идем.

Сталин тагын аягына басты, Берияга карады:

—Миңа кем яный?—диде.—Кем соң мине үтерергә җыена?

—Халык!—диде Берия.

—Димәк, гаепле табылды!—диде Сталин һәм тагын ипи валчыгын әвәләргә тотынды, берсен—- Кировка, икенчесен—Вахитовка, өченчесен Солтангалиевкә томырды. Ядрәләрнең барысы да буш урындыкларга барып тиде.

Сталин авызын киң җәеп шаркылдап көлде дә әйтте:

—Күпләп кулга алулар башлагыз!—диде.—Беломорканалны төзеп бетерергә кирәк!

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ ЯДКАРЕ



*Габделәхәт Госманов (беренче рәттә) гаиләсе. Миркасыйм Госманов икенче рәттә, сулда. Голжа (Кытай). 1954 ел.*





*М. Госмановның 2004 елда чыккан китабы.*



*Галим үзенең шәкертләре белән. 1994 ел.*



*Болгар шәһәрлегендә, Бөек Идел су юлы конференциясендә. Профессорлар (сулдан уңга): Клаус Хеллер (Гиссен, Германия), Миркасыйм Госманов, Сергей Кляшторный (С.-Петербург). 2001 ел.*



*Мисыр. Пирамидалар янында. 1998 ел.*



*Актер Әзһәр Шакиров белән.*

Дамир
Исхаков

# ТАТАР ЮЛЫ ТАКЫР ТҮГЕЛ...

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭТНИК ТАРИХЫ, ХАЛЫКНЫ ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ СӘЯСӘТ

**VI бүлек**

### СОВЕТ ЧОРЫНДА ҺӘМ АННАН СОҢГЫ ДӘВЕРДӘ ТАТАР ИДЕНТИТЕТЛЫГЫ. АНЫ САКЛАУДА ҺӘМ НЫГЫТУДА МИЛЛИ ЗЫЯЛЫЛАРНЫҢ РОЛЕ

1920 елны Татарстан АССР төзелгәннән соң татар идентитетлыгы аннан элгәре чордагы юнәлешләр буенча үсте. 1920нче еллар урталарына «татар» этнонимында чагылыш тапкан идентитет төп урын алды һәм Татарстанда зыялыларның милли аң өлкәсендәге эшчәнлегенең иң әһәмиятле юнәлеше булып Ш. Мәрҗани нигез салган традицияне дәвам итү булды. Татар милләте бер дәүләтчелек эчендә берләшә алмау сәбәпле, бу дәвердә Татарстаннан читтә калган татарлар мәсьәләсе калкып чыга. Аның шулай икәнлеген Г. Ибраһимовның 1927 елны язылган, әле чагыштырмача иркле фикерләр әйтелгән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» исемле хезмәтеннән күрергә була. Галим һәм сәясәтче болай дип яза: «... җөмһүрияттән тыштагы татарлар белән даими контакт саклау мәсьәләсе татар мәдәниятенең үсүендә, көчәюендә аерым урын тоткан моментларның берсе булачак».

Шулай да бу чорда революциягә кадәр үк барлыкка килгән татар идентитетлыгы мәсьәләсендә аның болгар мирасы белән бәйлелегенең алга чыгару юнәлеше дә яшәгән. Беренче чиратта, мондый караш мөселман руханилары даирәсеннән булган тарихчыларга хас була (мәсәлән, мөфти Р.Фәхреддингә). Ләкин ошбу караш тарафдарлары алар белән генә чикләнмәгән—Татарстанда эшләгән кайбер рус галимнәре дә шул позициягә якын торганнар (М.Худяков, Н.Фирсов һ.б.) Беренче чиратта бу тарихчы галимнәргә ул вакытта бик йогынтылы булган Маррның «яфетик» теориясенең тәэсире белән аңлатыла (ул теория халыкларның барлыкка килүен «автохтон», ягъни җирле булудан чыгып аңлатырга тырыша). Шуның өстенә, зыялылар аңына Татарстанның тар территориаль кысаларда төзелүенең йогынтысын да күрсәтергә кирәк—нәкъ менә шушы тәбәктә ул дәвернең тарихи белеме өчен болгар мирасы артык зур булып күренә. Бу исә үз чиратында Алтын Урданың тарихы начар өйрәнелгән булу белән аңлатыла.

1920-1930 елларның чикләрендә татар җәмгыятенең чагыштырмача иркле

*Ахыры. Башы 9, 10 саннарда.*

үсүенә чик куелды. Мөфти Р.Фәхреддин үзенең 1932 елны төгәлләнгән «Болгар һәм Казан төрекләре» атлы тарихи хезмәтендә тикмәгә генә болай дип язып калдырмаган: «Бу дәвер хакында язарга түгел, хәтта күңел белән фикерләүгә дә мөмкинлек юк. Алла насыйп итсә, җәннәткә кергәнебездән соң язарбыз». Әмма әле 1930нчы елларда да милли идентитетның (үзаңның) ике концепциясе—татар һәм болгар (болгар-татар) концепцияләре бер-берсе белән көндәшлек итеп яшәп килгәннәр. Мәсәлән, М. Җәлил тарафыннан 1935-1936 елларда язылган «Алтынчәч» тарихи операсының либреттосында (аның нигезенә «Җикмәргән» дигән эпик әсәр салынган) Алтын Урдадан чыгучылар буларак Казан ханнарына тискәре караш чагыла. Билгеле, моны ул заманга хас сыйнфый бәя белән бәйләп карап та булыр иде—ханнар халыкны «изүчеләр» булалар бит инде. Ләкин, эш монда гына түгел, ахрысы. Яшь шагыйрь шушы бәяне болгар-татар теориясе белән мавыкканлыктан да бирмәде микән дип уйларга урын бар. Шул ук вакытта, параллель рәвештә милли тарихны язуның татар концепциясе һәм аның аркылы татар идентитеты төзү юнәлеше дә яшәгән, аның иң ачык чагылышы—1940 елны «Совет әдәбияты» журналында (хәзерге «Казан утлары») «Идегәй» халык дастаны басылып чыгу. Бу дастанның җыелма текстын әзерләгән әдип һәм фольклорчы Н. Исәнбәт ул әсәрне чыгарганда аңа Алтын Урда тарихына багышланган киң күләмле тарихи комментарийлар да биргән. Аларда исә бу урта гасыр чорының иң зур татар дәүләтенә карата уңай бәя ярылып ята.

Димәк, 1920-1930 еллардагы гаять катлаулы иҗтимагый-сәяси шартларда да милли зыялылар халкыбызның тарихи «дәвамчанлыгын» тәэмин итәргә тырышканнар һәм моның өчен элек оешкан татар идентитетлыгы концепцияләрен эшкәрткәннәр.

Ә менә 1940 нчы еллардан башлап Советлар Союзында татар милли идентитетын үзгәртү буенча масштаблы акция башкарыла. Ул исә бу чорда илдә яңа—империячел милли-большевистик идеология формалаштыру белән бәйле була. Соңгысы Бөек Ватан сугышы елларындагы рус патриотизм күтәрелеше белән, Сталин тоталитар режимының аны үз мәнфәгатьләреннән чыгып файдаланырга тырышуы белән бәйле иде. Шул ук вакытта, бу акцияне әзерләгән үзәк партия органнарында идеологик һәм оештыру юллары белән бу вакыттагы татарларда күзәтелгән милли аң күтәрелешен, бигрәк тә зыялылар арасында барган күтәрелешне, бастыру бурычы да куялар. Соңгысы җиңел эш булмый. Чөнки ул заманда да татар зыялылары империячел ысуллар белән иҗтимагый аң өстеннән гомуми контроль урнаштыру өчен тырышуларга каршылык күрсәткәннәр. Шуңа күрә дә 1944 елдан башлап татар милли аңын бастыру өчен үзәк партия органнары берничә документ кабул итәләр. Алар нигезендә татар зыялыларына каршы конкрет оештыру эшләре дә башкарыла. Шушы вакыйгаларны анализлап карасаң, коммунистчыл идарәче даирәләрнең татар җәмгыятенең иҗтимагый аңын ныклап үзгәртергә керешкәнлеген аңларга була.

Инде тарихчылар тарафыннан исбат ителгәнчә, Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты тарафыннан 1944 елның 9 августында кабул ителгән карары безнең милли тарихыбызның иң әһәмиятле чылбырын—Алтын Урда чорын алып атуга юнәлдерелгән булган. Дөрес, коммунистик идарәчеләр бу очракта Алтын Урдага хас булган тарихи рус-татар каршылыгын юкка чыгарырга тырышканнар (моның өчен алар татарлардан болгарлар «ясап», соңгыларын «уртак дошман»га, ягъни Алтын Урдага каршы көрәштә русларга союздаш көч дип игълан итүдән дә тартынмаганнар). Ләкин ахыр чиктә мондый «операция» татар зыялылары, идеологлары тарафыннан озак вакыт дәвамында корылып килгән милли идентитетлыкка каршы юнәлдерелгән иде. Чынлап та, милли тарихны язган вакытта тарихи чорлар аркылы «тезелә» торган идентитет чылбырының һәрбер буыны әһәмиятле була һәм уникаль төс ала. Шуңа күрә, алга таба инде легитим төс алган тарихи чылбырдан аның бер генә өлешен дә милли үзаңга зыян китермичә төшереп калдырып булмый иде. Моны истә тотканда партия идеологларының никадәр мәкерле эш иткәнлекләре ачыла.

Шул ук вакытта, милли тарихка Алтын Урда дәверен кертүне тыю белән беррәттән, Советлар Союзында болгар-татар концепциясенә аерым урын бирелеп, 1940нчы еллардан ук, никадәр берьяклы булмасын, аны Татарстан тарих фәне өчен рәсми доктринага әйләндерделәр.

Башка партия документларында (1948, 1952 еллар) татар тарихында буржуаз этапнын прогрессив роле инкаръ ителде. Бу беренче чиратта татар җәмгыятендәге ислам реформаторлыгына (киң кулланышта «җәдитчелек» дип билгеле) карата негатив мөнәсәбәт булдыру аркылы тормышка ашырылды. Күрсәтелгән карарларда җәдитчелеккә «контреволюцион буржуаз-милләтчелек хәрәкәте, милләтчелек, пантюркизм, татар милләте эчендә сыйнфый каршылыксызлык идеологиясен алга сөрүче» дигән мөһерләр сугылды.

Билгеле, күрсәтелгән документларны тикшергәндә Советлар Союзында хакимлек иткән коммунистик даирәләр 1940-1950 елларда татарларның буржуаз этап өчен хас милли-азатлык хәрәкәте булмаган халыкка «әйләнүен» кайгыртканнар дип уйларга мөмкин булыр иде. Әмма мондый аңлатма һич тә җитәрлек түгел. Минем фикеремчә, Советлар Союзының сәяси элитасы каршында ул чорда катлаулырак бурыч торган: татар зыялыларына, гомумән җәдитчелеккә, димәк, милли тарихның буржуаз дәверенә карата инде бирелгән бәяләүләргә яңа караш булдырмаска, сталинизм чорында барлыкка килгән карашларны саклап, татарларның тарихи аңына аларның күптән түгелге тарихларын кертмәскә. Ә бу нәрсәгә китерергә мөмкин иде соң? Әгәр дә без татарларның милли идентитетлыгының XIX-XX йөз чикләрендә, беренче чиратта җәдит интеллектуаллары тырышлыгы белән барлыкка китерелгәнлеген истә тотсак, коммунистик идеологларның татарларга үзләренең милләт төзелеше белән бәйле булган иң әһәмиятле тарихи этапларын оныттырырга тырышуларын аларның хәзерге чор белән бәйле идентитетлыгын җимерергә омтылу дип карарга кирәк.

Бу шартларда татар зыялылары, бигрәк тә галимнәр, төп көчләрен Мәскәү конструктивистлары корган идеологиягә каршы юнәлдерделәр. Мәсәлән, өстән төшерелгән татар тарихын яктырту кысалары белән барлык татар тарихчылары да килешмәделәр. Әйтик, инде 1961 елны «Вопросы истории» исемле үзәк тарихи журналда Казан тарихчысы Х. Гыймади һәм Алтын Урда тарихы буенча белгеч, Саранскида эшләгән М. Сәфәргалиев арасында бик тә гыйбрәтле бәхәс булды. Х. Гыймади республикада тарих гыйлеме (историография) өчен рәсми булган, татарның болгардан барлыкка килүе турындагы позициядән чыкса, икенче тарихчы татар халкы оешуда Алтын Урда чорындагы төрки төркемнәрнең әһәмияте мәсьәләсен күтәрде. Бу саф академик төстәге дискуссия артында чынлыкта Татарстаннан читтә яшәүче татарларга мөнәсәбәт һәм урта гасыр татар дәүләтчелегенең тарихын ничек ачып бирү кебек гаять әһәмиятле мәсьәләләр ята иде. Билгеле, бу милли аң, идентитет белән нык бәйле булган проблемалар.

Чынлап та, татар тарихында Алтын Урда чорын инкарь итү югары уку йортлары өчен язылган дәреслекләрдә (алар «Татарстан АССР тарихы» дип атала иде) һәм мәктәпләрдә төбәкләр тарихы укыту өчен хәзерләнгән укыту кулланмаларында татарларның идентитетлыгы формалашуы мәсьәләсен аңлатканда катлаулылыклар тудырды. Чөнки бу дәреслекләрнең авторлары 1940-1970 еллардагы тарих гыйлемендә ныклап урнашкан татар идентитетлыгының «ясалма» булуыннан, аның халыкка тыштан кертелгәнлегеннән һәм фәкать тик XVII—XVIII йөзләрдә генә, хәтта аннан да соң дәвердә таралганлыгыннан чыгып эш иттеләр. Ул вакытларда нәшер ителгән мәктәп дәреслекләрендә мондый юлларны укырга була: «... Руслар татарлар дип монголларны атаганнар. Соныннан ул исемне алар ... болгарларга да җәелдерделәр. Якынча XIX йөздән болгарларның һәм башка төрки халыкларның варислары ... үз-үзләрен татар дип атый башлаганнар». Күренә ки, моннан укучылар татарның кем икәнлеген, аның милли аңының ничек барлыкка килгәнлеген аңлый алмаганнар. Икенче мисал. Мәктәп укытучылары өчен чыгарылган методик кулланмада (1967 ел) болай дип әйтелә: «Укучылар ачык итеп күзалларга тиешләр—Казан татарларының, халык буларак, исемнәреннән тыш, монгол-татарлар белән бернинди уртаклыклары да юк...». «Татар» атамасы болгарларга соңрак дәвердә кушылган». Билгеле, моның ише аңлатмалар белән балаларның башлары буталып кына беткән. Бу хәл озак сакланды һәм хәтта 1970 елларның ахырларында да, инде Сталин чоры белән чагыштырганда Советлар Союзындагы демократия күзгә күренеп

арткан заманда да, татар тарихчылары өчен Алтын Урда темасы күп яклары белән тыелган килеш калды.

Ләкин, Хрущев заманындагы «җылыну» дәвереннән башлап, илдәге тарих фәнендә үзгәрешләр сизелә башлады һәм алар арасында Алтын Урда тарихына игътибарның көчәюен дә күрсәтергә кирәк. Аерым алганда, 1960 елны, провинциядә булса да, М. Сәфәргалиевнең «Алтын Урданың таркалуы» исемле китабы басылу яңа күренешләрнең чагылышы булып тора. Кайбер кимчелекләре булса да, бу хезмәт милли тарих фәнендәге иске традицияләрне дәвам итте. Аннан соң Татарстанда, 1960-1970 елларда тарих гыйлемендә яңа юнәлешләргә нигез салган шактый гына хезмәтләр басылды. Беренчедән, алар арасында милли тарихны киңрәк аңларга ярдәм итүче этник тарих буенча тикшерүләр бар иде. Алар территориаль яктан да киңрәк төбәкне (Татарстанны гына түгел) колачладылар. Икенчедән, тарихи һәм аларга якын булган хезмәтләр сериясе дә басылды (М. Госманов, В. Хаков, Ф. Вәлиев Р. Фәхретдинов. Ә. Мөхәммәдиев һ. б. моногорафияләре). Башка яңалыклардан тыш аларда татар тарихының Алтын Урда һәм татар ханлыклары дәверләрен өйрәнү буенча да әһәмиятле өстәмәләр бар иде, аларны өйрәнү өлкәсендәге бурычлар да күрсәтелгән иде.

Шулай да, 1980нче елларның урталарына кадәр татар тарихчылары массакүләм басмаларда, мәсәлән, югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен булган дәреслекләрдә, милли идентитетны формалаштыруны, милли-большевистик (империячел) идеологлар эшләп чыгарган күрсәтмәләр нигезендә алып барды. Әлеге сәясәткә каршылык, инде күрсәтелгәнчә, күбрәк академик фән кысаларында булды.

Бу хәл М. Горбачев чорындагы үзгәртеп кору вакытларында гына, милли хәрәкәт күтәрелеше башлангач, үзгәрде. 1987-1990 елларда милли этноним турында периодик басмаларда, электрон мәгълүмат чараларында «татар» һәм «болгар» атамаларын куллануны тәкъдим итүчеләр арасында барган дискуссияләр—ә алар вакыт-вакыт киеренке көрәшкә әйләнделәр—ахыр чиктә Татарстанда ике идеологик агым—«татарчылар» һәм «болгарчылар» юнәлешләре формалашуга китерделәр. Ягъни татар җәмгыятендә демократия шартларында элекке дәвердә булган карашлар кире кайттылар. Күрсәтелгән идея агымнарының соңгысы эчендәге, аның урталыгында торучы галимнәр, татар этник тарихының төрки-татар теориясен эшләп чыгарып, тарих буенча дәреслекләр әзерләүдә әһәмиятле урын тота башладылар һәм, асылда, Ш. Мәрҗани традициясенә барып тоташучы милли идентитетны корунын иске моделен торгыздылар. 1990нчы еллар урталарында алар татар тарихын иске рухта язарга омтылучыларны бик нык тәнкыйтъ иттеләр. Нәтиҗәдә, фәндә болгарчылык агымы сакланса да, милли тарихны язуда төп рольне төрки-татар теориясе тарафдарлары уйный башлады. Алар фикеренчә, урта гасыр татар этносы формалашуда Алтын Урда чоры төп этап булган

Инде әйтелгәнчә, озак вакыт, асылда, 1980нче елларнын башларына кадәр, татар тарихының буржуаз чоры 1948 һәм 1952 елгы партия карарлары рухында тасвирланды. Әмма кайбер соңрак чорда югары уку йортлары өчен эшләнгән дәреслекләрдә (1968, 1973 һәм 1980 елларда басылганнарында), яшерен рәвештә булса да, җәдитчеләрнең либераль-буржуаз канатының эшчәнлегендәге уңай яклар да күрсәтелә башлады (аларның милли мәктәпне яклаулары, телләрнең тигезлеге өчен һәм дин ирегe өчен җан атуы һ. б.). Ләкин төбәк тарихы буенча булган мәктәп дәреслекләрендә татардагы мөселман реформаторлыгы мәсьәләсе бөтенләй күтәрелмәде. Ахрысы, бу мәсьәлә катлаулы булу сәбәпле һәм сәяси чикләүләр басымы астында, әйтелгән проблема «демократик мәгърифәтчелек» буларак кына яктыртылды, ягъни XIX-XX йөз чикләрендәге татар милли хәрәкәтеннән—ә ул бербөтен күренеш иде—анын коммунистик идеологлар фикерләгәнчә, «уңай» булган өлешен генә бүлеп алып яктырттылар. Әле шуның өстенә, «демократик мәгърифәтчелекнең» төп сыйфаты итеп, гадәттә, үз халкын рус мәдәниятенә тартуын (кайбер очракларда—дөнья һәм рус мәдәниятенә) күрсәттеләр. Әмма мәктәп дәреслекләренең кайбер басмаларында барыбер югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрдәге иске фикерләр чагылды (татар буржуазиясенең «реакцион» булуы, анын мөселман руханилары белән бергәләп хезмәт ияләрен «пантюркизм» рухында тәрбияләргә омтылуы,

татарларның «тормышларының барлык якларын ислам чорнап алган төрекләр мисалында» барырга теләүләре турындагы фикерләр һ. б. шуңа охшаш нәрсәләр күренде). Билгеле, мондый дәреслекләр нигезендә тәрбияләнгән татар җәмгыятенең иң зур өлеше 1980нче елларның урталарына кадәр үз милләте тарихының буржуаз чоры турында төгәл мәгълүматка ия була алмады.

Ләкин Татарстанда галимнәр арасында инде 1940нчы елларда ук җәдитчелекне мәгърифәтчелекнең бер этабы буларак карау юлы белән легальләштерергә тырышу башланды. Официоз тарихчылар ул вакытта да, соңрак чорда да мондый галимнәрне тәнкыйть иттеләр. Әмма 1960-1970 елларда татар җәмгыятенә хас булган тарихи мираска үтә игътибарлылык (Америка галиме Э. Лаззерини аны «мирасчылык» дип атады) ахыр чиктә онытылган тарихны торгызуга һәм этник идентитетны яклауга китерде. Милли тарихны бөтен тулылыгында торгызу кирәклеге 1970нче елларда җәдитчелекнең, дөрес, мәгърифәтчелек исеме астында, тарихи хезмәтләргә кире кайтуын тәэмин итте. Ә моның белән бергә милли аң формалашу мәсьәләсе, аның тирәсендә XX йөз башларында барган дискуссияләр дә янадан халыкка барып ирешә (язылган хезмәтләрне укып баручыларга, билгеле).

1980нче елларның икенче яртысында барган иҗтимагый андагы үзгәрешләр акрынлап Татарстанда эшләүче галимнәрнең хезмәтләрендә җәдитчелекне бәяләүне үзгәртте—җәдитчелек XIX-XX йөзләрнең чикләрендә татар җәмгыятендә барган буржуаз-демократик хәрәкәтнең идеологик чагылышы дип карала башлады (Я.Г. Абдуллин). Бу очракта җәдитчелек мәгърифәтчелекнең бер этабы буларак каралса да, алар арасында булган принципиаль аермалыклар ачык итеп күрсәтелә башлады. Аннан соң инде кайбер тикшерүчеләр турыдан-туры җәдитчелекне «милләт төзү» этабы итеп карый башладылар.

Шулай итеп, татар зыялылары 1990нчы елларда җәдитчелеккә карата Татарстанда 1920нче елларга кадәр яшәп килгән бәяләүләргә кире кайттылар. Үз чиратында мондый трактовкалар хәзерге заманда чит ил галимнәре хезмәтләрендә булган бәяләүләргә якын тора—алар җәдитчелек хәрәкәтен XIX-XX йөзләрдәге татарлар арасында барган буржуаз реформаторлык фонында карыйлар. Академик даирәләрдә татарларның буржуаз этап тарихын яңача күзаллау башлану җәдитчелек феноменын милли тарихка багышланган дәреслекләрдә яңача аңлатуга китерде. Аларда инде «җәдитчелек» һәм «мәгърифәтчелек» төшенчәләренең бер үк мәгънәгә ия булуы, ә Ш. Мәрҗанинең татар реформаторлыгының иң күренекле вәкиле икәнлеге турыдан-туры күрсәтелде. Кайбер дәреслекләрдә җәдитчелек мәгърифәтчелекнең дәвамы буларак, реформаторлык хәрәкәте яисә татар милли хәрәкәтенең бер юнәлеше итеп тасвирлана. Ә җәдитче сәясәтчеләрнең сәяси проектлары (милли-мәдәни мохтарият, Идел-Урал штаты) федератив Россия эчендә милли дәүләтчелек булдыруга омтылыш буларак карала. Димәк, дәреслекләрдә әле Татарстан гуманитар фәнендә татарларның буржуаз этабы турында соңгы елларда барлыкка килгән яңа трактовкалар тулысы белән чагылмаса да, XIX-XX йөзләр чикләрендә татар җәмгыятенең үсеше турындагы иске стереотиплар юкка чыгарылды. Эшнең шул якка барганлыгын кайбер чит ил галимнәре инде 1980нче елларның башларында ук аңлаганнар иде. Мәсәлән, Америка тарихчысы Э. Лаззерини татар зыялыларының милли аңны торгызырга тырышуларының мәдәният өлкәсе белән генә чикләнмичә, сәясәт сферасына да күчәчәген һәм ахыр чиктә Советлар Союзында барган иҗтимагый процессларның милләтебезнең урынын билгеләү өчен хезмәт итәчәген 1981 елны ук язып чыккан иде.

Шулай итеп, Советлар Союзы кысасында тоталитар режимның берничә буын татар зыялылары тырышлыгы белән барлыкка китерелгән милли идентигетны юкка чыгарырга омтылулары бөтенләе белән уңышсызлыкка очрады. Коммунистчыл-большевистчыл «конструкторчыларга» каршылык күрсәтүдә төп рольне татар зыялылары, бигрәк тә тарихчылар уйнадылар. Нәкъ менә алар, үзгәртеп кору (Горбачев чоры) башлангач, беренче булып милли идентитет өчен (ә ул көчле мөселман «компонентын» да үз эченә алды) көрәшкә кереп, советлардан соңгы ун ел эчендә иҗтимагый аң өлкәсендәге

империячел-коммунистчыл «корылмаларны» тулысынча җимереп, беренче «милләт төзүче»—Ш. Мәрҗани нигез салган татар идентитетлыгын үстерүнең магистраль юнәлешен янадан торгыздылар.

VII бүлек

## КИЛӘЧӘККӘ ЮЛ: ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАСЫ ТУРЫНДА

Татарларның хәзерге хәленә диагноз куеп, аларның алдагы үсеш юлларын билгеләргә омтылулар соңгы вакытта аерым зыялыларыбызның игътибарын җәлеп итә башлады (З. Хәким, Р. Сафин, Р. Хәким һ. б.). Татар җәмгыятенә куелган диагнозлар еш кына шактый күңелсез булып, перспектива югалып та кала башлады. Әмма моның ише бәяләүләр безнең җәмгыять өчен яңа күренеш түгел—әле XX йөз башында ук күренекле сәясәтче һәм язучы Г. Исхакый үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле мәшһүр әсәрендә мондый фикер әйткән иде: «... мин һич... өметләр кәтәрлек «төпле» бер эш күргәнем юкка, хәзер дә халкыбыз арасында сөйләнә торган сүзләргә, эшләнә торган эшләргә вакытлы килгән «бизгәк» дип кенә карыйм... кычкырышларга «курчак туе» дип кенә исем бирәм». Шул тирән мәгънәле, әле бүген дә искермәгән сүзләргә ялгап, әдип мондый сүзләр өстәп куя: «Тырышыйк, авырлыклар күтәрик, бернәрсәбезне дә кызганмыйк, менә шуннан соң милләт милләт төсле булса булыр». Билгеле, «тырыша» башлаганчы кайсы якка таба бару кирәклеген билгеләү хәерлерәк. Ә бу, бүгенге шартларны исәпкә алсак, җиңел эш түгел. Шулай да, безгә беренче чиратта татарларның мөселман өммәте буларак үсеш юллары турында уйларга кирәк. Керәшеннәрнең перспективасы, төп татар массасы белән бәйле булса да, башкачарак.

Россиядәге мөселманнарның тарихын бик яхшы белүче галим—А. Беннигсен үзенең «Мусульмане в СССР» дигән китабында татарларның революциягә кадәр булган үсешенә бәя биреп, алар ярты гасырдан да азрак вакыт эчендә «квази урта гасыр ислам җәмгыятеннән хәзерге заман, динамик һәм тормышчан җәмгыятькә әверелеп, Сталин террорын һәм совет ассимиляциясен дә үткәреп җибәрә алдылар»,—дип язган иде. Татарлар арасында барган реформация А. Беннигсен уйлаганга караганда элеккерәк заманнардан башланса да, галимнең төп фикере дөрес: Россиядәге башка мөселман халыклары белән чагыштырганда татарлар чынлап та заманча милләтчелеккә иртәрәк күчкәннәр. Беренче чиратта бу православ метрополия белән колонизацияләнгән мөселманнар периферияse арасындагы конфессиональ аерымлыклар булудан чыгып аңлатылырга тиеш. Әмма татарларның мәдәниятле һәм цивилизацияле халык булуы да бу очракта әһәмиятле булган. Ләкин татарларның буржуаз үсеш юлыннан китүләре шактый иртә башланса да, алар капиталистик модернизация юлын тулысынча үтә алмадылар, чөнки аңа алмашка бик иртә совет модернизациясе килде. Соңгысы татарларда нык эз калдырды—әле бүген дә милләтебез совет рухыннан (аны русча «совковость» диләр) арынып бетә алмый. Моның ачык бер мисалы—«Звезда Поволжья» газетасы битләрендә соңгы вакытларда барган татар интеллигенциясе арасындагы «көрәш», чөнки ул чынлыкта «совковый» зыялыларның таркалу процессын күрсәтә. Аның ише нәрсәне Мәскәүдә барган «Татар мәсьәләсе» тикшерү семинарларындагы аерым чыгышлардан да күрергә була. Иң кызганычы шунда ки, бу уннарча еллар дәвамында үзләштерелгән совоклар психологиясе безнең тарихи рәвештә формалашкан либерал-ислам рухыбызга (җәдитчелек аша сеңгән рухыбызга) берничек тә туры килми. Бүгенгә кадәр безне коткаручы—шушы рухыбызның бөтенләй үк сындырылып бетмәве.

Алга таба үсү турында уйлаганда, безгә большевиклар тарафыннан өзелгән милли юлыбызга кайту турында сүз алып барырга кирәк. Әмма, бер аккан суга кире кереп булмаган төсле, бу юлга турыдан-туры кайту мөмкин түгел. Әле шуның өстенә алда берничә юл бар, безгә шулар арасыннан берсен сайлап алырга кирәк булачак.

*Тарихыбызның җәдитчелек чорына социо-сәяси караш*

Россия төрки-мөселман бергәлегенең XIX-XX йөзләрнең чикләрендәге сәяси үсешнең тарихчылар тарафыннан үтә дә начар өйрәнелгән һәм чынлыкта алар тарафыннан аңланмаган бер бик тә гыйбрәтле векторы бар. Сүз илдә бердәм әдәби телле зур төрки-мөселман милләте төзү проекты турында бара. Россия империясендә булсын, аның яңа версиясе булган Совет империясендә булсын, бу проект «пантөркичелек» һәм «панисламчылык» мөһере белән гел сүгелеп килде, ләкин аңа тиешле объектив бәя бирелмәде. Ә бит дөнья андый тормышка ашырылган проектны да белә—гарәпләр, аларның төрле тармаклары арасында бер-берсен аңларга комачаулаучы диалекталь аермалыклар булуга карамастан, гомум-гарәп әдәби теле дәрәҗәсендә үзләренең тел бердәмлеген саклап кала алдылар. Сәяси тормышта «гарәп милләте» дигән төшенчә дә яши, гарәпләр арасында таркаулык бетмәгән булса да, еш кына без аларның бер-берсенә ярдәмен һәм булышлыгын күрәбез. Тиздән, сәяси аренага яңа буыннар (белемле, киң карашлы, гарәп милләтчелеге рухында тәрбияләнгән) чыккач, бу бердәмлек яңа дәрәҗәгә күтәрелер дигән өмет тә бар.

Тарихи хезмәтләрне укыганда анда без бер гомуми фикер күрәбез: төрки-татар бердәмлеге идеясенә нигез салган И. Гаспралы (1851-1914) XX йөз башында җиңелеп, аның концепциясе урынына төркиләрдә аерым әдәби телләр (милли телләр) булдыру концепциясе килде,—дигән фикер. Бу гомумиләштерүдә беркадәр дөреслек бар, билгеле. Әмма тикшерелә торган бик катлаулы процессның эчтәлеге моның белән генә чикләнми. Беренчедән, Россия төркиләренең теге яки бу дәрәҗәдә ирекле үсешләре бик кыска булды—инде 1920нче еллар урталарыннан совет тоталитаризмы ныгып урнашты. Шуңа күрә милли әдәби тел нормалары да күп очракта совет чорында формалашып, аларның алфавитлары да коммунистик-большевистик идеологларның ныклы контроле астында эшләнде. Нәтиҗәдә сөйләм телләре һәм диалектлары якын булган төркиләрнең әдәби телләре этник яктан тугандаш булган берлекләр өчен дә аңлашылмый торган булып чыкты. Икенчедән, XX йөз башларындагы Россиядәге төрки-мөселман бергәлегенең динамикасы еш кына бу илдә чыккан хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә гади генә түгел. Әйтик, 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Мәскәүдә (май аенда) булган I Бөтенрусия съездында «икеләтелгән автономия» (территориаль һәм милли мәдәни мохтарият) концепциясе кабул ителеп, ул кысаларда җирле (региональ, милли) власть һәм идарә органнары гына түгел, ә бөтен төрки-мөселманнар өчен уртак булган гомуми бер үзәк орган да төзү күздә тотылган. Соңгы структура илдәге төрки-мөселманнарның бердәмлеген тәэмин итеп, аларның рухи-мәдәни эшләрен (дин, мәгариф һ. б.) алып барып, үз компетенцияләре эчендә үзенә күрә «мөселман парламенты» ролен (хәтта кайбер юнәлешләр буенча законнар чыгару да күздә тотыла) башкарырга тиеш була. Бу орган төзелә дә башлый—Бөтенрусия мөселман шурасы шуның яралгысы иде (аның башында Башкарма комитет торды—рәисе осетин Ә. Цаликов). Дөрес, революция чорындагы ыгы-зыгылар аңа яхшылап эшләп китәргә мөмкинлек бирмәделәр (1918 елның май аенда таратылганчы ул оешманы финанс ягыннан татарлар гына тәэмин итеп тордылар). Шулай да, күпмедер вакыт ул төрки-мөселманнарның гомуми бер үзәк органы ролен башкарып килде. Мәсәлән, Казанда булып II Бөтенрусия мөселман съездында (1917 елның июле), татарлар күпчелекне тәшкил итү шартларында, «Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнары» өчен милли-мәдәни мохтарият төзү турында карар кабул ителгәч, Вакытлы хөкүмәт адресына бу турыда аерым «Мөрәҗәгать» (анда югарыда искә алынган карарны тормышка ашыруның юридик механизмнары каралган була) Бөтенрусия мөселман шурасы башкарма комитеты рәисе Ә.Цаликов имзасы белән юллана.

Большевикларның хакимияткә менүе вәзгыятьне, билгеле, үзгәртә, ләкин бөтенләй үк түгел. Бу турыда большевикларның берсе артыннан берсе килүче, үзара бәйләнгән мөселман оешмалары «чылбырын» төзергә мәҗбүр булганлыклары сөйли (1918 ел, гыйнвар—Үзәк мөселман социалистик комиссариаты; 1918 ел, март—Үзәк мөселман социалистик комитеты; 1918 ел, июнь—Россия мөселман

коммунистлар партиясе; 1919 ел, ноябрь—Мөселман коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы). Монда өстәп тагы әһәмиятле сәяси роль уйнаган «Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Бөтенрусия съездларын» (беренчесе—1918 елның ноябрендә, икенчесе—1919 елның ноябрендә) күрсәтергә кирәк. Димәк, үзгәрешләргә карамастан, төрки-мөселман милләтенең «тәне» әле исән булган! Ә М. Солтангалиевнең Туран республикасы (башта Советлар Союзы кысасында) һәм анда хакимлек итүче Туран эшче-крәстиән социалистик партиясе төзү проекты. Милли коммунистлар арасында иң эре сәяси фигура булган М. Солтангалиевнең шул ук төрки-мөселман милләтен булдыру проекты түгелме соң бу?

Дөрес, монда язылган мәсьәләләр күбрәк тарихи әһәмияткә генә ия, чөнки хәзерге заман XX йөз башларыннан нык аерыла. Беренче чиратта, элек Россия империясенә, аннан соң Советлар Союзына кергән эре төрки милләтләрнең мөстәкыйль дәүләтләр төзеп яши башлаулары белән аерыла безнең заман. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: алга таба Россия күрше төрки дәүләтләр белән тыгыз икътисади һәм сәяси бәйләнештә булачак, ә ана чиктәш төрки дөньяда (Төркияне дә кертеп) 250-300 млн. төрки яшәячәк. Шуның өстенә, демографик прогнозлар буенча, бүген Россиядә мөселманнар халыкның 1/5 тәшкил итсәләр, илле елдан соң алар 40 процентка житәчәкләр. Димәк, яңа шартлар турында илнең төрки мөселман бергәлеге интеллектуалларына һәм сәясәтчеләренә нык уйланырга кирәк. Нәкъ менә шул вакытта безнең уртак тарихыбызда калган төрки-мөселман милләтенең шәүләсе янадан күренәчәк. Ә ул гади нәрсә түгел. Гомумән, Россиядәге мөселман өммәте динамик, тормышчан һәм реформаларга баручы җәмгыять булып тора. Үзләренең бик озын тарихларында күпне күргән төньяк мөселманнары үз бурычларына ирешә беләләр һәм үз көчләренә таянып эш итәргә күнеккәннәр. Шуңа күрә дә төрки-мөселман милләте проекты алдагы көннәрдә тагын калкып чыгарга мөмкин.

### *Үсеш модельләре: гомуми һәм татарлар өчен специфик булган вариантлар*

Киләчәкне чамалау җиңел түгел. Бу турыда «Сумерки Запада» исемле китап авторы, күренекле Аурупа футуристы К. Коукер болай дип язган иде: «Без үзебез төземәгән Үткәннең шәүләсе астында торып беркайчан да үзебез күрә алмаячак Киләчәкне көтеп яшәүчеләр». Чынлап та шулай бит: шул ук әдип әйткәнчә, без киләчәкнең үзебезнең варисларыбызга нәрсә билгеләвен әйтә алмыйбыз һәм безгә киләчәктә нәрсәнең әһәмиятле, нәрсәнең әһәмиятсез булачагын күз алдына китерүе кыен. Димәк,—дип дәвам итә бу галим—алга таба хәрәкәт итү өчен безнең нигезебез юк. Шушы беркадәр пессимистик рухта язылган сүзләр дөреслеккә бик якын булсалар да, киләчәккә үтеп керергә тырышуны мин кирәк дип саныйм. Ни өченме? Алга таба булачак үсеш юлларын чамаласак, милләтебезгә кайбер озын юлларны кыскартып, яңа тормышка тизрәк житү мөмкинлеге булыр дип уйлыйм мин. Аннан соң шуны да истә тотарга кирәк: бүген бик тә реаль булган кайбер киртәләр иртәгә бөтенләй юкка чыгарга, яисә әһәмиятсез бер нәрсәгә әйләнергә мөмкин. Шуңа күрә инде бүген үк киңрәк фикерләүгә күнегү зарур. Футуристик күзаллау моңа нык ярдәм итә ала.

Гомумән алганда, бүген Татарстанның суверенлыгы күпкә кимеде, республика РФ эчендәге бер субъектка әйләнде. Өстән-өстән генә фикерләгәндә без элекке автоном республика хәленә кайткан төсле күренергә мөмкин. Ләкин чынлыкта Советлар Союзы дәвере белән чагыштырганда безнең хәзерге хәлебез арасында фундаменталь аермалык бар:

1) Татарстанда 1920нче елларда шәһәрдә татарларның 1/10 генә яшәсә, хәзер шәһәрдә яшәүчеләрнең проценты 70кә житте. Ил буенча күрсәткеч аннан да югарырак. Бу—бик әһәмиятле социаль үзгәреш. Чөнки шәһәр халкын массакүләм информация чаралары аркылы тизрәк туплап була, ул белемлерәк,социаль яктан күп тармаклырак һ. б.

2) Соңгы ун елдан артык вакыт эчендә татарлар арасында бай һәм бик бай

кешеләр катламы барлыкка килде, урта катлам да формалаша башлады.

3) Сәяси система совет чоры моделеннән ераклашты—инде бер партияле система бүтән кире кайтмас дип уйларга урын бар. Шуңа күрә хәзерге заманда революциягә кадәр татар җәмгыяте өчен хас булган кайбер күренешләр күзгә ташлана, беркадәр совет дәверендәге НЭП заманында булган үзенчәлекләре дә юк түгел.

Ләкин бу үзгәрешләргә дә карамастан, татарлар беркадәр модификацияләнгән иске юлны кабатларга дучар ителгәннәр, ахрысы. Ни өченме? Эш шунда ки, без Россиянең нык инерцион төстәге цивилизация пространствосында яшибез, шуның өстенә ул пространство бик нык совет мирасы белән укмашкан. Менә шушы чолганыш татар җәмгыятенең алга таба үсүенә көчле йогынты ясаячак һәм без аны берничек тә истән чыгарырга тиеш түгелбез. Ә гомумроссия сәяси пространствосында бүген күзгә чалынып торган ике җәмгыятьне формалаштыру концепциясе бар: а) либераль модель (Аурупа юлы); б) традиционалистик модель (Ауроазия юлы). Күбрәк өлкән буын вәкилләре арасында йогынтысын саклаучы өченче—коммунистик проектның киләчәге юк. Шуның өстенә, үзенең базис элементлары буенча ул традиционалистик модель белән якынайтыла ала. Аның беренчесе (либераль проект) Көнбатыш өчен хас кыйммәтләргә таяна, шәхес мәнфәгатьләренең коллектив мәнфәгатьләреннән өстенлеген таный. Икенче проект иске рус кыйммәтләрен, шул исәптән совет йогынтысы нигезендә барлыкка килгәннәрен дә алга сөрә. Алар арасында коллектив мәнфәгатьләрен шәхеснекеннән өстен куйган корпоративлык рухына таяну да бар. Әгәр дә беренчеләре арасында булган аз йогынтылы үтә дә либераль рухлы төркемне исәпкә алмасак, Россия җәмгыятенең үсеше буенча күзгә ташлана торган бу ике проект консерватив билгеләре белән аерылып тора. Алар арасында иң ачык күренгәне—милли (этник) проблемаларны күпчелек принцибы аркылы хәл итәргә омтылу. Моның төп сәбәбе шул: алдагы елларда рус җәмгыяте өчен милләтчелек зур урын алып торачак (бу башка илләргә дә хас күренеш). Безнең ил кысаларында фикерләсәк, мондый иҗтимагый аңның төп урын алуы ике нәтиҗәгә китерергә мөмкин: а) милли республикаларны юкка чыгарып губерналарга нигезләнгән административ системага күчү һәм милли мәсьәләне милли-мәдәни мохтарият аркылы хәл итәргә омтылу; б) бу республикалар сакланган очракта (стратегик курс буларак түгел, ә вакытлы бер зарурилык буларак) Федераль үзәк файдасына вәкаләтләрне бүлешү һәм шуның нәтиҗәсендә реаль хакимиятнең тагын этник яктан күпчелек булган халыкның мәнфәгатьләреннән дә чыгып тормышка ашырылуына ирешү. Бу һәр ике очракта да милли азчылыкларның коллектив хокукларын илдә берәү дә якларга җыенмый. Билгеле, мондый сәяси системаның төп юнәлеше, ул нинди генә форма алса да (либераль яисә традиционалистик—җирлек модельләре), «инородецларны» этник күпчелек эчендә «эретүгә» корылган булачак. Андый сәясәт Америкада шактый еллар алып барылды (аны «эретү тигеле» сәясәте дип атадылар). Бездә исә ул бик тә билгеле сәясәт—1917 елга кадәр яшәгән иске Рус империясендә булсын, аның дәвамы булган Совет империясендә булсын (кыска гына «интернационализм» чорын исәпкә алмаганда), нәкъ менә шундый сәясәт алып барылды.

Моннан нинди нәтиҗә килеп чыга соң? Менә мондый: алдагы елларда Россиядә «күп мәдәниятле», заманча, милли азчылыкларның хокукларын гарантияләгән җәмгыять төзү ул, беренче чиратта, шушы милли азчылыкларның (алар бүген илдәге халыкның 1/5 тәшкил итәләр) эше булып тора. Рус булмаган халыклар арасында иң эресе булган татарларга теләгән киләчәккә ирешү өчен үзләренең стратегик курсларын сайлап алырга кирәк. Аның нинди булуына татарның үз язмышы гына түгел, XXI гасырдагы Россия җәмгыятенең үзенчәлекләренең күп өлеше дә бәйле булачак. Бүгенгә татар зыялылары яна татар җәмгыяте формалашуның өч төп юлын (моделен) тәкъдим иттеләр. Шартлы рәвештә аларны татарстанчылык, татарчылык һәм исламчылык дип атап була.

*Татарстанчылык.* Бу Татарстанда хәзер хөкем итүче сәяси элитаның рәсми доктринасы. Аның нигезләрен Татарстан Республикасы Президентының сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе Р. Хәкимов «Сумерки империи. К вопросу о нации и государстве» (1993) исемле хезмәтендә эшләде. Француз политологы Жан-Робер

Равио бу доктрина турында мондый фикер әйткән иде: Татарстанның сәяси элитасы фәкать тик социаль һәм икътисади мәнфәгатьләргә генә нигезләнеп ясалма «милләт» кору юлына баскан. Чынлап та, югарыда күрсәтелгән хезмәтне өйрәнгәндә республика суверенитетының нигезен милләтсез Татарстан «халкы» тәшкил итә дигән идея ачык күренә. Кайбер Татарстан галимнәре һәм искә алынган француз политологы этно-мәдәни үлчәмсез «татарстанлылар милләтен» төзеп булмаячагы турында кисәтеләр. Шул исәптән, андый «милләтнең» «россиянлылар» милләтеннән аерылып тора алмаячагын да исәпкә алып әйтелгән иде бу кисәтү. Бүген инде кисәтүнең бик тә урынлы булганлыгы ачык. Шунлыктан, Р. Хәкимовның татарстанчылык доктринасын модернизацияләргә кирәклеген күрсәткән яна хезмәте дөнья күрде (сүз «Кем син, татар?» дигән, 2002 елны басылган китап турында бара). Монда татарчылык идеологиясенә авышу нык кына сизелә.

Татарстанчылык проектының иң әһәмиятле моменты—аның элеккеге совет номенклатурасы белән бәйле булган хәзерге республикадагы идарәче даирәләр тарафыннан хуплануы. Билгеле булганча, бу төркем үзенең сәяси ориентирлары буенча эре капитал мәнфәгатьләрен чагылдыра (юкка гына аның сәяси юлбашчылары үзләрен «уң үзәк» белән тәңгәлләштермәделәр).

*Татарчылык.* Аның доктринасы нигезләрен милли хәрәкәттә актив катнашкан гуманитар интеллигенция вәкилләре эшләгән иде. Татарчылыкның төп юнәлеше—милли мәнфәгатьне, татарның этник хокукларын яклау булды. 1994 елгы шартнамә төзүдән соң шушы проектны формалаштырган идеологлар республика суверенитетының нигезен беренче чиратта татар милләтенең суверенитеты тәшкил иткәнлегенә басым ясый башладылар. Алар фикеренчә, этномәдәни нигездән башка аерым милли-дәүләти организм була алмый. Республикада яшәгән русларның этномәдәнияте гомуми рус мәдәниятеннән бер ягы белән дә аерылып тормаганлыктан, Татарстан «халкының» үзбилгеләнүенең бердәнбер алшарты булып татар милләте, аның үзбилгеләнүе тора. Монда татарларның руслардан кайсы ягы беләндер «яхшырак» булулары турында сүз бармый, суверенитетның объектив җирлеге турында сүз бара. Дөньяда этник нигезе булмаган кисәкле федератив дәүләтләр булса да (мәсәлән, Германия, АКШ һ. б.), аларда да аерым «җирләрнең» ниндидер милли төсмерләре бар (Канададагы Квебек һәм Һиндстандагы аерым штатлар кебек), яисә алар тарихи, этник, конфессиональ һ.б. яклары белән (АКШтагы испан телле Техас штаты, ул илдәге кайбер штатларның элек инглизләр, французлар, испанлылар кулында булулары, яки Швейцариядәге кантоннарның төрле дин һәм этник төркемнәр вәкилләреннән торулары һ. б.) башка территорияләрдән аерылып торалар.

Татар факторының республикабызның язмышы өчен әһәмияте Татарстан җәмгыятенең фикерле белгән өлеше өчен һәрчак билгеле бер нәрсә булды. Бу фактордан башка республиканың эчке төзелеше, социаль-сәяси бөтенлеккә ия булган милли-дәүләти организмга әверелә алмаячагы көн кебек ачык. Бүген, яна сәяси шартларда, ул киңрәк даирәләргә дә аңлашыла башлады. Дөрес, монда татарстанлылар милли-дәүләти берлеген булдыруның аерым моделен тәкъдим итү кирәк, ягъни аның эчке төзелеше нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап бирү зарур. Чөнки республикада яшәүче татарларның аерым хокуклары белән монда яшәүче барлык этник төркемнәрнең тигезлек принцибын саклауны тәңгәлләштерергә кирәк. Минемчә, бердәнбер дөрес юл—республиканы эчке яктан федеральләштерү юлы белән китү. Сүз Татарстанда ике төп этник төркемнең—татарлар һәм русларның—аерым общиналар булуын конституцион нигездә беркетү (бәлки, башка зур төркемнәрне дә «танырга» кирәк булыр) турында бара. Бу исә аларны реаль сәяси субъектларга әйләндереп дәүләт төзелешендә һәм демократияне үстерүдә этник факторның ролен тану дигән сүз. Нәрсә күз алдында тотыла соң монда? Беренче чиратта, Татарстан Дәүләт Советында милли җәмгатьләрнең (общиналарның) вәкиллелегенә депутатларның милли составын квоталау нигезендә ирешү турында сүз бара (аның башка бер варианты—парламентта милләтләр палатасы булдыру). Бер үк вакытта, республиканың эчке административ-территориаль төзелешен дә үзгәртү кирәк булачак—хәзерге гел экономик принциптан чыгып төзелгән районнар урынына

этник һәм тел күрсәткече буенча төзелгән күпкә эрерәк кантоннар булдырып булыр иде. Шәһәр шартларында Бельгия тәҗрибәсеннән чыгып милли бергәлекләр төзү кирәк булачак. Шулай итеп, сайлаулар этник нигездә (аерым курияләр аркылы) барып, этник мәнфәгатьләрне ачык рәвештә, парламент кысаларында күтәрергә мөмкинлек туа. Димәк, милли җәмгатьләр эчке яктан берләшеп, сәясәттә халык массаларының роле артачак. Шуңа күрә дә бу модель тормышка ашырылган очракта халыкның төп өлешенең, вак һәм урта милекчеләрнең мәнфәгатьләре беренче урынга чыгып, скандинав илләрендәге социал-демократлар төзегән җәмгыять төсле җәмгыять барлыкка китереп булыр иде. Гомумән, татарчылык проекты ул сәясәттәге «сул» канатның (ләкин коммунистик булмаган) доктринасына нигезләнә.

*Исламчылык*. Әйтелгән доктрина 1990нчы елларның урталарына, Татарстанда һәм башта татарлар яшәгән төбәкләрдә милли хәрәкәтнең радикаль канаты фундаментализмга якын карашларга күчкәч формалашты. Бу фикри агым вәкилләренен төп идеясе—хакимиятнең «чын ислам» рухындагы властька әйләнүе. Үзенә күрә халыкчан рухта булган шушы доктринага караганда, җәмгыять тулаем мөселман мәхәлләләре нигезендә корылырга тиеш, ә Милли Мәҗлеснең (милли законнар кабул итүче иң югары орган) мәхәлләләрдән үсеп чыгуы каралган. Әмма эш шунда ки, мәхәллә үзе дә, Милли Мәҗлес тә фәкать тик 100 процент мөселманнар—«кануни татарлар» тарафыннан гына оештырыла. Башка төркемнәр исә шушы катлауга буйсынырга тиеш була. Татарстан башында торучы җитәкчесенең дә Милли Мәҗлескә буйсынуы каралган.

Тикшерелә торган доктрина «зур җиһадта» җиңеп чыгуны күз алдында тота. Беренче чиратта ул рухи өлкәдә, мәгърифәт, милләтнең рухын көчәйтү юлы белән ирешелә торган җиңү. Әмма башка төрле җиһад та каралган (шул исәптән физик көч куллану юлы да).

Ныклап уйлаганда шул ачыклана—исламчылык доктринасы йөзендә без берничә иҗтимагый факторның бергә кушылу нәтиҗәсен күрәбез (кискен социаль катлаулану, татар җәмгыятендә ислам кыйммәтләренең көчәюе, Россиядә халыклар арасында тигезсезлекнең саклануы һ. б.). Ләкин шуны да истә тотарга кирәк: исламчылык проектына ниндидер дәрәҗәдә «халыкчанлык» һәм демократия рухы да хас. Дөрес, «кануни» мөселманнар өчен генә. Ахрысы, бу идеология «өченче» юл, ислам социализмы һ. б. шуның ише иҗтимагый модельләр белән бәйле.

Йомгак ясап, шуны күрсәтү кирәк: безнең каршыбызда алга таба татар җәмгыяте трансформацияләнүнең өч юлы. Минем уйлавымча, татарстанчылык һәм татарчылык җәдитчелек идеологиясеннән үсеп чыга һәм аның кысаларындагы ике тармакны тәшкил итә. Берсе—либераль юнәлеш, икенчесе—халык демократиясе (социал-демократик) юнәлеше. Аларга каршы торучы исламчылык проектын җиһадлылык проекты дип атау дөрес булыр. Аның идеологик нигезен татар җәмгыяте үсешенең фундаменталистик варианты тәшкил итә. Беренче ике юл бер-берсе белән янәшә яши ала—дөресрәге, алмашка килүче ике сәяси система тәшкил итә ала. Әмма башка комбинацияләр дә була ала, шул исәптән, исламчылык проекты белән дә. Әйтик, сәяси процессларның мондый варианты да мөмкин: урталык сәясәте тарафдары булган исламчыларның бер өлеше либераль юнәлешнең демократик канаты һәм халык демократиясе яклылар белән берләшергә мөмкиннәр. Мәсәлән, XX йөз башы татар тарихыннан билгеле булган мөселман социалистлары шушы вариантка якын торганнар. Мондый блокның сәяси платформасы бик тә кызыклы булыр иде, ләкин әлегә Россиядә андый сәяси документның күренгәне юк.

Югарыда сүз барган яңа татар җәмгыятенең аякка басу модельләре илне рәткә салуның гомумроссия проектлары белән ничек яраша ала соң? Бу сорауга җавап эзләгәндә, бер әһәмиятле методологик караштан чыгып эш итү кирәк: гомумроссия сәяси кырында либераль-ауропачылык тарафдарлары да, традиционалистик-ауроазиячелек карашларын яклаучылар да милли азчылыкның, шул исәптән, татарларның да, мәнфәгатьләрен тулы рәвештә исәпкә алырга җыенмыйлар. Шулай булгач, ничек итеп татар юлы белән илдәге төп сәяси агымнарны килештереп була соң? Һичшиксез, киләчәк ул кадәр үк өметсез түгел.

Чынлап та, Татарстанның хакимлек итүче элитасы үзенең «уң үзәк» идеологиясе

белән либераль проект кысаларына кереп китә ала. Әле ул сәяси процесс ике төрле дә булырга мөмкин: Беренчесе—компрадорлар юлы (Р.Мөхәммәтдинов). Мондый модель сайлаганда жирле элита үзенең хакимлеген саклау өчен татар милләтенең этник мәнфәгатьләрен икенчел дәрәҗәдә калдырачак. Үзләре вазифалары буенча «татар» булып, этно-мәдәни эшләрне аның бөтен яклары буенча карап торып, алар бер генә бурыч куячаклар—жирле җәмгыятьне шушы элита тарафыннан билгеләнгән иң урталыктагы милләтчелектән читкә чыгармаска. Мондый юл белән китсәк, татар җәмгыятенә югары бәя түләргә туры киләчәк: милләтебезнең тарихи рәвештә формалашкан «югары» мәдәнияте төссез-милләтсез «татарстанчыл» мәдәниятнең бер компонентына гына әйләнеп, соңгысы үз чиратында, гомуми россияле—рус мәдәни кырындагы бер кисәк кенә булып торачак. Әмма шушы гаять зәгыйфь үсеш векторы саклансын өчен дә Татарстанның яшәве кирәк. Әгәр дә Россиядә яңа, эреләтелгән административ-территориаль бүленешкә күчеш булса—ә мондый вариантның булу мөмкинлеген теоретик яктан инкарь итеп булмый—хәзер республикада хакимлек итүче уң либераль проект тарафдарлары, үзләренең мәнфәгатьләрен яңа территориаль кысаларда, мәсәлән, Идел буе округы кысаларында институцияләштерергә тулысынча әзер булмау сәбәпле, җиңелүгә генә түгел, ә тулаем һәлакәткә дучар ителәчәкләр. Шулай да, мондый нәтиҗә мәҗбүри түгел: әгәр дә Татарстанның хәзерге элитасы булачак үсешләргә әзерләнеп өлгерсә, яңа шартларда ул үзенең урынын табачак. Әмма аның бүгенге халәтеннән чыгып караганда мондый ихтималлылыкның тормышка ашуына ышаныч аз. Икенче, либераль кырдагы хәрәкәт проекты, үз чиратында, ике төрле булырга мөмкин. Аның берсен тормышка ашыру өчен хакимлек итүче элита компрадорлыктан китеп, жирле патриотизмны, этник мәнфәгатьләрне һәм милли капиталны яклауга күчәргә тиеш. Бу юлдан бару өчен халык демократиясе тарафдарлары һәм хәтта урталыктагы исламчылар белән якынаю да мәҗбүри булу сәбәпле, андый проектка күчү хакимлек итүче элитадан, аның белән тыгыз бәйлелектә торган эре капиталдан зур мобильлек һәм акыл таләп итәчәк. Тагын башка бер юнәлеш хакимиятнең төрле юллар белән, шул исәптән, сайлау механизмы аркылы да, демократик даирәләр кулына күчүе белән бәйле. Бу очракта республика мәнфәгатьләре һәм татарларның этномәдәни мәнфәгатьләре күпкә эзлеклерәк яклана алыр иде.

Күрсәтелгән ике сәяси проектны да тормышка ашыру җиңел булмаячак, чөнки алар үсеп баручы, бөекмилләтчелек идеологиясе белән сугарылган рус милләтчелеге фонында тормышка ашырылырга тиеш. Соңгысын күз алдына китерү өчен берничә социологик мәгълүмат бирим. Руслар арасындагы урта сыйныф вәкилләренең 55 проценты «Россиядә фәкать тик руслар гына хакимлек итәргә тиеш»,—дигән карашта торалар, 62 проценты илне бөек супердержава буларак күз алдына китерә, 66 проценты исә үзәк власть органнарын көчәйтү ягында («Эксперт» журналы, 2003 ел, №7). Дөрес, әгәр дә бездә сәясәткә киң халык массалары тартылса, таяныч итеп урта һәм вак капитал алынса, алда тасвирланган юл җиңүгә китерә ала. Иң әһәмиятлесе—үсеш темпларын арттырып, Россиянең витринасына әйләнү. Билгеле, бу очракта да тискәре яклар кала—иске рус психологиясе нигезендә безне итәктән тотып калдырырга маташачаклар (латинга күчү белән шулай булды бит). Ләкин, әгәр дә безнең уңышлар үзебезнең югары мәдәниятебезгә нигезләнсә—ә ул үзенең тамырлары белән реформатик-мөселманлык рухлы, ягъни мөселман протестантлыгы дип карала ала—хезмәттәге уңышларга, житештерүче капиталга, бөтен халыкның тормышын яхшыртуга йөз тотса, Татарстанның милли-дәүләти берлек буларак исән калуы гарантияләнә ала. Әгәр дә уңышлы үсүче Татарстан берникадәр вакыт яши алса, акрынлап либеральләшә баручы Россия ахыр чиктә безнең яшәвебез һәм аерым халәтебез белән килешәчәк. Шул исәптән, Россиянең башка регионнарының да шундый ук юл белән барырга теләкләре булу сәбәпле.

Ә инде өченче—жиһадчылык юлы ахыргы бер, инде бүтән мөмкинлекләр калмаган очракта кулланырлык проект булып кына тора. Ана без Россиянең алга таба баруы тукталса, либераль проект тулаем җиңелсә генә йөз тота алабыз, чөнки ул традиционалистик җәмгыятькә кире кайту дигән сүз. Ягъни бу очракта татар җәмгыятенә нindидер дәвергә, бәлки шактый озын бер чорга, «йомылырга» туры

киләчәк. Безнең үз тарихыбыз күрсәткәнчә (XVI-XVII йөзләрдә), мондый халәт өчен идеаль вариант—фундаменталистчыл рухта корылган җәмгыять.

Югарыда анализланган модельләр, аларның катнаш вариантларын да исәпкә алып, татар җәмгыятенең алдагы көннәрдәге үсешенең чагыштырмача «чиста» проектлары гына. Реаль тормышта күпкә катлаулырак иҗтимагый үсеш юллары булу да мөмкин. Ләкин бу очракта, Татарстанның һәм татар милләтенең стратегик үсеш магистрален билгеләү өчен, ул юлның төп юнәлеше күрсәтелде. Әмма барлык сөйләнгән мәсьәләләр буенча бер сингез да кирәк булыр.

### *Киләчәк Россиядә төрки-мөселман милләте*

Күренекле Америка галиме, милләтләр теориясе буенча белгеч Б. Андерсон үзенең бер хезмәтендә мондый фикер әйткән иде: «... Милләт ... һәм милләтчелек үзенә күрә аерым бер мәдәни артефакт ул». Безнең киләчәгебезгә шушы күзлектән чыгып караганда, хәлләр бүген никадәр генә авыр булсалар да, алда өмет чаткысы бар.

Чынлап та, татар тирән тарихи тамырлы мәдәнияткә ия. Әле ул бүген халкыбызга бөтенләе белән кайтарылып бирелмәсә дә, аның зур өлеше инде кулланышта. Нәкъ менә шушы мәдәни мирас безне цивилизацияле милләтләр рәтенә куя.

Россиянең үзе өчен татар факторы структура төзүче бер фактор булып тора. Россия дәүләтчелегенең һәм этномәдәни кырының базис элементы буларак, татарлар бу илдәге төрки-мөселман цивилизациясенең—ә ул рус-христиан цивилизациясеннән бер ягы белән дә калышмый—иң әһәмиятле өлешен, аның умырткасын тәшкил итә. Алар, реформаторчыл рухтагы ислам тарафдарлары буларак, Россиядә һәм БДБ илләрендәге төрки-мөселман берлегенә демократик импульс бирә алучы көч булып торалар. Алай гына да түгел, татарлар дөньядагы либераль-исламчылык хәрәкәтен (ауроисламчылык, җәдитчелек) җитәкләп, Россиянең ауропачыл юнәлештәге дәүләт буларак позициясен дә көчәйтә алалар.

Шуна күрә, Татарстанның Россия Федерациясе кысаларында статусы татарларның Ауроазиядәге аерым роленнан үсеп чыга. Соңгысы исә, элекке Советлар Союзы җирлегендәге төрки-мөселман берлегенең либераль-прогрессистлары рәвешендәге лидеры булу, дип формалаштырыла. Ләкин Россиянең бүгенге үзәк элитасында татарларның мондый ролен аңлау юк. Моның берничә сәбәбе бар. Иң әһәмиятлесе—татарларның бу турыдагы дәгъвалары ачык итеп белдерелмәгән һәм, ни кызганыч, оештыру ягыннан, шулай ук финанслау буенча, ныгытылмаган. Билгеле, мондый дәгъва әллә ни көчле яңгырамый. Шушы халәтне исәпкә алып, татар элитасының хакимлек итүче өлеше өчен алга таба хәрәкәтнең берничә төп юнәлешен билгеләп була.

Россия Федерациясенең хәзерге сәяси үсеше һәм аның яңа территориаль-административ төзелешкә күчү мөмкинлегенең артуы, төрки-мөселман зыялыларының һәм сәясәтчеләрен илдәге төркиләр арасындагы чын этномәдәни чикләр, төрки халыкларының консолидациясе тәгәлләнү дәрәҗәсе турындагы мәсьәләләр тирәсендә уйлануга этәрергә тиеш. Шушы ук проблемалар БДБ илләре интеграциясе һәм киңрәк кысаларда үзара якынаю турында фикер туплаганда да алга килеп баса. Дөресен әйтим: киләчәкне лаеклы каршы алу өчен төрки-мөселманнарга милләт төзүгә карата совет чорыннан калган тар карашлардан чыгып күз салырга кирәк.

Инде бүген үк киләчәккә баруны башлау өчен яңа рухтагы тарихи хезмәтләр язу белән шөгыльләнә башлау зарур. Ул хезмәтләрдә безнең тарихыбыз коммунистчыл-большевистчыл идеологлар һәм сәясәтчеләр кисеп биргән милли «фатирлар» кысасыннан түгел, ә бәлки советтан соңгы пространствода яшәүче төрки-мөселманнарның язмыш берлеге позициясеннән чыгып яктыртылырга тиеш. Бу җиңел эш түгел, чөнки совет чорында һәм аннан да алда тудырылган кайбер милли мифлардан арынырга туры киләчәк. Әмма шушы юл гына безнең барыбыз өчен дә иң кулай юл.

Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларында Казанда татарларга гына түгел,

ә бөтен Россия төркиләренә хезмәт итүче Халыкара милли университетның гаять кызыклы проекты басылып чыккан иде *(авторы—Ю. Шамилугълы)*. Әгәр дә бу проект тормышка ашырылса, советтан соңгы кинлектә яшәүче төрки-мөселманнарның элитасы арасында интеграция реаль рәвештә тормышка ашырылыр иде.

Мәдәни адымнардан тыш сәясәт өлкәсендә дә хәрәкәт кирәк. Әйтик, Россиядәге төрки-мөселман халыкларының милли-мәдәни мохтариятләренең эшчәнлегендә тыгызрак координация вакыты житте. Эшкә яраксыз «Россия халыклары ассамблеясы» урынына—ә ул оешма, гомумән, халыклар мәнфәгатендә төзелгән микән дигән шик бар—төрки-мөселман халыкларының гомум-милли (федераль) милли-мәдәни мохтариятләрен бер оешмага туплап, аның башкарма органын, финансларын, ижтимагый шурасын («парламентын») булдыру зарур. Илдә кабул ителгән милли-мәдәни мохтарият турындагы закон да мондый берләшүгә каршы килми.

Шулай ук, мөселманнарның регион оешмаларын берләштерүче үзәк органнарын Казанда җыярга тырышырга кирәк. Яшәп килүче мөфтиятләр, аларның берләшмәләре өстеннән корылган шура булдыру юлы иң кулае булыр иде. Шушы гомуми проектка Казандагы Россия ислам университеты да бөтен төрки-мөселманнарның үзәк йорты буларак кертелә ала. Соңгысы гаять әһәмиятле, чөнки бу уку йортында халыкларыбызның рухи тормышларында мөһим роль уйнаячак дини элита хәзерләү барачак бит. Әгәр дә алар бер-берсенең терсәген тоеп яшәргә һәм эшләргә өйрәнсәләр, алга таба төрки-мөселман милләте оешу активрак барыр иде

Ләкин әйтелгән барлык адымнар да илнең гомуми мәнфәгатьләре кысасында алып барылачак, алай гына да түгел, Россиянең үсешенә дә уңай йогынты ясый ала. Әйтик, Федераль үзәк белән килешеп, чит илләрдәге ислам капиталын җәлеп итү өчен Казанда халыкара ислам инвестиция үзәге булдыру ил өчен начар булыр идеме? Шул нигездә Татарстанны, Россиядәге төрки-мөселман бергәлегенең алга киткән вәкиле буларак, глобаль финанс-икътисади системасына тоташтыру полигонына әйләндерү барса, ил моннан файда гына күрер иде. Дөрес, андый проектны тормышка ашырган вакытта ислам капиталын житештерүче буларак саклаучы механизмны булдыру гаять әһәмиятле. Шуна күрә, бу очракта сүз инновация эшенә игътибар бирү, вак һәм урта кул житештерүне үстерү турында барырга тиеш.

Әгәр дә югарыда әйтелгән юнәлештә һәм кайбер башка тармакларда хәрәкәт башланса, берникадәр вакыттан илдә православ рус һәм башка цивилизацияләр вәкилләре белән тигез партнерлык кора алырлык, хәзерге замандагы белән чагыштырганда күпкә эрерәк булган төрки-мөселман бергәлеге (милләте) оешыр иде. Әгәр дә Россиянең алдагы үсешен күпмилләтле җәмгыять формалаштыру аркылы барачак дип күзалласак, мондый юл ил өчен бик тә файдалы булачак.

Ләкин Татарстанның һәм Россиянең яна халәткә күчүе хәлиткеч дәрәҗәдә торган бурычларны элита ягыннан аңлауга бәйле. Шуна күрә Татарстанның сәяси элитасына, республикага берникадәр вакыт үзенә генә эш итәргә туры киләчәген исәпкә алып, мин төп игътибарны теләгән киләчәкне булдыруның интеллектуаль төзелешенә юнәлтергә тәкъдим итәм. Ул яңалыкларның һәм аларны тормышка ашыруның тирән нигезләнгән сценарийлары белән генә түгел, ә иң соңгы чиктә алда әйтелгәннәргә «күчү» белән шөгыльләнүче югары дәрәҗәле менеджер технократлар, сәясәтчеләр, галимнәр һ. б. белән дә бәйле.

**VIII бүлек**

## БӨТЕНРУСИЯ ХАЛКЫН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ СӘЯСӘТ[1]

2002 елгы халыкны исәпкә алу акциясе алдыннан илдә татар мәсьәләсенең фәнни-методик ягы буенча Казан һәм Мәскәү галимнәре арасында кискен дискуссия булды. Әйтергә кирәк, «татар проблемасы» федераль фәнни-статистик учреждениеләр тарафыннан шушы гомумдәүләт эше алдыннан төзелгән методологик конструкциянең «ныклыгын» тикшерү җәһәтеннән яхшы сынау булды. Бу уңайдан Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институтында эшләүче

[1] Тулырак вариантын Ab Imperio ( 2002.№ 4. - 235-243бб.) журналыннан карагыз.

һәм федераль якнын карашларын чагылдыручы фәнни хезмәткәр С. В. Соколовский язган, «Бөтен Русия халыкны исәпкә алуда «татар проблемасы»»[2] исемле мәкалә игътибарга лаек, чөнки ул 2002 елгы Бөтенрусия халкын исәпкә алу вакытында—ә ул исә советлардан соң чорда булган исәпнең беренчесе булды—фән һәм сәясәтнең нинди чагыштырмада кулланылуны анларга ярдәм итә.

Бу чорда Татарстан ягыннан федераль учреждениеләр тәкъдим иткән халыкны исәпкә алунын методологик аспектларын шактый еш тәнкыйть итәргә туры килү сәбәпле, ул тәнкыйтьнең эчтәлегенә тирәнрәк тукталу кирәк, чөнки безнең позициянең, ягъни республика галимнәре һәм сәясәтчеләре карашларынын, үзенең эчтәлеге һәм логикасы бар. Нәкъ шушы вакытта халыкны исәпкә алу алдыннан барган дискуссияләрнең эчтәлеге турында тулырак караш булдырырга һәм исәп беткәннән соң да федераль һәм республика яклары арасында башланачак үзара көрәшнең нинди юнәлешләрдә барачагы турында тирәнрәк күзалларга мөмкин булыр.

Билгеле, тарихи экскурстан башларга кирәк сүзне. Безнең фикеребезчә, ул экскурстан С. В. Соколовский фикереннән үзгә булган нәтиҗәләр һәм күзәтүләр алып була.

### *Татар этниясе мифмы, әллә чынбарлыкмы?*

Бер аңлатма биру фарыз. Этния (инглизча—ethnie)—фәндә, бигрәк тә инглиз телендәге терминнар белән эшләүче тармакларда, «халык» дигән төшенчәгә якын (ләкин аңа бөтенләй үк тәнгәл булмаган) термин. Бу очракта без шушы аңлатманы кулланырга мәҗбүрбез, чөнки татар этниясенең эчке структурасы катлаулы, аны «халык» һәм «милләт» дигән төшенчәләр белән генә биреп бетереп булмый.

С. В. Соколовский совет чорында, бигрәк тә XX йөзнең беренче унъеллыкларында булган халыкны исәпкә алунын методологик нигезләренә гомуми теоретик күзәтү ясаганда, «татар» дигән төшенчәнең «тарихи композит» булып, анын артында бердәм этниянең («халыкның») тормаганлыгын расларга тырыша. Мондый адекват булмаган төшенчә формалашуның сәбәбен ул «читтән караучы аермаучы карашнын» булуында күрә.

Шушы тезиска охшаган фикерләр бу авторда гына түгел, башкаларда да күзәтелә, шунлыктан ул карашны ныклап тикшерү кирәк. Шул ук вакытта татар этниясенең формалашуы турындагы мәсьәләне читтә калдыру кирәк, чөнки бу турыда сүз булды инде. Шулай да, әгәр ул проблеманы тулырак өйрәнергә телүчеләр бар икән, аларга «Татары» (М., 2001) дигән фундаменталь китапны тәкъдим итәм.

Тулаем алган вакытта инде күптән билгеле—Көнбатыш Ауропада һәм Русиядә озак дәверләр «татар» дип төрекләрлән башка барлык төрки, кайбер очракларда, төрки булмаган халыкларны да атаганнар. Ләкин бу вәзгыятьнең татар милли этнонимы формалашуына мөнәсәбәте бик аз. Иң күп дигәндә кайбер дәверләр өчен Русиядә яшәгән халыкларның империячел классификациясе турында сүз алып барып була, шул гына. Ә XX йөз башында реаль вәзгыять менә мондый була: «татар» дип ил эчендә, кайбер нюанслар белән, дүрт төбәктә яшәүче халык атала—Идел-Урал буе, Кырым, Көнбатыш Себер һәм тарихи Литвада. Русия чикләреннән тыш Румыниядә «Буджак татарлары» күренә.

Татар этниясе барлыкка килүне милли интеллигенция эшчәнлегенен нәтиҗәсе дип карарга омтылу булганда, анын «татар» исемен «консолидация коралы» итеп сайлап алуын алга сөргәндә, түбәндәге сорау туа: без бу фикерләүдә реаль чынбарлыкны бик нык гадиләштерүне күрмибезме? Әгәр дә «татар» исеме таралунынң географиясен карасак, мондый сорау барлыкка килүнең юкка гына түгел икәнлеге аңлашылыр. Шунын өстенә, әгәр дә төптән уйлап карасан, түбәндәге фундаменталь фактка барып төртеләсең: «татарлар» фәкать тарихи чыганаклардан урта гасыр дәвереннән Алтын Урда халкы варислары яшәгәнлеге билгеле булган төбәкләрдә генә «борынлый». Аннан соң, милли этноним сайлау—ә «татар» атамасы нәкъ менә шундый «гомумиләштерүче» категория булып тора—милли берлеккә

[2] Ул мәкалә шул ук журналда басылды (карагыз: 207-234 бб.)

нигез салучы атакайларга гына бәйле түгел. Билгеле, берникадәр дәрәҗәдә алардан да тора, ләкин эш шунда ки, ул «сайлаучылар» үзләре дә конкрет тарихи-мәдәни кысада булалар һәм аларның гомуми этноним «кору» буенча эшчәнлекләре (ул атаманы «дистилляцияләү» юлы белән булдырылды дип әйтәсе килә) шушы конкрет мирастан чыгып алып барыла. Нәкъ менә шул мирас «татарныкы» булган да безнең очракта. Нәрсә күз алдында тотыла соң? Менә нәрсә—ул мирас вакытлар узу белән үзгәрсә дә, аның үзенең бер инвариантлы үзәге, ягъни цивилизацион төстәге үзенчәлеге, булган. Юкка гына төрки-мөселман тарихын һәм мәдәниятен бик яхшы белгән В.В. Бартольд, XX йөз башларында «татар» исемен йөрткән берничә халык барлыгын таныса да, СССРда яшәүче барлык татар төркемнәренә карата «татар милләте» төшенчәсен кулланырга мөмкин дип санамаган. Бу категориянең эчтәлекле икәнлеген Кырым татарлары арасында әле күптән түгел генә төгәлләнгән шушы этник берлекнең исеме тирәсендәге дискуссия күрсәтә. «Кырым татары» (Кырым татарлары, Кырым татар халкы) яисә «кырымлы» (кырымлы, Кырым халкы) булу турындагы мәсьәлә көн тәртибенә баскач, ахыргы карар гомуммилли этноним булган «Кырым татары» атамасы файдасына булды. Һәм Кырым татар идеологлары белән сәясәтчеләре нәкъ шушы этноним артында үзләренең бөтен тарихлары торуын тулаем аңлыйлар: дискуссиядә катнашучыларның берсе әйтүе буенча, «шушы «татар» дигән этник идентитетлык яшәгәндә... [безнең] бабаларыбызның бөек мирасына мораль хакыбыз бар», ә ул мирас «мифик түгел—аның шактый ачык географик, икътисади, сәяси һәм мәдәни чикләре бар». Кырым татарларының хәзерге хәлләрен истә тотканда бу фразаны яхшы аңларга мөмкин.

Әгәр инде тикшерелә торган мәсьәләгә конкрет килсәк, 1926 елгы халыкны исәпкә алу нәтиҗәләреннән үзен «татар» дип исемләүче шактый эре этния барлыгын күрәбез. Әгәр дә аның составыннан Кырым татарларын төшереп калдырсак—ә совет дәверендәге сәяси карар нигезендә СССРдагы «татарлар» составына Кырым татарларын кертеп санауны Татарстандагы сәясәтчеләр һәм галимнәр өнәмәделәр—ул этник берәмлекнең 1926 елдагы саны 2,74 млн. кешегә житә. Ә 1926 елны үзен башка этник атама сайлап та, соңыннан татарлар эчендә исәпләнүчеләрнең саннары 352,1 меңгә житә. Шулай итеп, 1920 елларда татар этниясенә теге яки бу рәвешле катнашы булганнарның 88,6 проценты үзләре өчен «татар» исемен сайлап алган булып чыга. Шушы вакытта татар этниясенең реаль яшәүе турында сөйли түгелме соң бу факт? Хәтта ул чорда татар исемен сайламаучылар буенча да «соңгы карар» чыгару иртәрәк, чөнки өстән-өстән генә фикер йөртүчеләр уйлаганча гади мәсьәлә түгел бу.

Шул уңайдан 1926 елгы исәпнең методик якларына игътибар итәргә кирәк. С.А. Соколовский дөрес күрсәткәнчә, әле шушы исәп башланганчы нинди «халыктан/милләттән» булу турындагы сорауның эчтәлеге буенча фикер каршылыклары була. Ләкин ул ошбу мәсьәләне караганда фәнни әдәбиятта бу хакта сүз булса да, аның бер әһәмиятле ягын төшереп калдырган. Галимнәр арасында «милләтләрнең бер-бер артлы үзбилгеләнү нәтиҗәләрен» беркетү тарафдарлары белән бергә бүтән төрле фикердә торучылар—«халыкның этнография яисә кабилә составы картинасын» күрсәтү тарафдарлар да бар иде. Ахыр чиктә «шәхси листокта» (сораган вакытта анкетаның 4нче соравы) нинди «халыктан» (народность) дигән формулировкада тукталсалар да, ул сорауны аңлату үзенчәлекле булды: бу сорау халыкның «кабилә (этнография) составын ачыклау ихтыяжы булуын ассызыклау өчен куелды». Әлеге проблемага кереп китмичә (аның башка нечкәлекләре дә бар), нәтиҗә өлешенә күчик: югарыда күрсәтелгән 4нче сорауның трактовкасы нинди «халыктан (милләттән) икәнлекне «этнографик» («кабилә») билгеләмәсе белән бутады. Халыкны исәпкә алу өлкәсендә югары квалификацияле белгеч булган галим—С. И. Брук (минем укытучым) шушы буташтыруның нәтиҗәсе турында икенче бер күренекле тарихчы—демограф В. М. Кабузан белән уртак басмада ап-ачык итеп әйтте—аның фикеренчә, шушы методик үзенчәлек аерым халыкларның саннарын арттырып кына калмады, ә «күп кенә этнографик төркемнәр булган этник берәмлекләрне» мөстәкыйль халыклар итеп күрсәтте. *(Карагыз: Советская этнография, 1982, №5—16 б.).* Хәзер С. В. Соколовскийга кушылып

иске совет этнографиясе башлыкларын ( Ю. В. Бромлейны, С. И. Брукны, һ. б) бәлки тәнкыйть итеп буладыр ( шулай да моны эшләү өчен аргументлар кирәк), чөнки алар ул заманнарда халыкны исәпкә алу чорларында сәясәттә катнаштылар, шул исәптән, милләтләрне «зурайту» сәясәтендә дә, әмма, моңа карап 1926 елгы исәпнең методик яклары турындагы бәяләү үз көчен югалтмый—ул чынлап та исәпкә алуның нәтиҗәләрен «этнографияләштерде»! Шуңа күрә, 1926 елда татарлар эчендә саналмыйча аерым этнияләр буларак бүленгән төркемнәр чынлап та шундый булганнар дип уйласак, без нык ялгышырга мөмкинбез. Шуның өстенә, бу халыкны исәпләүгә әзерләнгән методик материаллар, С.В. Соколовский аларны төшереп калдырса да, югарыда ясалган нәтиҗәләрне куәтлиләр.

Әйтик, типтәрләр турында 1926 елгы халыкны исәпкә алуны оештыручылар түбәндәгедән чыгып эш итәргә тәкъдим иткәннәр: аларның «нинди халык (народность) икәнлекләре төгәл билгеләнмәгән». Шушы инструкциядән чыгып Башкортстан Үзәк статистика идарәсе РСФСР Үзәк статистика тарафыннан расланган инструкциягә таянып эш итәргә тиеш була. Ә анда түбәндәгечә әйтелгән: «... типтәрләрнең халык (народность) булмауларын истә тотарга кирәк, алар төрле халыклар кушылу нигезендә барлыкка килгән төркем. Шуңа күрә, әгәр дә хисапланучы үзен типтәр дип атаса, санаучы аңа өстәмә сораулар биреп ачыклый—ул башкорт, татар, мещеряк, чуаш, мари, мордва, вотяк түгелме дип. Конкрет җавап алынгач, кәгазьдә ике өлештән торган атама языла: «типтәр-башкорт», «типтәр-вотяк» һ. б. Әгәр дә бөтенләй җавап алып булмаса—ә андый хәл ул чыккан халыктан бөтенләй аерылган очракта булырга мөмкин—кәгазьдә бер генә билгеләмә ясала—«типтәр».

Нәтиҗәдә, бу халыкны исәпкә алу материалларында «өстәмә рәвештә билгеләүгә таянып төгәл милли атама аркылы төрле рубрикаларга таратылмаган» аерым бер «калдык» кына типтәрләр (барлыгы 22,3 мең кеше) булып йөри. Бу мәсьәләне тулаем тикшергәндә Т. И. Семенов башта «типтәрләр исеме астында сословие төркеме вәкилләре күз алдында тотыла», ди. Аннан соң галим болай дип тә әйтә: бу төркем вәкилләренең этник йөзләре «тел турындагы мәгълүматләр аркылы билгеләнергә тиеш». Шуннан соң ул йомгак ясый: «... 22,3 мең типтәр, күрәсең, тел буенча (типтәр теле) «башкалар» рубрикасына кертелгән ачыкланмаган «калдык» булса кирәк». Әмма тел мәсьәләсе буенча ихтирамга лаеклы галимебез ялгыша—Башкортстан АССР архивларындагы мәгълүматлардан күренгәнчә, ул исәп буенча «типтәр» дип язылучыларның күпчелегенең туган теле татар теле була *(БР Милли архивы, ф. 472, оп. 1., эш 572)*. Безнең фикеребезчә, 1926 елны «типтәр халкы» барлыккак килүдә төп рольне бу очракта этнографик—«кабилә» билгесе кебек саклануы сословие үзаңы уйнаган. Аның шулай икәнлегеннтиптәрләрнең бер төбәктә булмыйча, таралып утырулары да раслый (Уфа кантонында—6278 кеше, 4 волостьта; Бөре кантонында—8348 кеше, 8 волостьта; Тамьян-Катай кантонында—5703 кеше, 1 волостьта; Бәләбәй кантонында—1633 кеше, 5 волостьта; Эстәрлетамак кантонында—428 кеше, 2 волостьта).

Хәзер сүз мишәр «халкы» турында. Бу «халык», 1926 елны, билгеле булганча, ике төбәктә—Пенза губернасы (100 меңнән артыграк, ләкин аларның 40 меңе урыс мешерасы) һәм Башкортстан АССР (137,9 мең) кысаларында күренә. Соңгыларына карата сословие факторы йогынтысы булуын уйласак та (исегезгә төшерәм, Урал буйларында мишәрләр типтәрләр төсле үк аерым сословие вәкилләре буларак җир биләү буенча өстенлекләргә ия булганнар һәм шул сәбәптән совет чоры колхозлаштырылуына кадәр бу яктан алар башка крестьяннардан аерылып торганнар), Пенза мишәрләренә карата мондый фикерне әйтеп булмый. Шуңа күрә, бу очракта «этник» як та булган дияргә туры килә. Ләкин шул якка игътибар итәргә кирәк: мишәрләрнең саннары XIX йөз ахырына 600 меңнән дә ким булмаган, шулай булгач, 1926 елда үзенең нинди «халыктан» икәнлеген күрсәткәндә аларның күпчелеге «татар» булып язылган булып чыга. Шуның өстенә, бөтен мишәрләр дә үзләренең туган телләре дип татар телен атаганнар. Шулай итеп, бу вәзгыятьтә 1920нче елларда аерым мишәр «халкы» булган дип әйтү өчен гадәттән тыш зур кыюлык кирәк. Әле бит көнбатыш (мишәр) диалектының урта диалект белән бергә

хәзерге татар әдәби (милли) телне барлыкка китерүдә катнашканлыгын да истә тотарга кирәк.

Керәшеннәр (керәшен татарлары) буенча 1920нче елларда Т. И. Семенов әйткән белән чикләнергә мөмкин булыр иде. Ул исә болай дигән: «... «керәшен халкы» (керәшен татарлары) дип атау—төгәл булмаган билгеләмә». Мәсьәләгә болай караганда, шул ук фикерне нугайбәкләргә карата да әйтергә мөмкин—алар бит казак сословиесенә кереп башка керәшеннәрнең бераз аерылган төркеме генә. Ләкин чынлыкта керәшеннәрнең татар-мөселман өлешеннән читләшүе шактый зур булган, шуңа күрә дә элегрәк ул төркемне татар этниясе эчендәге субконфессиональ төркем буларак карау кирәк дигән караш әйтелгән иде. Бу мәсьәләгә күбрәк тукталу мөмкин булмау сәбәпле, берничә фикер генә әйтеп китик. Беренчедән, татарлар белән керәшеннәр арасында тел һәм мәдәният ягыннан уртаклык күзәтелә. Икенчедән, XX йөз башларында керәшеннәрнең массакүләм ислам динен кабул итүләре була—ул чорда керәшеннәрнең яртысы диярлек мөселманлыкка чыга. Өченчедән, 1920нче елларда Татарстан житәкчелеге фактик яктан «керәшен проблемасы» булуын таный һәм шушы үзенчәлекле төркемгә карата аерым сәясәт булдырып, аны тормышка ашыру өстендә эшли. Бу проблеманың бөтен катлаулылыгын истә тотып, XX йөзнең башлангыч унъеллыкларында керәшеннәрнең татар этниясенең мөселман өлеше белән консолидацияләшүе төгәлләнмәгәнлеген танырга мөмкин булыр иде. Ләкин, Т.И. Семеновка кушылып, керәшеннәргә карата «халык» (народность) төшенчәсен куллануга без каршы. Шул исәптән, әйтелгән фикергә тагы бер факт этәрә: Русия ФА Этнология һәм антропология институты вәкилләре әле күптән түгел генә Татарстанда керәшеннәр яшәгән районнарда булып, анда «керәшен» булырга теләүчеләр белән беррәттән «керәшен татарлары» исемен кабул итүчеләрнең дә булганлыгын расларга мәжбүр булдылар. Ә инде 2002 елгы халыкны исәпкә алу вакытында керәшеннәрнең саны РФ буенча 25 меңнән артмады (шуның 18 мене—Татарстанда). Димәк, барлык керәшеннәрнең 90 проценты үзен татарлар эчендә дип хис итә.

Аннан соң, татарлар этниясенә карата булган С. В. Соколовский позициясенең тагы бер зур кимчелеген күрсәтми булмый. Эш шунда ки, ул XIX-XX йөзләр чикләрендә татарларда милли мәдәният, шул исәптән, аның «югары» катламы да, формалашканын танырга теләми. Әйтелгәнчә, 1917 елга кадәр бу мәдәниятнең кайбер «югары» катламга караган өлешләре әле өлгереп житмәгән булсалар да (алар соңыннан Татарстан эчендә беркадәр импульс алалар), ул мәдәниятнең булуын, аның Себер һәм Әстерхан татарларында таралуын танымыйча мөмкин түгел (ул мәдәният башкортларга һәм күпмедер дәрәжәдә казахларга да хезмәт итә). Ә мондый «югары» мәдәният булу дөньяда танылган теоретик хезмәтләрдә милләт оешуның төп билгеләренә кертелә. Әйтергә кирәк, Себер һәм Әстерхан татарларын бердәм татар этниясенә кертеп карау, башка сәбәпләрдән тыш, шушы уртак мәдәни-информацион системага аларның «интеграцияләшүе» белән дә аңлатыла.

Чынлыкта хәзерге заман татар этниясенең (татар милләтенең) нигезен нәкъ менә шушы милли мәдәният тәшкил итә дә. Ул мәсьәләнең шушы фундаменталь ягыннан читләшергә тырышу билгеле бер позицияне чагылдыра һәм ул—сәяси позиция.

### *«Татар мәсьәләсенең» сәяси ягы*

«Татар проблемасынын» хәзерге аспектына күчкән вакытта С. В. Соколовский белән килешмәүнең берничә принципиаль моментын күрсәтү кирәк. Башлап, билгеле, бу халыкны исәпкә алу чорында кулланылучы «милләтләр исемлегенә» кертелгән яңалыкларның «беренче дәрәжәдәге максатын» гражданнарның этник һәм тел идентитетлыгын мөстәкыйль сайлап алу хокукын тәэмин итүдә» күрү. Шушы уңайдан РФ Конституциясенә нигезләнү күзәтелә (26.1 маддәсе). Анда мондый юллар бар: «Һәркемнең үзенең милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә хакы бар». Ә бу автор тарафыннан аерым төркемнәр ягыннан үзләрен мөстәкыйль булырга омтылышларын аренага «чыгару» механизмы түбәндәгечә тасвирлана: берләшмәләр үзләренең «законлы вәкилләре» аркылы хөкүмәткә, президентка һәм башка рәсми

оешмаларга аларны аерым «исәпләү категориясе» буларак тану турында мөрәҗәгать итәләр.

Бенең фикеребезчә, мондый позициядә берничә бәхәсле як бар. Әйтик, РФ Конституциясенең 26.1 маддәсе өстән-өстән караганда гына бик тә үтә күренмәле булып тоела. Чынлыкта, әгәр дә төркемнәрнең «үзбилгеләнүе» инде «законлаштырылган» русияле халыкларның коллектив хокукларына кагыла башлый икән, шунда ук мондый «идентификация» сайлау актының бер дә гади түгеллеге ачыклана. Фикеребезне аңлатып китик. С. В. Соколовский керәшеннәр барлык татарлар эченнән «чыгып» киткәннән соң Татарстанда татарның гомуми саны кимеп, алар чагыштырма рәвештә булса да, милли азчылыкка әйләнәләр (моннан килеп чыгучы башка нәтиҗәләре белән),—дип күрсәтүе мондый «бүленеп чыгуның» шунда ук сәяси күренеш булуын ачыклый. Аннан соң, сорау туа: һәрбер төр төркемнәр дә этния булып үзбилгеләнә аламы? Ни өчен мондый сорау туа дисәгез, исегезгә төшереп китик: 2002 елгы исәп вакытында, кайбер мәгълүматләр буенча, илдә «инклар», «скифлар», «папуаслар», «марсианнар», «хоббитлар» һ. б. барлыгы билгеле булды. Журналистлар язганча, аларның кайберләренең саны Русиядәге аз санлы халыклардан күбрәк булып чыкты. Билгеле, моның ише «үзбилгеләнүдән» соң конкрет дәгъвалар ишетелмәсә, бу нәрсәләргә шаяру дип карап булыр иде. Әмма, Татарстандагы «болгарлардан» күренгәнчә, эш гел алай тормый—соңгылары «болгар» булып теркәлеп алганнан соң Милли-мәдәни ассоциацияләр бинасында урын даулый башладылар һәм аның белән генә дә чикләнмәделәр. Ә болары инде, табигый, акча таләп итә.

Чынбарлыкта төркемнәр этния статусында «үзбилгеләнгәч», аннан башка нәтиҗәләр дә килеп чыга. Ә алар турында исәп тирәсендә политтехнология белән мәш килүче мәскәүлеләр уйламыйлар, яисә ул турыда ачыктан-ачык сөйләшергә теләмиләр. Мәсәлән, күз алдына китерик—Себер татарлары этносы «төзелде» ди. Моңарчы Көнбатыш Себердәге татарларның мәдәни ихтыяҗларын Татарстан канәгатьләндерә иде (дәреслекләр, видео-, аудиоматериаллар, концертлар һ. б.). Искәртеп китик—бу эш Татарстанның үз бюджеты хисабына башкарыла. Һәм ул гына да түгел: кайбер очракта бу булышлык үзебезнең «бертуган» диаспора хисабына да башкарыла. Әгәр дә кем дә булса читкә җибәреләсе мәдәни байлыкларны туплау бик җиңел дип уйласа, татар гәҗитләренең берсендә басылган түбәндәге игъланга карасын: «Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты Россия регионнарындагы татар мәктәпләре өчен халыктан дәреслекләр һәм матур әдәбият җыя». Хәзер күз алдына китерик: Татарстан «бүленеп чыгучыларга» мәдәни, белем бирү һ.б. кыйммәтләрне җибәрүдән баш тартты ди. Бу очракта аерылганнарны ни көтә? Ике альтернатива бар алар өчен—бик тизләп үзләренең «югары» мәдәниятләрен булдыру—билгеле, бусын тиз арада булдыру икеле, яисә, башка мәдәнияткә барып сырышу—безнең шартларда төп халык—урыслар мәдәниятле булачак инде ул. Моның нәрсә белән бетәчәген бик тәфсилләп сөйләп тору кирәк түгелдер.

Шушы уңайдан әйтергә кирәк—бердәйлекләр исеменнән, аларның «законлы» вәкилләре булуларын игълан итүчеләрне тыңлап теге яки бу төркемгә «исәпкә алу категориясе» бирү турында карар кабул итү үтә дә җиңел акыллылык булыр иде. Әле күптән түгел генә В.А. Тишков әфәнде хәтта Бөтендөнья татар конгрессы турында да—ә ул сайланган оешма, аның урыннарда сайлау турында беркетмәләре бар—ул бары тик «иҗтимагый коалиция» яисә «этноҗыелыш»,—дип әйтте һәм аның татар халкы исеменнән сөйләү хокукын инкарь итте. Ә бит шушы әфәнде җитәкләгән Этнология һәм антропология институтына килеп, анда «вәкил» булып «милләтләр исемлеген» төзүдә үз таләпләрен күтәрүчеләр БТК кадәр дә легитим түгелләр! Мәсәлән, керәшен милли-мәдәни җәмгыятьләренә сайлаулар ничек барганлыгы абсолют ачык түгел. Аннан соң, ул җәмгыятьләрнең вәкилләре арасында кем булып—керәшенме, керәшен татарымы—үзбилгеләнү турында уртак фикер юк.

Чынлыкта шул ук хәл Себер татарларында да күзәтелә. С. В. Соколовскийның Себер татарларының «Бараба» (себерчә—Параба), «Тара», «тоболлык», «туралы», «эушта» һ. б. төркемнәренең «вәкаләтле» съездларында үзләренең «аерым саналу хокукларын яклап» чыгулары турында язганын укыганда, көләсе килә башлый. Ни

өчен дисезме? Беренчедән, күрсәтелгән төркем вәкилләренең бернинди съездлары да булмаган—ул бүленешләр турында инде иң карт Себер татарлары да бик аз хәтерлиләр (бу турыда белгеч буларак сүз әйтәм, чөнки Көнбатыш Себернең күп төбәкләрендә этнограф буларак эшләргә туры килде). Икенчедән, бу региондагы төрле төбәктә яшәүчеләрнең күп өлеше беркая да «аерылып чыгарга» җыенмый. Әйтик, Омск өлкә милли-мәдәни мохтарияте мондый «аерымлануга» 2002 елны каршы чыкты. Еш кына мондый карар җирле татарларның читтән күчеп килүчеләр белән катнашып беткәнлегеннән дә килеп чыга. Әйтик, Себер татарлары буенча белгеч булган этнограф Н.А. Томилов үз вакытында күрсәткәнчә, Томск өлкәсе татарлары арасында «чиста» төркемнәр яртыдан кимрәк, катнашлар—24 процент тәшкил итә, ә Идел-Урал татарлары—шул кадәр үк. Шул ук картина Новосибирск өлкәсендә яшәүче бараба татарлары арасында да—катнашмыйча «чиста» калучылар монда 44 процентган кимрәк, башкалар исә «метислар». Билгеле, мондый «метислашу» нәтиҗәсез калмый. Әйтик, бараба татарлары теле буенча белгеч булган Л. В. Дмитриева, 1950нче елларга караган, Бараба татарлары телен тасвирлаган язмаларында бер җирле татарның түбәндәге сүзләрен китерә: «... Барабалар Русиядан килгән татарлар белән катнашу сәбәпле, аларның телләре бер булды». Билгеле, бу тикшерүчене «пантатаризмда» гаепләү авыр, нәтиҗә исә бик тә конкрет—Көнбатыш Себердә яшәүче төрле төркем татарлар арасындагы диалекталь аермалыклар XX йөзнең урталарына нык кына «юылган» инде. Искәртик, Л. В. Дмитриева бараба татарларынын тел үзенчәлеклерен тасвирлаганда мондый баш куя: «Бараба татарларының теле», ә мәкаләсенең эчтәлегендә әйтә—«татар теленең Бараба диалекты; Бараба сөйләше». Билгеле, бу очракта С. В. Соколовскийга караганда этник вәзгыять лингвистка күбрәк күренә.

Инде китерелгән мисаллар «татар проблемасының» 2002нче елгы халыкны исәпкә алуга хәзерлек вакытында һәм барышында сәяси ягы барлыгын раслау өчен җитәрлек булыр иде. Әмма бу фикерне куәтләгән тагын ике мисал китермичә булмас.

Этнография һәм антропология институты директоры В. А. Тишков биргән бер интервьюдан күренгәнчә, ул вакытта РФ президенты булган В.В. Путинга Патриарх Алексий исеменнән «халыкны исәпләү вакытында керәшеннәрне аерым халык итеп тану турындагы үтенеч» язылган хат юллана. Һәм илнең иң дәрәҗәле этнографы ул турыда болай дип белдерә: «Үзегез аңлыйсыздыр, Патриарх РФ президентына мөрәҗәгать итсә, бу бик мөһим. Моны исәпкә алмыйча булмый.»

Икенче мисал. РФ Дәүләт статистика комитеты тарафыннан расланган (171нче карар, 02.09.2002) «Милләтләр һәм этник атамаларның исемлеге» дип аталган документта кайбер «сәерлекләр» бар—анда «керәшен» атамасы бар, шулай ук «крешенцы», «крещеные» да каралган, ә «керәшен татарлары» юк! Ничек инде бу очракта сәяси заказ булу турында уйламыйсың ди? Алга таба, әйтелгән документта, сез ничек кенә эзләсәгез дә, «татар телле башкортлар» дигән позицияне таба алмассыз. Шул ук вакытта анда нинди генә «типтәрләр» юк: гади «типтәрләр», «татар-типтәрләр», «башкорт телле типтәрләр», «башкорт-типтәрләр». Ә бит 1989 елгы халыкны исәпләү вакытында Башкортстанда (180 меңгә якын) һәм күрше төбәкләрдә дә татар телле башкортлар яшәп ятканнар. Ни өчен шушындый хәл туа соң? Уйлап карасаң, «Алфавит исемлектән» татар телле башкортларны алып ату Башкортстан җитәкчеләренә ярау өчен эшләнмәдеме икән дигән фикер килә башка. Әллә тагы берәр сәбәп бар микән монда? Инде татарларның үзләрен генә алсаң, бу «Алфавит исемлектә» хәтта 45 позиция табабыз—аларның кайберләре мөстәкыйль этнияләр буларак язылганнар: «татардан» һәм «Кырым татарларыннан» тыш бу «нугайбәкләр», «Себер татарлары», «керәшеннәр», «карагашлар» һәм «чулымлылар». Дөрес, бу исемлекне укыганда шундый авырлык турында уйлыйсың—Этнология һәм антропология иститугы хезмәткәрләре исәп алу беткәч, «керәшен татарлары» дип язылучыларны кая куярлар микән, ә аларның саны аз булмады (хәзер төгәл әйтеп була—шушы исем астында 25 мең кеше язылды). Ничек итеп «керәшен татарларын» мөстәкыйль «керәшен халкы» итеп булыр икән?

Язманың бу өлешен төгәлләү алдыннан 2002 елгы халыкны исәпкә алу вакытында Мәскәү ягының бер ачык хакыйкатьне танырга теләмәвен әйтергә

кирәк—гомуммилли идентитетлык (үзан) артында ахыр чиктә хәзерге заман татар «югары» мәдәнияте тора. Юкка гына С.В. Соколовкий әфәнде бер милләткә караучы «кешеләр берлегенең ихтыяҗы (тел, дини, мәдәни яктан бер төрле булу) турындагы» карашны тәнкыйтьләп язмый. Бу очракта ул, күп кенә башка федераль органнарның вәкилләре шикелле үк, милли этнонимнан баш тартып башка идентитетлыкка күчү, гомуммилли мәдәнияттән баш тартып (аннан соң инде җирле мәдәният «этнографияләшә») яисә (һәм аның белән бергә) башка мәдәниятка күчү куркынычы булганын танымау юлына баса. Ә татарларның исәп вакытында гомуми бер этник берлек буларак исәпләнә алу хокукын алга сөргән Татарстан ягы татарларның РФ эчендә дәүләт төзүче халыкларның берсе булуын (бу факт ил эчендә «татар» билгеләре булган республика яшәвендә дә чагыла), ягъни аларның, башка халыклар белән бергә, шушы федератив дәүләтне барлыкка китерүче «күпмилләтле халык» эченә керүләрен күз алдында тотты. Аерым радикаль «конструктивистлар» тели дип бу дәүләтнең нигезен җимерү дөрес булмас. Безнең фикеребезчә, 2002 елның 30 августында Казанда РФ президенты В.В. Путин БТК делегатлары белән очрашудан соң аерым бер документка кул куеп (бу шул ук елның 8 октябрендә булды), югарыда әйтелгәнне тирән аңлавын күрсәтте. Чөнки ул документта мондый юллар бар: «Гомуми урта белем бирү стандартларын эшләгән вакытта белем бирү учреждениеләрендә Русия халыкларының телләрен һәм милли мәдәниятләрен өйрәнү (теләүчеләр өчен) мөмкинлеген булдырырга». Әгәр дә мәсьәлә шушы рәвешчә куелса, шунда ук «югары» милли мәдәниятнең кирәклеге алга чыга. Ә инде мондый мәдәният бар икән, аны йөртүченең исеме дә булмыйча калмый. Шуңа күрә, аерым этния буларак татарлар бар һәм булачак. Әгәр дә кемдер бу берлектән «чыгып китәргә» уйлый икән—рәхим итсеннәр, татарлар берәүне дә көчләп тотарга җыенмыйлар үз берлекләре эчендә.

### *Соңгы сүз*

2002 елны үткән халыкны исәпкә алуга әзерлек вакытында һәм аннан соң барган кайбер дискуссияләр дәвамында мондый, дәүләт кимәлендә алып барылган акцияләрнең сәяси ягы барлыгы ачылды.

Шуңа күрә дә белгечләр халыкны исәпкә алуда «конструкцияләү» элементлары барлыгын (ул «халыклар», «телләр» исемлекләре төзү, төрле ведомстволар өчен эшләнгән кулланма-инструкцияләр булдыру аркылы алып барыла) элек-электән искәртеп килделәр. Билгеле, милләтләр эчендә барган этник, сәяси һәм мәдәни процессларны да истә тоту кирәк. Чынлап та, 1980 елларда ук татар милләте эчендә янарыш чоры белән бәйле төбәкчелек үсеше башланды. Беренче чиратта ул этнорегиональ үзаң (Көнбатыш Себердә, Әстерхан өлкәсендә һәм кайбер башка төбәкләрдә) үсү һәм этноконфессиональ үзаң (керәшеннәрдә, нугайбәкләрдә) ныгу белән аңлатыла. Татар милли берлегендә башланган дезинтеграция процессының тарихи сәбәпләре барлыгы ачык. Алар турында инде сүз алып барылды. Ләкин төп сәбәп—Татарстанда тупланган милли үзәк белән читтәге татар төркемнәренең совет чорында мәдәни-мәгълүмати багланышлары йомшау. Беренче чиратта андый тискәре тенденция шул чорда алып барылган партия-дәүләт сәясәтенә бәйле. Ул сәясәт милләтнең этномәдәни бердәмлеген бетерүгә юнәлдерелгән иде. Күрсәтелгән гаять тискәре тенденциянең тагы бер алшарты—1940нчы елларда Татарстанда милли тарихны тар бер кысада—республика чикләрендә һәм татарлар барлыкка килүенең «болгар» теориясе кысаларында язу. Бу шулай ук партия органнары басымы астында эшләнде. Нәтиҗәдә, читтә яшәүче татарлар тарихы—күп очракта алар башка төбәкләрдә гасырлар буе яшәп, шунда формалашкан иделәр—«Татарстан АССР тарихы» эченә сыймыйча, бөтенләй милли тарихтан төшеп калды. Ә милли аң үсеше башлану төрле төбәкләрдә җирле тарихка игътибарны көчәйтте. Казан ягыннан тиешле тирәнлектә язылган тарих булмау сәбәпле, еш кына җирле тарихны язу анда яшәүче төркемнәргә аерым легитимлык бирә башлады. Бигрәк тә кайбер региональ дәрәҗәдә эшләүче рус һәм татар галимнәренең теге яки бу төбәктәге төркемнәрнең тарихын, этнографиясен башка татарлар белән булган тарихи,

мәдәни, тел ягыннан килгән бәйлелекләрне күрсәтмичә, аларның гомуммилли мәгълүмати-мәдәни кырдагы урыннарын билгеләмичә эшләүләре шундый нәтиҗәгә этәрде. Дөресен әйтергә кирәк, Татарстандагы кайбер галимнәр дә, үзләренең ялгыш концепцияләреннән, тар фикерлекләреннән чыгып, бу тенденцияне көчәйттеләр.

Шулай итеп, соңгы ун-унбиш ел эчендә барган милләт эчендә күзәтелгән таркаулык катлаулы бер иҗтимагый сәяси процесс булып тора. Аны әле ныклап өйрәнеп, ул хәлдән чыгу юлларын ачыкларга кирәк.

Ләкин бүген шунысы ачык: татарлар, РФдә яшәүче башка халыклар белән бергә, ул Федерацияне оештыручылар буларак, бер милләт булып танылырга хаклы. Һәм безнең милли берлегебез алга таба үсүебезнең иң әһәмиятле алшарты булып тора. Ә инде РФ төзүдә катнашкан милли берлек буларак, татарлар, халык исәбенең нәтиҗәләрен билгеләгәндә, бер гомуми этник берлек (милләт) буларак саналырга хаклы. Ә инде теге яки бу татар этник төркеме үзбилгеләнергә тели икән, аны милләт эчендә дә эшләп була. Ул очракта мондый төркемнәр РФнең үзәк фәнни һәм статистик органнарына үз позицияләрен төгәл һәм тулы килеш җиткерергә тиешләр. Милли җәмәгатьчелек исә андый позицияләр турында белергә хаклы. Әгәр дә шушы катлаулы процесста иҗтимагый оешмалар, дәүләт органнары һәм фәнни оешмалар бергә-бергә хәрәкәт итсәләр, барлык килеп чыккан мәсьәләләрне артык сәясәтләштермичә хәл кылу мөмкин булачак.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# АЛЛАҺ БОЕРСА, МӘЧЕТ ТАВЫНА АП-АК КАРЛАР ЯВАР...

*Әгүзе биллаһи минәш шәйтан ир раҗим.*
*Бисмилләһир рахмәнир рахим.*
*Таш атып куылган шайтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам.*
*Рәхимле вә изгелекле Аллаһы Тәгалә Исеме белән.*

Шагыйрь-язучыларның һәм башка адәм балаларының да әдәбиятка, китап дөньясына килүләренең, тормыш сорауларына китап, әдәбият аша җавап эзли башлауларының үз тарихлары буладыр.

Минем күңелемдә еллар аша туган авылымның уртасында урнашкан нәни генә тау яңара.

Ни өчен? Чөнки бу—Әдәбият, Китап белән мавыгу гүзәл бер кичне Олы Ачасыр авылының Мәчет тавында башланып китте.

Хәзер дә хәтердә: СССР киңлекләрендә 1978-79 ел кышы иде.

Без, 11 яшьлек бер төркем балалар, Мәчет тавында электр баганаларыннан төшкән яктылык астында көлешеп чана шуа идек. Ә өстән, югарыдан дөньяга, күңелләргә сафлык, чисталык алып килеп ап-ак кар энҗеләре әкрен генә төшәләр дә төшәләр иде.

Мәчет тавы ул вакытта безгә, әле дөньяны күпмедер дәрәҗәдә туган авыл офыклары белән чикләүче 11 яшьлек балаларга, зур күренә иде. Аннан төшкәч тә башланучы урам, Май тавына кадәр дәвам итеп, әнием йөргән инешкә илтә иде.

Табигать куенында шулай чана шуып күпме уйнаганбыздыр, шулвакыт бер иптәш малаебыз безне Мәчет тавында урнашкан авыл китапханәсенә кереп журналлар карап чыгарга чакырды. Хәзер дә хәтерлим: безне уку залында якты йөз белән китапханәче, сугыш ветераны, үзешчән рәссам Нури абый каршы алды...

Һәм... шуннан башланды да инде... Күңелдә бер якты үзгәреш булды. Китапханә минем күңелемне үзенчә күпмедер тетрәтте, әсир итте. Бу минем өчен ачылган өр-яңа бер дөнья иде. Бүтән балалар китапханәгә шуннан соң ничек йөргәннәрдер, ачык кына хәтерләмим, мин исә инде Мәчет тавында урнашкан Китап йортына эземне суытмадым.

Күңел түрендә якты урын яулаган китапханә... Соңрак... еллар узгач та төшләремә еш керә иде ул—Олы Ачасыр китапханәсе: аның якты уку залы, гаҗәеп серле тоелучы китап киштәләре... Бу китапханәгә йөрү—минем өчен күпмедер дәрәҗәдә рухи дөньяны ачу булган икән.

(Вакытлар узгач уйлап та куйгаладым: бәлки, кайчакларда мин артык та мавыкмадым микән?! Чөнки кайбер вакыт китап укуым, мәктәпкә барасымны да онытып, таң атканчы дәвам итә иде.)

Ап-ак карлар яуган кичләрдә мин ак сукмаклар буйлап әле яңа ачкан шагыйрьләрнең, язучыларның укучылар аңына сафлык-пакьлек, мәрхәмәт, җитдилек, яхшылык белән килергә ашкынган китапларын алып өйгә ашыгам...

Ә дөньяда ниндидер бер серлелек хөкем сөрә. Бу матурлык, сафлык җанга

да, биткә дә йомшак кына кагыла. Еракларда яшәгән ил-җирләр, гүзәл шәһәрләр өстеннән томан тарала. Китап барлыгы аша синең күңел офыклары киңәеп китә төсле. Син егет белән кызның авырлыклар җиңеп чыккан саф сөю-мәхәббәте турында укыйсың, ата-ананы кечкенәдән хөрмәт итү мөһимлеге турында вәгазьләнәсең, кыенлыкларда сыналган дуслык турында беләсең, тормышның кадерен белергә өйрәнәсең...

Син, яшь кенә бала, зур Хыял дөньясына китәсең, якын-ерак кыйтгалар, күктәге йолдызлар турында уйлыйсың, олы җанлы кешеләрдән үрнәк алырга омтыласың... Бәлки, үз-үзеңне, үзеңнең тирә-ягыңны, яшәешеңне өр-яңадан танып-белә башлыйсың.

Әйе, Галиҗәнап Китап безнең өчен күңелебезне пакьләүче белем чишмәсе булып кала. Һәм бу белем чишмәсе безнең күңелләргә һәрвакыт, һәр чорда да якындыр...

Еллар узгач, белемгә омтылу Ислам дине буенча да тирән мәгънәгә ия икәнен укып белдем. Билгеле, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен алган, өйрәнгән белем генә файдалы.

Мәчет тавында урнашкан Олы Ачасыр клубы—Культура йорты урынында кайчандыр Аллаһ Йорты булган. Егерменче, җитәрлек рухи адашулар, туры юл эзләүләр тулы гасырның утызынчы елларында аның манарасын кисеп клуб ясаганнар. Сүз дә юк: чукындыру чорын да күргән Олы Ачасыр мөселманнары өчен бу тирән фаҗига булган. Гомумән, атеизм сәясәтенең нindирәк начарлыкларга, нindирәк фаҗигаләргә нигез булып ятканлыгын тулысынча аңлап бетерә алдык микән әле без?!—Бер Аллаһ белә.

Аллаh Сөбханәкә Тәгалә моңа кагылышлы рәвештә Коръән Кәримдә түбәндәгечә кисәтеп үтә:

«Әллә намаздан тыючы ул кяфер белмиме Аллаһның һәркемне күргәнен? Юк, алай кирәкмәс, намаздан тыю ни кабахәт эштер, әгәр ул, бу эшне туктатмаса, әлбәттә, маңгай чәченнән тотып җәһәннәмгә өстерәрбез.» (*Галәк сүрәсе, 19 аять, 19).*

Без үскәндә, безнең балачакта Мәчет тавында ак таштан өр-яңа, матур, зур Мәдәният йорты салдылар. Әтием авыл клубы өчен ак кирпечләр Чувашиянең Төрләмә тимер юл станциясенә кайткач, аларны ничек итеп бер кырыйга өйгәннәрен, аннары авылга алып кайтканнарын хәзер дә искә алып сөйли.

Ә соңрак мин тагын бер Мәчет тавында балаларның чыр-чу килеп, көлешеп, рәхәтләнеп чана-чаңгы шуганнарын күзәттем. Ул мең еллар кичкән Казан исемле баш шәһәрдәге-каладагы «Мәдинә» мәчете урнашкан таучык-ерганак булды. Вә ул шатланып чана-чаңгы шуып уйнаучы балалар арасында минем улым да бар иде. Сөбхәнуллаһ!

Әйе, бу таучык-ерганакны да Мәчет тавы дип атарга булыр иде. Тик бу очракта Мәчет тавы өстендә Аллаһ Йорты заман җилләре эчендә Ходай кушканча имин тора иде...

Кайчакта күңелгә шундый уй да килә: бабаларым дини йорт салгач та исеме барлыкка килгән Мәчет тавына, без үскәндә төзелгән Мәдәният йортына—Китап Мәгарәсенә тәүге адымнар ясап мин монда үзем дә сизмәстән Галәмнәр Раббысыннан—Аллаһы Тәгаләдән иңгән, гасырлар буе үзгәрешләрсез-бозуларсыз сакланган Изге Китапны—Коръәнне эзләмәдем микән?! Ә татар әдәбияты, мәдәнияте әле болгар чорларыннан ук, Кол Галиләр дәвереннән үк мәңгелек, бакый мөселман кыйммәтләрен куәтләп иҗат ителгән бит.

Шуңа да, халкыбызның күпмедер дәрәҗәдә йөзе булган татар әдәбияты дөньяның иң пакь әдәбиятларының берсе түгелме икән?!—Бер Аллаһ белә.

Китапханәгә йөри башлагач, әдәбиятта тоткан урыннарына карамастан, кайсы гына шагыйрьләр, язучылар белән мавыкмадым икән! Китапханәдән иң беренче алып кайткан китаплар арасында, хәтерләвемчә, XX йөз башы татар классик шагыйрьләре Һади Такташның вә Хәсән Туфанның мәҗмугалары бар иде. Мәктәп программасына кергәнгәдер дә бу олуг татар шагыйрьләре күңелгә ак юл салдылар: «Үтеп барышлый», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай», «Киләчәккә хатлар», яки: «Башлана башлады», «Урал эскизлары», «Агыла да болыт агыла», «Кырда ике ак канат ята», «Сиңа», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Тугызынчы дулкын»...

Башка кайбер кардәшләремә хас булганча, Тукайның кабатланмас, тирән шигъриятенә мәхәббәт исә миңа бераз соңрак килде...

Ә аннары нинди генә китаплар укылмады! Мәчет тавындагы Китап мәгарәсеннән кайсы гына шагыйрьнең, язучының мәҗмугаларын алып кайтмадым мин!

Аерым вакытларда мин Әнвәр Давыдов, Атилла Расих, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Сарьян, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ (Гатауллин), Вакыйф Нуруллин, Шамил Рәкыйпов, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Дамир Хәкимов, Хәбиб Хәлилов, Максим Горький, Анатолий Маркуша, Борис Полевой, Михаил Лермонтов, Юрий Бондарев, Джек Лондон, Жюль Верн, Войнич, Чыңгыз Айтматов, Оноре де Бальзак, Пабло Неруда, Михаил Шолохов һ. б. күпләр белән мавыктым..

Бу китаплар үзләре нинди рухи байлык китергәннәрдер,—Бер Аллаһ белә. Ләкин, алар, башта бала, ә аннан яшүсмер күңелендә туган әнә шул яшәеш, чынлык мәсьәләләренә кагылышлы төгәл җавап эзләү дә иде...

Әдәби әсәрләрне уку күңелләрдә нинди генә уй-фикерләр уятмас икән: әдип ни әйтергә теләгән? Яшәүнең мәгънәсе ни-нәрсәдә? Адәм баласы Җирдә ни өчен яши? Гомумән, без ни өчен яратылганбыз?..

Билгеле, язучыларга, аларның язганнарына СССР чорында хөрмәт зурдан иде. Яшүсмер чакта кайчакны халыкка танылган кайбер язучы, шагыйрь белән бер утырып сөйләшү дә тормышның бөтен асыл сорауларына, барлык төп серләренә җавап табарга булышыр төсле тоела иде...

Әмма язучыларның, шагыйрьләрнең әсәрләренә мөнәсәбәт тә яшәеш дәверендә үзгәрергә мөмкин икән. Бу—кешенең рухи тормышта күпмедер югарырак биеклеккә күтәрелүедер инде.

Без башта татар әдәбиятын укыйбыз. Аннары урыс әдәбияты белән танышабыз, соңрак дөнья әдәбияты әсәрләре белән дә танышу алабыз.

Кайчакларда күңелдә, инде алдан әйтеп узганымча, шундый бер сорау туа: татар әдәбиятын дөньяның иң пакь әдәбиятларының берсе дип санарга мөмкин түгелме икән?! Ни өченме? Чөнки йөзьеллыклар кичкән татар әдәбияты, әйткәнемчә, Ислам хакыйкате белән тыгыз бәйләнгән. Һәм әгәр совет чоры татар әдәбиятын алсак, ул чор татар әдәбияты әсәрләрендә булган саф хисләрне сурәтләү, миһербанлылык, яхшы күңеллелек, олы җанлылык—алар дини чорның шифалы тәэсиреннән дә түгел идемени?!

(Ә бит шунысы куанычлы: җитмеш еллык коммунистик-атеистик чорда Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылучыларның беткәне булмады. Минем бер бабам Касыйм Абдулкави улы (без аны дәү әти дип атый идек) үзе КПССның актив әгъзасы иде, үзе намаз укый иде. Ибраһим (г.с.), Йосыф (г.с.), Муса (г.с.), Мөхәммәт (с.г.в.) пәйгамбәрләр турында иң беренче мин әнә шул бабамнан ишетеп белдем. Сабый чакта, әле балалар бакчасына йөргәндә, без сеңлем белән бабабыз артыннан намаз укырга да өйрәнә идек...)

Әйе, шиксез ки, Аллаһы Тәгалә дине буенча яшәргә алгысу, гөнаһлардан тыелып саваплы эшләргә омтылу—дин тәэсире атеизм чорында да татар әдәбиятына уңай йогынты ясамый калмаган...

Шиксез ки, безне бу дөньяга Галәмнәрнең Хуҗасы—Аллаһы Сөбханәкә Тәгалә яраткан һәм без җавап бирер өчен Аңа әйләнеп кайтырбыз да. Коръән аятендә нәрсә диелгән: *«Кеше илә җенне халикъ кылмадым, мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә кылдым».* (Коръән. Зарият (Таратучы) сүрәсе 60 аять, 56.) Бу инсан чынбарлыгының Аллаһ Тәгалә чынбарлыгыннан башка күз алдына да китерү мөмкин түгеллеген ачык күрсәтә...

Коръән—Аллаһ Тәгаләдән иңгән вә Ахыр замангача сакланачак Китап. Киләчәккә барган саен без Коръәннең дөреслеген күбрәк ачабыз, яшәеш сорауларына чын җавапны нәкъ менә анда табабыз, һәм адәм балалары тудырган башка төр фәлсәфәләргә Аллаһ Китабыннан чыгып карарга омтылабыз...

Бу соңгы еллар әдәбиятына карата мөнәсәбәттә дә ачык күренә ала.

Мәсәлән, кайчандыр—80нче еллар ахырында, 90нчы елларда «тимер рәшәткә» артыннан кайткан, без ул чорда азмы-күпме мавыккан язучыларны, фәлсәфәчеләрне искә төшерик. Коммунистик чорда җитәрлек нык тыелган төрле-төрле, үзенчәлекле язучылар иде алар.

Демократик җилләр исә башлагач, «яңа кайткан» язучыларны укучылар башта барысын да укыды кебек. (Төрле язучылар, төрле милләт ул-кызлары, төрле әсәрләр...) Альбер Камю, Жан-Поль Сартр, Серен Кьеркегор, Мартин Хайдеггер,

Фридрих Ницше... Солженицын, Домбровский, Рыбаков, Пастернак, Набоков, Бродский... Әхмәтһади Максуди, Мирсәет Солтангалиев, Гаяз Исхакый...

Укучылар аңында иләкләнә-иләкләнә ни-нәрсә калды?

Вакытлар узган саен, Ислам дине яңарыш кичергән саен, кайбер язучыларның, фәлсәфәчеләрнең әсәрләренә карата фикер дә нык кына үзгәрде... Мәсәлән, Ислам диненең шифалы сулышын тойган кайберәүләр аерым язучыларның тимер рәшәткә артыннан кайткан, кеше бозыклыкларын сурәтләгән аерым әсәрләрен укудан тәүбә иттеләр. Ә бит әле аларны яшәешнең асылына кагылышлы мәңгелек сорауларга җавап бирердәй язучылар, фәлсәфәчеләр дип тә фикерләп маташкан идек...

Бу—язучыларның, фәлсәфәчеләрнең эзләнүләрен, кайбер мәсьәләләрдә иҗтиһад кылуларын кире кагу түгел. Бу иң әүвәл аларны үзеңә кумир итүнең никадәр куркыныч икәнен аңлау. Чөнки алар да синең кебек үк камиллеккә омтылган, вакыты белән хаталанган адәм балалары, Аллаһ коллары лабаса.

Ә мәңгелек сорауларга җаваплар исә күптән инде Аллаһ Китабы—Коръән Кәримдә яши.

Демократик җилләр исә башлагач кайткан әдәбиятка килсәк: мәсәлән, кайбер язучыларның, фәлсәфәчеләрнең (Ф. Ницшеның, Ю. Мамлеевның) яхшылыкны, кече күңеллекне, мәрхәмәтне кире каккан, имморализмны сурәтләгән әсәрләре, билгеле, адәм балаларында яхшы хисләр тәрбияләмиләр, аларны Аллаһ юлына, туры юлга чыгара алмыйлар, рухи адашуга, бозыклыкка илтәләр.

Күңелдә исән әсәрләр исә шәфкать, мәрхәмәт, сафлык, җаваплылык һ.б.ш. хисләр тәрбиялиләр: «Туган ягым—яшел бишек» (Г. Бәширов), «Әйтелмәгән васыять» (Ә. Еники)... Яисә: «Беренче мөгаллим» (Ч. Айтматов), «Матера белән хушлашу» (В. Распутин), «Чын кеше турында хикәят» (Б. Полевой) һ. б....

Киләсе заманнарда, киләчәктә әдәбиятның барысы да кирәк булырмы икән?! Сүз беренче чиратта зур бозыклыклар сурәтләнгән әсәрләр турында бара. Мондый әсәрләрне «кара әдәбият» дип тә атыйлар кебек.

Мәсәлән, бүгенне көндә бер урыс язучысы (тәүбәгә килер дигән өметем булганга исемен атамыйм) үзенең бер романында ачыктан-ачык оятсыз сүгенү сүзләрен кертеп яза. Романында кешенең зур бозыклыкларын сурәтләү дә урын алган. Сорарга мөмкин: мондый китапны укыган кешенең күңеле пычранмыйча кала аламы? Туамы аның күңелендә саф-пакь хисләр?!

Билгеле, теләсә нинди әдәбиятны да игътибар белән укырга омтылырга кирәк. «Аң булыгыз!» диелгән Коръәндә, чөнки, син укыган әдәби әсәр бөек Ислам Хакыйкате аңа турыдан-туры каршы да чыгарга мөмкин.

Кайсыдыр күренекле бер америка язучысы, «язучыга үз-үзен тәэмин итәр өчен фәхешханә тотарга кирәк», дигән фикер әйткән... Язучылык данын Мәңгелек Сәгадәттән өстен кую... Укучыларга нинди үрнәк бирә ала шушы сүзләрне тәкърарлаган язучы? Ислам дине буенча фахишәлек-фәхешлек—җәһәннәмгә илтүче юл. Мөхәммәт (с.г. в.) әйткәнчә, әгәр зина кылырга уйласаң, зиначы хатын урынына үз әниеңне, сеңлеңне, кызыңны куеп кара.

Ахыр заман җиткәч, кеше үзенең бар кылган эш-гамәлләре, сүзләре, уй-фикерләре өчен дә җавап бирер, диелгән Коръән Кәримдә. Язучы, әдип Аллаһы Тәгалә алдында үзенең язганнары өчен дә җавап бирмәс микән беркөнне?! Әгәр адәм баласы гөнаһлы эшләре өчен, гөнаһлы сүзләре өчен, гөнаһлы уйлары өчен тәүбәгә килә ала икән, ул шулай ук үзенең язганнары өчен дә тәүбәгә килә аладыр.

Шагыйрьләрне Хакыйкатьне якларга чакыру Коръәндә дә ачык табыла. «Мәгәр иман китереп Коръән белән гамәл кылган кешеләр, ялганчы шагыйрьләргә вә кяферләргә һәм шайтаннарга иярмәсләр, ул мөэминнәр Аллаһны күп зекер итәләр, ул мөэминнәр, исламны яманлап шигырь әйтүче кяферләргә каршы исламны мактап, кяферләрне яманлап шигырьләр әйтәләр иде, алар кяферләрдән золым күргәннән соң Аллаһ ярдәме белән ярдәмләнделәр һәм өскә чыктылар, алга киттеләр. Ул золым итүче кәферләр тиздән белерләр, нинди урынга кайтарылачакларын! *(Коръән. Шүгарү (Шагыйрьләр) сүрәсе, 227 аять, 227).*

Коръән—Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә шәфкате. Монда яшәеш сорауларына җаваплар да, үз яшәешеңне Мәңгелек Бәхеткә илтүче юлда төзергә чакыру да бар...

«Ошбу Коръән кешеләрнең акылларына вә күңелләренә хакыйкый белем күзедер, аның илә олугь максудкә, мәңгелек бәхеткә ирешү юлын күрерләр, вә

ул Коръән илә гамәл кылган кеше адашу юлыннан чыгып туры юлга керер, вә аның илә гамәл кылучыларга Аллаһтан рәхмәттер» (Коръән, Жасийә (Тезләнү), 37 аять, 20).

Әдәбиятта җәмгыятьтәге, үзендәге кимчелекләргә, начарлыкларга каршы көрәшүче, әхлакый чисталыкка омтылучы, рухи биеклекләргә ашкынучы каһарманнар еш сурәтләнә. Аларның тормышлары да төрле, көрәш нәтиҗәләре дә төрле... Әмма нишләп без—Аллаһ коллары Ислам Хакыйкатен, Ислам нигезләрен онытабыз икән дип уйлап куясың кайчак. Аллаһның Барлыгын, Берлеген танып, Аңа итагать итеп, гөнаһлардан тәүбә кылып, сафланып, изге, саваплы эшләр эшләп адәм балалары котылуга килә ала бит. Ахыр чиктә, Ислам дине буенча, әдәбиятның бурычы җәмгыятьнең, кешеләрнең тискәре якларын зиннәтләп күрсәтү түгел, ә бәлки Ислам Хакыйкатен күрсәтү, адәм балаларын яман, гөнаһлы эшләрдән тыелуга, яхшы, саваплы эшләргә чакыру, яхшылыкка, пакь-саф хисләргә дәшү, рухи үсеш юлына өндәү...

Коръән—Аллаһ Китабы безнең өчен һәрвакыт, һәр заманда рухи маяк булып калыр, иншаллаһ.

...Аллаһ боерса, киләсе кышта да Мәчет тавына ап-ак, саф карлар явар. Инде Олы Ачасырның башка урынында торгызылган вә имин торган, авылның саф йөрәге булган авыл мәчетеннән Галәмнәр Раббысы—Аллаһы Тәгалә алдына басарга чакырып тәүлегенә биш тапкыр азан яңгырар...

Авыл китапханәсенә дә иртән, көндезләрен һәм кичләрен ак сукмаклар буйлап яңа укучы балалар килер. Китап җанлы Земфира апа аларны якты йөз белән каршы алыр вә бай китап дөньясына атлап кереп китәргә ярдәм итәр, иншаллаһ.

Нәрсә сөйләр китап йортыннан кулына китап тотып шатланып-сөенеп кайтып баручы, тормышка әле яңа гына аяк баскан укучының юлында явучы энҗе бөртекләре—ап-ак карлар?

Онытма, монда кайчандыр бер Аллаһ Тәгаләгә намаз укырга чакырып азан яңгырый иде, бу тауда бабаңнарның якты эзе калган, дип...

Хыяллан, әмма, реаль, чын тормышны исеңдә тот, дип.

Барысы да җиңел түгел, әмма, килерсең, Аллаһ боерса, Илаһи яктылыкка, дип.

Кеше бара... Яктылыкка таба...

Ә китап дөньясы киң...

Рухи сафлык, рухи байлык, рухи таң—кеше өчен Бәхеткә илтүче озын-озак юл...

**Илшат ВӘЛИУЛЛА**

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1908 ел

**2 гыйнвар.** Купеческое собрание залында шәкертләр катнашында әдәбият кичәсе була. Өч бүлемнән торган кичәнең икенче бүлемендә Г. Тукайның «Безне урынсыз яманлыйлар» исемле шигыре укыла. «Безне урынсыз яманлыйлар» шигыре дә бик акрын тавыш вә бөтенләй бер генә төрле тон вә жестларсыз, вә хәтта бәгъзе галәмәтләргә дә игътибарсыз укылып, бөтен хөсненнән гари булып чыкты, дияргә мөмкиндер»,—дип яза Ф. Әмирхан.

**3 гыйнвар.** Тукай үги әнисе Газизә апа белән күрешә. Шагыйрь бу вакыйганы түбәндәгечә тасвирлый: «Яңа бистәдә, жимерек кенә жир астындагы бер өйдә бер карчык бар икән. Көннәрдән бер көн мин, ничектер, шул өйгә чакырылдым. Анда мине әнкәем көтеп торачак иде. Вакыт төн иде. Мин әллә нинди баскычлардан төшеп, караңгыда шул өйгә барып кердем.

Кергәч тә, түрдә яше кырыклардан узмаган диярлек, кара кашлы, кара күзле, тулы гәүдәле бер хатын күренде. Моның әни икәнлеген танып: «Исәнме, әни»,—дип күрештем. Ул кулын бирде дә: «Син дә сәламәтмени соң әле?»—дип егълап жибәрде. Минем дә күңелем йомшарды, ничек тә үземне тота алдым».

**6 гыйнвар.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем. Казан. Шәрәф матбагасы, 1908. Титул битендә «1907» диелгән) исемле китабы чыга. Бу—Тукайның басылып чыккан икенче җыентыгы. Казан губерна жандарм идарәсенең дөньяга чыккан китапларны теркәү дәфтәрендә җыентыкның басылып чыгу вакыты итеп 1908 елның 6 январе күрсәтелгән.

**2 февраль.** Ф. Әмирханның «Габдулла Тукаев шигырьләре (4 нче дәфтәр)» исемле бәяләмәсе басыла. Автор җыентыкка уңай бәя бирә: «Габдулла әфәнденең моннан әүвәл бер шигырь мәҗмугасе нәшер ителеп, бөтен татар матбугаты тарафыннан иң гүзәл тәкъризләр белән каршы алынган иде. Бу икенче мәҗмуга да шулай ук гүзәл шигырьләр белән тутырылган вә рус мәшһүре шөгарәсеннән бик муаффәкыять белән тәрҗемә ителгән шигырьләр белән зиннәтләнгәндер»,—дип, шагыйрь иҗатын мактаганнан соң, җыентыкның кимчелеге итеп «Мужик йокысы» шигырен күрсәтә. «Мал юк, дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә Русия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер»,—ди. Бу әсәр иске карашы сәбәпле Тукаев шигырьләре арасында урын алырга тиеш түгел, дигән фикер әйтә.

**15 февраль.** Әстерханда үткәреләчәк «Әдәбият ахшамы»ның программасы басылган. Программада Г. Батыров тарафыннан Г. Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигыре укылачагы күрсәтелгән.

Г. Тукай, В. Бәхтияров, Г. Шәрәфләр белән бергә, Казанның Зур театрында француз композиторы Ш. Гуноның «Фауст» операсын карый.

В. Бәхтияровның истәлекләрендә Тукайның опера арияләренә караганда халык җырларын күбрәк яратуы турында әйтелә. Яраткан җырлары итеп «Уел», «Ашказар», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Порт-Артур», «Әминәкәй гүзәлем» кебек халык җырлары китерелә.

Казан губерна жандарм идарәсенә «Перс» яшерен имзасы белән ялланган

*Дәвамы. Башы 8 санда*

шымчы Г. Тукай турында донос кертә. Шагыйрьнең хөкүмәткә дошманлык белән сугарылган шигырьләре Чистай мәдрәсәләренә таратылуы, шәкертләрнең шуларны укулары турында яза. «Китмибез» шигырен мисал итеп китерә.

**Яз.** Г. Тукай Ф. Әмирхан белән бер очрашу вакытында аңа эч серен ача: «Мин үзем килеп эләккән кругымнан разый түгел. Мин Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем бүлмәдә көне-төне буе вакытларыны кайда куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар...» «вә сүзенең хатимәсендә үзенең эш эшлисе килгәнене, бу эшсез, «идеалсыз», «чиле-пешле» кешеләр тирәсеннән котылырга теләгәнене... бәян итте».

**7 март.** «Сабах» нәшрияты җитәкчесе Хәбибрахман Зәбири Оренбургка «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәримигә хат яза. Хатында ул, мохтаҗлыкта яшәүче Г. Тукайга ярдәм итәргә, әгәр дә аңа матди һәм мәгънәви ярдәм ителмәсә, татар халкы үзенең бер шагыйрен югалтырга мөмкин, дигән фикер әйтә.

**15 март.** Х. Зәбири киңәше белән Ф. Кәрими, Тукайның бер иптәшенә хат язып, шул хат аркылы шагыйрьне «Вакыт», «Шура» редакциясендә эшләргә чакырган. Хатында шагыйрьгә түбәндәгеләрне вәгъдә иткән: «Ашау-эчү, фатир үземнән булып, 40 сум җалунье бирелер».

40 сум ул вакытта иң югары хезмәт хакы булып исәпләнгән. Г. Тукай Оренбургка бармаган.

**17 март.** «Шагыйрь», «Шайтанның муенына» исемле шигырьләре басылып чыккан.

**27 март.** Г. Тукай Казаннан Уральскидагы апасы Газизә Госмановага хат яза. Ул болай ди: «...дус-иш күп. Күңелле, укыган кызлар белән дә танышырга туры килде. Гәзитәләр күп, китаплар һәркөн яңадан-яңа чыгып тора. Укыймыз, үземез дә язамыз. Әле бу арада тагы бер зур гына шигырь китабы яздым.* Монысы, һәртөрле матур буяулы сурәтләр илә зиннәтләнеп, балаларга бүләк өчен язылды. Тиздән басылып чыгачак. Чыккач та Сезгә җибәрермен.

«Иртәгә Казанда әдәбият кичәсе була. Анда Казанның барча мөселманнары, хатын-кызлары—һәммәсе җыела. Мин шунда үземнең «Утырышу» атлы шигыремне җырларга өстемә алдым».

**28 март.** Казанда, Купеческое собрание залында, Биржа йортында үткәрелгән әдәби кичәдә Г. Тукайның «Теләнче» шигырен В. Бәхтияров, «Утырышу» шигырен Тукай үзе укый.

«Г. Тукайның укуы начар булса да, әсәре матур гына язылганга күрә, халыкка ошады»,—диелә кичә турында басылган хәбәрдә.

**3 апрель.** Ф. Әмирхан «Әдәбият кичәсе» дигән мәкаләсендә болай ди: «Утырышу»ны да мөхәррире укып, халыкнын бик озак кул чабуын җәлеп итте һәм, чыгып, икенче бер кыска шигырен укырга мәҗбүр булды».

Апрель. Г. Тукай Г. Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятында экспедиторлык һәм корректорлык эшен дәвам иттерә.

**27 апрель.** «Чын вә ялган», «Күңелсез минутта» исемле шигырьләре чыга. Соңгысы «Все говорят» көе белән җырлана» дигән искәрмә һәм «Шүрәле» имзасы белән басылган. («Яшен ташлары», икенче җөзьә, Казан, «Өмид» матбагасы, 1912 исемле җыентыгында шигырьнең исеме «Бер кайгы көнендә» дип үзгәртелгән.)

**Апрельнең соңгы көннәре.** Г. Тукай якын иптәшләренең тәкъдиме белән Унъяк Кабан урамы, 15 нче йортка, бер бүлмәле фатирга күчә. Монда ул ике ай чамасы тора. Шушы фатирда аның барлык әйберләре югала. Беркөнне фатир хуҗасы, Тукайның әйберләрен җыеп алып, каядыр чыгып китә.

**Май урталары.** «Әл-ислах» идарәсенә Троицки кунаклары Бибиҗиһан һәм Зәйтүнә Мәүледовалар килеп йөри. Ф. Әмирхан бу кызларны Тукай белән таныштыра.

З. Мәүледова Чистай шәһәрендә заманы өчен шактый культуралы гаиләдә үскән кыз. Г. Тукайның язганнарын яратып укыган, шагыйрьнең үзе белән танышырга теләгән. Бу чибәр туташ Тукайның күңелендә яшерен мәхәббәт хисләре уяткан.

**19 май.** «Саташкан» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басыла. Шигырь С. Рәмиевнең «Алданган» *(«Әл-ислах», 1908, 4 май)* исемле шигыренә пародия рәвешендә язылган.

**27 май.** «Үпкә», «Истамбул шагыйрьләре», «Шекспирдан да бер сүз» исемле шигырьләре чыга. («Истамбул шагыйрьләре», «Габдулла Тукаев» диваны «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр» (1909) дә «Мәддахе Истамбул шагыйрьләре», «Шекспирдан бер сүз» «Шекспирдан» дип үзгәртелгән.)

**3 июнь.** «...гә (Мәслихәт)», «...гә (Бай баласы бит...)», «...гә (Очраган юлда...)» шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән басыла. Истәлек авторлары һәм әдәбият белгечләре бу шигырьләрнең З. Мәүледовага багышланган булуы турында әйтәләр.

**9 июнь.** Г. Тукай «Китаб» нәшрияты хуҗасы Габдрахман Дәүләтшинга хат яза: «Сезгә актык мәртәбә мөрәҗәгать итәм: әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзенез әйткәнчә, беткән булса да, пожалуйста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәренез әле. Мин Сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен».

Хатыннан күренгәнчә, Г. Тукай «Китаб» нәшриятында июнь аенда эшләмәгән инде, ул моннан апрель ахырларында ук чыккан булырга мөмкин. В.Бәхтияров истәлекләреннән шул аңлашыла.

**12 июнь.** Г. Тукай «Кызык гыйшык» исемле шигырен яза. Матбугатта басылган нөсхәсенең ахырында «12 июнь, 1908» датасы тора.

Ф. Әмирхан «Дамелла» имзасы белән басылган «Татар шагыйрьләре» исемле мәкаләсендә, татар шагыйрьләре тирәсендә барган бәхәскә кушылып, Тукай шигырьләре турында А.Пинкевич фикерләренә теләктәшлек итә. Тукайны халык шагыйре итеп бәяли. Касыйм Уралецны татар поэзиясен белмәгәне, Тукай иҗатына дөрес бәя бирмәгәне өчен тәнкыйтьли.

**18 июнь.** «Волжско-Камская речь» газетасында «Татарин» имзалы берәү «Невежество или глупость?» исемле мәкаләсендә Касыйм Уралецка каршы чыга, А. Пинкевичны яклый, Тукайны чын шагыйрь дип таный. «Татарин»ның кем имзасы икәне билгеле түгел.

**28 июнь.** «Өмид» исемле шигырен яза. Шигырьнең матбугатта басылган нөсхәсенең ахырына «28 июнь, 1908 сәнә, Г. Тукаев» дип куелган.

**13 июль.** «Тормыш», «Тешләре ямьсез бер матурга» исемле шигырьләре басыла. Соңгысы «Шүрәле» имзасы белән чыга.

**20 июль.** «Кулың» (Мактый беләм микән, дип кенә мактаган) исемле шигыре басылган.

В. Бәхтияровның язуына караганда, шигырь Зәйтүнә Мәүледовага багышланган.

«Мөхәммәдия»дән» дигән шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

**Июль ае.** Демократик яшьләр органы «Әл-ислах» газетасы редакциясе «Болгар» номерларыннан хәзерге Тукай урамы, 63 нче йортка күчә (Ф. Әмирханның җизнәсе Шәкүр Аппаков йорты). Тукай бу йортка һәркөн килә, кайвакыт бөтен көнен диярлек идарәханәдә үткәрә. Газетада эшләү өстенә, кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырып килә дә, йорт хуҗасының балаларын алып чыгып, кузна уйный.

**Июль ахыры.** Тукай Кабан күле буендагы йортта яшәүче руслашкан немец хатыны Мария Карловадан унбиш-егерме көннәр немец теле дәресләре ала. Рус һәм Көнбатыш әдәбиятыннан киң мәгълүматлы булган бу хатын йортында С. Рәмиев кебек яшьләр катнашында әдәбият кичәләре дә үткәрелә, бәхәсләр оештырыла.

**3 август.** Казанда Г. Тукайның сатирик таланты үсүгә зур этәргеч ясаган рәсемле сатирик «Яшен» журналының беренче саны чыга (1909 елның июнь аенда туктала). Нашире һәм мөхәррире—Г. Камал. Секретарьлык эшен Г. Тукай алып бара. «Журналның беренче номерында башыннан ахырына кадәр Тукайның каләме йөри»,—ди Г. Шәрәф.

**5 август.** Г. Тукай Г. Камал белән бергә Мәкәрҗә (Нижний Новгород) ярминкәсенә бара. «Сәйяр» труппасы белән берлектә ярминкәдә урнашкан «Двухсветная» дип йөртелгән кунакханә залында концерт куюга катнаша. Хор чыгышында капельмейстер-дирижер ролен үти. Ул бу концертлардан ризасыз кала. Соңыннан анда катнашуы өчен үкенә.

**18 августтан соң.** Г. Тукай Казанда «Сәйяр» труппасы куйган «Бәхетсез егет» (Г. Камал) спектаклен карый. «Кариевның Кәрим бай, Сәхипҗамал Гыйззәтуллинаның Гайни, Фәйзуллин-Болгарскийның Мәгъри карчык ролендә уйнауларын һәрвакыт

искә алып сөйли иде»,—ди артист Касыйм Шамил.

**31 август.** Гыйльметдин Шәрәф туганы Борһан Шәрәфкә (Оренбургка) язган хатында Г. Тукайның Мәкәржә ярминкәсеннән әйләнеп кайтуы һәм «Болгар» номерларында яшәве турында хәбәр итә.

Сентябрь башы. Казанга, Никитин циркына Карәхмәт дигән көрәшче килә. Ул «Болгар» номерында Тукайдан берничә номер аркылы гына тора. Аны күрү Тукайга мәдрәсәләрдә укылып йөргән «Иске Кисекбаш» китабын искә төшерә. Китапны яңадан укып чыгу «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын язуга этәргеч ясый. Поэма язылып беткәч, Тукай аны «Яшен» журналында бастырырга уйлый. Ләкин иптәшләре аңа бу зур поэманы журналда бүлеп-бүлеп чыгармаска, башта ук аерым китап итеп бастырырга киңәш итәләр. «Тукайның әлегә кадәр басылган егермегә якын әсәрләре эчендә беренче чыгуында ук иң күп таралганы «Печән базары...» булды»,—ди Г. Шәрәф.

**8 сентябрь.** «Бер рәсемгә (Төрекләргә тәкълид)» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

**23 сентябрь.** «Ташмөхәммәд» имзасы белән басылган «Зыялы шәкерт» исемле фельетонда Ф. Әмирхан Г. Тукайның «Дөньяда торыйммы?»—дип киңәшләшкән дустыма» (1907) дигән шигыреннән түбәндәге өзекне китерә:

*Эчтән динсез булып, тыштан «дин», «дин» дисәң,*
*Ярлыларны дошман күрмәк диндин дисәң,*
*Мин мәсләкле, мин мәзһәбле, мин эшлекле,*
*Һәр артыклыкның чишмәсе «мин», «мин» дисәң.*

**30 сентябрь.** «Яшен»дә «Авыл җырлары (икенче көлтә)» «Шүрәле» имзасы белән басылган. Ахырга: «Өченче вә дүртенче көлтәләре дә бәйләнмәктә. Идарә»,—дип куелган, ләкин болары чыкмаган.

**13 октябрь.** «Төлке һәм Йөзем җимеше» исемле мәсәле чыккан. Әсәр И. А. Крыловның «Лисица и Виноград» исемле мәсәленнән файдаланып язылган. Шунда ук «Бәйрәм бүген» шигыре урнаштырылган.

«Әл-ислах»ның 48 нче санында Купеческое собрание залында 14 октябрьдә булачак әдәбият кичәсенең программасы басылган. Кичәдә Г. Тукайның «Кызык гыйшык» һәм «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын укыячагы әйтелгән.

**14 октябрь.** Г. Тукай «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын Купеческое собрание залында «Әл-ислах» газетасы файдасына уздырылган әдәби-музыкаль кичәдә укый.

«Халык, җөмлә тәмам булганын да көтә алмыйчан, самими бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып кул чабалар һәм, укучыны бүлеп, әллә никадәр вакытлар туктап торырга мәҗбүр итәләр иде»,—ди Ф. Әмирхан «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» исемле мәкаләсендә.

**2 ноябрь.** «Йолдыз» газетасы берничә санда түбәндәге игъланны урнаштырган: «Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» китабы басылып чыкты».

Декабрь урталары. «Хөсәен Әбүзәров («Таң мәҗмугасы»ның мөхәррире) үзенең квартирасында (Дегтярный урамында, хәзер ул йорт урынында бакча) яшьләр мәҗлесе ясый. Мәҗлестә Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, В. Бәхтияровлар була. Матур тавышлы С. Рәмиев мәҗлестә «Әминәкәй гүзәлем», «Ашказар», «Әллүки» һ. б. борынгы татар көйләрен җырлый. Тукай бик бирелеп тыңлап утыра. С. Рәмиевнең җырлавын бик ярата, аны «татарның Шаляпины» дип атый иде. С. Рәмиев җырлаган моңлы көйләр тәэсирендә Г. Тукайның «Милли моңнар» (1909) шигыре туа. «Тукай искиткеч зиһен иясе иде. Ул бер әсәрне укыса яки күз генә йөртеп чыккан кебек күренсә дә, ул аны (бигрәк тә шигырьләрне) күңеленә алган, ул аны ятлаган була.

Кабатлап уку, яхуд ятка алу өчен берничә мәртәбә карап чыгу анарда юк иде»,—дип искә ала В.Бәхтияров.

Истәлек иясе тагын шуны өсти: «Тукай халыкка үз вакытында әдәби тәнкыйть аша түгел, ә шигырьләренең телдән-телгә күчеп йөрүе аша танылды».

Миркасыйм
Госманов

# АКСАКАЛЛАР МӘҖЛЕСЕННӘН

Узган гомеремдә язмышым миңа күп кенә бүләкләр бирде. Матди түгел—мәгънәви бүләкләр. Бу очракта мин кайбер асыл затларыбыз, сүзнең чын мәгънәсендәге олы, дөресрәге, олуг шәхесләребез белән очрашып танышуларны, беркадәре генә булса да, аларны тыңлау, хәтта сөйләшү, әңгәмәләшү кебек бәхетле минутларны күз уңында тотам.

Рәсми рәвештә бирелеп, ара-тирә фамилия янына куела торган мактаулы исемнәрдән, формаль дәрәҗә белдереп, аннары төшеп кала торган сүз-титуллардан нык аерыла алар. Әлбәттә, болары да адәм күңелен бер җылытып ала. Тик... Орден-медаль ише ялтыравыклы билгеләр вакыт узу белән тоныкланалар. Күп булса, җеназаңны чыгарган чакта бәләкәй мендәр битендә бер ялтырап куялар. Боларның берсе дә үзең белән бергә китми...

Матди байлык ишеләре исә—алары да язмышыңның бүләкләре сыман—ничек килгән булсалар, шулай ук «тиз эреп бетәләр». Аларның булганнары белән булмаганнарын күп вакытта онытып йөрисең. Кайберләрен искә алмаска тырышасың, исеңә төшерсәләр, шәхси эшләреңә тыкшынудан кәефең кырылырга мөмкин. Болары да шулай ук үзеңнән башка яши алалар. Синнән калып та...

Әмма олуглар, асыл зыялы затлар белән булган мәгънәле, гыйбрәтле очрашулар хакындагы хатирәләрең гел үзеңнең күңелеңдә сакланыр; алар—чын-чынлап үз байлыгың. Үзең ачмасаң, аларга беркем дә тыкшына алмас. Гел үзең белән бергә булыр. Көндезләрен дә, төннәрен дә. Кайберләре уйландырыр, икенчеләре моңландырыр. Өченчеләре искә төшкәндә, елмаеп та куярсың. Димәк, чын байлыгың, чын бүләгең икән алар. Үзеңнән аерылмый, үзеңнән калмый торганнары!..

Шундыйлардан берсе.

Күңелле, яки көлкелерәк мизгелләре белән дә...

### Мәгърифәтче әдип

Ул елларда университетның татар бүлегендә студентларның «фәнни түгәрәк» дигән иректә оешмасы актив һәм даими эшләп килә иде. Беренче курстан соңгысына кадәр аның эшләренә катнашырга тырыша идек. Барыбыз булмаса да, күпчелегебез. Гадәттә югары курслардан берәрсе доклад укыр, шул докладны тикшерүләр, бәхәсләшүләр булыр. Яисә берәр күренекле әдип, галим белән очрашу оештырылыр. Укытучылардан да берничә кеше йөрер иде андый утырышларга.

1958-1959нчы уку елында түгәрәкнең бер утырышына билгеле драматург, популяр «Хуҗа Насреддин» комедиясенең авторы Нәкый ага Исәнбәт чакырылган иде. Шуңа күрә утырышка анда драматургия, яңа спектакльләр хакында сүз булыр, атаклы драматургны да күрермен дип килгән идем. Үзен күргәнче мин аны зур гәүдәле, беркадәре кырыс холыклы кешедер дип күз алдына китерә идем. Тик ул кечерәк гәүдәле, еш кына елмаебрак тора торган, сакал-мыексыз, шулай ук бик гади киенгән һәм шактый хәрәкәтчән кеше булып чыкты.

Утырыш та сәхнә сәнгатенә түгел, бәлки тел белеменә багышланган икән. Өченче-дүртенче курслардан бер егет (исемен инде хәтерләмим) хәзерге әдәби тел нормалары хакында сөйләде шикелле. Истә калганы: «Ни өчен «Азат хатын»

журналы «кухня» дип дөрес язасы урынга, әдәби телебез нормаларын бозып, «күхнә» дип яза?»—дигән соравы гына истә калган. Фикер алышуга катнашучыларның кайберләре докладчыны якладылар кебек. Ниһаять, аудитория бераз шаулап алгач, монарчы беленер-беленмәс хәлдә елмайган килеш кенә тыңлап утырган Нәкый ага сүзгә килде. Докладчының һәм кайбер чыгыш ясаучыларның рәсми политиканы исәпкә алып сөйләүләрен билгеләгәч, докладчыга сорау бирде:

—Ярар, егетем, күхнә димичә кухня-я дип яздык ди. Алайса, ни өчен бревно димичә бүрәнә сүзен кулланабыз, самоварны самауыр дип әйтәбез? Мондый татар теленә күптән кереп, аның кануннарына ярашкан урыс сүзләре бездә дистәләп кенә түгел, йөзәрләп бит! Бәлки, безгә аларны да нәкъ урыс телендәгечә язып, татар теленең үзен җимерергәдер?!



Әле генә гөрли башлаган аудиториядә тирән тынлык урнашты. Нәкый ага елмаюдан туктап, бер кулының бармаклары белән өстәлгә тавышсыз гына суккалап, сынаган төсле, беркадәре вакыт залга сүзсез карап утырды. Аның чыгышы шул рәвешчә башланып китте.

—Игътибар иткәнсездер: «рус» сүзен дә рәсмилектән азат сөйләм телебездә «урыс» рәвешендә яңгыратабыз. Гарәпчә «рузә»не дә «ураза»га әверелдердек. Телебезнең эчке кануны шулай, анда «р»га башланган сүзләр алдыннан сузык аваз әйтелү таләп ителгән.

Сөйләгән саен Нәкый ага кыза төште, төскыяфәтендәге елмаючанлык та бөтенләй юкка чыкты диярлек. «Татар теленең,—диде ул,—үзенә хас аваз системы, стиль, дәресрәге, өслүб һәм мәгънә үзенчәлекләре барлыгын тел галимнәренең һәммәсе дә таныйлар. Мин дә шулай уйлыйм!—дип раслап куйды.—Димәк, аның кануннарын да исәпкә алырга кирәк икән. Әгәр алмасак, конкрет халыкның әдәби теле нормаль, мөстәкыйль милли тел булудан туктаячак». Моннан соң Нәкый ага һәр телнең үзенә генә хас мәгънә һәм стиль үзенчәлекләре булуга тукталды. «Шуна күрә,—дип әйтте ул,—Такташ шигырьләрен һаман урысчага барлык сыйфатларын да саклап тәрҗемә итә алмыйлар. Кайбер чын урыс шагыйрьләрен дә татарча абсолют төгәл итеп яңгыратып булмаячак. Гади мисал да китерергә мөмкин, мәсәлән: «Әйдәгез, бер чәйләтеп җибәрик әле» дигән татарча гап-гади гыйбарәне бөтен мәгънә, хис төсмерләрен саклап тәрҗемә итеп карагыз әле»,—диде ул бераз елмая төшеп.

Чыгышының икенче өлешендә Нәкый ага әдәби мирасыбызны җентекләп өйрәнү, дөньяга чыгару мәсьәләләренә тукталды. Хәзер күзәтелә торган иң зур кимчелекләр сыйфатында ул элек гарәп язуында язылган текстларны хаталар белән бастыруны атады. «Соңгы утыз-кырык ел эчендә генә үзебезгә мең елга якын хезмәт иткән язуны дөрес итеп укый алмаслык хәлгә төштек бит! Мисал кирәк икән, ерак барып торасы түгел, әнә Габдулла Тукай шигырьләренең яңа басмаларындагы хаталарга карагыз»,—диде. Ниһаять, үзенең һаман да шул гарәпчә язуны куллануын да әйтте: «Үзем язган әйберләрнең беренче вариантлары шул язу белән язылган булыр». Иң ахырдан чыгарган хөкеме хәзер гамәлдәге язуыбызның кимчелекләре, хәтта әдәби телебез өчен «бөтенләй яраксызлыгы» хакында булды. Берничә көлкеле мисал да китерде.

Бу очрашу вакытында (һәм соңгыларында да) минем игътибарны җәлеп иткән нәрсә ул—аның сөйләү, хикәяләү, үз фикерләрен раслау үзенчәлеге, җыеп әйткәндә, һәр сүзе, фикере өчен үзен җаваплы сизүе иде. Ул, мәсәлән, берәр оригинал һәм кыюрак фикер әйтү белән «мин шулай уйлыйм» дип раслап куярга онытмас, ара-тирә «бәлки, ялгышамдыр» дип тә өстәп куяр иде. Аның мондый алымы гел кабатланыр иде.

Гаять җанлы рәвештә барган утырышның шактый озак дәвам итүен, студентларның теләмичә генә таралуын һәм, ниһаять, утырышка катнашкан кайбер укытучыларның кунак чыгышыннан бик үк канәгать булмауларын да абайлап калдым шикелле. Укытучыларга, минемчә, студентларны иске язуыбызга, әдәби тел нечкәлекләренә начар өйрәтү хакындагы сүзләре ошамагандыр. Ләкин беркем дә каршы сөйләп тормады.

Нәкый ага белән икенче очрашуыбыз аның тарафыннан төзелгән «Татар халык мәкальләре»нең беренче томы чыкканнан соң булды. Яна китап белән күпчелегебез танышып, үзара фикер алышып, зур китап кадәре күләмле, гаять эчтәлекле кереше буенча бәхәсләшеп тә өлгергән идек инде. Барыбыз да диярлек халык авыз иҗаты буенча беркадәре лекцияләр тыңлаган, шул өлкәгә караган, нигездә формаль социологизм рухында төзелгән фәнни кулланмалар белән дә беркадәре таныш идек. Нәкый аганың мәкальләрне мөстәкыйль монография дәрәҗәсендә һәрьяклап анализлаган, мәсьәләне традицион булмаган рәвештәрәк яктырткан әлеге зур хезмәте исә безнең өчен сүзнең чын мәгънәсендә яна дөнья ачу иде. Кайбер мәкальләрнең, әйтемнәрнең «тарихларына» карый торган легенда-бәлешмәләре дә безнең өчен кызыклы яңалык булып тоелган иде. Шуңа күрә яңа китап турында фикер алышу җанлы һәм кызу рәвештә барды.

Студентларны иң элек мәкаль-әйтемнәрне эзләү, җыю, дөресрәге, технология мәсьәләсе күбрәк кызыксындырды. Кайберәүләрнең Татарстаннан читтә дә халыктан җыелган мәкальләрнең ярыйсы гына күплегеннән шаккатулары минем истә уелып калган; алар өчен, күрәсең, татарлар бары Татарстанда гына яшәргә тиеш иде кебек... Нәкый ага бу мәсьәләгә махсус тукталып, республика оешкан чорда нинди сәясәт уздырылуын шактый ачык тәфсилләп тасвирлады. Минем игътибарны кайбер укытучыларның чырайлары карангылана төшүе җәлеп иткән иде ул көнне. Моның сәбәбен соңрак аңладым...

Әлбәттә, икенче вә өченче томнарның кайчаннар чыгуы турында да кызыксынулар булды. Нәкый ага әле эшлисе эшләрнең күп икәнлеге хакында аңлатмалар бирде. Икенче-өченче томнарга керәсе мәкальләр язылган карточкалар зур төркемнәргә бүленеп куелган инде. Аларны хәзер шул төркемнәр эчендәге ваграк төркемчәләргә бүлгәләү, алфавит тәртибендә урнаштыру кебек тавык чүпләп бетерми торган эшләрнең иге-чиге юк дип әйтерлек икән. Мәкальләрнең төрдәшләрен, ягъни вариантларын сайлау да вакыт сораячак. Элек теркәлгән мәкаль-әйтемнәр гарәп язуы белән язылганнар. Шул карточкаларны хәзерге язуга күчереп чыгасы да бар икән. «Элекке язуыбызны укый ала торган машинисткалар да бетеп бара бит!»— дип көрсенде галим.

Очрашу тәмамланып, халыкның күпчелеге таралгач, без өч-дүрт студент—арада булачак фольклор белгече Ленар Җәмалетдинов та бар иде—Нәкый аганы трамвай тукталышына кадәр озата бардык. Шунда анардан: «Карточкаларны төркемләү, күчереп язу өчен бездән берәр ярдәм кирәк булмас микән?»—дип сорадык. «Кызык фикер,—диде Нәкый ага чак кына көттереп.—Сез дә катнашсагыз, тагын да әйбәт булыр иде!»

Тукталышка җиткәч, ул телефонын әйтеп, берәр атнадан шалтыратып белешергә кушты.

Ун-унбиш көннән соң, алданрак килешү буенча, Нәкый агаларның Журналистлар урамындагы фатирына килдек. Ленар Җәмалетдиновтан башка тагын бер студент бар иде безнең янда. Хуҗа кеше безне якты чырай белән шаяра-шаяра хуплап каршы алды. Бигрәк тә әллә ничек солтанатлы кыяфәттәге Гөлсем апа—Нәкый аганың җәмәгате—аерата ачык йөз күрсәтеп сәламләде, һәрберебез белән күрешеп, танышып чыкты. Нәкый ага белән сөйләшә-сөйләшә зур язу өстәлендә торган катыргы әрҗәләрдә бәйләм-бәйләм булып өелеп яткан карточкаларның чит-кырыйларыннан гына бераз карый башларга өлгермәдек, Гөлсем апа безне табын янына чакырды. Үзебезне ашар өчен генә килгән кеше кебек сизеп, бераз уңайсызланыбрак калдык. Моны сизгән Нәкый ага мәсьәләне җиңел юл—шаяру юлы белән хәл итте, үзе беренче булып торып басты: «Әйдәгез, ашау белән сынап карыйк әле үзегезне. Элекке байлар ялчылыкка алырга кеше сайлаганда иң әүвәл ашатып карый торган

булганнар: тиз һәм күп ашый алганнарын гына эшкә алганнар».

Кәҗүнни ашханәләрдә гел бер төсле, яисә тулай торак бүлмәләрендә әшер-өшер әзерләнгән нәрсәләрдән туеп беткән, өй ризыгын сагынып өлгергән студентлар өчен Гөлсем апа пешергән кайнар өчпочмаклар көтелмәгән бәйрәм иде, әлбәттә. Артык тартынып тормадык, билгеле. Табын вакытында, без икешәр-өчәр өчпочмакны «урган» чакта, берсен генә әкеренләп чеметкәләп утырган Нәкый ага элекке мәдрәсә хәлләре хакында сөйләде. Мәдрәсәдә торып укучы шәкертләрнең ничек яшәүләре, туенулары, үзара эш бүлешүләре, ничек нәүбәтләшеп кизү торулары, кемнәргә күбрәк эшләргә туры килүе хакында тәфсилләп сөйләгәннәре затлы табынны тагын да бизәп, мәгънәлерәк итеп җибәрде. Кичләрен шәкертләрнең шаярулары, үзенчәлекле күңел ачулары, бигрәк тә «мендәр сугышлары» җанлы манзара булып күз алдыннан уза тордылар. Табын янында тора башлауга Гөлсем апаның «яратып ашавыбыз өчен» безгә үзе беренче булып рәхмәтләр әйтүе истә калган.

Нәкый агага ярдәм итү мәсьәләсенә килгәндә, анысы хакында авыз тутырып әллә нәрсә әйтә алмыйм хәзер. Ярдәм дигәнебез гарәп хәрефләре белән кайчандыр ашык-пошык язылган мәкальле карточкаларны әвеш-тәвеш китерүдән әллә ни ерак китмәде шикелле. Чөнки Нәкый аганың кульязмасы авырлык белән укыла иде (студентлар, гадәттә, басма текстларны гына әйбәт укыйлар). Шуна күрә безнең ярдәм дигәнебез элек тә тематик яктан тулаем гына төркемләнгән карточкаларны сүтү, кычкырып укып, Нәкый агага аларны ваграк төркемнәргә аерыр өчен булышу, аннары санап чыгу ише механик эшләрдән ары узмады шикелле. Нәкый ага исә барыбер сер бирмәде, бәлки жыенып китәр чакта «зур эш эшләдегез, егетләр» дип рәхмәтләр укып калды. Аның каруы без шулай карточкалар актарып утырган чакта, Нәкый ага үзе университетта кайсыбызның нинди фәннәр, нindirәк конкрет темалар белән кызыксынуыбыз, гомумән, татар бүлеге студентларының нәрсәләргә игътибар итүләре, гыйльми хезмәтләрдән нәрсәләр укуы хакында сорашып, белеп утырды. Мәкальле карточкалардан бигрәк аны шушы мәсьәлә күбрәк кызыксындыра иде кебек.

Гомумән, бу һәм моннан соңгы әңгәмәләр вакытында Нәкый аганың үзенең дә Мәскәү-Ленинградларда, башка җирләрдә чыккан яңа хезмәтләр белән яхшы ук таныша барганлыгы сизелеп тора иде. Димәк, эзләнә, күп укый дигән сүз. Кайбер мөһим яңалыкларны да миңа аннан ишетергә туры килә иде. Мондый сыйфаты аның күпкә кадәр сакланды...

Хушлашу алдыннан мин үземдә дә күптән мәкальләр языла килгән бер калын дәфтәрнең барлыгын, әгәр мөмкин булса, аны күрсәтергә теләвемне әйттем. «Кайчаннар яза башлаган идең?»—дип кызыксынды Нәкый ага. Голжада чакта ук жыя башлавымны, соңра да дәвам итүемне, хәзерге язуга да күчереп куюымны әйткәч, ул тагын да җанланыбрак: «Бик кызык булыр иде, әйдә, китер. Еракларда яшәгән татарлардан булуы бигрәк тә әһәмиятле. Көтәм!»—диде. Алдан телефоннан шалтыратып хәбәр итәргә кушты.

Бу юлы үзем генә килгән идем. Мин китергән дәфтәрне шунда ук актарып та чыкты Нәкый ага. «Икенче томга кирәрлек әйберләр бар икән монда!»—дип куйды ул. Шунда ук кайбер мәкальләрнең башка телләрдән татарчалаштырылган булуын да билгеләде. Әйбәтләре бар икән, дип кабатлады. Чыннан да, «Татар халык мәкальләре»нең соңрак чыккан икенче, өченче томнарында «М.Госм.», ягъни «Студент Миркасыйм Госмановтан» дип, чыганак билгесе куелган житмештән артык әйтем-мәкаль урнаштырылган иде.

Дәфтәр хакында сүз беткәч, Нәкый ага төп мәсьәләгә күчте: «Әгәр вакытың мөмкинлек бирсә, укуыңа зарар килмәсә, әлбәттә, берничә буш көннәреңдә үзең генә килеп, бераз ярдәм итсәң, бик тә шат булыр идем. Синең элекке язуыбызны иркенрәк укуың мөһим минем өчен. Син укый торырсың, мин аларны тиешле төркемчәләренә куя барырмын»,—диде. Шатланып риза булдым, әлбәттә. Соңрак шунысы аңлашылды: Нәкый аганың күзләре элегрәк вак хәрефләр белән язылган текстларны начаррак күрә башлаган, мин исә үзенә күрә «җанлы күзлек» ролен башкарган икәнмен.

Шулай итеп, минем үземә студент елларында ук Нәкый агаларда тагын әллә

ничә мәртәбәләр булырга, кайчандыр язылып, аннары тулаем гына төркемләнеп, бәйләп-бәйләп куелган карточкаларның беркадәре өлешен укып чыгарга туры килде. Ике-өч сәгатьтән артык утырмый идек гадәттә. Шул рәвешчә ваграк төркемчәләргә бүленгән мәкальләргә Нәкый ага яңа исем биреп, тагын бәйләп, аларны бер читкәрәк куя бара иде.

Бер көнне бер бәйләм карточкаларның тыштагы беренче кәгазендәге «Әдәпсез мәкальләр» дигән сүзләренә игътибар иттем. «Болары, билгеле, кермәячәк, тик кызганыч»,—диде Нәкый ага һәм аларны бер читкә алып куйды. Мин дә елмаеп, үземнең дә узган җәйдә, Бараба якларында диалектологик экспедиция вакытында, бер карт әби авызыннан шактый әдәпсез мәкаль ишеткән булуымны әйттем. «Йә, ниндиен ишеттең соң?»—дип сорады әңгәмәдәшем. Минем икеләнебрәк торуымны күргәч, ул: «Тартынма, әйт, син чыгарган нәрсә түгел бит ул»,—диде. Мин беркадәре шомартырга тырышып, кайбер сүзләрен алыштырып: «Арт артка ябышты, артка бәла ябышты»,—дидем. «Туктале, моны мин дә ишеткән идем бит»,—дип, әлеге читкәрәк куелган бәйләмне яңадан алды, бавын чишеп актара ук башлады һәм бер карточканы миңа тоттырды. Анда нинди юл белән женси чир йоктыру хакында аты-җүне ачык әйтелгән нәкъ шул ук мәкаль иде. Бары хәбәрлек (фигыль) сүзләре генә «йәбеште» рәвешендә нечкәртеп язылган, язылу урыны дип нәкъ шул ук Бараба күрсәтелгән.

Ул мәлдә мине гаҗәпләндергән нәрсә ике кеше тарафыннан ике чорда әйтелгән мәкальнең үзара абсолют охшашлыгы булмады. Юк, мәкаль дигән хикмәтнең гаҗәп дәрәҗәдә тотрыклы икәнлеге, кайберләренең йөзәр, хәтта меңәр еллар узгач та үзгәрмәве хакында беркадәре хәбәрдар идем инде. Мине гаҗәпләндергәне—Нәкый аганың хәтер көче иде; ул 40нчы елларда ишеткән (Нәкый ага Бараба якларында, ялгышмасам, сугышка кадәр, «Идегәй» дастаны буенча материаллар җыеп йөргән) язып алган әлеге әһәмиятсез генә бер мәкальне һаман хәтерендә саклаганлыгы булды. Мәкальне ул материалларны төркемләгән чакта тагын искә төшергәндер, дип аңлатырга да мөмкин. Ләкин меңләгән-меңләгән мәкаль арасыннан берсен ачык хәтерләве очраклы күренеш түгел иде, әлбәттә.

Студент елларында Нәкый ага белән әңгәмәләшүләрдән туган икенче бер гаҗәпләнүем дә һаман истә. Гадәттә турыдан ярып сөйләшергә ярата торган Нәкый ага кайчакларын үзенең фикерен, хөкемен гаҗәп нечкә кинаяләр белән дә белдерә иде. Уку елларында безнең бүлектә һәвәскәр драмтүгәрәк актив эшләп килгән иде. Аның җитәкчесе Рәшидә апа Җиһаншина иде. Мин катнашкан беренче спектакль Нәкый ага язган «Муса Җәлил» драмасы булды. Баш рольне Рим Кәримев башкарды. Миңа исә Рәшидә апа «ватан хаины» Зәбихулла Альбиковның улы, германлы солдафон офицер кисәге Фердинанд-Фәриднең ролен тапшырган иде. Мин, әлбәттә, аны чын фашист кешесе итеп күрсәтергә тырыштым шикелле. Һәрхәлдә, спектаклебез Казанда да уйналды, аны Арчага барып та күрсәттек. Нәкый ага үзе дә караган икән безнең маташуларны. Бер очрашканда аның фикерен белергә теләдем. Ул иң элек әсәрне шулай аңлап, шул рәвешчә үтемле итеп башкаруыбыздан канәгать икәнлеген әйтте. Рим Кәримевтән өметле икәнлеген дә белдерде. Мин «башка рольләр ничегрәк» дип, үзем хакында да аның фикерен белергә теләгән идем. Башка «артистлар» хакында да беркадәре әйткәч, ул иң ахырдан: «Син дә әйбәт кенә уйнадың кебек. Тик Фердинандны артык беркатлы итеп күрсәтәсең. Ул авыр роль, әлбәттә. Минемчә, сиңа үзеңнең мең-миңлегең башка кеше образына керергә комачаулый шикелле. Бәлки, мондый сыйфат фән өчен кулайрактыр»,—дип йомгаклап куйды. Кыскасы, синдә артист-мазар сәләте юк, дигән кырыс хөкем шулай җайлап кына әйтелгән иде.

Әле генә Нәкый аганың хәтере бик әйбәт булуга бер мисал китергән идем. Әйе, Нәкый ага белән беркадәре аралашу, әңгәмәләшү сәгатьләрендә дә миңа аның гыйбрәтле, кызыклы истәлекләрен дә шактый мул ишетергә насыйп булган иде. Ул аларны тәмләп, вак детальләренә кадәр тасвирлап сөйләргә ярата иде. Шулардан берничәсен монда искә төшерсәм, артык булмастыр дип уйлыйм. Тик ул тасвирлаган «детальләрнең» барсы да минем хәтердә сакланмаска мөмкин.

«Сугыш елларында без язучылар, гадәттә,—дип башлаган иде ул бер көнне

чираттагы истәлеген,—якынрак районнардагы берәр авылга барып, халык белән очрашулар оештырып, чыгышлар ясап кайтырга тырыша идек. Рәсми бурычыбыз патриотик шигырьләр укып, халыкның рухын күтәрү булса, үзебезнең чын максатыбыз исә колхоз тарафыннан гонорар рәвешендә бирелә торган өч-дүрт кадак бәрәңге була иде. Чыгышларыбыз, табигый, ярлы киенгән хатын-калач, бала-чага, карт-корылар, аксак-чулаклар белән тулы клубларда уза. Җимерелеп бетә язган клублары ни тора!

Казанга шактый якын бер авылда әллә ничә кат кабатланган чыгышлар һаман онытылмый. Андагы колхоз персидәтеле, зур бәдәнле, олы яшьтәге бер карт агай, гадәттә алгы рәттә утырган булыр. Ул ишарә бирмәсә, әллә нәрсә укысаң да, клуб тып-тын кала бирер. Әгәр ул аякка басып, халыкка карап кул чаба башласа, бөтен зал гөр килеп, безне алкышларга тотыныр. Тегең туктауга зал да шып итеп тынып калыр... Шулай, гаҗәп дәрәҗәдә буйсынучан, хәтта кирәгеннән артык күндәм кешеләрдән тора бит безнең халык. Ярар, алкышлары шулай түрә командасы белән оештырыла иде ди. Безнең өчен иң мөһиме башка персидәтелләргә караганда әлеге агайның гонорарны ике-өч кадакка артыграк бирүе иде...

Хәзер уйлап карасам, үзебез дә әлеге күндәм халыктан әллә ни аерылмаган икәнбез... Кешене «ризык кыймылдатыр», дигән бит бер шагыйребез. Акмулла бугай...»

(Үзем шушы истәлекне искә төшереп язып утырам, үзем хәзерге заман татар авылларындагы сайлауларның түп-түгәрәк дип әйтерлек гел унай нәтиҗәләре хакында уйлыйм. Русиядә, Советлар Союзында озак еллар система рәвешендә хөкем сөргән авыр тормыш, ачлык халыкны шулай күндәм көтүгә әверелдергән икән. Хәтта язучылары кебек зыялыларын да...)

Икенче бер истәлеге дә шулай язучыларның авылларга барып бәрәңге белән «гонорар» эшләп йөрүләре хакында иде. «Андый гастрольләргә,—дип башлады Нәкый ага,—без, гадәттә ике-өч язучы берләшеп, үзенә күрә кечкенә генә бригада оештырып барырга тиеш идек. Бер-беребезгә контроль булу өчен шулай кирәк булгандыр ул, күрәсең. Мин үзем андый сәфәрләргә Әхмәт Фәйз белән бергә чыгарга тырыша идем. Киң белемле, яхшы күңелле чын зыялы, безнең чорда әйтмешли, гаҗәеп хушсөхбәт, сүзгә тапкыр кеше иде мәрхүм Әхмәт Фәйз. (Нәкый ага үзе еш кына яратып телгән ала торган әдипнең фамилиясен Фәйзи димичә, шулай «кырт кисеп», кыскартып әйтергә ярата иде.)

Балык Бистәсендәге бер авылдагы очрашудан соң кичке якта Казанга кайтырга дип, җәяүләп кенә пристань ягына юнәлдек. Әллә ничә чакрым барасы. Көзге пыскак янгыр сибәли. Тәмам чыланып беттек. Кулыбыздагы дүрт-биш кадак бәрәңге салынган чүпрәк капчыкларыбыз да авырайган. (Әңгәмәнең нәкъ шул төшендә мин: «Машинада яки арбада озатмадыларммы соң?»—дип кызыксынган идем. «Һи,—диде ул гаҗәпләнгән төсле,—китерү, илтеп кую түгел, халыкны җыеп, клубка кертсәләр дә, түбәбез күккә тия иде...»)

Шулай, тәмам чыланган килеш балчык ерып барабыз. Ниһаять, пристань дә күренә башлады. Анысы да чалышаеп, кыйшаеп беткән, буяу-фәләннән бернәрсә дә калмаган дебаркадер булмыш бер такта алачык кына. Борылып карасам, Әхмәт Фәйз дә, эшләпәсе тәмам сәлперәеп беткән, үзе дә бөрешеп калган төсле күренде. Тагын әлеге дебаркадерга карагач, үзебезнең кыяфәтебез дә шуңар охшаган төсле булып тоелды. «Карәле, Әхмәт,—дидем,—теге дебаркадер хакында бер шигырь әйт әле!» Әхмәт Фәйз, сәлперәеп мангаена төшкән эшләпәсен чак кына күтәреп куйды да, калын пыялалы күзлеген төзәткәләп, дебаркадерга беркадәре карап торды, аннары кулын алга сузып, әллә нindирәк тавыш белән кыска гына әйтеп тә куйды:

Әй, дебаркадер!

Бетте нибар кадер...

Шулай, тапкыр сүзле кеше иде мәрхүм Әхмәт Фәйз...»

Нәкый ага соңрак бу истәлеген үзенең юбилеенә багышланып, Галиәсгар Камал исемендәге театрның элекке бинасында уздырылган тантаналы кичәнең истәлекләр өлешендә дә кабатлаган иде.

Әңгәмәләр вакытында Нәкый ага үзен борчыган, борчый торган мәсьәләләргә дә

кагыла иде. Шундый темаларның берсе тарихыбызны Русия тарихындагы әһәмиятсез бер кушымтага әверелдереп, аны өстән-өстән генә яктыртуга карата ризасызлыктан гыйбарәт иде. Ана бигрәк тә безнең тормыштагы һәрбер унай күренешне, яналыкны гел читләрдән килгән тәэсир итеп аңлатырга тырышу, шул эштә үзара ярыша-ярыша маташу ошамый, хәтта аның ачуын да китерә иде. «Ә урыс тәэсирендә күпме унай, затлы сыйфатларыбыз, яхшы гадәтләребез онытылды?.. Моның хакта ник бер сүз әйтмиләр?!»—дип гарьләнә иде. Татар-монгол, татар-монгол дип чәйнәп, безне килмешәк итеп күрсәтергә тырышалар. Юк, без 1552 елда урыслар килгәнче дә шушында әллә ничә гасыр ике-өч дәүләт корып яшәгән, эшләп, тир түгеп, үз-үзебезне туендырган, хәтта ачлык елларында урысларга да ярдәм итеп гомер кичергән мөстәкыйль тарихлы халык! Менә шул зур тарихны белергә, дөрес белдерергә тиешбез. Юкса төчкерү белән йөткерүгә дә соң гына өйрәнгән булып чыгабыз. Аң-белем, мәктәп-мәгариф, китапчылык турында әйтеп тә торасы юк. Шулкадәр боздык, пычраттык үз тарихыбызны...»

Чак кына соңрак Тукай клубында барган бер җыелышта Нәкый ага әлеге фикерләрне тагын да җыйнаграк, образлырак һәм усалрак итеп янгыраткан иде: «Әгәр дә Русия, руслар дигән бер тарихи арба булса, татарлар шул арбага тагылган дегет чиләге сыман сурәтләнә!»

Аның иң өнәмәгән, хәтта куралмаган нәрсәсе ул кайбер татар галимнәренең үз халкына түбәнсетеп каравы, «аң һәм канга сеңеп өлгергән мескенлек, мокытлык» иде. Минем мондый күренешнең тыштан ясалган тәэсир нәтиҗәсе икәнлеге хакындагы репликамны ул шунда ук кире какты: «Нәрсәгә аларга сылтау? Синең үз башың, үз акылың кайда? Юк, егетем, яхшылыкны гына түгел, яманлыкны да башкаларга сылтама. Үзеңчә уйла, үзеңчә фикер йөрт. Ә урыска ышансаң, ул гел үзенчә генә эшли. Әнә, алман-герман дигән төгәл бер халыкның телен юкка исәпләп, немой—немец, дип, тулаем телсезгә чыгарды, ана шул оятсыз кушаматны исем итеп такты... Урыс үзеннән башка бер халыкны да санга сукмый ул...»

Тел дигәннән Нәкый ага ана телебезнең язмышы, аның һаман зәгыйфьләнә баруы өчен борчыла, үзенчә әйткәндә, кайбер «гыйлем кисәкләренең» шул процессны «унай күренеш, үсү» дип бәяләүләре өчен гарьләнә иде. Мәсәлән, шул алтмышынчы елларда әле генә дәрәҗә алган бер фәннәр докторының киләчәктә дә татар теленнән гарәп-фарсы сүзләрен чыгарып ташларга кирәк, әйтик «исраф» урынына «әрәм-шәрәм» сүзен генә кулланырга, гомумән урамда сөйләшкәнебез кебек язарга тиешбез, дип бер-бер артлы мәкаләләр бастыруыннан, хәтта Тукай клубында шул рухта доклад укып шау-шулар куптаруыннан шомланган иде. «Димәк, аңар обкомнан шулай кушылган; димәк, бу—махсус сәясәт, партия-дәүләт сәясәте дигән сүз, хәтәр процесс башлануга ишарә бу!..»—дип, мәсьәләнең тамырларын күреп, уйга батып утырган иде. Чыннан да тиздән Тукай клубында өлкә комитеты секретаре Фикрәт Табеевның: «Тагын егерме елдан соң сезнең татар телегезнең кирәге калмаячак. Ә ни өчен сез һәммәбезгә кирәкле рус теле хакында уйланмыйсыз?!»—кебегрәк сүзләрен ишетергә туры килгән һәм әлеге авторның шул түрә тирәсендә еш бөтерелгәләве хакында мәгълүм булган иде. (Дөрес, әдәби тел мәсьәләсендә кызыл вульгарлыкка бирелгән әлеге авторның соңрак, СССР таркалгач, беренчеләрдән булып «төрекчә латинчыга» әверелүен, елына өч-дүрт мәртәбә Төркия юлларын таптап, бөтенләй башка рухтагы мәкаләләр сиптерүен Нәкый агага күрү, белү, уку туры килмәде, әлбәттә.)

Шул ук вакытта Нәкый ага, татар филологиясендәге кимчелекләрне күрү, белү, алар өчен борчылу өстенә, безнең кайбер казанышлар өчен сөенә дә иде. Мәсәлән, татар диалектларын, аерата Себер, мишәр тел элементларын җыю, туплау эшләрен бөтен тюркологиядәге мөһим хезмәтләр дип бәяләп: «Безнең диалектология алдан бара!»—дип горурлана иде.

Аспирантурада укып йөргән чорда 20-30нчы елларда хөкем сөргән репрессияләр, шул чактагы кешеләрнең бер-берсенә яла ягуларының киң колач җәюе хакында ишеткәләргә туры килгәли иде. Бер көнне, Нәкый ага белән әңгәмәләшеп утырган чакта, кешеләрнең шулай «бер-берсен ашау» фактлары турында сүз чыкты. Мин үземнең гаҗәпләнүемне белдердем. «Нигә гаҗәпләнергә?!—диде Нәкый ага үзе

гаҗәпләнебрәк һәм чак кына туктап торгач, әкрен генә өстәде.—Хәер, син ул елларда хөкем сөргән шартларны бөтенләй белмисең шул. Хәтта аларны күз алдына да китерә алмыйсыңдыр, шуңа күрә дә гаҗәпләнәсең»,—диде. Аннары, бераз уйланып алгач, сүзләрен ашыкмыйча гына дәвам итте:

—Шартлар исә ил җитәкчеләре, хөкүмәт тарафыннан махсус тудырылган, ягъни оештырылган, даими хуплап, бөтен ил буенча үстерелгән иде. Һәркайдан, һәр җирдән, һәр кешедән гел дошман эзләү көндәлек гадәткә, шөгыльгә әверелә язган, кешеләрдә бер-берсенә ышанмаучанлык хөкем сөргән иде. Хакимияткә килүче яңа көчләр, властька омтылучылар моннан оста файдаландылар. Бигрәк тә түбәннән күтәрелгән әтрәк-әләм, юксыллар, яки юксыллык битлеген киеп югары үрмәләүчеләр. Игътибар иткәнсеңдер, купчелек язучыларның тәрҗемәи хәлләрендә гел «ярлы крестьян гаиләсендә туган» дип күрсәтелә. Мондый мәгълүматларның яртысыннан артыгы ялган. Бу—элекке укымышлырак, хәллерәк кешеләрнең җәмгыятьтән кысрыклап чыгарылу нәтиҗәсе. Өстәвенә затлы кешеләр «аклар» буларак җиңелгән, сөрелгән яки бөтенләй илдән качып киткән... Кыскасы, эш башына гел надан ярлы-ябагай, кызыл авыз әтрәк-әләм менгән яки үрмәләгән чор. Шуңа күрә бер-берсе өстенә яла ягу, донос язу, шул рәвешчә урын-дәрәҗә яулау киң таралган күренеш булды. Бала ата өстеннән, хатын иренә каршы донос язу фактлары да булгалады инде. Бүген берәү шундый әләкләү белән өскә менсә, иртәгә аның үзенең өстеннән дә донослар язылды. Әлбәттә, һәрберсе үзен «социализм», «чын гаделлек» өчен көрәшүче итеп күрсәтергә омтылды. Шул рәвешчә халыкны, кешеләрне үзара бүлгәләү барлыкка килде. Ә бүлгәләү, үзең дә беләсең инде, хакимлек итүнең, идарә кылуның төп чарасы, сыналган ысулы.

Ул елларда бер-берсеннән дошман эзләмәгән, иң киме башкаларга шикләнмичә караган кешеләр аз булгандыр, мөгаен. Кайберәүләрнең үз башларын саклау өчен, үзен эзәрлекләүчеләр өстеннән язган булуы да ихтимал,башка чараң калмагач... Һәрхәлдә, бер сүз белән әйткәндә, тулаем, гомуми психоз хөкем сөргән шомлы замана иде. Мондый шартларда бик сирәк кешеләр генә башкаларга шикләнеп карамыйча пакь вөҗдан белән кала алгандыр. Гомумән алданучылар, коткыга бирелүчеләр күбрәк булгандыр...» Нәкъ шул төштә хикәяче кинәт туктап калды. Икеләнеп әйтер сүзен таба алмыйча утыргандай итте. Мин кинәт туктауны яхшы хәтерлим, сонрак та аны искә төшергәләдем, сәбәпләрен дә аңлаган шикелле булдым. Хәер, бу хакта икенче бер урында сүз булыр әле...

—Аннары,—дип ул, бер карарга килгән сыман икенчерәк тон белән сөйләвен дәвам итте.—Аннары мин үзем дә күп гыйбрәтләр күрдем. Кайбер доносларның өстән кушылу буенча, ягъни басым астында мәҗбүри язылган булу ихтималын да онытмыйк. Моны да онытмаска кирәк. Шундый басымга җүнле кешеләр дә дучар була иде. Моның трагикомик мисаллары да булгалады... Сиңа шуны күрсәтә торган бер вакыйганы сөйлим әле. Игътибар белән тыңла.

Билгеле булганча, заманында мине «җидегәнчеләр» дигән әллә нинди бер серле, уйдырма оешма әгъзасе булуда гаепләп, шактый эзәрлекләп каныма тоз салган, бер ара утыртып та куйганнар иде. Анысы белән әллә ни барып чыкмагач, «сәхнәгә» башка «куркынычрак букиләр» чыгарылды. Миңа бәйләнүләр гел туктамады. Сәбәбе бик гади, рухани кеше улы булуым, революциягә кадәр Уфада «Хәсәния», Казанда «Мөхәммәдия» кебек мәдрәсәләрдә укуым, Шәехзадә Бабичлар белән аралашып, милли рухта шигырьләр язган булуым һ.б. Кыскасы, минем «иярчен», ягъни «ят элемент булуым» сәбәп иде. Шулай йөргән чакта миңа беркөнне якынрак егетләрдән берсе тиз араларда язучылар оешмасында махсус җыелышта миңа зур гаепләр тагарга уйлаулары хакында ишеттерде. Әллә җәлләп, әллә сөенеп әйтте ул—аңламассың. Җыелышларда «фаш ителгән» кешеләрне шунда ук кулга алулар ул елларда еш була торган күренеш иде...

Болай да һәркөнне диярлек, төнлә килеп алып китә калсалар дип, чистарак эчке күлмәк-ыштан киеп ятарга, иң кирәкле әйберләрне дә бер капчыкка салып түшәк янына куярга гадәтләнгән заманнар иде бит. Шуңа күрә чакыру алгач, арурак эчке киемнәремне киеп, Гөлсем ханым тоттырган капчыкны да алып бардым әлеге җыелышка. Күрсәтүләре буенча алгы рәтләрнең берсенә барып утырдым.

Ул вакытта түрәрәк булып йөргән Мирсәй Әмир жыелышка рәислек итеп, президиумда утыра иде. Сүзне ул, үгезне мөгезеннән тотып дигәндәй, турыдан башлады. «Күпме халык дошманнары арадан чыгарылган, төрмәләргә ябылган булса да, әле дә сафларыбыз бөтенләй чистарып бетмәгән, дошманнарның кайберләре әле дә арабызда йөри»,—дип башлады ул сүзен. «Димәк,—дип уйлап алдым,—мине кулга алу буенча күрсәтмә бирелгән икән...»

Әмма нәкъ шул вакытта президиум утыра торган кечкенә сәхнәнең арткы ишеген каерып ачып, ике хәрби килеп керде. Минем исемне әйтеп өлгермәгән жыелыш рәисе, кирәкле кешеләр килеп тә житкән икән дип уйлаган төсле: «Әле генә ул кеше залда утыра дигән идем...»—дип кабатлауга, хәрбиләрнең берсе: «Кто здесь Мирсай Амир?»—дип кычкырып сорады. Рәис кеше «Я—Мирсай Амир» дип әйтүгә ике хәрби аны ике яктан култыклап, алып та китте...

Жыелыш шуның белән таралды, билгеле.

Шулай итеп, ул көнне миңа өйгә кайтып, үз түшәгемдә йокларга насыйп булган икән. Күрәсең, икенче берәүнең саллырак доносы көчле әмер-фәрманга әверелеп, элегрәк урта кул түрәдән минем хакта бирелгән күрсәтмәдән уздырып ук жибәргән.

Шуннан соң төрмәдә утырып чыккан бичара Мирсәй юашланып, үтә дә сакчыл, хәтта куркаграк кеше булып калды. Гажәеп жор телле, чын юморист Мирсәйнең элекке кыюлыгы, тапкырлыгы шактый кайтышланган иде. Дәлил кирәк булса, әнә «Агыйдел» повестының беренче басмасы белән «партия кушуы буенча төзәтелгән» икенче басманы чагыштырып кара...

Менә шулай, егетем, ул елларда вәзгыять минут саен үзгәреп тора иде. 20-30 еллардагы репрессияләр чорында дошманнарны фаш итү буенча иң тырышкан кешеләрнең барсы да диярлек башкалар өчен казыган чокырларына үзләре үк мәтәлеп төшкән иде. Шуна күрә ул вакытлардагы кеше өстеннән язуларга, доносларга артык исең китмәсен синең. Ихлас ышанып адашучылар да булгандыр, билгеле. Аздыруларга, демагогия дигән шайтан коткысына тиз иярәбез шул, кызганычка каршы... Әнә Галимжан Ибраһимовны гына ал. Революциягә кадәр бер кеше иде, аннары бөтенләй үзгәрде, кызарды. Шактый кешенең башына житте, Кырымда яткан килеш... Дөрес, ара-тирә үзе булып калырга, иманы кушканча сөйләргә дә тырышты шикелле. Әйтик, яңалиф хакында, татар мәдәниятенең киләчәге турында. Тик хәзер аның кызыллыгын гына мактап язалар. Хәер, монда да үзгәрүләр булыр әле. Без капчыкта ятмый ул, тишеп чыгачак.

Әл-хасыйль, безнең баштан кичкән ул хәлләрне аерым кешеләрнең генә жүнсезлеге дип түгел, ә куркыныч эпидемия, үләт китерә торган бәла-каза, кешеләрне тулаем кыра торган үтә дә йогышлы ваба яки тагун үләте кебегрәк кабул итәргә кирәктер. Мин үзем хәзер, Хрущев докладыннан соң, ул кабәхәт шартлар хакында шулайрак аңлый башладым. Хәер, элек тә күңел сизә иде. Элегрәк ул кешелексез систем хакында күп нәрсәләрне аңлап бетерми дә идек шулай да.» (Нәкый ага «система» сүзен һәрвакытта кыскартып, татарчага яраклаштырып әйтә иде.)

Сәер һәм гыйбрәтле вакыйганы шулай тәфсилләп тасвирлаган Нәкый ага үз хикәясенең ахырында берничә кат миңа төби төшеп, игътибар иттереп йомгаклап та куйды:

—Син хәзер аспирант инде. Киләчәктә, бәлкем, галим дә булып житлегерсең, ихтимал, халкыбызның тарихын язуга да катнашырсың. Әгәр егерменче-утызынчы еллар турында язарга туры килсә, шул коточкыч чорда яшәгән, нидер эшләгән, көрәшкән, жәфаланган, корбан булган кешеләрдән берәүләрен генә мактап, икенчеләрен яманлап, сүгеп язудан саграк булырга тырышырсың. Гаеп аерым кешеләрдә түгел, бәлки шундый шартларны, психозны тудырган сәяси системда, бәлшәвиклар партисе уздырган кабәхәт, әйе, кабатлап әйтәм, чын-чынлап кабәхәт, кешелексез сәясәттә иде. Ниһаять, егетем, тагын бер мөһим сәбәпне дә онытма: адәм баласы дигән жан иясенең табигатенә көнчелек, хөсетлек, башкалар өстеннән хужа булырга омтылу, карьеризм дигән начар сыйфатларның хас булуын һәрвакыт исеңдә тотарга тырыш. Тасвирлана торган елларда андый әшәке сыйфатлар бездә гөрләп чәчәк аткан иде...

Хәер, хәзер дә әллә ни ерак кителмәгән...

Моннан соң Нәкый ага чак кына сүзсез утырды, аннары әкерен генә өстәп куйды: «Мин сөйләгәннәрне үзең генә хәтерләп ал. Белеп торуыңның файдасы булыр. Киләчәктә барлык серләр ачылыр—тәмам яланбот килеш калырбыз әле. Ә хәзергә сак бул, шымчылар, доносчылар һаман да адым саен...»

Нәкый ага шулай тәфсилләп сөйләгән хикәянең күпме өлеше документаль төгәллеккә ия, кай төшләре әдәбичә бәян ителгән булуы турында мин бүген дә кистереп бернәрсә әйтә алмыйм, билгеле. Чөнки гыйбрәтле, шул ук вакытта гаҗәеп рәвештә кискен борылышлардан торган вакыйгадан шаклар каткан, тетрәнгән, бигрәк тә бөтен СССР иле, большевизм адресына әйтелгән бәяләмәдән, кырыс хөкемнән беркадәре аптырап, мингерәп тә калган, дөресен әйтсәм, шактый каушап, хәтта шүрләп тә калган идем мин әлеге мәлдә.

Әңгәмәнең 60нчы елларда барганлыгын, ул вакытта исә узганны тәнкыйтьләү бер Сталин исеме тирәсендә генә таптанудан ары узмаган, мәгәр Ленин тәгълиматының, ул нигезләгән большевиклар партиясе гамәлләренең тулаем дөреслегенә һаман ышанган, ышандырыла килгән вакытлар икәнлеген искә төшерсәк, әлеге мәлдәге мин кичергән аптыраулы халәтне аңлавы әллә ни артык кыен булмастыр дип уйлыйм. Дөрес, иллә хөкем сөргән тәртипләргә карата белдерелгән, мәгәр шыпыртак рәвештә әйтелә торган тәнкыйть сүзләрен моңарчы да ишеткәләгән бар иде. Әмма без ул вакытта Нәкый ага китергән дәлилләрне, фактларны, ул яңгыраткан үтергеч хөкемнәрне, бигрәк тә «кабәхәт» кебек аерым эпитетларын белмәгән, ишетмәгән идек әле. Бары 80нче елларның икенче яртысыннан алып аларны төгәлрәк, әтрафлырак итеп ишетә, үзләштерә башладык.

Әңгәмә вакытындагы тетрәнүемнең икенче бер сәбәбе дә бар иде. Ул аның дәүләт-партия «системы» хакындагы кырыс фикерләрен «антисоветчылык» дәрәҗәсендә итеп миңа ачыктан-ачык әйтүе, сүзләрен шулай ышанып тапшыруы иде. Әллә ни якыннан кардәше булмаган бер ят егеткә чишелүе... Батырлыкның да чиге була бит. Әмма болай ук турыдан-туры ярып әйтү... (Димәк, дип, соңрак борныма киртеп куйдым: ышанычны акларга да кирәк икән! Шуңа күрә мин әлеге фикерләр, усал сүзләр һәм гомумән Нәкый ага белән булган әңгәмәләр хакында бүгенгә кадәр, менә шушы истәлекне язганчы, кемгә булса да авыз ачып бер сүз дә сөйләмәдем...)

Шулай итеп, ул мизгелдә мин әңгәмә буенча хикәячегә бер сорау да бирмичә калдым. Хәтта Мирсәй Әмир белән ничегрәк аңлашулары, хәзерге үзара мөнәсәбәтләре хакында да җыйнап бернәрсә белә алмадым. Күрәсең, моның кирәге дә шуның кадәр булгандыр ул чакта.

Бераз соңрак икенче бер авызлардан Мирсәй Әмирнең ни өчен кулга алынуы хакында икенчерәк, тагын да гыйбрәтлерәк версияне дә ишетергә туры килгән иде. Имештер, «Чаян» журналының бер рәссамына Мирсәй Әмир сатирик сурәт өчен тема биргән икән. Рәссам әсәре басылып та чыккан, анда трамвай астында калып аякларын өздергән берәү: «Әйбәт булды әле, Казанда барыбер галушлар табып булмый иде»,—дип сөенеп утыручы кыяфәтендә сурәтләнгән, имеш. Моны зур түрәләр, имеш, «совет сәүдәсенә яла ягу» дип кабул иткән икән... 30нчы еллардагы репрессияләр тарихын, аларның әдәбиятыбызга китергән зарарларын җентекләп өйрәнгән Рафаэль Мостафин сүзләренә карагада, беркадәре нигезе булган, дөресрәге, 20нче еллардагы бер вакыйгага бәйлерәк әлеге имеш-мимешләрнең югарыда тасвирланган кулга алуга бернинди катнашы юк икән. Мин исә әлеге имеш-мимешне, Нәкый ага хикәясенә өстәмә рәвештә, 1960-1970 елларда тагын нинди риваятьләр йөрүгә бер мисал булсын дип теркәп куюны кирәк таптым. Чөнки архивлар ачылмаган чорда андый тартып-сузуларның да таралуы табигый...

Нәкый аганың әлеге җыелыш хакындагы гыйбрәтле вакыйганы тәфсилләп сөйләве, хикәясенең ахырында кинәшләр бирүе, кисәтүләр ясавы гадәти генә эч бушату булмаган, күрәсең. Аның мин язып бастырган эреле-ваклы мәкаләләрне күзәтеп, кайберләрен җентекләп укый барганлыгын белә идем. Олы мәгърифәтчеләребезгә багышланганнарын ул хуплаган да иде. Бер көнне тарихи дөреслек, фәнни төгәллек хакында сүз кузгатып ул болай дигән иде: «Документларны нәкъ үзенчә файдаланырга кирәк. Мәрҗани шулай эшләгән. Ә Риза казый исә үз

өслүбенә яраклаштырып, үзгәртеп күчергән. Минемчә, болай эшләү дөрес түгел». Шулай ук ул минем диссертация белән дә кызыксынып, кинәшләрен дә биргәләгән иде. Хәтта аны яклау утырышына да килеп, фикер алышулар вакытында татарчалап чыгыш та ясаган иде. Үзенең темперамент белән башкарылган чыгышында ул, минем гыйльми эшчәнлегемне мактап дигәндәй, диссертациямдә чыгарылган кырысрак хөкемнәрнең дөреслеген яклаган иде. Шулай ук диссертантның «үз стиле булуын» махсус билгеләве дә истә калган. Дөрес, гел урыс телендә генә бара торган гыйльми советта татарча янгыраган әлеге чыгыш кайберәүләргә ошап та бетмәде шикелле: гел милләтчелектә гаепләнеп килгән кешенең татарча чыгышы ВАКта шик тудырырга мөмкин, дип, мине өркетүчеләр дә булгалады. Кызганыч ки, Нәкый ага чыгышын язып алу ул вакытта башыма килмәгән. Ә урысча төзелә торган беркетмәдә, билгеле инде, чыгышның фикерләре гомум сүзләр белән генә теркәлгән була...

Дөрес, Нәкый аганың диссертация яклау утырышына килүенең икенче бер, бәлки, мөһимрәк сәбәбе дә булган икән. Үзенә авторефератымны илтеп биргән чакта ул, беренче оппонентның Мәскәүдән киләчәк Әмир Нәҗип икәнлеген күргәч, яклауда һичшиксез булачагын, аның белән очрашып Алтын Урда чоры әдәби истәлекләре турында сөйләшеп алырга теләге барлыгын әйткән иде. Шунда Нәкый агадан үзем өчен тагын бер яңалык белдем: «Казан утлары» журналында Әмир Нәҗипнең Алтын Урда чорына караган язма истәлекләргә багышланган мәкаләләрен бастырганы өчен баш редактор Гази Кәшшафны эшеннән алып ташлаганнар икән.

Утырыш башланганчы ук ихлас сөенеп күрешкән аксакаллар яклау беткәч тә бераз сөйләшеп алдылар. Икенче көнне безнең өйдә—университетның ишек алдындагы кечкенә бүлмәбездә дә очрашып, табын янында озак кына әңгәмәләшкәннәр иде. Сүзләр нигездә элекке чорларга, бигрәк тә Алтын Урдага, Казан ханлыгы дәверләренә караган истәлекләр тирәсендә барды. Аннары шул ук көнне Әмир ага туктаган, Бауман урамындагы элекке «Казан» кунакханәсенә барып, икәү генә калып серләшкәннәр иде. Үзләрен шунда озатып куйгач, аларның аулак калырга теләүләрен сизгәнгә, хушлашкан идем. Тик кичен, Әмир ага янына аны озатырга дип килгәч, ул Нәкый аганың свитеры онытылып калганлыгын әйтеп, аны миңа тапшырган иде.

Миңа тамашачы сыйфатында Нәкый аганың өч юбилеен күрү бәхете насыйп булды.

Алтмыш яшьлек бәйрәменә багышланган тантаналы кичә Казан университетының тарихи актлар залында шыгрым тулы халык белән уздырылган иде. Тантананың университетта башлануы «Татар халык мәкальләре»нең I томы чыгуы белән бәйле булса кирәк, чөнки әлеге хезмәт ул вакытта чын гыйльми казаныш сыйфатында кабул ителгән иде.

Зур гыйлем иясе булган әдипнең иҗаты, бигрәк тә халык иҗатына багышланган хезмәтләре хакындагы докладны тарих-филология факультетының аксакал мөгаллимнәреннән доцент Якуб ага Агишев ясады. Юбилярның шигырьләрен укудан, җырларын тыңлаудан, драматик әсәрләреннән кайбер өзекләр күрсәтелүдән соң безнең өчен—залдагы күпчелекне тәшкил иткән студент халкы өчен—юбилярның үз чыгышы гаять кызыклы, гыйбрәтле булып тоелды. Башта ул кеше гомеренең төрле чорларын көлкелерәк итеп тасвирлады. Дүрт аяклап мүкәләүдән башлаган адәм баласының ике аякка баскач бик озак йөгереп йөрүе, аннары «өч аякка» күчәргә (таякка таянырга), бик картайса, тагын дүрт аяклап кына хәрәкәт итәргә мәҗбүр булуы ихтимал икән. Алай гына түгел; гүзәл, сөйкемле, матур җан иясенең—яшь баланың гомер узып картайгач, бит-кыяфәте җыерылып маймылга да охшап калуы да табигый икән. Бу хакта бер көлкеле хикәят тә китерде...

Менә шулай үзгәрә-үзгәрә яши торган кеше үз гомеренең, вакыт дигән олы хикмәтнең кадерен белә микән? «Мине,—диде юбиляр—докладчы озак яшәгән, күп эшләгән, күп хезмәтләр тудырган кеше итеп сурәтләде. Әйе, бер карауга ярыйсы гына озак яшәлгән. Ләкин гомернең күпме өлеше мактап телгә алырлык файдалы эшкә бирелгән икән? Әйтик, алтмышны тутырган кеше гомеренең өчтән бере балалык һәм әллә ни кырмый, кыра алмый торган яшьлек чорына туры килә. Тагын өчтән берсе йокыга бирелә. Калган егерме ел чамасы гомернең күпмесе

ашап-эчүгә, төрлечә ял итүгә, юк-бар бәйрәмнәргә, кирәкмәгән ләчтит сатуларга, эшкә барып-кайтуларга, мәгънәсез талашып, ызгышып йөрүләргә, төрле буш җыелышларга китә дисез?.. Чамалап кына исәпләп караган идем, гомеремнең нибары дүрт-биш елы гына мәгънәле, ил-халык өчен файдалы, кирәкле әдәби, гыйльми эшкә багышланган булып чыга икән. Әгәр һәр сәгать белән һәр минутны кадерләп эшләсәң? Сез, студентлар, мәсьәләнең шушы ягын да гел уйласагыз иде, дип сөйләдем боларны...»

Нәкый аганың мин шаһит булган беренче юбилей кичәсе шул рәвештәрәк хәтергә сеңеп калган.

Әдипнең юбилеена багышланган тантаналы кичәсе халык белән шыгрым тулы Академик театрның элекке бинасында (хәзерге Кәрим Тинчурин театры) уздырылган иде. Андагы юбилярның йомгаклау чыгышының минем истә уелып калган өлеше әдипнең бакыйлыкка күчкән замандашларына бәйле истәлекләреннән гыйбарәт иде. Аларның да иң күнеллесе, аерата бер җылылык, төрле бизәкләр белән тасвирланганы, Нәкый ага гел сагынып искә ала торган Әхмәт Фәйзинең экспромтына багышланганы булды. Әчтәлеген электән үк белгән булсам да, аны ул кичәдә өр-яңа хикәят ишеткән төсле ләззәтләнеп тыңлап утырдым. Әйе, ул үз каләмдәшләре арасында Әхмәт Фәйзине аеруча ярата иде. Бер мәлне аның хакта сүз чыккач, Нәкый аганың: «Заманының, яшәгән чорының гаҗәп дәрәҗәдә кысынкылыгы, әшәкелеге аркасында таланты чын-чынлап ачылмыйча калган иде мәрхүмнең»,—дип күрсенгәнен хәтерлим.

Әгәр университетта уздырылган чара чикләнгәнрәк рәвештә билгеләнгән булса, театрда ул киң пландарак, ягъни шагыйрь, драматург, фольклор белгече галим—гомумән, киң колачлы әдипнең бәйрәме итеп, зур әзерлек белән оештырылган иде.

Житмеш еллыкны каршылауга мин үзем дә, кечтеки генә булса да, бер өлеш керткән идем шикелле. Мәкальләрнең томнары басылып чыккач, аларның тарихи информация чыганагы буларак әһәмияте дигән кебегрәк тема буенча бер мәкалә кисәген «Казан утлары»нда бастырып чыгарган, шул юнәлештә эшләр өчен мәйданның киңәюен расларга тырышкан идем. Моннан тыш, «Яшь ленинчы» газитендә, аның сәркәтибе Ренат Харисның тәкъдиме буенча, башта Нәкый ага белән бер әңгәмә дә оештырган идем. Шул әңгәмәнең бер мизгеле истә уелып калган. Юбилярдан: «Иң бәхетле, гел сагындыра торган чагыгыз дип кайсы чорны атар идегез?»—дип сораган идем. Нәкый ага ике дә уйлап тормастан: «Балалык чагым, билгеле!»—дип кистереп әйткән иде. Бу җавапка карата мин гаҗәпләнү сыманрак кыяфәт күрсәттем шикелле, анысын хәзер төгәл хәтерләмим. Ләкин Нәкый аганың миңа төбәп: «Картая башлагач, үзең дә аңларсың, үзең дә сагынырсың әле!»—дип әйткәне, син әле күп нәрсәне аңламыйсың шул, дигән кебегрәк мәгънәле итеп баш чайкаганы һаман күз алдында. Әңгәмә нәтиҗәсендә язылган зур гына мәкалә әлеге газитнең 1970 елгы өченче санында (юбилей бәйрәме көннәрендә) «Хезмәт төбе—хәзинә» дигән баш астында басылып чыккан иде.

Исәнбәтнең моннан соңгы юбилеена багышланган тантаналы кичә исә бөтенләй башка сыйфаты—көтелмәгән, хәтта гадәттән тыш вакыйгасы белән тарихка кереп калды дип бәяләргә лаек. Кичә шул ук театр бинасында уздырылырга тиеш иде. Ләкин, кичәгә берничә көн каларак, Нәкый Исәнбәт Урал ягына, Башкортстанга киткән, Казанга кайтмый икән дигән хәбәр таралды. Юк, ул зур юбилей алдыннан туган авылына барып, туган туфрагына сәлам биреп, хушлашырга киткән, юбилеена кайтып житәчәк, кич белән булса да кайтып җитәргә тиеш, диючеләр дә булгалады.

Зур зал бу юлы да шыгрым тулы, хәтта балконнарда да буш урыннар калмаган иде. Сәхнәдәге президиум өстәле артында берничә олы яшьтәге могтәбәр әдипләр белән өлкә комитетының идеология эшләре буенча секретаре Мирзаһит Вәлиев утыралар. Нәкый Исәнбәт үзе күренми. Президиумдагылар бер-берсенә карашып, кайдан, нәрсәдән һәм ничегрәк башлап җибәрергә белмәгән төсле тоелдылар. Ниһаять, карангырак чырайлы зур түрә торып басты. Юбилярның үзе булмаган килеш кичәгә җыелуыбыз «очень странно» дип башлады ул һәм кыскача гына

зур әдипнең, галимнең юбилеен билгеләргә тиешбез дигән төсле берничә җөмлә әйтеп, сүзне докладчыга—Мөхәммәт ага Гайнуллинга бирде. Чәче-бите шома итеп кырылган докладчының Фантомаска охшабрак киткән кыяфәтен генә хәтерлим. Нәрсәләр һәм ничекләр сөйләве истә калмаган. Чөнки, башка күпчелек кебек үк, минем зиһенне дә ул кичәдә: «Ни өчен Нәкый ага кайтмаган?»—дигән сорау биләп алган иде. Сорауларның тагын «ни өчен үз юбилееннан баш тарткан», яки «болай эшләп кемгә ачу белдерә» дигән кебекләре дә баштан чыкмады. Кыскасы, юбилей кичәсенең берниндн тантаналыгы калмаган иде.

Сонрак беркадәре билгеле булганча, Нәкый ага нәкъ юбилей көннәре алдыннан икенче җәмагате Нәҗибә апа белән Казаннан махсус китеп барган икән. Берничә кешедән ишетүемә караганда, китапларын ул үзе теләгәнчә бастырмаулары өчен нәшриятка, республика җитәкчеләренә, аның теләкләрен якламаган Язучылар союзына үпкәләгән булган. Имештер, минем иҗатымны бәяләсәләр, үземне хөрмәт итсәләр, әнә әсәрләремне бастырсыннар, дип белдергән икән. Бу сүзләр күпмегә дөрестер, анысын кистереп әйтә алмыйм, үз авызыннан ишетмәдем, ә үзеннән сорашырга базмадым.

Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, киң колачлы олы әдип республика, Язучылар союзы һәм нәшрият җитәкчеләренә үзенең үпкәсен, ачуын, характерын шулай ачык демонстрация, хәтта протест рәвешендә белдергән иде...

Нәкый Исәнбәтнең үзе белән алып киткән тагын бер зур үпкәсе бар. «Идегәй» дастанының текстын җыю, беренче мәртәбә бастырып чыгару, 1944 елгы мөдһиш карардан соң кыерсытылулар бер якта торсын. Үзгәртеп корулар башланып, дастан тексты янадан басылган чакта, ишетүемә караганда, югарыдан: «Только без Исанбета!»—дигән, 1944 елгы карар кушканча әмер-фәрман төшә. Шуңа күрә 1988 елда яңадан чыккан басмада китапның контртитулында гел түрәләрдән җыелган формаль редколлегия исемлеге бар, нәшрият редакторлары бар. Ә китапны төзүчеләре юк!..

Татар язучыларының иҗатларын яхшы белә торган мәрхүм Рәис Даутовның үземә әйтүенә караганда, шагыйрь, драматург, лингвист, халык авыз иҗаты, ниһаять, әдәбият һәм культура тарихы белгече Нәкый Сиражи угылы Исәнбәтнең хезмәтләрен—әдәби һәм гыйльми мирасын чын-чынлап инләр, тулырак күләмдә халыкка җиткерер өчен иң кимендә уртача калынлыктагы егермегә якын том кирәк булачак икән. Өч томлы калын мәкальләр җыелмасы үзе генә дә гадәти зурлыктагы алты-җиде китапны тәшкил итәр иде. Ә күпме шигырьләр, җырлар, драматик әсәрләр, сүзлекләр, фольклор текстлары, мәкаләләр?!.

Әлеге күңелсез вакыйга хакында Нәкый агадан махсус сорашмавымның үзем өчен бик аңлашылып җитмәгән икенче бер сәеррәк сәбәбе дә булды шикелле. Гөлсемападан соң, гәрчә Нәҗибә апа да килүләремне ачык чырай белән каршыласа да, мин ни өчендер Нәкый агаларга сирәгрәк йөри башладым. Солтанатлы, гаҗәеп затлы мөгамәләдә була торган Гөлсем апаның кыяфәте күпкә кадәр күз алдыннан китми иде. Хәер, шул сирәгәя төшкән баргалауларымда аларда Нәкый аганың балалары да күренмәде. Ә элегрәк, Гөлсем апа исән чакта, улы Празат абыйны, кызы Йолдызны, хәтта килене белән оныгын да күргәләргә туры килә иде. Бәлки монысы миңа гына шулайрак туры килгәндер.

Ләкин Гөлсемападан соң да Нәкый ага белән аралар бөтенләй өзелде дип әйтергә урын юк. Соңгы елларда, алдан шалтыратып, кайчан барсаң да, Нәкый ага һәрвакыттагыча эшләп утырган булыр иде. Элегрәк язу өстәле янында каршы алып, шунда кәгазьләрен актара-актара сөйләшер иде. Шул арада чираттагы бер истәлеген, яисә мәзәген дә сөйләп куяр. Күбрәк синең «нәрсәләр кырып йөрүең» һәм фән өлкәсендәге, бигрәк тә татар тарихы, татар филологиясе буенча яңалыклар, нинди яңа хезмәтләр чыгу белән кызыксынып, һәрвакытта диярлек студентлар, аспирантлар дөньясындагы хәлләр турында төпченеп сорашыр иде. Соңгырак вакытларда Нәкый аганы түшәктә утырган хәлдә эшләргә тырышуын да күргәләргә туры килгәләде. Беренче мәртәбә андый хәлдә килүем өчен уңайсызлануымны сиздергәч, ул: «Моңа игътибар итмә, кәефем әйбәт, тик аякларым җылына алмагач, шулай түшәнеп утыруым,—диде һәм өстәп куйды,—шулай шалтыраткалап килгәләп

тор, юкса бит дөньядан бөтенләй хәбәрсез яшим... чыгып йөри алмагач...»

Шулай да Нәкый ага сирәк-мирәк булса да чыккалый иде «дөньяга». Бер килүемдә, 1984 елның яз айларында иде, минем булачак юбилеем хакында сорашты (календарьдан белгәндер, күрәсең) һәм банкетың буламы, дип сорады. Мин кыюланып «сезне дә анда күрергә теләр идем», дидем. «Чакырсаң, һичшиксез, барачакмын»,—диде ул. Һәм чакырдым да көне якынайгач, Нәҗибә апа белән икесен дә, әлбәттә. Килделәр. Сибгат ага Хәким дә килгән иде. Шул рәвешчә 85 һәм 73 яшьлек ике мөгътәбәр аксакал әле пенсиягә дә чыкмаган кешенең беренче юбилей табынында иң түрдә утырып, мәҗлесемә нур өстәделәр.

Шул кичәдә Нәкый ага бүләк иткән, кара суырта торган, калпагына котлау сүзләре уелган затлы каләм, хәзер инде кара суыртып язулар кулланылмаса да, һаман өстәлем тартмасында саклана.

Нәкый ага бүләк иткән икенче бер кыйммәтле бүләк тә бар миндә. 1984 елның көзендә Гөржестандагы Цхалтубо шифаханәсендә дәваланып кайтуга мине өйдә почта аркылы Нәкый ага җибәргән «Балалар фольклоры» дигән автографлы китап көтә икән. «Хөрмәтле Миркасыйм һәм Салисә ханым. Буш вакытыгызда күз салгалап, бәлки безне дә искә төшерерсез дигән өмет белән, гаиләгезгә зур хөрмәт белән: Нәкый бабайдан бер хатирә. 1.XI.84. Казан.» (Соңгы сүз гарәп хәрефләре белән язылган).

Икенче көнне үк Кавказдан кайткан җимешләрдән киптерелгән хөрмә һәм йөземнән күчтәнәч алып барып чыктым Нәкый агаларга. Ул мине түшәктә килеш кабул итте. Үзе шактый ябыгып, кечерәеп калган иде. Күзләре дә начарлана төшүе сизелде. Беркадәре әңгәмәләшеп утырды. Һәрвакыттагыча гел фән, гыйлем өлкәсендәге яналыклар турында сорашты. Үзе дә кайбер элекке игътибарга лаек вакыйгалар турында сөйләргә тырышты. Кызыксынучанлыгы, берәр мәсьәлә буенча гыйбрәтле мисаллар китерүгә хирыслыгы һаман кимемәгән булса да, көч-хәленең шактый кимүе күзгә күренеп тора иде. Арый башлавын сизүгә бүләк китабы өчен рәхмәтләремне әйтеп, хушлашырга ашыктым. Моннан соң еш-еш авыргалавы хакында ишетелде...

Әлеге күрешүем аның белән соңгы очрашуларымның берсе һәм истә уелып калганы булды...

Ул вафат булганда мин читтә—командировкада идем. Шуңа күрә аның төскыяфәте минем истә һаман тере килеш саклана.

Әмма Нәкый ага белән иң күңелле, үзенчә мәгънәле, гыйбрәтле очрашуларым минем студентлык һәм аспирантлык елларына туры килгән иде дисәм, дөресрәк булыр. Чөнки һәр очрашу үзенә күрә бер вакыйга иде: берәр гыйбрәтле тарих сөйләвен яки кызыклы истәлеген ишетәсең. Ул үзе дә, әйткәләгәнемчә, гел яшьләр, студентлар тормышы хакында сорашырга, белешергә тырыша иде. Бер үк вакытта хикмәтле мисаллары, гыйбрәтле истәлекләре, төптән уйланган саллы фикерләре белән үзенчәлекле сабак биреп, сине баетып та җибәрер иде. Мондый сыйфаты белән Нәкый ага миндә егерменче гасыр башында яшәгән, үз халкын, милләтен белемле итеп тәрбияләргә омтылган, тырышкан янарыш чоры зыялыларыбызның бер вәкиле, хәтта дәвамы буларак тәэсир калдыра иде.

Утыз елга якын сузылган танышлык чорында, өзек-өзек булса да, дәвам итә килгән очрашулар нәтиҗәсендә мин аның холык-фигылендәге, табигатендәге, теләк-омтылышларындагы бер гаҗәеп сыйфатны—тотрыклылык белән үзгәрмәүчән эзлеклелекне күрдем, күзәттем дип әйтер идем. Ул үзгәрмәүчән тотрыклылык исә, беренче нәүбәттә, хәтта иң элек, аның төрле яклап рухи, мәдәни, гыйльми вә иҗтимагый тормышыбыз хакында барысын белеп торырга, моның өчен күп укырга һәм гел сорашырга хирыслыгыннан гыйбарәт иде. Икенчедән, үзе генә белү белән чикләнмичә, сина да нәрсәнедер белдерергә, үзе белгәннәреннән өлеш чыгара барырга омтылуы да аның холкына хас төп сыйфат иде.

Еллар, гомерләр узу белән, гадәттә, кеше дә, аның холкы да үзгәрә. Үзгәрергә тиеш тә. Нәкый ага исә олыгая барган саен да, элек күпме кыерсытулар, эзәрлекләүләр күрсә дә, үзенең эчке дөньясында, күпкырлы иҗатында ныклыгын, хөрлеген алмаштырмады. Киметмәде. Бары тышкы яктан гына үзгәрде—картайды, кечерәйде,

ябыкты. Тик рухи яктан ул һаман да шул ук билгеле, гел эзләүчән, кызыксынучан, башкаларны да кызыктыручан Нәкый Исәнбәт килеш ан-белем хәзинәлеге булып кала бирде.

Үзе дә артистыбыз Равил Шәрәфиев белән бер әңгәмәсе вакытында: «Мин шагыйрь дә, драматург та түгел, мин—мәгърифәтче»,—дип әйткән икән.

Шактый дөрес, яшәргә хаклы билгеләмә бу, минемчә. Әдипнең әсәрләрендә дә аның шушы сыйфаты үзен нык сиздерә. Хәер, Нәкый ага белән булган кайбер очрашулар бер карауга гадәти генә көлкеле эпизодлар сыманрак тоелсалар да, чынлыкта алар да үзенчә бер мәгънәгә, гыйбрәткә, хәтта сабакка охшап китәләр иде. Шундый гап-гади, бер ук вакытта мине гыйбрәтле нәтиҗәгә китергән бер очрашуым һаман хәтердә саклана.

1961 елның сентябрь ае иде бугай. Студент чагым, билгеле. Китапханәдән чыгып, Ленин бакчасы дип атала торган бакча аркылы трамвай тукталышына таба юнәлдем. Лобачевский бакчасы янында Нәкый ага очрады. Кулында саргылтрак төстәге кыршылып беткән зур гына күн портфель. Исәнләшеп, кая барасымны белгәч (буйдак фатирым ул чакта Арча кырында, элекке «Акчарлак» тирәсендәге бер йортта иде), ул:

—Әйдә, көн бик матур бүген, теләсәң, паркка кадәр җәяү барыйк,—диде.

Бик теләп килештем, әлбәттә. Берничә мәртәбә безгә, студентларның гыйльми түгәрәге утырышларына килгән, шунда танышкан, татар мәкальләре җыелмасының беренче томы белән һушларыбызны алган, узган елны гына алтмыш яшьлек юбилеен университетта да уздырган олуг әдипкә ияреп бергә баруың үзе ни тора!

Барабыз шулай әкерен генә сөйләшеп. Нәкый аганы гадәттәгечә студентларның иҗтимагый аңлылык дәрәҗәсе, фән белән шөгыльләнү-шөгыльләнмәүләре кызыксындырды. Үзенең егет чагындагы яшьләрнең иҗтимагый активлыгын да искә төшерде. Күптән түгел аның үзенә биргән минем кульязма җыентык кисәгендәге кайбер мәкальләрнең икенче томга алынуын да әйтте. Горький урамында элекке радиокомитет турысыннан узып, уң яктагы бакчага (хәзер Бакыр бабай—Державин «утыра торган» төшкә) җитәрәк, минем күз каршы яктан килүче бер гаҗәеп чибәр, сылу хатын-кызга төште. Төс-кыяфәтенең искитәрлек гүзәллегенә сокланып, шул кадәр аңар төбәлеп караган булганмын ки, аягым нәрсәгәдер төртелеп, абынып, егылып та китә язганмын. Сылу ханым узып киткәч, Нәкый аганың соңгы сүзләрен ишетми калуымны әйткән идем.

—Һым...—диде ул мыек астыннан гына елмаеп.—Бер уйлап алдым диген, ә... Матур хатын-кыз шулай ул, абындыра өйләнмәгән егетләрне, чукрак та итә...

Өч-дүрт адым баргач, ул әллә ничек уйчан гына өстәп куйды:

—Хәер, өйләнгәннәрен дә...

Аның ничектер сагыш беләнрәк әйтелгән бу соңгы сүзләрендә үзенең шул елларда язылган бер шигыренең яшерен моны да яңгырап киткән сыман булды:

*Әй яшьлегем, яшьлегем,*
*Яшьлегем—гүзәллегем,*
*Акылым биреп алыр идем,*
*Бер генә җүләрлеген!*

Кайтарып булмый икән шул андый яшьлеккә генә хас бәхетле чорларны, хәтта мизгелләрне дә.

Нәкый ага 1969 елның ахырында, әңгәмә вакытында, яшьлекне сагыну хакында үземә төрттереп бер әйткәнчә, хәзер күп нәрсәләр аңлашыла төште инде...

*2003; 2009. Казан, Наратлы, Казан*

# ИСКЕ АРАКЧИНОНЫҢ КҮККӘ АШУЫ

*Хөрмәтле Илдар! Танышуыбызга бик шатмын. Талантыңның күпкырлы булуы мине сокландырды. Сәнгатең көчле һәм гүзәл, электән үк яшәп килгән матурлыкның серен үзендә саклый алар. Йог-дәвачыларның Ходай биргән сәләте ерак чорлардан килә. Бөтендөнья храмы төзергә һәм барча күңелләрне берләштерү ниятең чынга ашсын, сиңа сәламәтлек һәм кодрәт теләп калам. Бел, сине бик күпләр тыңлый, ләкин һәммәсе дә ишетеп бетерми. Ләкин ул көн киләчәк! Сиңа яктылыклар теләп—*

**Святослав Рерих.**
*Һиндстан, 1986 ел.*

Илдар Ханов турында язу һәм рәхәт, һәм читен. Рәхәт–чөнки аның иҗаты да, шәхесе дә сине бердәй дәрәҗәдә таң калдыра, тирән фәлсәфи уйларга этәрә, күңеленне сафландыра. Читен димен, чөнки аның сәнгать әсәрләрендәге энергитиканы, реализмнан котылган символик сурәтләрне, калку яисә сынык бирелгән пропорцияләрне, буяуларның гадәти булмаган экспрессив төсмерләрен анлар өчен зур әзерлек, шуңа өстәп эле рухи тугандашлык та кирәк.

Бу әсәрләр сәнгать телендә сөйли һәм чаң кага! Аларны бер дә икеләнмичә «заманыбызның психологик картиналары» дип тә атарга мөмкин. Кешеләрне комсызлык, усаллык, физик һәм фикри ялкаулык, байлык һәм акча колы булу, түрәлеккә ашкыну, әхлак белән санлашмау шулкадәр нык биләп алды ки, безне хәзер һәр адымда диярлек рухи һәм экологик катастрофалар сагалап тора. Жир шарының төрле кыйтгаларында һаман саен сугышлар кабыну, атом бомбалары турында әйтеп тә торасы юк. Инде менә СПИД, наркомания афәте ябырылды. Кеше үзенең Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән төп вазыйфасыннан һаман саен ераклаша, читләшә бара. Акыл иясе буларак, кеше фән-техника өлкәсендә шулкадәр уңышларга ирешә ки, ул хәтта үзен-үзе бетереп ташларга, юкка чыгарырга да мөмкин. Ә моңа юл куярга ярамый. Кешелекне физик һәм рухи яктан коткару мәсьәләсе бөтен аяусызлыгы белән көн тәртибенә килеп баскан. Коткаруның бердәнбер юлы–тәүбәгә килү, дин юлына басу, Аллаһыга сыену, күңелләрне сафландыру һәм берләштерү.

Яналыкка дәгъва кылуым түгел бу, болар–рәссам, скульптор, төзүче, мәгърифәтче, дәвачы, философ, шагыйрь, гуманист Илдар Мәнсәви улы Хановның иҗатын күзәтә килүдән, сәнгати әсәрләреннән ташып-ургылып чыккан энергия һәм шәхси яшәү рәвеше белән якыннан танышу нәтиҗәсендә туган уй-фикерләр.

Илдар Хановның иҗат манифесты киң, колачлы: кешелекне һәлакәттән коткарырга, рухи сафлык һәм тынычлык байрагы астына берләшергә, Ходай күрсәткән юлдан тайпылмаска... Төрле конфессияләргә бүленүенә карамастан, бу олуг миссияне дин генә башкарып чыга алачак, дип саный һәм шуңа ышана ул. Чөнки диннәрнең һәркайсы асылда рухи-әхлакый камиллеккә, дуслыкка, яхшылыкка чакыра. Менә шундый рухи-мәдәни яңарышка ирешү, юл яру өчен ул Бөтендөнья храмы төзүне төп максаты итеп куя. Бу теләк-ихтыяҗның нигезендә–кешеләргә ярдәм итү, аларның җанын-тәнен ямандыктан коткару. Храм рухи һәм мәдәни энергия чыганакларын үзенә туплаячак. Ничек итепме? Моны без әлеге идея-проект авторының үзеннән ишетергә тиеш булабыз.

Ә хәзергә...

Ә хәзергә–Идел кинлекләреннән гадәти булмаган бер корылмага караш ташлыйк әле. Яр буена галәмнән, әйтерсең лә, аллы-гөлле гаҗәеп бер чәчәк бәйләме төшеп утырган. Әлеге «букет» дигәнең мәчетләрнең мәгърур манарасын, католик соборның кырыс башнясы һәм православ чиркәвенең гөмбәзен, салават күперендәге барлык төсләрне үзенә сыендырган. Күкнең шушы төбәгендә фәрештәләр канат җилпи, тылсымлы нурлар үзләре генә белгән телдә пунктирлар сыза кебек. Аңлаган кешегә–биредә яхшылык нурлары белән тукылган, уңай энергияле, утәкүренмәле аура барлыгын тоемлау читен түгел..

Дөньяда тиңе, үрнәге булмаган әлеге Бөтендөнья храмын Илдар Ханов төзи. Сәер тоелырга мөмкин, ләкин ул ихластан, үзенең көченә һәм Аллаһының кодрәтенә ышанып–сугыш һәм көчләүләрдән азат булган, бары тик тынычлык һәм яхшылык кына тантана иткән дус-бердәм гаилә төзү, кешеләрнең җанын коткару турында хыяллана. Матур хыял ич, шулай түгелме! Кем моңа каршы килер икән?..

Язмыш аңа барыр юлын үзе күрсәтеп биргәндер шикелле. Балалар өчен махсус мәктәп, рәссамлык училищесы. Аннары–Мәскәүнең Суриков исемендәге художество институтында уку. И. Ханов үзенең иҗат эшчәнлеген 1960нчы елларда башлый. Мәскәү авангардистларының социалистик реализмга үткен «чакыру» ташлаган чагы. Шушы юнәлешкә ияреп, Илдар да «татар модернизмы»нда кыю экспериментлар ясый. Мәскәүгә Ленин исемендәге халыкара премияне алу өчен килгән Мексика кунагы–художник-монументалист Давид Сикейрос белән таныша. Ул, гомумән, дөньяның күп кенә бөек шәхесләрен якыннан белә: Фидел Кастро, Пабло Неруда, Индира Ганди, Рерихлар, Булат Окуджава, Высоцкий, Евтушенко. Әле боларга Брежнев, Андропов һ. б. Политбюро әһелләрен дә өстәсәк, бу татар баласының нинди «казанда» кайнаганын чамалау кыен түгел.

Тормыш үзе генә түгел, иҗат дөньясы да контрастлардан тора. 1975 ел. Чаллы каласы. Мәйданда Илдар Хановның «Ватан-ана» дигән монументын ачалар. Аксыл пәрдә шуып төшү белән зур кунаклар һәм халык алдында һәйкәл–яртысы хатын-кыз, яртысы кош образыннан коеп ясалган символик образ пәйда була. Чаллыга килгән данлыклы скульптор Лев Кербель яшен укларын чәчә: «Скульптураны–шартлатырга, рәссамны–атарга!» Ходай кушып, ярый әле бу вандализм һәм «линч суды» эшләнмичә кала...

Быелның апрелендә исә сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен Илдар Хановка Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде.

***

**—70 яшь. Синең кебек юбиляр өчен нәрсә ул? Уйландырамы...**

—Бу минем өчен билгеле бер этап, әлбәттә. Тормышымда һәм иҗатымда яңа сәхифәләр башланачак. Балачак һәм яшүсмер чакта кайбер хыялларымны инде өлкәнәя төшкәндә чынга ашырачакмын дигән сүз. Максатлар үткенәя, яшәү һаман активлаша бара. Мин кешеләрдән башка, аралашудан тыш яши алмыйм. Шуның белән бергә, кешеләрнең тәнен һәм рухын савыктырырга, җирдә һәм дөньялыкта ничек яшәргә кирәген аңлатырга телим, шуны чынга ашыруның яңа юлларын эзлим. Минем өчен һәр кеше туганым кебек кадерле, кулымнан килгәнчә кайгыртуны югарыдан тапшырылган бурычым дип саныйм. Җирдә золым, явызлык, ахырзаман куркынычы көчәйде. Атом бомбасы, экологик фаҗигаләр заманында кешенең

үзенә дә юкка чыгу куркынычы яный. Безгә моны аңларга һәм иждиһат дигән асылыбызга кайтырга вакыт.

**—Рәссам булуың балачактан киләме, әллә моның бүтән сәбәпләре булды микән?**

—Рәсем ясау сәләтем балачактан ук килә. Гәжит кәгазьләренең буш битенә беренче «үрнәкләр»емне күмер белән ясый идем. Буяуларым исә—кишер, чөгендер, чәчәк таҗлары, суган кыягы. Мин моны үз-үземне табарга, расларга тырышу булгандыр дип саныйм. Эчке бер ихтыяҗ ымсындырып тормаса, шулай эшләр идеммени? Сугыш башында туган балалар туп-туры ачлыкның авызына килеп эләкте. Бу—образлы итеп әйтү генә түгел, дөресе шулай. Ике абыем ачлыктан үлде. Үзем дә үлем тырнагыннан чак котылганмын...



*Менә ул Бөтендөнья храмы...*

**—Балачак димәктән, журнал укучыларыбызга биографияңдәге кайбер сәхифәләрне искә төшерик әле.**

—Безнең нәсел Казан буена Мамадыш ягыннан күченеп килгән. Бабам Иске Аракчинода мәчет сала башлаган, нигезен-фундаментын үзе корган. Атеизм сөреме белән агуланган большевиклар аны атып үтерәләр. «Халык дошманы» дигән кара тамга сугылу сәбәпле, әти-әнием һәм безнең гаилә кыерсытуларга дучар ителә. Әтием Мәнсәвине эшеннән куалар, ахыр чиктә ул йөкче булып эшкә урнаша. Әнием Әсма да иң авыр эшләрне башкара.

Өч-дүрт яшьләр тирәсендә туберкулез белән авырыйм, иске бишмәт эчендә бөркәнеп үлем көтеп ятам икән. Күрше-тирә әбиләрнең дога укыганы һәм җил улаганы ишетелә. Яна торгач, лампа уты сүнә һәм мин дөм караңгылыкка чумам... Баштарак гәүдәм, аннары үзендәге голланд миче белән бергә бөтен өй эче әйләнә башлады. Мин боларны әле дә хәтерлим... Канатлы фәрештәләр мине күтәреп каядыр югарыга алып киттеләр. Музыка. Ап-ак киемле кешеләр ак болытлар арасында әйлән-бәйлән уйный, имеш. Миңа бу ошый, сугыш, үлем, ачлык булган җиргә кабат кайтасым килми. Ак киемлеләр арасыннан чыккан бер карт миңа: «Бар, кайт, син кешеләргә кирәк!...—дип пышылдый. Ул мине хәтта кулы белән этәреп тә җибәрде шикелле.

Саташулы төштән уянам. Күрше әби: «Бүген күмәргә соң инде. Әтисе дә эштән кайтмаган. Хәзер тәнен юасы булыр,—ди. Үз әбием мине ак биләүгә били. Кулларны алып, кинәт ул кычкырып җибәрә: «Сөбханалла! Ул җылы, ул исән!» Аның артыннан бүтәннәр дә «ах» итәләр, дога укырга керешәләр. Шушы саташуымнан мин бөтенләй икенче кеше булып уянам: әнием, сеңелләрем яисә песиебез авырый икән, мин аларны массаж ясау юлы белән азмы-күпме савыктыра башладым... Дәвалау һәм рәссамлык сәләте миңа әнә шулай галәмнән, табигатьтән бирелгәндер дип саныйм.

**—Яхшы, ышанычлы дәвачы иң әүвәле нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

—Иң элек кешеләргә ярдәм итәргә үзеңдә көчле теләк, эчке ихтыяҗ булу шарт. Монысы—төп нигез, ачкыч, этәрелеп китү ноктасы. Ярдәмне яшәештә куллану, чынга ашыру өчен кешеләрнең тәнен һәм җанын ныклап өйрәнергә кирәклеген яшьтән үк аңлаган идем. Мәктәптә анатомия дәресен ашкынып көтеп ала идем. Училищеда, аннары Мәскәүдә укыган елларымда да бу фән белән кызыксынуны ташламадым. Мин—үзлегемнән, күзәтү һәм шәхси тәҗрибәләрем аша гыйлем туплаган кеше, моның шулай булуына һич кимсенмим. Ә нигә, заманында Әбүгалисина дә бернинди медицина уку йортларын тәмамламаган ич, әмма


савыктыру һәм чирләрне куу гыйлеменә үзеннән никадәрле өлеш керткән! Шулай ук миңа медицина, тәндәге нокталар системасын аңлатучы акупунктура, йога турындагы китаплар бик нык ярдәм итте.

Авыруларны яратырга кирәк. Әгәр үзендә кемгәдер пычак белән ташланырга сәләтле эчкече яки наркоманны яратырлык көч табасың икән, мондый шәфкать каршында ул сагыздай эри, сиңа ышана, савыгырлык көч таба үзендә һәм аңлы, сәламәт тормыш башлап җибәрә. Кул хәрәкәте ярдәмендә организм белән әллә нинди манипуляцияләр ясарга мөмкин, әмма дә ки әгәр пациентыңны ихластан ярата алмыйсың икән, тиешле нәтиҗә килеп чыкмаячак. Ярату дигәнне бу очракта барыннан да элек авыруның хәленә керү, аның яхшы мәгънәдәге җан хәрәкәтен, ихтыяр көчен уяту дип тә аңларга кирәк.

**—Ә менә яхшы рәссам булыр өчен кайсы мөһимрәк: күзме, кулларммы, буяуларммы...**

—Барыннан да элек йөрәк кирәк! Моны—кешеләргә, тормышка, дөньяга мәхәббәт дип аңлату мөмкиндер. Бу тойгыны, борчу-гамьнәреңне кешелеккә җиткерү өчен әйтер сүзең булу кыйммәт. Ә инде син әйтеп киткәннәр икенчел нәрсә.

**—Үзегезнең скульптура һәм монументаль-декоратив композицияләргә матур, истә калырдай исемнәр куша белгәнсез: «Паганини», «Гасыр туу», «Тормыш агачы», «Шигърият агачы» һ. б. Мондый әсәрләр тиз һәм ансат кына иҗат ителмидер...**



*Остаханәдә.*

—Әйе, скульптура телендә нинди дә булса фәлсәфи концепцияне халыкка җиткерү җиңелләрдән түгел. Төзү материалын табу һәм урнаштыру өчен генә дә байтак вакыт исраф ителә. Кешелек дөньясының үсешен, галактика һәм антимир проблемаларын коллачларга тырышам. Мине аңлаучылар күп, андыйлар киләчәктә тагын да күбрәк булыр дип уйлыйм.

Бөтендөнья храмын төзү турындагы уй 18-19 яшьләремдә үк билеп алган иде мине. Күрәсез, ул әле һаман да ахыргача төзелеп бетмәгән. Миңа гади кешеләр дә, эшмәкәрләр дә, күкләр дә булыша. Хөкүмәт тә игътибарыннан ташламый...

**—Дөньядагы күп кенә дин атрибутларын бер түбә астына җыйнап храм салуыгыз белән ни әйтергә телисез, нинди фәлсәфи идеяне алга сөрмәк булдыгыз икән?**

—Барлык диннәрнең асылы, тоткан мәсләге ахыр чиктә дуслыкка, үзара тату яшәүгә, яхшылык һәм тынычлыкка кайтып кала. Һәрбер дин Аллаһыга үз юлы белән килә. Кешелекне рухи янарышка чакыру исә—иң дөрес юл. Юк, биредә сүз диннәрне берләштерү турында бармый. Мине «үз динен үзенчә итеп төзергә тырыша» дип уйлаучылар нык ялгыша. Мондый ыгы-зыгы, шикләнүләр бер дә урынлы түгел. Минем олуг ниятемне хуплаган Рерих, биредә дини йолалар башкарылмас, ул Бөтендөнья мәдәният храмы булырга тиеш, диде. Әйе, биредә галәмнең уңай энергиясе һәм кешелек мирасының рухи казанышлары тупланачак. Бу юлны инде безгә бик борынгы акыл ияләре, якынрак замандашларыбыздан Кол Гали һәм Шекспир, Пушкин һәм Тукайлар сызып калдырган. Мин шундый гигантлар үрнәгенә таянам. Кешелекнең дөрес һәм хак юлдан барышына үз өлешемне кертәсем, кулымнан килгәнне эшлисем килә.

Храмның күп кенә бүлмәләрендә күргәзмә хәзинәләр урын алачак. Мин архитектура һәм символлар сарае, дини һәм мәдәни үзәк төзүне максат итеп куйдым. Тукай, Сәйдәш заллары әзер, инде татар-башкорт шагыйре Мостай Кәримгә багышланган бүлмә дә тәгәлләнеп килә. Храмда йога дәресләре үткәрү турында да

хыялланам. Биредә шулай ук спортзаллар—гимнастика, штанга, у-шу, самбо, дзюдо, татарча көрәш секцияләре эшләп торачак. Музыка да яңгырар. Рухи кыйммәтләрне матди байлыктан өстенрәк санаган яшь буын тәрбияләү кирәк безгә. Юкса киләчәк буын упкын алдында тора. Кешелек яралары бер хәл, ә күңел ярасы моңардан да зуррак. Без үзебезне фәкать үзебез генә коткара алабыз.

**—Сез кешеләрне «кешеләштерергә» омтыласыз дип аңларга кирәктер моны.**

—Әйе, нәкъ шулай!

**—Синең иҗат эволюциясен бер җепкә болайрак тезәргә мөмкин: Казан, Мәскәү, Чаллы, Аракчино... Шулай да Мәскәүдән нигә китеп бардыгыз? Юкса анда үсү-танылу өчен мөмкинлекләр зуррак булгандыр бит..**

—Мин дан артыннан кумадым. Туган ягым, туган нигезем үзенә тартты. Храм нигезенең үзәген, йөрәген әти-әниемнән калган буралы агач йорт тәшкил итә. Нәсел чылбырын әнә шулайрак итеп тә ялгадым шикелле. Тагын бер хикмәтле хәлне сөйлим әле. Казанда чакта ук яшьлегемдә мин Кол Шәриф мәчете макетын күтәреп обкомга килгән идем. Сөйләшү кая, аны шундук пыр туздырдылар, үземә исә 24 сәгать эчендә Казаннан чыгып качарга «киңәш» бирделәр. Милләтчелектән өркегән ул чактагы түрәләрнең куркаклыгына аңлатма бирү кирәкмидер. Мәскәүгә әнә шулай барып эләктем мин...

**—Иҗатыгызда кризис булганы бармы?**

—Андый хәлләр киләсе булса, мин моны алдан ук сизәм һәм мөмкин кадәр туктатырга тырыша идем. Кыенлыкларга юлыксам да йөземне югалтмадым—ничек бар, шулай калдым. Ватаныма, халкыма, әти-әниемә һәрвакыт тугрылык сакладым.

**—Су басып, соңрак сваркадан янгын чыгу сәбәпле йөзгә якын картиналарыгыз юкка чыккан. Бу югалтуларны кире кайтару, ай-һай, мөмкин микән?**

—Ягу торбасы шартлау нәтиҗәсендә Мәскәүдәге остаханәмне, чыннан да, бервакыт су баскан иде. Беренче хатыны белән аерылгач, Володя Высоцкий берара миндә яшәп алды. Синдә әйбәт язылa, дияр иде ул. Минем картиналар бер хәл, Володяның легендар гитарасы да кайнар су күлендә йөзеп йөри... Шагыйрь моны авыр кичерде, билгеле.

Нишлисең бит, иҗатымның бу өлешен өр-яңадан эшләү, кире кайтару мөмкин түгелдер. Алар көл булып мәңгелекнең куенына күчте. Болар миңа—җебеп калмаска, әһәмиятлерәк әсәрләр иҗат итәргә дигән кисәтүле тамга иде, шулай кабул иттем.

**—Италиянең XV гасырда яшәгән атаклы рәссамы, скульптор Леонардо да Винчиның һөнәрләрен санап бетерерлек түгел: металлургия миче, туку һәм агач эшкәртү станокларына бәйле сызымнар, дельтоплан һәм парашютка охшаш очу конструкцияләре, танк һәм су асты көймәсе модельләре, велосипед эскизлары дисеңме ... Синең дә һөнәрләрне санный башласак, хәйранга җыелыр иде...**

—Бардыр инде (көлемсери). Талант ягын Ходай бирәдер дип саныйм. Бала чакларымда ук скрипкада уйный идем. Хәзер Рубин Абдуллин бүләк иткән кечкенә органда уйнап азапланам. *(Көлә.)* Шигырьләр язам, ләкин аларны беркая да биргәнем булмады. Ә инде төрле авыруларны, эчкече һәм наркоманнарны дәвалау—кешеләргә ярдәм итәргә, булышырга теләүдән килә. Йоглар тәгълиматын өйрәнү һәм медитация миңа галәм белән аралашу серләрен ачты, биологик сәләтемне үстерде. Кешеләрне дәвалау—минем өчен шулай ук үзе бер сәнгать, хакыйкатьне раслау һәм шуна ирешүнең ачык чагылышы. Мин башкача була алмыйм. Болар—минем иманым, ышануым.

Кем ул наркоман? Моны һәркем белә диярлек. Кабатлап булса да әйтәм, наркоман яисә эчкече—Ходай билгеләгән әхлакый юлдан тайпылып, үз-үзенне җимерү дигән сүз. Андыйларның күбесе, дөресен әйткәндә, вакытлыча ләззәт алудан мәхрүм

калырмын дип курка. Төймә яисә укол да түгел, иң яхшы дару—сүз, наркотикларсыз яшәү чын бәхет икәнен аңлату, раслау, төшендерү. Ә моның өчен авыруны туганың кебек итеп, үз тиңең итеп кабул итәргә кирәк. Ул сиңа ышансын.

Шулай да иң мөһиме—авыруның үз теләге белән килүе, фаҗигагә килеп терәлгәнен чын күңелдән аңлавы. Бу очракта кешенең тәнен генә түгел, җанын-рухын да дәваларга кирәк.

**—Ярдәм сорап кайсы катлам кешеләре күбрәк килә?**

—Нигездә, яшьләр һәм студентлар. Балигъ булган кеше 20 яшенә кадәр тормышта үз урынын таба алмый икән, аңа инде якын киләчәктә (потенциаль) наркоман булырга әлләни ерак түгел. Андыйлар тормыштан берни дә алмый, бирә дә алмый. Хәзер миңа Татарстан районнарыннан килүчеләр дә ешайды, чөнки бу бәла, афәт авылларыбызга ук барып җитте. Хәтта оныгы да, бабасы да наркоманлык чоңгылына төшү очраклары бар.



*И. Ханов (уңнан беренче) Тукай бүләген алганнан соң. 2010 ел.*

**—Күп киләләрме?**

—Төрле авырулар белән килүчеләрне күздә тотсак, кайчагында йөзләп, кайчакны өч йөздән артыграк кешеләрне кабул итәргә туры килә. Һәрберсенә аерым мөнәсәбәт, аерым ачкыч кирәк. Кешеләр бит бер-берсенә охшамаган, һәркайсы аерым утрау шикеллерәк. Чит илләрдән, әйтик АКШ, Голландия, Германия, Израил кебек илләрдән килүчеләр дә юк түгел. Кешеләрнең чирен, тазалыгын билгеләү өчен миңа тәрҗемәчеләр дә, рентгент та кирәкми.

Дәвалау һәм дәвалану йөз проценты белән чынга аша дип әйтмәс идем. Кешесенә карап—нәтиҗә. Храмнан, минем яннан китү белән койманың теге ягында аларны икенче тормыш көтеп тора бит: мохит бар, гамь-борчулар ташкыны, сыналу, үз-үзең белән көрәш... Ихтыяр көче нык булган кеше генә аңлы, тәрбияле, яңа тормыш башлап җибәрә ала, үзенең шушы гамәленнән тәм, куаныч таба. Бер ирне тәмәке тартудан дәвалаган идем, ике-өч ай дигәндә хатыны килеп җитте: янәсе тырышлыгы өч айга гына җиткән иренең... Күп нәрсә кешенең үзеннән дә тора.

Чирләрнең бик күбесе, әгәр шулай әйтергә яраса, «чишмә башы»—усаллыктан да килә. Үч, мәкер, көнләшү, явызлык—болар барысы да кешенең шәхесен, асыл табигатен җимерә. Күп нәрсәләр нерв системасына бәйле. Үз хисләрең белән идарә итә белмәү—кешенең төп бәласе менә кайда ул. Әйткәнемчә, дөньядагы барлык диннәр дә әхлакка, хак юлга, Аллаһыга таба якынаерга өйрәтә. Кешелекне афәттән, җимерелүдән коткаруның бүтән юлы юк. Без барыбыз да—Ходай баласы...

***

Сорау туарга мөмкин: дөньядагы мәдәни казанышларны бер ноктага, бер энергетик үзәккә туплау үрнәге Җир шарында тагын бар микән? Белеп һәм икеләнмичә әйтәм—юк. Әнә бит, Арчада оешкан «Әлифба» музееның аналогы да беркайда, берниндиинтернетта юк. Мәгълүм сүзләрне кушып әйтсәк, кайчагында

«Без булдырабыз!» да, ахрысы? Татарлар дип әйтүем.

Хыял-маҗараларга ышанмаучы, үз читлегендә генә яшәгән тар карашлы кешеләр Илдар Хановның галәми фәлсәфәсен кабул итмәскә, анын үзен исә «чудак»ка санаулары да бик мөмкин. Язмамда мин аны идеаллаштырырга тырышмадым, ничек бар—шулай яздым. Чыннан да, аның грандиоз архитектура төзелеше корып җибәрү, тәүлекнең яртысы буе диярлек элекке СССР шәһәрләреннән дә килгән авыруларны кабул итүе, бер уйласаң, гайре табигый хәл шикеллерәк. Ләкин аның гамәлен-фикерен уртаклашучылар, теләктәшлек итүчеләр күп. Иң мөһиме—И. Хановның мәгърифәтчелек, күпкырлы эшчәнлеге кешеләргә, гуманизмга хезмәт итә. Мондый олуг гамәл исә хуплауга, мактауга лаек. Әлбәттә, бөтенесен дә бер Аллаһка гына «аударып» калдыру шактый бәхәсле нәрсә, ләкин тормышыбызда Илдар Ханов дигән феномен бар һәм моны танымаска мөмкин түгел. Ул пәйгамбәрлеккә дәгъва кылмый, үзен Мөхәммәтнең, Будда һәм Христосның җирдәге бер шәкерте генә дип саный.

Дөньякүләм хакимлеккә сусау, шәхси мәнфәгатьләрне өстен кую, камилләшкән һәм сәбәпсез усаллыклар берсе дә эзсез-нисез узмый, иртәме-соңмы, кешелеккә җавап тотарга туры киләчәк, кешелек үзенең асылына кайтырга тиеш дип саный ул. Иҗатында Хиросима фаҗигасен кисәтүе белән ул әлеге сүзләрне әйтергә йөз тапкыр хаклы. Аның яшәвенең һәм иҗатының бар мәгънәсе—кешеләргә хезмәт итү.

Бөтендөнья храмына инде делегацияләр, туристлар килә. И. Ханов—үзе гид, үзе экскурсовод, чөнки андагы бүлмәләрне, энергетик тупланышны аның үзеннән дә яхшы белүче юк.

...Иделнең аргы як ярыннан бу манзара бигрәк тә аермачык күренә: әнә, Иске Аракчинодагы Бөтендөнья храмы галәмдәге югары көчләргә төбәлгән, айлы манзаралары һәм суганбашлы гөмбәзләре белән күккә ашкан! Ул барыбызны да матурлык, дуслык һәм туганлык иленә чакыра, асылыбызга кайтырга өнди.

**Рашат НИЗАМИ**
*Сентябрь, 2010*

***Редакциядән.** Күпсанлы укучыларыбыз исеменнән Илдар Хановны 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, аңа саулык-сәламәтлек һәм илһамлы-бәрәкәтле көннәр телибез!*

Әзһәр
Шакиров

# БУЛМАС ДИМӘ, ДӨНЬЯ БУ!

## Салпы якка салам...

Минем тормышта мәзәкләр, кызык хәлләр бик күп булды инде ул. Шуларның берничәсен генә искә төшерәсем килә, чөнки безнең артистлар, үземә караганда кызыграк итеп сөйлиләр. Болар чыннан да булган хәлләр. Бәлки аларны мавыктыргыч итеп сөйли дә, яза да алмам, ләкин үз авызымнан ишетү сезнең өчен бер истәлек булып калыр, дип уйлыйм.

Күңелем күтәрелеп киткәндә үземне шул кадәр иркен тотам, минем өчен бернинди киртәләр дә юк. Нәкъ Гогольнең Хлестаковы инде менә. Нәрсә телим, шуны эшлим, андый кешене «йөгәнсез» диләр. Иптәшләрем бераз үсенеп китә торган гадәтемне белеп алгач, кирәк чакта моны бик оста кулланалар иде. Ә мин шуна чын күңелдән сөенә идем. Шулай бер вакыт Уфада гастрольдә чагында «Сүнгән йолдызлар» спектаклен уйнап бетергәч, Башкорт академия театры артистлары «күчтәнәч» белән килеп керделәр. Бераз мине мактагач, күңелемне күтәргәч, түзмәдем, үземә чакырдым. Кайтып күңел ачып, көлешеп, җырлашып утыргач, безнең бетте дә куйды, самый кызган чакта. Хәзер нишләргә инде? Барысы да миңа карый: тапсаң син генә табасың, янәсе. «Бирсәләр, сиңа гына бирәләр, бөтен өмет синдә. Сине бит бөтен кеше белә, син талантлы, кыяфәтеңне кара!»–дип күңелемне үстерәләр. «Бу дөньяда бер генә яшибез, бер утыру–бер гомер, әйдә, истәлеккә калсын! Күрсәт инде үзеннең кемлегеңне!»–дип, салам кыстырып, ялынып-ялварып урамга чыгарып җибәрделәр. Үзем дә кызмача булгач, ярар, мине көтегез, хәзер кайтам дип, төнге сәгать уникедән соң аракы эзләргә чыгып киттем. Беләм инде, рестораннар ябык, булса шул таксистларда булуы мөмкин. Басып торам кунакханә төбендә, инде нишләргә? Тукта әле, мин әйтәм, «Агыйдел» ресторанының каравылчысыннан сорап карыйм әле, дим. Шулай итеп ресторанның ишеген шакый башладым, бер кем дә юк. «Откройте!»–дип үзем дә сизмәстән кычкырыбрак җибәрдем. Ишек төбенә берәү килде дә: «Кто там? Ресторан давно закрыт. Иди отсюда!»–дип миңа кычкыра. «Не кричите на меня! Я, Шакиров, прошу, откройте!»–дим. Ишек артындагы урыс:–«Ну и что, что ты Шакиров?»–ди. «Позовите главного администратора. Он знает кто такой Шакиров!»–дип, мин дә кимен куймыйм. Бер заман ишек артында: «Шакиров! Шакиров!»–дигән тавышлар ишетелә башлады.

Ишекне ачтылар, каршымда чибәр генә хатын-кыз басып тора. «Я–администратор. Вы кто такой? Что вам нужно?»–ди бу.

«Я, Шакиров. Вы что, Шакирова не знаете? Мне Вас очень жаль. Вы должны были знать, кто такой Шакиров. Не хорошо, не хорошо! Что не знаете Шакирова!»–дип, киттем тезеп... Күрәм, администратор бер агарды, бер кызарды, кинәт нәрсәдер исенә килеп төште. «Извините, не узнала Вас. Чем могу помочь?»–ди бу хәзер. «Ике шешә аракы, өч кымыз, ашарга тәмле ризыклар булсын!»–дим. «Сейчас сделаем, извините нас!»–ди гүзәл ханым. Күрәм, матур бер тартмага ике шешә аракы, өч кымыз, әле яңа гына пешкән сарык ите, казылык, бавыр, икмәк төреп салып бирделәр.

---

Әзһәр ШАКИРОВ (1940)–*Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. "Язмыш" исемле китап авторы. Казанда яши*

Рәхмәтләр әйтеп, түләргә акча сузган идем: «Что вы, что вы? Не обижайте нас. У вас брать? Что вы будете думать о нас? Нет уж, угощайтесь, приходите еще, всегда будем рады!»–диләр. Рәхмәт әйтеп, бик зур кеше булып чыгып киттем. Чыккач кына аңладым, болар бит мине Башкортстанның беренче секретаре Шакировның туганы дип кабул иттеләр. Ул чагында Шакиров–Башкортстанның «Алла»сы иде. Күрәсең, без бер-беребезгә бераз охшаганбыздыр. Мин зур түрә ролен шундый итеп уйнаганмын, администраторга чут-чут инфаркт булмый калды. Кутәренеп кайтып кергәч, башкорт театры артистлары шаккаттылар. «Ну, малай, үзеңне теләсә кайда беләләр, зурлап каршы алалар. Булырсың икән бу хәтле бәхетле авыз!»–дип, чын күңелдән сөенделәр. Мин әйтәм: «Онытмагыз, язып куегыз: төңге сәгать икедә артист Шакиров җаны ни тели, шуны таба дип!»

Икенче көнне айныгач кына аңладым үз хәлемне. Әгәр дә шунда кемлегемне белсәләр, җанымны алырлар иде. Академия театрында бер артист Башкортстанның беренче секретаре Шакировның туганы булып йөри дип, икенче көнне үк театрдан куарлар иде. Хәзер дә күз алдыма килү белән йөрәгем жу итеп куя. Шуннан бирле «Агыйдел» ресторанына керү түгел, әйләнеп уза торган булдым.

## Мин ничек үлемнән калдым

Тормышымда булган гыйбрәтле бер вакыйганы искә төшерәсем килә.

1970 елда мин гаиләм белән бергә беренче мәртәбә Кырымга, Ялта шәһәренә ял итәргә бардым. «Актер» санаториясенә түгел, кешедә фатир алып тордык. Шунда беренче мәртәбә диңгезне күрдем. Нишләптер, бер дә исем китмәде, һәр көнне кызынырга, коенырга «Актер»га төшәбез, анда кеше күп түгел, урын җитәрлек, иркенләп кызынып ятарга була. Өстәвенә, Советлар Союзының иң талантлы артистларын күрәсең, бездән театрның директоры Рәшидә апа Җиһаншина, Әзһәр абый Абдуллин, ВТОның секретаре Гатова бар иде. Бер көнне диңгез бик куркыныч шаулый, һәр җирдән радиодан кычкыралар: «Суга керергә ярамый, көчле шторм!»–безнеңчә әйтсәк, өч-дүрт метрлы биек-биек дулкыннар ярга килеп бәрелләләр, сызгырып-сызгырып вак ташлар оча, көчле җил исә. Пляжда кеше аз, хатын-кызлар җыелышып диңгездән искән җылы җилдән, көчле дулкыннардан, шомлы тавыштан җан тынычлыгы табып, хозурланып, диңгездә була торган бик сирәк күренешне гомер буена истә калдырырга теләп утыралар. Табигать бик серле, диңгез кешенең күңелен тынычландыра, бигрәк тә шторм вакытында. Яр кырыенда басып торам, диңгез шул хәтле сихерләп үзенә тарта. Чыннан да, дулкыннарны җиңеп йөзәсем килә. Менә шунда беренче мәртәбә күрдем инде диңгезнең нинди көчле, сихри икәнен. Мәңге онытмаслык! Кичә кич белән мине фатир хуҗалары әйбәт кенә сыйлаганнар иде, шуңа күрә иртән хәлем бик шәптән түгел. Менә бер вакыт яр кырыена урыс артисты Василий Лановой килде дә, чишенде дә, матур итеп диңгезгә чумды да. Бөтен хатын-кыз «ах» итте: менә ичмасам ир! Берниგә карамыйча кереп китте, рәхәтләнеп йөзеп тә чыкты. Моны хатын-кызлар сырып алдылар, и мактыйлар, и мактыйлар, шаккаттылар, нишләргә белмичә янында бөтереләләр, мина да карап алалар. Бу минем «самолюбиегә» тиде. Янәсе, без Василий Лановойдан кайсы ягыбыз белән ким?! Мин дә бик тиз генә киемемне салып аттым. Йөзәргә булдым, күрсеннәр әле, без дә төшеп калганнардан түгел! Диңгез кырыена басуым булды, дулкын үзе белән суырып алып та кереп китте, сизми дә калдым. Су шундый җылы, дулкыннарда тирбәлә-тирбәлә, әллә кем булып йөзәм. Өстемә биек дулкыннар килгәндә аска чумам да, дулкын узгач, кире калкып чыгам. Шундый рәхәт, үзеңне шундый көчле итеп тоясың, ярый әле кердем, курыкмадым, мондый рәхәтлекне гомеремдә дә күрмәгән булыр идем. Шулай бер ун-унбиш минут матур гына йөзгәч: «Менә күрдегезме, без дә шулай йөзәбез ул, бер Лановой гына түгел!»–дип кычкырам. Хәзер инде әкрен генә, матур гына, балык кебек яр кырына килеп чыгыйм әле, дип йөзәм. Яр кырына килеп җитеп, аякка басыйм гына дигәндә, зур дулкыннарның берсе мине кире өстерәп диңгезгә алып кереп тә китте. Мин, нәрсә уйларга да белмичә, кире ярга чыгарга йөзәм, нәкъ шул яр кырына җиткәндә генә дулкын мине тагын эчкә алып кереп китте. Куркып калдым. Янадан ярга таба йөзәргә керештем, ләкин әлеге хәл тагын кабатланды. Ничек инде мин судан ярга чыга алмыйм?! Инде нишләргә? Ярдәм итегез, дип кычкырыр идем, мондый көчле

жилдә дингез шундый куркыныч шаулый, мине барыбер бер кеше дә ишетмәс иде. Шушында батып үләм икән дип уйлавым булды, аяк-кулымны көзән җыерган сыман бик каты авырттыра башлады. Дингез һаман дулкыннар белән әкрен-әкрен генә үзенә эчкә алып керә бит. Үләм бит, аракы эчеп батып үлгән, дип әйтәчәкләр. Шушы әшәке уй җанымны өзгәли башлады. Моннан бит мине бер кеше дә таба алмаячак. Улым Рөстәм нишләр? Хәзер ничек кенә булса да моннан чыгарга, дигән уйлар бер-бер артлы башымнан узалар. Юк, баш эшләми, куллар, аяклар гына хәрәкәт итә. Соңгы мәртәбә бөтен көчемне җыеп, яр кырына килеп җиттем. Тукта, мин әйтәм, җиргә төшеп тирәнлеген карыйм әле, әгәр җирдән тырмашып яр кырына чыксам? Шулай диеп су астына чумуым булды, дулкын бүрәнәне ничек ярга китереп ыргытса, мине дә шулай ярга чыгарып ыргытты. Яр кырында ятам, янымнан зур-зур ташлар оча, бөтен дөнья дөм караңгы булды, куркуымнандыр инде. Карасам, тирә-ягымда хатын-кызлар, бала-чага: «Что ты наделал? Что ты наделал?»–дип миңа кычкыралар, сүгәләр. Әле мин үлемнән котылганга, үзем белән булган хәлне аңламыйм, миндә шок. Бер заман карасам, бөтен тәнем сыдырылып беткән, таш тишеп бот төбемнән ит асылынып тора. Минем чыга алмыйча җәфалануымны бөтен кеше карап торган, медсестра белән Рәшидә апа, Әзһәр абый килеп җиттеләр. Минем хәлне күргәч, Рәшидә апа җылый башлады, Әзһәр абый сүгә, үзләренә номерларына алып керделәр. Медсестра сыдырылган җирләргә йода сөртеп, таш кискән бот төбен бинт белән, аякның ярылган урыннарын мазь сылап яхшылап бәйләде. Әзһәр абый ярты стакан аракы салып бирде, Рәшидә апа әйтә, хәзер инде көзгегә кара ди, караган идем, шаккаттым, бөтен тәнемнән әз-әз генә кан тамып тора, сыдырылмаган җире калмаган. Өстемә күлмәк-чалбарны киеп, әкрен генә сөйрәлеп фатирга кайтып киттем. Шулай итеп, шторм вакытында дингездән ярга ничек чыгарга икәненә гомерлек сабак алдым. Мондый кешегә татар әйтә: «Керәсеннән элек, чыгасынны уйла!»–ди. Бер атна буе дингездә рәхәтләнеп йөзә алмадым.

## Мин ничек Мәскәүдә Партиянең XII съездын ачтым

Театрыбызның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов артистлар белән булган кызык хәлләр турында бик образлы итеп сөйләргә ярата, үзенә күрә бер спектакль куя иде. Әлбәттә, монда аның баш режиссер булуы да ярдәм иткәндер, чөнки һәрбер сүзен чын күңеленнән кабул итмәсәң, үпкәләве бар. Шулай да, Марсель сүзгә бик оста кеше, минем белән булган хәлләрне шундый итеп сөйли, хәтта үзем дә, иптәшләрем белән рәхәтләнеп көлә-көлә тыңлый идем. Менә хәзер шундый бер вакыйганы искә төшерәсем килә.

Шулай бер вакыт Марсель белән икәү ВТОның (Всесоюзное театральное общество) XII съездына делегатлар булып Мәскәүгә бардык. Килү белән үк безне ВТОның председателе, СССРның халык артисты, Кече театрның җитәкчесе Михаил Иванович Царев үзенә чакыртып алды. Марсельгә кара икра белән коньяк, кофе китертте. Сүзне болай башлады: «Сез съездның президиумын тәкъдим итәргә тиешсез, шуңа әзерләнегез»,–ди. Марсель: «Вот, у нас актер Шакиров, кстати, он Ваш ученик, окончил Щепкинское, будет выступать от имени театра»,–ди.

Минем кулга өч бит русча текст тоттырдылар.

«Кара әле, Марсель, мин бит русча бик яхшы белмим, зинһар, үзең генә сөйлә әле»,–дигән идем,–«Борчылма, мин сине ничек сөйләргә өйрәтермен!»–ди бу. Ул әйткәч, тыңламыйча ярамый.

«Россия» гостиницасында төнге бергә хәтле бу мине шул кадәр өйрәтте ки, мин текстны яттан беләм, бер нинди акцентсыз, ул куйган басымнарны дөрес ясап шундый итеп сөйлим ки, Марсель аптырап карап тора. Үзем исә эчемнән генә, менә иртәгә русларга ничек сөйләргә икәнен күрсәтәм әле дип, чын күңелемнән сөенеп, горурланып та куйдым. Иртән иртүк торып текстны тагын берничә мәртәбә кабатладым, беләм инде, беләм–яттан беләм! Матур итеп юынып, киенеп, театрга киттем. Бик эре кыяфәт белән сәхнә артына кереп, үземне чакырганнарын көтеп торам.

Беренче булып сәхнәгә СССРның халык артисты, Ленин премиясе лауреаты Михаил Ульянов чыкты, шундый күтәренке рухта, көчле тавыш белән: «Я предлагаю почетный президиум нашего съезда, политбюро нашей партии во главе Леонидем

Ильичом Брежневым»,–дип әйтүе булды, бөтен зал торып кул чабарга тотынды. Шул вакыт чибәр генә бер хатын-кыз миңа:–«Прошу вас читать вот этот текст»,–дип кулымдагы мин ятлаган текст урынына өр-яңасын китереп тоттырды. Мин: «Что вы делаете, я же...»–дип теге хатынга аңлатмакчы идем, ул арада фамилиямне әйттеләр. Мин, сәхнәгә чыгып, Ульянов кебек бик күтәренке рухта, көчле тавыш белән: «Дорогие делегаты, по решению XII партийного съезда...»–дип әйтүем булды, бөтен зал тып-тын калды. Мин бит «ВТОның XII съезды»–дип әйтәсе урынга, «партиянең XII съездын» игълан иттем. Үземнең нинди зур хата җибәрүемне аңлагач, йөрәгем ярыла дип торам, күз алларым караңгыланып, башым әллә нишләп китте, куркуымнан як-ягыма карыйм, кем дә булса ярдәм итмәсме, янәсе–юк!–«Извините, здесь не так написано.»–дип кулдан язылган кәгазьне бөтен көчемә кычкырып укый башладым. «По решению парт групп нашего Театрального съезда предлагаю в президиум следующих товарищей». Исемлекне укый башлаган идем, әллә күземә күренә микән дип торам, мин ятлаган исемлектәге кешеләрнең фамилияләре бөтенләй юк, барысы да яңа исемнәр, һәр исемне укыган саен халык кул чаба, Прокопьевск шәһәрен–Прокопи, прокопи дип, өч мәртәбә кабатлагач, Циммерман дигән кешенең исемен Цукерман дип әйтүем булды, әйтерсең лә бөтен зал шуны гына көтеп торган, егыла-егыла көлә башладылар. Шуннан нишләгәнемне, ничек укып бетергәнемне хәтерләмим.

Үз-үземне кая куярга белмичә, еларга җитешеп, әкерен генә атлап залга төштем. Марсельне эзлим, ярдәм итмәсме, янәсе–юк, күренми генә бит, ат хәтле кеше әллә кая юкка чыкты. Кинәт сул күзем тартыша башлады, авыз кипте, тел әйләнми! Залда утырган артистлар: «Молодец, но насмешил, так насмешил, давно так не смеялись»,–дип минем күңелне «күтәрергә» тырышалар. Берзаман күрәм, Марсель урындыкка шундый итеп сеңгән, гәүдәсе бәп-бәләкәй булып калган, йөзе кып-кызыл, күзләре генә акаеп тора. Мин янына килә башлагач: «Килмә-килмә, хур иттең, хур иттең»,–дип җан ачуы белән кулын селти. «Мин бит сиңа әйттем, үзең укы дип, күрдеңме соң, миңа өр-яңа текст китереп тоттырдылар»,–дим.

Бик нык үпкәләп бер читкә барып утырдым. Җитмәсә, бөтен кеше миңа бармак төртеп күрсәтә, миннән көләләр шикелле. Бер артист яныма килде дә: «Ну что ты, бывает...»,–дип тынычландырырга кереште. Мин әйтәм: «Пожалуйста, не мешайте мне доклад слушать»,–дим, әйтергә сүз тапмагач.

«Москва» ресторанына кереп бераз җанны тынычландыргач:

–Марсель, зинһар өчен, бу турыда бер кемгә дә сөйләмә инде, бераз онытылгач сөйләрсең,–дидем.

Кая ул, мондый кызык вакыйганы ничек сөйләми түзсен! Мәскәүдән кайтып бер-ике көн узды микән, минем белән булган хәлне театр гына түгел, бөтен Казан белә иде. Шунысы кызганыч, миңа хәзер инде аларны искә алып сөйләрлек кеше дә калмады.

## Хәким абый белән күргәннәр

Ямьле җәй айларында без, артистлар, барыбыз да бергә рәхәтләнеп, Идел буендагы «Актер» да ял итә идек. Һәрбер гаиләгә–аерым йорт. Һәрберебезгә–аерым көймә, рәхәтләнеп балык тотабыз. Көймәдә балык тоту үзенә күрә бик күңелле, ләззәтле, мавыктыргыч шөгыль, чөнки балык шактый күп әлегә иде. Марсель белән Гөлнар көн саен икесенә кимендә 10-15 кило балык тоталар. Хатын-кызлардан Гөлнар–бердәнбер чын балыкчы иде. Шулай бер көнне иртән Гөлнар бик күп балык тоткан, кая куярга белми, әлбәттә, зур балыклар түгел, уртача 700-800 граммлы матур чабаклар. Әйткәнемчә, Марсель белән Гөлнар бик оста балыкчылар булгач, алар балыкларын бөтен кешегә тараталар. Балыкны бит җәй көне озак саклап булмый, тиз бозыла, ул чорда суыткычы да юк. Марсельнең этисе Хәким абзый Сәлимҗанов әйтә: «Әйдә, сатабыз»,–ди. Ул вакыт балык сатып йөрү артист өчен оят иде. Мин балык сатып йөргән артистны күргәнем булмады, соңыннан гына сата башладылар. Хәким абый әйтә: «Син, Әзһәр, борчылма, сатуын үзем сатармын, зинһар, күтәреп кенә бар!» Әгәр баш режиссер хатынының балыгы булмаса, бүтән кешенеке булса, аяк та атламас идем, нишлисең, «хуҗа»ныкы бит... Марсель Хәкимович: «Кара аны, тегеләй-болай йөрмәгез, сатыгыз да кайтыгыз!»–ди.

Мин кара күзлек, башка эшләпә, шорты киеп алдым. Беркем дә танырлык түгел! Иртәнге сәгатьтә ике зур чиләк белән балык күтәреп, «Светлая поляна» диган ял итә торган җиргә җәяүләп киттек. Бездән ике-өч чакрымлап булыр. Барып җиттек «Светлая поляна»га, тезелеп киткән тактадан салынган йортлар. Хәким абый бер йорт янында: «Кому рыба, кому рыба?»–дип кычкыра башлады.

Шуннан бер апа чыкты да: «Хәким абый, бу син түгелме сон? Кемне эзлисен?"–ди. Мин чиләкләрем белән агач арасына постым. Шуннан әкрен генә эндәшәм: «Әйдә, киттек!»–дим. Тагы бер өч йортны узгач, Хәким абый тагын кычкыра башлады: «Кому рыба, кому рыба?!» Өйдән өлкән генә бер әби килеп чыкты да: «Кем бар анда? Нәрсә сатасыз?»–дип Хәким абыйга таба килә башлады. Шуннан соң, таныгач: «Кара әле, Хәкимҗан, бу син түгелме сон? Нишләп йөрисен? Кемне эзлисен? Әйдә, өйгә керик, чәй эчәрбез. Сине ничә еллар күргәнем юк иде»,–дип Хәким абыйны чәй эчәргә кыстый башлады. Хәким абый ык-мык килеп басып тора. Мин әйтәм: «Гафу итегез, без бер кешене эзли идек, ул шушы урамда булырга тиеш. Әйдә, Хәким абый»,–дип алып киттем.

«Хәким абый, теге урамга чыгыйк әле, бәлкем, анда сине танымаслар»–дип, кинәш биреп барам. Урам буйлап икәү: «Кому рыба, кому рыба?»–дип кычкырып барабыз. Беркем дә балык алырга чыкмый. Шактый озак йөргәч, Хәким абый тагы кычкыра башлады: «Кому рыба, кому рыба?» Бер йорттан ике хатын-кыз килеп чыкты. «Нәрсә кычкырасыз, нәрсә бар? Кеше йоклый, ә сез монда...»–дип сүгенә үк башлаганнар иде. Берсе Хәким абыйны таныды ахыры: «Кара әле, кара, бу бабай артист түгелме сон? Абый, абый, син артист бит, әйеме?»–дип, икенчесе исә: «Кит, тиле, бу карт кеше, нинди артист булсын! Иртән-иртүк артист балык сатып йөри димени?! Юк инде, юк, нииндидер артистка охшаган гына. Хәзер исемен генә оныттым,»–дип үзара тарткалаша башлагач, мин урысча: «Пошли, тут нам нечего делать»,–дип Хәким абыйны тизрәк алып киттем. Хәким абый: «Эх, таныйлар бит»,–дип эчтән нәрсәдер сүгенде. «Хәким абый, синең белән бу балыкны сатып булмас ахыры, сине бөтен кеше белә, әйдә, бозылып беткәнче, кайтыйк, урыслар үзләре балык тота, аларга кирәкми, ә татарлар сине беләләр»–дим. Инде шулай кире кайтырга торганда, кинәт исемә төште, минем бит таныш хатын Зинка складта эшли. «Әйдә әле,–дим,–минем танышыма кереп чыгыйк. Бәлкем ул ярдәм итәр». Тәрәзәсен шакып, Зинканы уяттым.

–Ты что, Шакиров, с утра стучишь?

–Зина, менә безнең ике чиләк балык бар, сатарга уйлаган идек, безне таныйлар, оялдык, хәзер инде нишләргә белмим. Зинһар, ярдәм ит!

Зинаида Михайловна складны ачты да, балыкларны үлчәде, 20 килодан артык, 70 тиеннән, 14 сум акча бирде. Мин таныш марҗама рәхмәтләремне әйтеп, Хәким абыйны сөендереп, үземнең кемлегемне баш режиссерның әтисенә күрсәттем. Кайтырга чыктык. «Столовый» янына житкәч, Хәким абый әйтә: «Әйдә, Гөлнарга бер шоколад алыйк»–ди. Кердек ашханәгә, карасак, кукуруздан эшләнгән «Шепучий» саталар. Ул үзе шампанский шешәсендә, ләкин градусы бик аз. Хәким абый шул «Шепучий»ны алды. Минем әле үз гомеремдә «Шепучий» эчкәнем юк, шуна күрә ничек ачарга икән дип, аптырап тора идем, Хәким абый минем кулдан тартып алды да, ачарга тотынды. Пробкасын ачып бетергәч кенә, кулыннан ычкынып китте дә, өстәлгә килеп төште. Эчмәгәндә Хәким абыйның куллары калтырый иде (нәрсәдән икәнен яхшы беләсез). Шул вакыт бөтен «Шепучий» шампанский кебек очты да бетте. Бөтен өстәл тулды. Житмәсә, җыештыручы марҗалар Хәким абыйны сүгәләр, ача белмәгәч, ачмаска иде, дип. Икебезнең дә кәеф китте. Мин Гөлнарга шоколад алдым да, әйдә, кайтыйк, дим. Күрәм, Хәким абыйның сөйләшәсе дә килми, кайтасы да килми. Мина әйтә:

–Күпме балык сатып, коры кул белән Марсель янына кайтасым килми, әйдә, аракы ал!

Киттек кире тагын Зинкага.

–Зиночка, зинһар, бир инде безгә бер литр аракы, «Шепучий» эчмәкче идек тә ваттык, хур булдык...

Ул рәхәтләнеп, эче катып, егыла-егыла көлде, мин тагын бер ике кызык әйбер сөйләп күңелен күтәргәч, түзмәде, ике ярты аракы бирде. Кайтырга чыктык. Шунда Хәким абый әйтә:

–Әйдә, берсен ачып, берәр йөз грам эчик, калганын Марсельгә бирербез.

Кая инде ул, йөз грамм эчкәч, аракы кала мени, икебезгә бер ярты бетте.

–Ярый,–мин әйтәм.–Әйдә, Хәким абый, өйгә кайтыйк, Марсельгә бер ярты бар, Гөлнарга шоколад, калган акчасын бирерсен,–дип, юлга чыктык. Хәким абый телгә бик оста кеше, театр, артистлар, режиссерлар турында кызык итеп, истә калырлык чын мәгънә белән сөйли иде. Мин авызына гына карап барам. Шулай бара-бара бер вакыт болай ди бу: «Әзһәр, инде картайдым, үләр вакыт килеп житте. Мин үлгәч, сөйләрсең бит, Хәким абыйны сыйлый да алмадым, нинди зур үкенеч булып калды, дип»... Шушы сүз житә калды.

–Хәким абый, теләсән, ач теге калган яртыны!–дим.–Тагы бераз ял итеп алыйк.

Хәким абый шуны гына көткән булган икән, күнеле күтәрелеп китте.

–Мин бит синең нинди артист икәненне беләм!–ди бу.–Менә Туфанның «Канкай углы Бәхтияр»ендә сина Пугачев ролен бирергә әйттем әле. Анда сине зур эш көтә!

Мин нишләргә белмичә, сөенечемнән Хәким абыйга рәхмәт әйтә-әйтә, теге яртыны да бетердек. Хәзер инде буш шешәгә карап торам, ничек инде бер нәрсәсез Марсель Хәкимович янына кайтасың?!

–Хәким абый, буш кул белән кайтып булмый, әйдә барыйк, алыйк тагы бер литр, юкса, Марсельдән, Гулядан оят!

Киттек кире Зинага.

–Ты что, Шакиров, не видишь, что старик совсем осяк?

Минем ялынуыма Зина түзмәде, бирде.

–Прошу, больше не приходи!–ди үзе.

Тагын әкрен генә юлга чыктык. Минем инде хәзер үземне мактатасым килә:

–Син, Хәким абый, үз гомереңдә бер мәртәбә менә шулай эшли алыр идеңме? Юк бит, синнән булмый, гомереңдә бер кемне дә сыйлаганың юк бит. Эчкәч тә кагасың.

–Э-эх, Әзһәр энем, минем акчам булсамы-ы? Аннан соң, сине бит бөтен кеше белә, хөрмәт итә, үзең талантлы, син миңа безнең бөек артистларны хәтерләтәсең!–дип, син шундый, син мондый дип, мине күккә чөеп мактый башлады бу.–Аннан соң сине Марсель дә бик ярата бит...

Миңа инде шул сүз житә калды, бер яртыны ачып, Хәким абыйга әз генә салып бирдем.

–Ярый әле,–мин әйтәм,–синең кебек бөек, талантлы артист белән балык сатарга чыктык. Күрдеңме, үзеңне бөтен татар халкы белә, без менә нинди кешеләр!–дип, күкрәк кага башладым.

Хәким абый жылый.

–Булмады бит мин яшь чакта шундый артистлар, ничек эшләр идек без синең белән! Марсельне мин өйрәтәм. Мин аңлаттым аңа татар драматургиясен!–дип, агай янә ачылып китте.

Мин жырлыйм, ул нәрсәдер сөйли, ничек кайтып житкәнебезне хәтерләмим. Калган яртыны агач төбенә күмдек. Иртәгә алырбыз, янәсе. Марсель безне: хәзер кайталар, хәзер кайталар, дип бик тилмереп көткән. Без юк та юк, нишләргә белмичә, хатыным Сажидә янына кереп чыккан. Безнең арт сабакны укытырга дип торганда, мин Хәким абыйны житәкләп, көч-хәл белән кайтуыбызны күргәч, бик каты бер-ике мәртәбә кычкырды да, тынды. Мин әйтәм: «Марсель, Хәким абыйны бөтен «Светлая поляна» сыйлады. Нишләсен, ул да кеше бит, шул хәтле мактауга артист йөрәге түзә мени, әз генә капты. Әтиеңне исән-сау алып кайттым, рәхмәт әйт! Аракыны жыеп куйдым агач төбенә, борчылма, табарбыз. 10 сум акчасы кесәсендә. Без гаепле, үпкәләмә».

Икенче көнне көчкә таптык ул аракыны, эзләмәгән жир калмады. Шуннан бирле мине Хәким абый белән беркая да жибәргәннәре булмады.

*Ахыры киләсе санда*

# К

**КЫЙССА** (гарәп. хикәя, тарихи вакыйга, риваять), мөселман Шәрык халыклары фольклоры һәм әдәбиятындагы (ш.и. татар әдәбиятында) дастанга якын булган эпик, кайвакыт лироэпик жанр. Гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә «К.» атамасы б-н хикайәт, повесть, әкият, риваять һ.б. жанрларны атыйлар. К. героик, мәхәббәт-романтик, дини-суфи, әкияти, тарихи сюжетларны үз эченә ала, анда гыйбрәтле, мажаралы, кызыклы вакыйгалар тасвирлана. Шул ук вакытта шәрык әдәбиятына хас чынбарлык б-н фантастиканы берләштергән образлар һәм ысуллар кулланыла; романтик сәнгати фикерләү тибы өстенлек итә. К. тезмә, чәчмә һәм катыш рәвештә була. Кайберләрендә (бигрәк тә шигъри әсәрдә) лирик чигенешләр, автор, әсәр геройларынын фәлсәфи уйланулары урын ала. «Кысалы кыйссалар» аерым бер төр тәшкил итәләр. Аларда берничә мөстәкыйль сюжет бер сюжетка берләшә. Татар әдәбиятында К. жанрындагы әсәрләр 13 гасырдан ук билгеле (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия»се һ.б.). К.лар бигрәк тә 19 йөздә киң таралган була (Ә.Кормаши, Г.Мәхмүдов, К.Минзәләви, Ш.Рәхмәтуллин һ.б.ларның поэтик әсәрләрендә).

Әд.: Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. К., 1998.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«КЫЙССАИ АВЫК»** («Тау кәҗәсе турында хикайәт»), 14—15 йөзләр төрки—татар әдәбияты ядкәре. Авторы билгесез. 38 строфадан тора. Әсәрнең нигезен кяферләр кулына эләккән кыргый газәлнең Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан коткарылуы турында мажаралы сюжет тәшкил итә; кыйссада пәйгамбәрнең мәрхәмәтлелеге һәм гадәттән тыш мөмкинлекләре турында бәян ителә, ныклык һәм әйткән сүзгә тугрылык сыйфатлары хуплана. «К.А.» Идел буе һәм Урал төбәге татарлары арасында зур популярлык казана, һәм анын кульязма нөсхәләре күп таралган була.

Әд.: Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Хан кызы: Мөнәҗәтләр. К., 1994; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«КЫЙССАИ ЙОСЫФ»** («Йосыф турында кыйсса», 1233), урта гасырлар төрки-татар әдәбияты ядкәре. Авторы—шагыйрь Кол Гали. Поэманың сюжеты Йосыф пәйгамбәр турында Тәүратта һәм Коръәндә бәян ителгән кыйссага нигезләнә. Бу темага дөнья, аеруча Шәрык (100 гә якын) әдәбияты әсәрләре күпләп багышланган. Әлеге сюжетка беренче булып мөрәҗәгать иткән төрки телле язучы—Кол Гали. Аның әсәре урта гасыр башы төрки телле әдәбиятлар тарихында яңа сәхифә ача. Урта гасыр төрки шагыйрьләр Шәйяд Хәмзә, Сүли Фәкыйһ, Дурбәк һ.б. иҗатында Кол Гали поэмасының йогынтысы да сизелә. Әсәрнең фабуласын эшкәрткәндә, автор төрки эпос традицияләренә таяна. Мәс., әсәрнең төп геройлары—чыгышлары б-н төрле илләрдән: Йосыф—Кәнгъәннән (Фәлестин, Финикия һәм Сүрия җирләренең борынгы исеме), Зөләйха—Мәгъриб (Көнбатыш Африка) патшасы кызы. Йосыфнын тышкы кыяфәтен шагыйрь төркиләрчә тасвирлый: чәчләре толымлап үрелгән. Бу күренеш төрки этнографиясе буенча анын аксөякләр ыруыннан булуы турында сөйли. Әсәрдә күп кенә гомумкешелек мәсьәләләре чагылыш тапкан: яхшы б-н яман арасындагы көрәш, кешеләрнең бәхеткә, гаделлеккә, әхлакый камиллеккә омтылулары. Хикәяләүдә гипербола, күпкатлы метафорага мөрәҗәгать итеп, шагыйрь характерларны, вакыйгаларны, конфликтларны эреләтә, геройларнын әхлакый асылын ачып бирә. Әсәр үзәгендә—хөкемдар һәм халык тормышы өчен уңай шартлар тудыруда анын роле мәсьәләләре. Алар Йосыф образы аша хәл ителә. Әсәрнең калган проблематикасы да шушы тема б-н бәйле. Төп герой язмышында ул заман өчен новатор идея—түбән катлам кешесенең хөкемдар

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

дәрәҗәсенә ирешүе гәүдәләндерелә. Ләкин бу гына әсәрнең масштаблы мәгънәсен ачып бетерми. Йосыф күп газаплар күрә һәм бәхетсезлекләргә юлыга: көнче энеләре хыянәте (алар аны агулы еланнар б-н тулган коега ташлыйлар), чит илгә эләгүе, коллыкка сатылуы, зинданга ябылуы. Ләкин ул күңел төшенкелегенә бирелми, намусына хыянәт итми, һәрвакытта да иманлы, дөрес, тотнаклы, нык, сатылмас гадел, шәфкатьле, гади һәм кеше сөючән булып кала. Төп геройның иң мөһим сыйфаты—тугрылык; бу аның антына, кальбенә һәм гореф-гадәтләргә тугрылыгында гәүдәләнә. Шул рәвешчә, тугрылык, бәхеткә ирешүнең төп шарты буларак, поэманың лейтмотивы булып китә. Әлеге мотив Йосыфның төшендә чагылып, поэманың ахырына кадәр (Йосыфның атасы б-н очрашуына кадәр) дәвам итә.

Икенче бер әһәмиятле тема—ата б-н бала арасындагы мөнәсәбәтләр. Йагъкуб акыл иясе, сабыр, улы б-н кайчан да булса очрашуына ышанып яшәүче кеше буларак тасвирлана. Зөләйха образы да зур әһәмияткә ия. Бу ике персонаж да төп геройга мөнәсәбәтләре аркылы ачыла. Зөләйха, Йосыфны төшендә күреп, аңа гашыйк була. Шул рәвешчә, әсәргә шәрык әдәбиятына хас читтән торып гашыйк булу мотивы килеп керә. Зөләйха укучы күз алдына тугрылык һәм сабырлык үрнәге булып килеп баса. Геройның абыйлары әсәрдә гомуми планда гына бирелә. Алар индивидуальләштерелмәгән, 11 нән бары 4 се генә исеме аталган: Бинъямин, Равил, Йәһүд, Шәмгун. Бинъяминнән калганнары үзара бик охшаш: кече энеләренә карата көнче, алдакчы, рәхимсез. Йосыф исә, Мисыр хакиме булгач, абыйларын кичерә, алар аннан гафу үтенәләр.

Беренче булып поэманы татар шагыйре һәм акыл иясе Г.Утыз Имәни өйрәнә. Ул 1824 тә 10 га якын күчермәне чагыштырып, «К.Й» ның җыелма текстын басмага әзерли. Поэма 1839 да татар мәгърифәтчесе Р.Әмирханов тарафыннан нәшер ителә. 1831 дә немец ориенталисты Г.Л.Флейшер Дрезден китапханәсендә сакланган поэма күчермәсен шәрык кульъязмалары каталогына кертә. 1889 да Голландия галиме М.Хоутсма текстның берничә кульъязмасы нигезендә әсәргә сюжет һәм тел ягыннан анализ ясый. 1885 тә поэмага Ш.Мәрҗани мөрәҗәгать итә. «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенең 1 нче томында ул поэма теленең Идел буе Болгар дәүләте чоры эпитафияләре б-н охшашлыгы турында яза. 1917 дә язылган хезмәтендә немец ориенталисты К.Броккельман поэманың кайсы милләтнеке (төрекләрнеке итеп) икәнен ачыкларга омтылыш ясый. 1918 дә төрек галиме Ф. Күпрелезадә әсәрнең поэтик үзенчәлекләренә игътибар итә, һәм аның (поэманың) формасын борынгы төрки халык поэзиясендә традицион булган формалар б-н бәйли. 20 йөзнең 1 нче яртысында поэманы рус һәм татар галимнәре А.Н.Самойлович, Е.Э.Бертельс, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Б.Ә.Яфаровлар өйрәнә. 20 йөзнең 2 нче яртысында татар галиме Ж.Алмаз поэма текстын фәнни басмага әзерли, ләкин әсәр басылмый кала. 1960—70 елларда әсәрне өйрәнүне татар галимнәре М.Х.Гайнуллин, Х.Г.Госманов, Р.К.Ганиева, Х.Й.Миңнегулов h.б.лар дәвам иттерә. 1983 тә поэманың билгеле булган барлык күчермәләре нигезендә беренче тапкыр җыелма тәнкыйди-фәнни академик басма нәшер ителә. Кульъязмаларны тасвирлау, төп текстларны әзерләү, кереш мәкалә һәм комментарийларны язу эшен Ф.С.Фасеев башкара. 1979 да һәм 1984 тә Н.Ш.Хисамовның «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы: Сюжет чыганакларына һәм автор иҗатына анализ» («Поэма «Кыссаи Юсуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества», М., 1979) һәм «Бөек язмышлы әсәр» (1984) монографияләре басылып чыга. Бу хезмәтләрдә барлык чыганаклар өйрәнелә. Алар арасында автор төп чыганак итеп Герат (хәзер Әфганстан) галиме Ә.Әнсариның «Әнисел-мөридин вә шәмсел-мәҗалис» әсәрен (11 йөз) күрсәтә, иң мөһим сюжет мотивларының фольклор—эпик һәм этнографик тамырларын ача, әсәргә төрле яклы филологик анализ ясый. Н.Ш.Хисамов поэманың хәзерге татар телендә шигъри тәрҗемәсен дә бирә (2000). «К.Й.» поэмасы татар халык поэзиясенә хас булган манерада язылган: строфа дүрт юлдан тора, аааб схемасында рифмалаша, текстның буеннан-буена «имди» рәдифе бара.

*Гәүһәр—таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,*
*Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас,*
*Бу назымның кадерен һич ахмак белмәс,—*
*Гакыллар тыңлар, аңлар, белер имди.*

Строфика моделе Урта Азия шагыйре Әхмәд Ясәвидән алынган. Поэма әдәби төрки телдә язылган, бер үк вакытта угыз һәм кыпчак элементлары да очрый (мондый күренеш башка урта гасыр төрки—татар әдәби ядкәрләренә, ш.и. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәрләренә дә хас). Әсәр татар халкының эстетик күзаллавын тәрбияләүдә, аның әдәби телен үстерүдә зур роль уйный, халык авыз

ижатына әһәмиятле йогынты ясый. ТРда һәм татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә (Пермь өлкәсе, Башкортстан Респ-касы, Түбән Новгород һәм Оренбург өлкәләре, Әстерхан шәһәре һ.б.) поэманың 300 гә якын күчермәсе табыла. 1983 ел мәгълүматларына караганда, «К.Й» нең билгеле булган гомуми (161) күчермәләренең күбесе (115) Татарстан жирендә табыла. Казанда гына да 1839 дан башлап поэма 80 гә якын тапкыр нәшер ителә.

Поэма мотивлары буенча Н.Ш.Хисамов тарафыннан «Йосыф-Зөләйха» (1992) исемле тарихи драма языла, Л.З.Любовский «К.Й» балетына музыка яза һәм аның премьерасы 2001 дә булып уза (РФнең Дәүләт бүләге, 2005).

Чыг.: Гали (XII йөзнең азагы, XIII йөзнең башы) // Татар поэзиясе антологиясе. К., 1956; «Йосыф вә Зөләйха» // Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Кыссаи Йосыф. К., 1983; Йосыф кыйссасы. К., 2000; Юсуф и Зулейха (отрывки) // Антология татарской поэзии. К., 1957; Сказание о Йусуфе. К., 1985.

Әд.: Хисамов Н.Ш. Бөек язмышлы әсәр. К., 1984; Таһиржанов Г. Фирдәүси һәм Колгали // Казан утлары. 1968.№ 12; Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.1. К., 1984; Алмаз Дж. «Кысса-и Юсуф» Али-булгаро-татарский памятник // Труды XXV Международного конгресса востоковедов. М., 1960; Наджип Э.Н. О языке памятника начала XIII в. «Кысса-и Юсуф» Али // Советская тюркология. 1976. № 2; Тенишев Э.Р. О языке поэмы Кул Гали «Кысса-и Юсуф» // Turcologika 1986/ Л., 1986; Поэт—гуманист Кул Гали. К., 1987; Ахунов А.М. Арабский источник средневековой тюрко-татарской литературы: на материале трудов ат-Табари. К., 2001; Кузьмина Х.Х. Лексика поэмы кул Гали «Кыссаи Йусуф». К., 2001; Хисамов Н.Ш. Поэма «Кыссаи Юсуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества. М., 1979; его же. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XII—XV вв.: Проблема версий. К., 2001.

*Н.Ш.Хисамов.*

**«КЫЙССАИ СӘЕТБАТТАЛ ГАЗЫЙ»** («Сәетбаттал каһарман турында хикайәт»), урта гасырлар госманлы төрек әдәбияты ядкәре; героик дастан. Төп герой—Абдуллах Баттал (ш.у. фарсы тарихчысы әт-Табари (839—923) әсәренен төрек версиясендә искә алына) гарәпләр ягында византиялеләргә каршы сугыша. 740 та Акроинос (Кече Азия) янында сугышканда һәлак була. Дастан сәлҗүкләр эпосына нигезләнә. Анда төрки сугышчыларының каһарманлыклары, аларның башлыклары Сәетбатталның легендар батырлыклары сурәтләнә.

Башта телдән-телгә йөри, 14-15 йөзләрдә языла. Татарлар арасында 17 йөзгә кадәр киң таралган була. Дастанның иң борынгы татарча нөсхәсе 1709 елга карый. 19 йөздән алып берничә тапкыр нәшер ителә. Сәетбаттал каһарманлыгы темасы татар әдәбиятында да эшкәртелә. «Сәетбаттал китабы», «Мәнакыйбе Сәетбаттал газый», «Сирәте Сәетбаттал газый» кебек охшаш исемле күптөрле татар вариантлары да бар. Әлеге ядкәрне Европа, рус һәм татар галимнәре өйрәнә: Г.Флейшер, Гаммер-Пургшталь, В.Д.Смирнов, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты каршындагы кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә «К.С.Г.»ның 7 нөсхәсе саклана.

Әд.: Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. 1 җилд. Борынгы дәвер. К., 1923. 2 бүлек.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Әҗем

Әҗем авылы Апас районында, район үзәге Апастан—16, җирле үзидарә советы үзәге Әлмәндәр авылыннан 2 чакрым ераклыкта урнашкан.

Әҗем авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. 1565-67 еллардагы мәгълүматларны эченә алган Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә Әҗем суы һәм аның ярына утырган Әҗем авылы күрсәтелгән. Археологлар Әҗем авылы янында бронза чорыннан калган истәлек тапканнар.

XVIII йөз җыентыгында Әҗем авылында 136 ясаклы татар, 19 керәшен татары яшәгәнлеге әйтелә.

Казандагы Әҗем мәчете белән шушы Әҗем авылы арасында тыгыз бәйләнеш бар шикелле.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, авыл моннан 480—500 еллар элек барлыкка килгән. Аны башта Әҗмәр баба элеккеге Тәмте районы җирендәге Алгазы чокырлыгында нигезләгән. Әҗмәр бабайның чыгышы Болгардан була. Әҗмәр соңыннан Әҗемгә үзгәргән, диләр. Бу тирәләргә соңыннан руслар килеп утыра һәм Әҗмәр-Әҗем бабайны бу җирдән куып җибәрәләр. Әҗем бабай авылны хәзерге урынына нигезли. Балалары Йолдыз һәм Керәле авылына нигез салалар. Керәле авылында Әҗем чокыры дигән топоним әлегә кадәр сакланып калган.

Әҗем авылы урнашкан урын кара урман уртасында була. Басуларны урманнан чистартып ясыйлар.

Авылга нисбәтле географик берәмлекләр шактый. Авыл янынnан Әҗем суы агып үтә. Халык аны икенче төрле Инеш дип атый. Әҗем суының тота торган гадәте бар дип сөйлиләр. Әгәр суына сокланып юынсаң, битең бозыла, аягың аксый, имеш. Әҗем суын авыл халкы тагын Югары Әҗем буе һәм Түбән Әҗем буе дип тә атап йөртә. Югары Әҗем буенда Изгеләр зираты урнашкан.

Югары Әҗем буенда кызыклы гына йола да башкарылган. Елга янында чуашлар ак ат суеп авыл халкын сыйлап китә торган булганнар.

Авыл басуыннан Камыл, Камыш, Каз, Коры, Төбәк елгалары ага.

## Әлки авыллары

Атамаларында «Әлки» берәмлеге булган авыллар Әлки районында урнашкан. Районның үзәге—Базарлы Матак авылы. Түбән Әлки авылы Базарлы Матактан—16, Югары Әлки—19, Урта Әлки 13 чакрым ераклыкта урнашкан. Һәр өч авылда татарлар яши.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Кама аръягында Нугай юлы өстенә урнашкан Әлки авылы Казан ханлыгы чоры чыганакларында телгә алына. Югары һәм Түбән Әлки авыллары янында археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл урыны билгеләгәннәр.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, Урта Әлкине Әлки исемле кеше нигезләгән. Авылда «Әлки бабай түбәсе» дип аталган җир бар. Имеш, бу урында Әлки бабай утырып, чабатасын каккан икән. Башка авылларда мондый легенда Алып бабай исеме белән бәйле.

Түбән Әлки авылында элек өч өйдә руслар яшәгән, ләкин аларның олы яшьтәгеләре инде үлгән, калганнары моннан киткән. Биредә элек керәшен татарлары да булган. Аларны аерым зиратка күмгәннәр. Вакытлар үтү белән алар исламга кайткан. Түбән Әлки авылы халкы, аксакаллар әйтүенә караганда, Чирмешән суы буендагы Иске зират яныннан күчеп килгән. Авыл яныннан Ата суы ага. Ул Кече Чирмешәнгә коя.

Авылдан 200—300 метр ераклыкта Иске авыл булган. Ул тау битенә урнашып, түбәнлеккә таба кинәя барган. Монда болынлык җәелеп ята. Бу урыннарны казыганда көлнең бик калын булуы ачыклана. 150—180 еллар элек Югары Әлки Иске авылдан хәзерге урынына күчкән.

Түбән Әлки һәм Югары Әлки җирләрендә Кыналык чыгыры (чокыры) дип аталган инеш ага. Ул суын Ата елгасына китерә. Башланган җире урманда, сазлыктан. Аны Кочкарь дип тә атыйлар. Ата суына тагын Ермак, Тирән һәм Сай, Мал чокырлары, Кәҗә ташуы инешләре кушыла.

Тирә-юньдә күлләр шактый күп.

Югары Әлки һәм Түбән Әлки авылларында Татар академия театры артистлары Рузия Мотыйгуллина һәм Әсхәт Хисмәтов туып-үскәннәр.

## Әлмәндәр

Әлмәндәр авылы Апас районында, район үзәге Апастан 19 чакрым ераклыкта урнашкан.

XVIII йөздә Әлмәндәр авылында 132 ясаклы, 29 йомышлы татар һәм 9 керәшен татары яшәгән.

Аксакаллар сөйләве буенча, авыл шактый борынгы һәм аны нигезләүчеләр үзләрен Шәһри Болгардан килеп утыручыларның варислары дип саный, беренче килеп утырган җиде гаилә арасында иң өлкәне Әлмәндәр атлы булган һәм авыл аның исемен алган.

Икенче берәүләр сөйләвенә караганда, авылны беренче тапкыр Әлмөхәммәт исемле кеше нигезләгән.

Авыл урынында элек кара урман үскән. Каенлык, Шомыртлы куак, Агачлар рәте (Урман рәте) атамасы алган җирләр—шул вакытлардан калган истәлекләр.

Әҗем авылы белән ике арада борынгы зират була, ләкин хәзер ул беткән, сукаланган. Моннан тыш, авылда тагын Шәкертләр зираты, Югары зират бар. Керәшен татарларын аерым, керәшен зиратына күмгәннәр. Халык бу зират урынын белә. Авылда мукшылар да булган, ләкин алар Борнаш авылына китеп урнашканнар. Борнаш авылы кешеләре Әлмәндәр халкына чуаш кушаматы тагып йөртәләр.

Авыл инешен икенче төрле Әкә суы дип йөртәләр. Ул суын Үләмә елгасына илтеп коя. Борнаш авылы белән ике арада Мүкле күл бар. Чукындыру афәте килгәч бу күлгә халыкны куып кертеп, чукынмаган өчен кыйнаганнар.

Авылда һәм тирә-юньдә чишмәләр байтак. Иман, Кизләү чишмәләренең сулары тәмле, тирәләре каралган.

Авыл уртасында ике катлы мәдәният йорты бар, 1989 елдан алып анда туган якны өйрәнү музее эшли.

## Әсән-Елга

Әсән-Елга авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 9 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Пычак авылыннан—2, Вятка аланы пристаненнән 17 чакрым ераклыкта урнашкан.

Олылар, авыллары оешу турында болай сөйли.

Борын заманнарда Әсән исемле кеше авыл булачак урын яныннан агучы елга башлана торган чишмә янына килеп, йорт салып яши башлаган. Елга буйлап йомычка агып төшкәч, кешеләр кызыксынып, аның башлангычына барып караганнар. Килгән халык Әсәнне тапкан. Әсән үзе генә яши алмаган, күчеп киткән. Авыл Әсән Елгасы дип йөртелә башлаган.

Халык телендә авыл оешу турында икенче риваять тә бар.

Борын заманнарда авыл кырыеннан ага торган елга мул сулы булган. Авылдан бераз читтәрәк, тау битендә Әсән исемле кеше үзе генә яшәгән. Көннәрдән бер көнне аның йортында ут чыккан һәм ул янгынны сүндерү өчен су ташыганда елгага баткан, Әсәнне коткарып кала алмаганнар, йорты да янып беткән. Шуннан авыл Әсән-Елга исемен алган.

Авыл республиканың төньяк-көнчыгышында урнашкан. Табигате бик матур. Әсән-Елга озын бер урамнан тора. Йортлар бер-берсенә каратып салынган. Тирә-як халкы Әсән-Елга урамын чәч юлы кебек туры дип сөйли.

Ул буйдан-буйга 3 чакрымга сузылган. Аны 1919 елларда таш белән түшәгән булганнар. Урамның ике ягында төп-төз агачлар үсә.

Халык телендә авылны Көек дип тә йөртәләр. Бу исем каты янгыннардан соң калган, диләр. Көйгән, ягъни көек.

Авылның нәкъ уртасында мәчет урнашкан. Ул шактый күптән салынган. Аның кайчан төзелүен төгәл генә белүче юк. Анда хәзерге халыкның ата-бабалары йөргән. Манарасы киселмичә исән-имин калган. 1991 елда мәчетне һәм аның манарасын яңартканнар. Ул хәзер гөрләтеп эшли. Авыл картлары бирегә намаз укырга йөри. Колхозлашу чорларына кадәр мәчет белән рәттән урнашкан мәдрәсәдә муллалар ир балаларга сабак укыткан. Ә кызлар абыстайга йөреп сабак алган. Соңыннан мәдрәсә бинасы мәктәпкә әйләндерелгән.

Авылдан күренекле шәхесләр шактый чыккан. Пугачев явында полковник дәрәҗәсендә йөргән Мәсәгут Гомәрев, халык җырчысы Мәрьям Рахманкулова, әдәбият галиме, язучы Фуат Галимуллин, күренекле профессор Мәхмүт Яхин, Фәйзелхак Газизуллин, техник фәннәр докторы Фуат Шакиров, күренекле шагыйрь Әхмәт Юныс һ.б.

Әхмәт Юныс укыган һәм укыткан мәктәптә аңа багышланган музей бүлмәсе дә ачылган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

## «МИН ЙОЛДЫЗ ТҮГЕЛ, ҖЫРЧЫ ГЫНА»

*Бөек җырчы Фәридә Кудашевага бу елның декабрь аенда 90 яшь туласы иде. Кызганыч, күптән түгел генә аяусыз үлем аны арабыздан алып китте. Бу язма аның юбилее уңаеннан әзерләнгән иде. Без аны шул килеш, үзгәртмичә бирергә булдык.*

Озак еллар буе яратып укыган «Казан утлары» журналына биргән әңгәмәсендә Фәридә апа авыр бала чагы турында да, иҗатка ничек итеп килүе хакында да, сәнгать мәйданында кемнәр белән дус-иҗатташ булуы турында да истәлекләре белән уртаклашты.



Фәридә Кудашева—татар морзалары, затлы-зыялы Кудашевлар нәселеннән. Шуңа да аңа—иҗатына чын зыялылык, халыкчанлык, миллилек хас.

—Ата-бабаларыбыз морзалардан булуын белеп үссәк тә, элек аны күрсәтү ярамый иде,—ди Фәридә апа.—Хәзер генә мода китте ул морзалык белән мактану модасы, гәрчә кайбер шундый атама белән мактанучылар бу дәрәҗәгә бөтенләй туры килмәсәләр дә. Мин шуны хәтерлим—гаиләләребездә тәрбия бик күркәм иде. Безнең Келәш авылы—данлыклы татар авылы, укымышлы кешеләре дә күп иде. Күп атаклы шәхесләр чыкты бездән—Сәйфи Кудаш—минем әтиемнең энесе, Мостай Кәрим һәм башка күренекле затлар.

Мин үзем кечкенә чактан бик юаш, сабыр, тыныч идем. Ләкин шул ук вакытта шуклыкларым да була иде. Башымның тишелмәгән чагы аз булыр иде. Шулай да тыңлаучан, тәртипле бала булдым. Әнием мине «акыллы кызым» дип, гел аркамнан сөеп-яратып кына тора иде. Әнием бик тә зирәк хатын иде. 3 еллык мәдрәсәдә белем алган. Аннан соң үзлегеннән әллә күпме китаплар укыганы хәтердә. Аларны күренеп торган җиргә куя иде. Миңа «син дә укы» дип әйтми, ә күренгән урынга гына куя. Мин инде аңлый идем, алып укый идем. Күбрәк балалар китаплары укыдым. Туганыбыз Сәйфи Кудашның китапларын да укый идем ул чакта ук.

Мәктәпкә укырга төшәр алдыннан, мин Келәштән Уфага Сәйфи абыйларга килдем һәм аның кызы Сөембикә белән бер ел балалар бакчасының әзерлек бүлегенә йөрдек. Сөембикә белән бик күп китаплар укыдык. Ә бит безгә 6-7 яшь чаклар гына. Укырга сәләтебез дә теләгебез дә бик көчле иде.

Минем әти гаиләсендә 11 малай, бер кыз булган, ләкин ул кыз кечкенә чагында ук үлгән. 11 малай бер-берсенә ярдәмләшеп үскәннәр. Әтинең әтисе 40 яшьтә үк үлеп китә һәм 11 малайны әниләре карап үстерә, күз алдыгызга китерегез, ничек

бу хәтле йөкне тартып була! Малайлар үсә-үсә үзләре дә, әлбәттә, йорт-курада кул арасына керә. Шунысы хөрмәткә лаек—яшәргә ничек кенә кыен булмасын, 11 малайның барысы да диярлек музыкага, жыр-моңга тартылалар, сәләтлеләр иде. Гармунда, мандолинада бик матур уйныйлар иде. Бигрәк тә Әхияретдин абыйның моңлы жырлаулары һәм музыка коралларында өздереп уйнаулары истә калган.

**—Фәридә апа, димәк жыр-моңга сәләт Сезгә дә алардан күчкән, каннан килә бу талант.**

—Мин дә шулай дип уйлыйм. Чөнки кечкенәдән үк жырлый идем мин. Сеңлем дә матур жырлый иде. Аның белән өйдә сәке янына өстәлне китереп терибез дә, шуңа басып жырлыйбыз, концерт куябыз. Ә жырлап беткәч, йә шигырь сөйләгәч, сәкегә төшеп китәбез, анда чаршау да эленгән, монысы инде сәхнә арты, кулиса арты килеп чыга безнең өчен.

**—Сезгә ул чакта ничә яшьләр иде?**

—7-8 яшьләр инде, бәләкәй генә идек, ләкин хәтердә бик тә уелып калган шул чаклар.

*Автордан:* Фәридә Кудашевага кечкенәдән күп михнәтләр кичерергә туры килә. Гаиләләренә «кулак» дигән мөһер сугып, бар мөлкәтләрен тартып алалар. Күпмедер вакыттан соң алардан бу гаеп алына, әмма инде малларын кире кайтармыйлар. Шуннан әтисе «Башсоюз» ширкәте юлламасы белән, сәүдә эшләрен торгызу максатында, Баймак якларына чыгып китә. Башлангыч белемне башта туган авылы—Чишмә районының Келәш авылында, аннан соң Баймакта, аннан Кыйгы районында ала Фәридә. Артист, жырчы булу теләге исә тулысынча Кыйгы районында яшәгән чакта ныгый аның.

**—Фәридә апа, истәлекләрегездә туган авылыгыз Келәштән китүнең бала күңеленә бик авыр булганын әйткәнегез бар.**

—Әйе, бу күчүләр минем өчен бик күңелсез, сагышлы булды. Туган илдән кем туйган инде. Минем өчен бер кайгы булды ул вакыйгалар. Урал артына киттек бит инде. Бу минем өчен нindидер ерак чит илгә киткән кебек тоелды. Башкортлар арасына күчтек. Шунда башкортча да өйрәнергә туры килде. Минем ул якларга киткәндә жырлаган ике-өч жырым гомергә истә калды. Менә аларның берсе:

*Китәрмен илегездән,*
*Тынармын сүзегездән.*
*Сәхрәләрдә аккош булсам,*
*Су да эчмәм күлегездән.*

Монысы инде безнең гаиләне кулак дип рәнжетүләренә жавап булгандыр. Безнең авылда ике мәхәллә, ике мәчет бар иде. Аларның манаралары күккә ашкан. Шулардан азан тавышлары ишетелә. Искиткеч матур тавышлар инде. Сихри бер аһәң, сихри бер моң булып агыла иде алар. Шунда да ике жыр жырлаганым хәтердә.

*Иртә тордым иртә дип,*
*Намаз вакыты житә дип.*
*Азан әйтә, мин жылыймын,*
*Башым читкә китә дип.*

Манараларның сихри тавышы үзеннән-үзе безнең ул чактагы кәефне сагышлы итә иде. Жырламас жиреннән жырларсың!..

Аннан элек авылда яз көннәрендә киндер сугалар иде. Житен чәчәләр бит инде ул дәверләрдә. Шуны талкышлап эрлиләр, эшкәртәләр. Минем әни кул эшләренә бик оста иде—тегә, чигә, эрли, бәйли, белмәгәне юк инде! Аның бүләкләре, бирнәләре бар иде. Матур чигелгән, сугылган. Әле дә әниемнең бер тастымалын кадерләп саклыйм.

Киндер сугалар дип әйттем бит әле. Шул кадәр матур ритм белән сугалар иде аны. Үзе бер матур, моңлы музыка кебек янгырый иде бу эш барышы. Авылның бер башыннан икенче башына ишетелә иде бу могжизага тиң, галәмнән килгән төсле көйле тавышлар. Менә шул көйләр дә минем күңелемә моң орлыклары салгандыр димен.

**—Жырчы булырмын дигән теләк, сәнгать юлын сайлармын дигән максат, мәктәпне тәмамлаганда ук, үзеннән-үзе килдеме?**

—Күпкә элегрәк тә булгандыр инде ул. Чөнки мин, әйтүемчә, кечкенәдән жырлый идем. Ә мәктәптә, 1нче сыйныфта укыганда, туган авылыбыз Келәштә мине концертта жырлаттылар. Укытучым жырларга кушты. Нинди жыр жырлыйм соң, дип сораган идем, «Салкын чишмә» жырын жырла, диде. Белүегезчә, бу жыр бик иркен, киң сулыш таләп итә. Менә шуны жырладым. Хәзер инде ничек ул жырны ерып чыкканымны хәтерләмим, әмма бик озак кул чапканнары истә калган.



Элек бит авылда төрле мәдәни чараларда, бәйрәмнәрдә жырлаталар, аннан гаиләгә кунаклар килсә, алар алдында балаларны жырлаталар, биетәләр иде. Шундый гадәт бар иде. Шуннан минем яхшы гына жырлаганны күршеләр, авылдашлар, укытучылар белә башлады. Ә инде жырлый беләсең икән, сине бер чарадан да калдырмыйлар. Әбиләр-бабайлар әйтә торганнар иде минем хакта: «Бу бала йә бәхетсез, йә гомерсез булыр инде, бигрәк матур, моңлы жырлый»,—дип.

Ә сезнең жырчы булу теләгем турындагы соравыгызга шуны тәгаен әйтә алам. Кыйгы районында мәктәпне тәмамлагач та, артист булу теләгемнең көчле булуын аңладым. Мона бер көчле этәргеч тә булды. Элек бит кайбер районнарда колхоз-совхоз дәүләт театрлары бар иде. Кыйгыда да ачылды ул. Менә шул театр ачылганда, мин беренче спектакльдә уйнадым. Әнием үлгән яз иде, хәсрәтле-кайгылы чак. Төрле каршылыклы хисләр белән ул спектакльдә уйнарга ризалаштым. Анда мин башкарган рольдә ятим кыз бала, жырлый-жырлый, хәер сораша. Менә шул кызның образын уйнадым инде, халык бик ошатты. Бәлки театр актрисасы буларак әлләни осталыгым да булмагандыр, әмма жырымның сагышлы-моңлы чыгуын әле кайтып үзем дә аңлыйм.

Менә шул чактан мин үземне артист итеп хис итә идем инде. Мин шул юлдан китәргә телим дә соң, ләкин әтием, минем табиб булуымны теләп, Уфага медицина буенча укырга керергә жибәрде. Уфада башка туганнарыбыз юк бит инде, Сәйфи абый Кудаш кына бар гаиләсе белән. Аларга килдем. Сәйфи агадан сорыйм, кайда укырга барыйм икән дип. Сәйфи абый исә: »Үзең кая телисең, шунда кер»,—диде. Бу инде минем йөрәккә жылы йөгертте, канатландырды. Мин әйтәм Сәйфи аганың ризалыгы булгач, сәнгать юлыннан китсәм дә, әтием тиргәмәс әле, дим. Шулай итеп, ике дә уйламый, Уфа сәнгать техникумына барып кердем. Аны тәмамлагач, юллама белән барып, Дүртөйле колхоз-совхоз театрында эшләдем ике елга якын. Аннан соң Уфада филармония ачылды. Мине шунда эшкә алдылар. Мин анда эстрада төркемендә эшли башладым. Гастрольләрдә бик күп йөрергә туры килде. Зәмһәрир салкын кышларда ат чаналарында, авылдан-авылга йөргән чаклар да күп булды. Салкын клубларда «тере» тавыш белән жырладык. Яшь булганбыз, гайрәтле булганбыз инде.

**—Фәридә апа, сезнең үзегезнең дә әйткәнегез бар, иң җимешле иҗат елларым талантлы татар музыканты һәм композиторы Бәхти Гайсин белән бергә яшәгән һәм иҗат иткән еллар,—дип.**

—Бу чынлап та шулай. Мин башта филармониядә бер сукыр гармунчы Зарипов дигән агай белән эшләдем. Матур уйный иде баянда. Аннан соң музыкант Таһир Кәримов белән иҗат иттек, композиторлар әсәрләрен, татар һәм башкорт җырларын башкара идем. Ә Бәхти ул чакта Башкорт академтеатрында эшли иде. Шул чакта ук мин аның берничә җырын башкардым. Шуннан соң без аны филармониягә эшкә чакырдык. Искитмәле оста, виртуоз уйный иде ул музыка коралларында. Җайлап кына безнең Бәхти белән иҗат якынлыгы шәхси хис-тойгыларга да күчә башлады. Ә 1964 елдан без аның белән гаилә корып җибәрдек. Әлбәттә инде, музыкант һәм композитор белән бергә яшәү һәм гастрольләргә бергә йөрү җырчы өчен зур бәхет. Бәхти миңа гына әллә күпме яна җырлар язды, безнең репертуар шактый киңәйде. Әле минем 150дән артык җырым сакланып калган. Аларны тасмаларга язып, киләчәккә саклап калдык, ә күпме җырлар йә тасмага язылмады, йә язылса да югалды.

**—Фәридә апа, хәзерге җыр сәнгате турында төрле бәхәсләр бар. Халык җырларын башкара алучы талантлар кимүе дә билгеле...**

—Әгәр кеше халык җырларын, озын көйләрне башкара ала икән, аның табигатьтән бирелгән чын таланты бар дигән сүз. Ә хәзер яшьләр җинел-җилпе җырларга күбрәк йөз тота. Акча эшләү белән мавыгу да бар. Аңлыйм инде заманасы да шул, акча колына әйләндерә бу дәвер күп кешене, шул исәптән сәнгатькәрләрне дә. Сүз дә юк, хәзерге яшьләрнең кайберләре сәхнәгә чыгып бер-ике җыр башкара да, үзләрен әллә кемгә куя башлый. «Тере» тавышка җырлау юк дәрәҗәсендә. Фонограммага, «фанера»га җырлап, үз-үзләрен бетерәләр. Күпмедер сәләтләре булса да, аны камилләштермиләр. Шул килеш тә әле аларга йолдызлык чире йога. Кеше танымый башлыйлар, бер-бер артлы мактаулы исемнәр алалар. Ул бит «тере» тавышка җырласаң гына осталыгын арта, кимчелекләрне бетерә барасың, остарасың. Мин үземне элек тә, хәзер дә «йолдыз» дип исәпләмәдем. Мин бары тик Ходай биргән сәләтемнән чыгып, иҗат иттем, халкыма җырларым ошасын иде дип кенә уйладым.

**—Сезнең Татарстандагы әдипләр, җырчылар, композиторлар арасында да дусларыгыз күп иде. Алар Сезне «милләтебез сандугачы», «йолдызыбыз» дип йөртәләр.**

—Әйе, мине баштан ук күтәреп алдылар Казанда. Милләтебезнең чын зыялылары Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Сибгать Хәким кебек мәшһүр затлар белән аралашу бәхете тиде миңа. Алар мине язучыларның Казандагы Тукай клубында кунакка ала торган иделәр. Анда күп тапкырлар җырлаганым да булды. Әдипләребез үз китапларын имзаларын, теләкләрен язып бүләк итә иде.

Хәсән Туфанны беренче күрүем дә Тукай клубында чыгыш ясаганда булды. Шулай бер баруымда мин андагы сәхнәдә җырлап торам. Шул чакта урталагы бер рәттә ап-ак күлмәкле, ап-ак чәчле бер ир-ат утыра. Минем җырлаганны уелып китеп, онытылып китеп тыңлап утыра инде бу. Нигдидер хәсрәт-сагыш дөньясында гизгән кебек. Җырлаган чакта залга бик җентекле игътибар итеп булмый, үзен дә онытылып китеп җырлыйсың. Ә менә бу ак күлмәкле, ак чәчле ирдән аерым бер сихри дулкыннар килә кебек иде. Шуннан концерт беткәч, сорадым «менә бу ап-ак чәчле ир кем ул?» дип. «Күренекле шагыйребез Хәсән Туфан бит ул», диделәр. Шуннан танышып киттек аның белән дә, башкалар белән дә. Әмирхан ага Еники белән, Уфадан Казанга поездда барганда, беренче тапкыр күрешкән идек. Аннан дуслыгыбыз гомер буе дәвам итте.

Казанда күп тапкырлар чыгыш ясадым мин. Беренче баруымда төрле театрларда, мәдәният сарайларында 17 көн рәттән концертлар куйдым. Гастрольләрем 16 көнгә исәпләнгән иде. Әмма, халык соравы буенча, тагын бер өстәмә концертны Г. Камал театры бинасында бирдем. Шунда мин Казанның мине күтәреп алуын тойдым,

тагын да ныграк канатландырды, илһам өстәде бу хөрмәт.

Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова белән дус булдым, аларның күп җырларын халыкка җиткердем. Сара Садыйкова Уфага килгәндә, күршебездә генә яшәгән танылган композитор Нариман Сабитовның әнисе Рәйхана ханымда туктала иде.

**—Сез яшь чактан ук халыкның сөекле кызы, талантлы җырчысы булдыгыз. Ә менә үзегезгә бирелгән рәсми, мактаулы исемнәр җитәрлек булды дип уйлыйсызмы?**

—Әйе, мине халык бик яратты. Аеруча Татарстан һәм татар халкы бик күтәрде мине. Алар мине яратты гына түгел, хәтта иркәләделәр дә. Башкортстанда да мине таныдылар, халык таныды. Рәсми танылуга килгәндә исә, анысы инде түрәләрнең эше. Бер караганда, 10 ел эшләгән кайбер дуңгыз караучылар да Хезмәт Герое булды. Минем мактаулы исемнәргә әлләни исем китмәде. Шулай да яшь кенә җырчылар Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премияләрен алганда, күнел рәнжеп куя-куюын. Ләкин минем күнелемне шул җылыта—мине халкым яратты, халык сөюе яшәтте, озын гомер бирде. Минем җырларымның күбесе бүген дә яши. Ә халык мәхәббәтеннән дә югарырак бәя була алмый.

*Автордан:* Татар һәм башкорт халыкларын яшәтүче ике нигез бар. Аларның берсе—дин, икенчесе—моң. Шушы ике нигез зур байлык һәм бәхет. Фәридә апа Кудашева менә шушы ике нигезне ныгытучы бөек шәхесләрнең берсе.

Фәридә Кудашева, үзе әйтүенчә, Татарстанның күренекле шәхесләре хөрмәтен тоеп яшәгән һәм иҗат иткән. Менә аның хакында Сибгать ага Хәкимнең 1979 елда Нажар Нәҗмигә язган хаты:

«Фәридә Кудашева башкаруында безнең радио татар халык җырларын тапшырды. «Ишкәкче карт» һәм башкалар—ярты сәгать. Фәридәне мин тыныч тыңлый алмыйм, гел эчтән елыйм. Әлләниләр искә төшә, җирем, тарихым, халкымның бөтен узганы алга баса, әнкәй күз алдына килә, аның тавышын ишетәм. Саф татар теле, андый тел белән җырлаган башка бер генә җырчы да юк. Менә нинди Ходай биргән табигый талант! Хәзер инде куркам, аннан соң кем килер икән, туар микән Фәридәләр? Фәридә җырлаганда Идел, Агыйдел кушылды, бөтен чүп-чар юкка чыкты, бәхетле итте».

Үзе дә мәшһүр җырчы булган Илһам Шакиров та өлкән апасына иң ихлас хөрмәт хисләрен күндерә:

«Фәридә Кудашеваның озын җырларына йөрәк кушыла, җырчы белән бергә кин сәхрәләргә чыгасың. Урал тауларына күтәреләсен, салкын чишмәнең чылтырап агуын тоясың. Кайчак озын җырларда аның сулышы менә шушы урында бетәр инде дип уйлыйсың. Ләкин ул, сулыш алмыйча, яна көч белән икенче фразаны ялгап китә. Табигать Ф. Кудашевага йөрәккә ятышлы матур тавыш бүләк иткән булса, шундый озын сулышка ирешү, әлбәттә, җырчының үз хезмәте. Фәридә ханым бәрхет кебек тембрлы тавышына йөрәгеннән чыккан моңсулыкны, эчке хисләрне өсти».

Фәридә апабыз күренекле әдибебез Әмирхан ага Еники белән дә аның соңгы көннәренә кадәр аралашып, очрашып, телефоннан хәбәрләшеп торды.

«Кыр чәчәгенә хуш ис күпме хас булса, безнең халык көйләренә дә моң шулкадәр үк хас, табигый нәрсә. Димәк, татар кешесе дә җырдан иң элек моң көтә, моң ишетергә тели. Ә Фәридә Кудашевада исә искиткеч моң байлыгы бар, йөрәге аның гел тибеп торган моң чишмәсе кебек, нинди генә көйне җырламасын, ул иң элек моңлы итеп җырлый. Әгәр Фәридә моннан мәхрүм булса, җырчы булудан да туктар иде. Һәрхәлдә, без һичкемгә охшамаган үзенә бер талантлы җырчыны күрмәс идек» (Ә. Еники. «Хәтердәге төеннәр», 1983.)

—Мин гомерем буе бик киеренке эшләдем. Гомерем буена татар һәм башкорт халкының ихлас мәхәббәтен тоеп яшәдем,—ди Фәридә Кудашева.—Халык алдында үземне гел җаваплы тоттым. Хәзер тормышлар да бүтән төрле, илдәге хәлләр дә, ләкин халык шул ук. Ул һаман да минем иҗатымны үз итә. Һаман да яшәргә илһам бирә.

**Фәнис ФӘТХИ.**

*Уфа.*

Фирдәвес
Хуҗин

# КҮКЛӘР ШАҺИТ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Америкалыларда

Без «аяклы» кибән астыннан йокы туйдырып чыкканда, унбишенче апрель иртәсе үзенең сәер тынлыгы белән каршы алды. Шылт иткән аваз юк. Сугыш вакытында снаряд, бомба шартлавына иялəнгəн колак мондый гайре табигый тынлыкны кабул итә алмый. Күңел сиземләве моның юктан гына түгеллеген, асылында ниндидер сер булырга тиешлеген искәртә. Зур саклык белән якындагы тыкрык буенча авыл урамына төштек. Урамның аргы башыннан безгә таба килүче ике хәрби күренде. Алар ниндидер чит телдә туктарга кушып кычкырдылар. Немецлар түгеллеге сөйләмнәреннән һәм киемнәреннән беленә. «Америкалылар булырга тиеш», дип уйладык җиңел сулап. Хәрбиләр, яныбызга килгәч, шикчел караш белән баштанаяк кыяфәтебезне, өс-башыбызны күздән кичерде. Алар безнең элекке әсирләр икәнлегебезгә төшенделәр булса кирәк, үз телләрендә тагын сорау бирделәр. Аңламыйча тик карап торабыз. Берсе тиз генә якындагы йортка кереп, аннан икенче бер хәрбине ияртеп чыкты. Бусы урысча яхшы сукалый икән, сорау арты сорау яудырырга кереште. Иренмичә, тулырак җавап бирергә тырыштык. Чөнки киләчәк язмышыбызны хәл итүдә бу америка хәрбиенең шактый зур роль уйнавын чамалый идек. Алар безнең сөйләгәннәрдән канәгать калды булса кирәк, бер-берсенә баш селкеп: «Йез, олрайт»,—диештеләр. Урам буйлап үтеп барган автомашинаны туктатып, дустанә елмайган хәлдә, машина әрҗәсенә менеп утырырга куштылар. Тылмач ролен башкаручы, урысча белә торганы, хәзер безне моннан тугыз чакрымдагы Вирдаво дигән шәһәргә алып барып, андагы кунакханәгә вакытлыча яшәргә урнаштырачакларын әйтте. Иректә булуыбызга күңел ышанмый, шатланып кычкырасы, биисе-җырлыйсы килә. Әллә ничә көн ач торып, хәлсезләнүебезне дә онытып, каян шундый көч килгәндер, машина әрҗәсенә сикереп мендек. «Ә» дигәнче инде Вирдавода идек. Автомобиль союзниклар армиясенең ниндидер часть штабы урнашкан бина алдына килеп туктады. Штабка кереп тиешле теркәүләрне узганнан соң, ике йөз метрлар чамасы ераклыктагы бер ресторанның икенче катындагы кунакханәдән бер бүлмә күрсәттеләр. Тик «Әгәр немецлар кызыксынса, без—америкалылар, дип әйтерсез» дип кисәтеп куйдылар. Төрле хәл булырга мөмкин, чөнки Вирдавоны әле кичә генә дошманнан азат иткәннәр. Ресторанга алып төшеп әйбәтләп сыйлаганнан соң, кабат, билгеләнгән бүлмәгә менеп, ял итәр-

*Дәвамы. Башы 8 санда*

гә мөмкин икәнлеген әйттеләр. Соңгы көннәрдәге нерв киеренкелеге өстенә союзникларның туклыклы ризыклары, «аш астына» тотып куйган йөз грамм виски аракысы рәхәт изрәтеп, айдан артык рәтле урын-җир күрмәгән гәүдәгә кешечә ял сорый иде. Крахмалдай ак җәймәләр җәелгән караватларга сузылып ятып, тирән йокыга талдык.

Икенче көнне таң белән коридорда тавышлар ишетеп уяндык. Мин башта үземнең кайда икәнлегемне аныша алмыйча яттым. Никтер һаман да Пилауда әсирлектәдер, фашистлар төрмәгә яңа партия әсирләрне китергәннәрдер, менә-менә ишек ачылып китәр дә, аларны камерага кертерләр кебек тоелды. Бәхеткә, алай түгел. Чиста урын-җиргә, «тек-тек» итеп стенада вакыт санаучы сәгатькә күзем төште. «Иректә ич без, иректә!» дигән сөенечле уйдан бөтен гәүдәм буйлап җылы дулкын йөгерде. Саша да уянган икән.

—Хак, торабызмы инде?—диде ул акрын гына.—Русча сөйләшәләр, безнекеләр түгелме икән?—Метелкин ияге белән тавышлар килгән якка ымлады.

Йокы туйган, тамак тук, әлегә баш исән—адәм баласына үзен бәхетле сизәр өчен күп тә кирәк түгел. Торып, яткан урыныбызны җыештырдык та, юыну бүлмәсенә чыктык. Анда, күзгә каршына басып мәш килеп кырынучы Бобров, Буянов, Бондаренколарны күргәч, әллә ничә еллар күрешмичә торган туганнар шикелле кочаклашып күрештек. Минем күземә шатлык яшьләре бәреп чыкты. «Лагерьдан качкач ничек булды?» дип сорашулар башланды. Кәефләр тагын да күтәрелеп китте. Юынып-чистарынып, аскы каттагы ресторанга төштек. Анда безне ике америка хәрбие каршы алды. Итагатьле итеп кайсы өстәл артына утырырга икәнлекне күрсәттеләр. «Ну культура да соң боларда!»—дип уйладым союзникларга сокланып.—Аш-суны да ашыкмыйча, тәртибе белән генә чыгаралар. Боларга җитәргә ерак шул әле безгә.

Ашап-эчкәннән соң мунчада юынып чыгарга тәкъдим иттеләр. Немецларның «OS» тамгалы киемнәрен салдырып алып, алар урынына һәркемгә размерына карап унайлы костюм-чалбар бирделәр. Башка эшләпә дә кигәч, чын джентельменга охшап калдык. Урамда хәрби патруль тоткарламасын өчен вакытлыча пропуск белән тәэмин иттеләр.

## Фаҗига

Мең тугыз йөз кырык дүртенче елның беренче августында заводтан полкка ТУ-2 тибындагы яңа самолетлар кайтып бетте. Әлеге очкычта очу күнекмәләре алу көндез генә түгел, төннәрен дә дәвам итә. Айдан артыкка сузылган өйрәнүләрдән соң фронтка китәр көннәр дә килеп җитте. Элекке экипаж командирыбыз лейтенант Сазонов яралану алганлыктан, медицина комиссиясе аны ТУ-2дә очарга яраксыз дип табып, җиңел типтагы самолетка күчерде. Штурманны да башка экипажга билгеләделәр, аның урынына лейтенант Плюхинны куйдылар. Элекке экипажыбызның радисты Сысоев иде, ул да алышынды—Захаров фамилияле берәү радист булды. Шулай итеп, әүвәлге экипаждан бер мин калдым. Яңа командир—лейтенант Куликов—әлегә сугышчан очу күнекмәләре булмавына карамастан, экипажның мәхәббәтен яулап өлгерде. Чөнки ул логик фикерле, сабыр һәм салкын акыллы командир, катлаулы хәлдә дә каушап калуны белми, аннан чыгу юлын таба торган кеше.

Өйрәнүләр тәгәлләнгәч, дивизия штабыннан Литваның Шауляй шәһәре янындагы аэродромга очарга әмер алынды. Һава торышы начар булу сәбәпле, полктан беренче төркем поезд белән егерме бишенче августта озатылды. Яңгырлар егерме икенче сентябрьгә кадәр сузылды. Көннәребез аэродромда, болытлар таралуын көтеп үтә. Беренче мөмкинлек туу белән эскадрильялар һавага күтәрелергә әзер. Ниһаять, егерме икесе көнне бөтен полк белән зәңгәр күккә күтәрелдек. Ләкин йөз километр чамасы үтү белән юлыбыз кабат яңгырлы районнарга эләкте. Бусы

начар: дикъкатьне икеләтә арттырып очарга туры килә. Чама белән ярты араны үткәч, янгыр катыш карлы полосага кердек. Монысы инде тагы да яманрак. Эскадрильяга жир өстенә якын төшеп очудан башка чара юк. Хәлләр шулкадәр катлауланды ки, күпмедер вакытка координатларны югалтып тордык. Ярый әле болытлар сыегаеп, аста сирәгәйгән урманнар, кечкенә авыллар шәйләнә башлады. Алда бер шәһәр пәйда булды. Эскадрилья командиры капитан Либатюк шул шәһәр аэродромына төшеп утырырга дигән карарга килде. Чөнки инде кич якынлашкан, ә очуны дәвам итү төнлә генә түгел, көн яктысында да зур тәвәккәллек сорый иде. Әйләнә-тирәсен урманлык чолгап алган аэродром шәһәр янәшәсендә генә, эскадрилья командиры кай тарафтан төшүнең куркынычсызрак булуын ачыклар өчен аэродром өстеннән күзәтү очышы ясап, машинасын уңышлы гына төшереп утыртты. Ул инде кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып баш очында селки—бүтәннәргә ни рәвешле төшәргә икәнлеген күрсәтүе. Башка самолетлар да бер-бер артлы, тимер кошлар кебек командир әмеренә буйсынып, үзләренә күрсәтелгән урынга төшеп куна башладылар. Инде һавада ике генә очкыч калды. Алар да шул ук маневрны башкарганнан соң, аэродромда үзләренә тиешле урында тукталып, тынып калырлар. Тик шунда башка сыймаслык коточкыч хәл булды: бер ТУ-2 аэродром читенә якынлашканда биеклекне дөрес алмады, аның шассилары озын нарат агачларының ябалдашларына эләкте. Ул, сөрлеккәндәй, кинәт тизлеген югалтып, агачларны сындыра-сындыра әллә кайларга атылып барып төште. Аланлыкта басып, гайре табигый хәлне шаккатып күзәтеп торган барлык экипаж членнары дәррәү шул якка ташланды. Күз алдыбызда коточкыч манзара ачылды: корпусы бөкләнеп-йомарланып беткән самолет икегә аерылган, башлары һәм аяк-куллары өзелгән экипаж командиры лейтенант Грибанов белән очкычның техникы бер читтә ята, ә штурман һәм укчы-радист катапульттан сикереп өлгергәннәр. Икенче көнне һәлак булганнарны тан белән Едрице (каланың исеме шулай) шәһәре зиратына зурлап күмдек. Сугышчан иптәшләр истәлегенә залплар янгырады, эскадрилья командиры һәм кайбер башка очучылар нотыклар сөйләде. Корбаннарны инде берничек кайтарып алып булмый, нинди мәгънәсез үлем...

Аэродром янәшәсендә генә Ходикин дигән уртача зурлыктагы авыл бар. Ул—елга буйлап сузылган. Су буендагы авылларга хас олы гына су тегермәне сураеп утыра. Агач улаклы буасында чабак балыклары йөзеп йөри. Суы үтә күренмәле чиста, эре балыкларның төптә йөргәннәренә хәтле күренә. Буа аша чыгуга урман белән капланган таулык башлана. Аэродром шул таулыкның ачык өлешендә. Грибанов самолетының бәрелү көче коточкыч зур булуын, моторы илле метр ераклыктагы буа ярына килеп төшүен күрсәтә. Двигательдән аккан май һәм бензин калдыклары зур тап булып буа суын каплаган.

Ходикин авылында яшәүчеләр аз калган. Кайсылары партизаннарда йөреп, фашистларның каратель отрядлары белән бәрелешләрдә һәлак булган, кайберәүләрне, партизаннарга булышасыз дип, атканнар һәм асканнар, ә яшьрәкләрне Германиягә эшкә куып алып киткәннәр. Безне фатирга керткән өлкән яшьтәге йорт хуҗасы чәчләрне үрә торгызырлык хәлләр турында сөйләде.

Һавалар һаман ачылмады, янгырлар көчәя генә барды. Мондый хәлдә очып китү турында уйлашлы да түгел. Азык яклары болай да такыр иде, ашарга калмады диярлек. Ярый әле һәр экипажга коры паёк—«НЗ» бирелә, ачтан интекмәс өчен беренче вакытка ул ярап куя. Тик аның күләме зур түгел, шоколад, печенье, шикәр, балык консервысы ише ризыклардан гына гыйбарәт. Ә тамакны алдап булмый, ул ашарга сорый. Читтән продуктлар китерүгә дә өмет юк, әлеге дә баягы һава торышы комачаулый. Аптырагач, буадан балык тотып, уха пешерү хәстәренә керештек. Тегермәннән он алып, икмәк тә пешерттеләр. Тик, эскадрильядагы алтмышлап кешене туйдыру өчен болар гына житми иде.

Ходикин авылында бер атна яшәгәннән соң гына янгыр болытлары арасын-

нан кояш күренде. Кояш артыннан ук, ертык болытларны аралап, «Дуглас» самолеты түбәнәйде дә, килбәтсезлегеннән унайсызланган шикелле, аэродром читенә төшеп туктады. Ниһаять, безгә ярдәм килде. «Дуглас» очучыларга һәм техникларга азык-төлек, самолетларга ягулык һәм кислород запасы төяп китергән. Очкычларны җитәрлек күләмдә ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итеп, двигательләрен хутка җибәргәнче, көзге көн кояшы офык читенә якынлашты. Вакыт соң булганлыктан, Шауляй аэродромына очуны икенче көнгә калдырдылар. Шулай да ике экипажның членнарын «Дуглас»ка утырып, Двинск каласына кадәр очарга боердылар. Алар арасына мин дә эләктем. Союзникларның «тихоход»ына дивизия штабыннан югары чиндагы берничә офицер утырып килгән иде, без озатучылар ролен үтәргә тиеш булып чыктык. Двинскига житкәндә тәмам кич булды. Икенче көнне тагын яңгырлар башланып, моннан да, Ходикиннан да очкычлар бары тик өч көннән соң гына һавага күтәрелә алды. Без шул ук «Дуглас»та, ниһаять, соңгы очу ноктасы—Шауляйга октябрь ае башларында гына барып житә алдык.

## Вәхшилек

Кунакханә ресторанында америкалыларның деликатес ризыклары белән сыйланып яту бер нәрсә, безне әсирлектән коткарырга ярдәм иткән урыс һәм украин кызларының язмышы ничегрәк булды икән? Капитан исәнме? Әнә шул уйлар күнелемә тынгылык бирмәде. Бобровлар белән күрешеп, иртәнге чәйне эчкәннән соң, дөресрәге, кулларыбызга пропуск тоттыруга ук, Метелкинга үзебез качкан лагерьга барып килергә тәкъдим иттем. Саша каршы килмәде.

Лагерьны барып күргәч, «ялгышып килдекме әллә, улмы бу, юкмы?» дигән сорау белән гажәпләнеп бер-беребезгә карадык. Лагерьны танырлык түгел иде: капкадан кергәндә, безне ябып тоткан мунча бинасы авыр снаряд тиеп, ватык кирпеч өемнәренә әйләнгән; ишегалдында да снаряд чокырлары күренә; хәрби булмаган әсирләр тотылучы баракларның да кайберләре ярым җимерелгән. Капкадан берничә көн элек кенә безгә кайнар аш һәм култык астына «OS» тамгалы кием кыстырып ташыган кызларның берсе чыгып, инемә капланган кына шул лагерь икәнлегенә ышандык. Батыр йөрәкле кыз менә ниләр сөйләде:

—Тәрәзә тупсасы аша унсигез әсир сикереп төшеп, аларны озатып торучы капитан, инде качарга дип, шул тупсага менеп басуга, ишектән ике сакчы йөгереп керде. Алар беравыздан «һальт!» дип кычкырып җибәрделәр һәм тәртипсез рәвештә автоматларыннан ут ачтылар. Фашистлар шулкадәр котырынганнар иде, автомат магазиннары бушаганчы атуларын дәвам иттеләр. Мескен капитанның гәүдәсендә тишкәләнмәгән урын калмады. Ул шулай да бина эченә түгел, тырышып-тырмашып тышкы якка егылды, качасы килү теләге көчле булгандыр инде. Конвоирларның калганнары да йөгереп керде, бина эче акыру-бакыру авазлары белән тулды. Берничә сакчы качучыларны эзәрләкләп китте, икесе һәм тагын ике офицер бирелә калды. Алар кызларның, борын төбеннән, буташтырып, әсирләрне качыруын берничек гафу итә алмадылар. Арада дәрәҗәсе ягыннан иң өлкәне үзе белән елмаеп немец телендә сөйләшкән кызны кичекмәстән табып китерергә кушты. Офицерның әмере минут эчендә үтәлде. Фашист, төкерекләрен чәчә-чәчә, Людмилага ниләрдер әйтеп акырынды. Тик Люда дәшмәде, бары нәфрәт тулы күзләре белән немецка төбәлде. Конвой башлыгы кобурасыннан пистолетын тартып чыгарып, аның башына ике тапкыр атты. Миләре чәчрәп чыккан кыз бетон идәнгә тәгәрәде. Мин бу хәлләрне тәрәзә аша күреп тордым. Фашистлар качуда ярдәм иткән тагын берничә кызны стена буена бастырып атып үтерделәр. Мин бар көчемә бараклар ягына йөгердем. Баракларда калган барлык әсирләрне шундый язмыш көтә иде. Бәхеткә, шулчак союзникларның туплары атарга кереште һәм немецлар ният-

ләрен чынга ашырырга өлгерми калдылар. Ә икенче көнне америкалыларның мотопехотасы лагерь территориясенә бәреп керде.—Бу кызның сөйләгәннәрен тынлап торуы авыр иде.

—Капитанның җәсәде кайда?—дип сорадык. Кыз, безне мунча урынынннан ерак түгел бер калкулыкка алып барып, кызгылт балчык өеменә кадап куелган тактага күрсәтте:

—Менә ул.

Лагерь складыннан буяу сорап алып, капитанның исем-фамилиясен, үлгән елын язып куйдык. Кызганычка, штурмовиклар полкында эскадрилья командиры булган бу иптәшнең туган елы безгә мәгълүм түгел иде. Исән калганнарның күнеле шат, алар бәйрәм итәләр. Өсләреннән «OS» тамгалы киемнәрне салып ташлаганнар да, складтан үзләренә яраклы киемнәр табып алып кигәннәр. Лагерьдагы сак хезмәте өчен тәгаенләнгән складта кияргә генә түгел, тукланыр өчен дә әллә ниләр бар. Метелкин белән мине кыстый-кыстый алып кереп, төрле ризык һәм эчемлекләр белән шыплап тутырылган өстәл артына утырттылар. Урыс рухы шундый бит ул: моннан алда кычкырып еласа, икенче мизгелдә шатланып-көлеп, җырлап-биергә мөмкин. Бәлки, шулай дөрестер дә, өч көнлек дөнья ич. Шактый кызмача хәлдә, соң гына кайтырга чыктык. Патруль-фәлән туктатмады, кунакханәдәге бүлмәгә кайтып, йомшак мендәрләргә баш төртүгә, йоклап киткәнбез.

Икенче көнне иртәнге чәй янында мин барлык иптәшләргә штурмовик-капитан белән булган хәл турында сөйләп бирүне бурычым санадым. Без—әсирлектән качып исән калган 18 кеше—гомеребез белән капитанга бурычлы идек. Барыбыз аягүрә басып, капитанны бер минутлык тынлык белән искә алдык.

—Ә беләсезме, әсирлектән коткарылган совет кешеләре нәрсәләр сөйләде,—диде Бондаренко,—моннан ерак түгел хәрби әсирләр өчен концлагерь бар икән, дөресрәге—булган. Шунда коточкыч вәхшилекләр кылынган. Хәер, аларны да үз күзләрең белән барып күрү яхшырактыр. Теләүчеләр булса, рәхим итегез.

Бондаренко, Метелкин, мин һәм тагын берничә иптәш концлагерьны барып карарга булдык. Анда җитәргә 100 адымнар кала борынга укшыткыч ис килеп бәрелде. Чәнечкеле тимерчыбыклар белән әйләндереп алынган лагерь территориясенә якынлашкан саен начар ис көчәйде. Авыз-борыннарны кульяулык белән капларга туры килде. Яман истән алай гына да котылырга мөмкин түгел, ике иптәш тыела алмыйча укшырга кереште. Андыйларга монда урын түгел—концлагерь ишегалдыннан борылып чыгып киттеләр. Ә озын һәм киң итеп эшләнгән плацтагы (ишегалды) күренеш чәчләрне үрә торгызырлык иде. Капкадан кергәч тә сул яктагы тимерчыбык киртә буенда моннан ике-өч көннәр элек кенә фашистлар тарафыннан атып үтерелгән әсирләрнең мәетләре аунап ята. Аларның саны 50-60лап булыр. Бүген апрельнең 19ы гына булса да, Германиядә көннәр эссе тора, үлекләр өстендә чебеннәр кайнаша. Каралып һәм кабарып шартлар чиккә җиткән мәетләрдән чыккан ис тыннарны буа. Үле гәүдәләр киртә буенда гына түгел, бөтен плац буенча таралган. Бер кырыйдагы чүп түгә торган баз хезмәтен үтәүче зур котлаван да мәетләр белән тулган. Аның өстендә шулай ук чебен болыты бөтерелә. Лагерь сакчылары, күрәсен, союзниклар армиясе Вирдавоны штурмларга керешер алдыннан ашыгычлык белән хәрби әсирләрне автомат һәм пулеметлардан ут ачып кырырга керешкән. Котлаванга ыргытылганнары алданрак юк ителгәнгә охшый, чөнки араларында кибеп, мумиягә әйләнә язганнары да күренә. Вандализм актын башлап, хәлсез әсирләрне юк итүе җинел шул—тимерчыбыклы киртәләрнең дүрт почмагындагы дүрт вышкадан сакчыларга эре калибрлы пулеметлардан берничә минутта әллә ничә йөз әсирне кырып салу берни тормый.

Әсирләр яшәгән берничә барак тезелеп киткән. Аның беренчесенә якынлашабыз, ишекләре ачык. Бусагадан атлап керү белән, тораташ кебек катып калдык. Безгә ачылган күренешне тел белән генә аңлатырлык түгел. Баракның җир идә-

ненә буеннан-буена калын итеп салам түшәлгән, анын өстенә жиде рәт мәетләр салынган, алар өстенә нарат жердалары жәелгән, жерда өстенә кабат—салам. Һәм бу салам—мәет—жерда әрдәнәләре алты кат хасил итеп, ут төртеп яндырырга әзерләнгән. Бу турыда бер читтә әзерләп куелган ике чиләк бензин, бер чиләк керосин ачык сөйли. Газаплап һәм атып үтерелгән совет әсирләренең гәүдәләрен ут төртеп яндырырга житешмәгән фашистлар, палачларнын үзләрен союзниклар гаскәре килеп туздырган. Без, сугышта күпне күргән биш ир-егет, тавышсыз гына елыйбыз. Чөнки мондый кыргый күренешкә йөрәк түзми, аң һәм акыл аны кабул итми. Барак диварына акбур белән кемдер урысчалап: «Биредә сигез мең ярым рус хәрби әсире!» дип язып куйган. Авыр хисләр астында, борыннан кульяулыкларны алмыйча гына, икенче баракка юнәләбез. Аннары өченче, дүртенче... Һәрберсендә шул ук күренеш. Унике баракта биш меңнән алып ун меңгә кадәр үтереп ташланган адәм балалары, кемнәрнеңдер газизләре, фашистлар тарафыннан жинаять эзен югалтыр өчен, сөякләренә кадәр яндырырга әзерләнеп куелган. Үле гәүдәләре генә калган булса да, туганнар каберлегендә урын алырга тиеш алар. Тик менә союзниклар бу мәшәкатьле эшне үз өсләренә алырлармы, әллә кремацияләүне кулай күрерләрме? Һәрхәлдә, әлеге проблеманы сузарга ярамый, инфекция таралып, әллә нинди чирләр килеп чыгуы ихтимал.

Соң дәрәҗәдә кырылган кәеф белән кайту ягына борылдык. Кунакханәгә кайткач та, өске киемнәргә сеңгән мәет исе бетмәде. Аптырагач, аларны салып, шифоньерда эленеп торган башка киемнәр кидек. Бәхеткә, киемгә кытлык юк. Запаста костюм-чалбар, күлмәк, эшләпә, ботинка гына түгел, галстукларына кадәр бар. Безнең карамакка американнар жиңел машина бирделәр. Алар безне ресторannarында көненә өч тапкыр туйганчы ашату белән генә чикләнмичә, беткәннән-беткәнгә виски, затлы сигаретлар һәм башка төрле азык-төлек белән тәэмин итү ягын да кайгырттылар. Әнә, әле хәзер дә Бобров бер америкалы солдат белән машинага утырып каядыр китте һәм озак тормыйча әйләнеп тә кайтты. Машинаны тутырып деликатеслар төяп кайтканнар. Һәркайсыбызга алтышар банка итле макарон, дүртәр банка печенье һәм конфет өләштеләр. Бишәр банка колбаса, яшел борчак һәм бәрәңге катыштырылганы да бар икән әле. Боларга өстәп бишәр кап сигарет белән унар кап шырпы бирделәр. Каян килә икән соң совет кешеләре империалист дип кенә белгән янкиларга шундый юмартлык? Гаҗәпләнүебезнең чиге юк. Банкаларны ачу механизмы да гаять унайлы һәм жиңел көйләнгән, һәр калай савыт өстендә махсус тартып ача торган ачкычы бар.

Шулай да мондый рәхәтлекләр озакка бармады, 22 апрельдә кунакханәдә яшәп ятучы, әсирлектән котылган очучыларны һәм танкистларны союзниклар штабына Америка генералы әңгәмәгә чакырды.

### Шауляйда

Шәһәр сугыштан нык зыян күргән. Күп йортлар жимерелгән, яндырылган. Жимерелмичә калганнарынын да стеналары дары сөременнән һәм төтеннән каралып, котсыз булып күренәләр. Стратегик әһәмияткә ия олы күперләрне генә түгел, фашистлар чигенгәндә вагракларын да шартлатып киткәннәр. Кала, инглиз язучысы Герберт Уэлснын жирне марсианнар басып алуын сурәтләгән мәгълүм фантастик романындагы күренешне хәтерләтә.

«Дуглас» ишеген ачып трап куюга, жиргә төшәргә ашыктык. Аэродромда безне алдан поезд белән киткән полкташлар көтеп тора иде инде. Жыелышып казармага киттек. Стеналары ядрәләр тиюдән шадраланып беткән, ике катлы кызыл кирпеч бинаны казарма иткәннәр. Анын тәрәзә пыялалары исән калмаган диярлек, ыржаеп торган өлгеләрне фанера кисәкләре белән каплаштырганнар. Казарма эче салкынча булса да, чиста, әлегә аз кеше яшәгәнлеге сизелә. Яна килүчеләр белән мәзәккә охшаш хәл дә булып алды.

—Карыныгыз ачкандыр, ашханәгә кичке ашка барып килегез,—дип тәкъдим иттеләр. Никтер, элекке килгәннәрдән кем дә булса озата барырга ашыкмады. Ашханә шактый читтә, анда барганда көн яктылыгы сүнеп бетмәгән, һәм сүзгә мавыгып, кайсы урамнардан үтүебезгә игътибар итмәдек. Ә кайтырга чыкканда октябрь төне дегеттәй караңгылык белән каршылады. Күктә ник бер йолдыз сынары, урамнарда ник бер ут әсәре күренсен. Кем әйтмешли, уңда, сулда, алда, артта кругом караңгылык. Шауляйга фронт якын булганлыктан, дошман авиациясе һөҗүменнән сакланып, йорт тәрәзәләрен, ут яктысы төшәрдәй башка объектларны төнгә яхшылап маскировкалыйлар икән. Шуңа без кызык та, кызганыч та хәлдә калдык. Хәер, таркаулыгыбыз өчен үзебезне әрлисе, чөнки сугыш вакыты законнары буенча якындагы торак пунктларны гына түгел, ә фронттан меңәр чакрым ерактагыларын да маскировкалау турындагы махсус күрсәтмәне әле беркемнең гамәлдән чыгарганы юк. Капшанып диярлек атлыйбыз. Шулай да кайбер тәрәзәләрдән саран гына яктылык саркый, ул бәрелмәс өчен ориентир хезмәтен үти. Казарманы эзләп тапканчы ике сәгатьләп вакыт үтте. Иптәшләр борчылып көткәннәр. Талчыккан кыяфәтле биш кешенең берсбер артлы ишектән керүен күргәч, кайсыдыр бер җор теллесе:

—Кайтмаслар дигән идегез, әнә ич кайтканнар,—дип шаяртты. Шул җитә калды, казарма эчен дәррәү көлгән авазлар күмде. Без дә үзебезнең төнге «мажараларны» сөйләп көлдердек.

Һавалар һаман ачылмады. Казармадагы бертөрлелек тә туйдыра. Ашханәдә иртәнге чәй, төшке аш, кичке аш. Көндезге ял сәгатьләрендә «кызыл почмак»та домино, кәрт сугабыз, китергән почтаны караштырабыз. Хат алучылар җавап хаты яза. Көн саен диярлек аэродромдагы очкычлар янына барып, һәр экипаж члены үзенә беркетелгән эш урынын тәртипкә китерә. Мин инде әллә ничәнче мәртәбә пулеметны, пушканы сүтеп җыйдым, аларны майладым. Дошман белән бәрелештә йөзгә кызыллык китерерлек булмасын, яшәү белән үлем арасы аларның төзеклеге белән үлчәнә.

Октябрьнең унөче көнне, ниһаять, болытлар таралды. Икенче көнне бөтен һава дивизиясе белән дошманның диңгез порты урнашкан шәһәргә авиаудар ясарга әмер алынды. Инде сугышчан очышларда катнашмаганга да бишбылтыр. Йөрәк урынында түгел. Моңа кадәр йөздән артык һава операциясен баштан кичерергә туры килсә дә, тәүге тапкыр самолетка утыргандагы кебек дулкынландыра. Гел шулай, чөнки бер очыш икенчесеннән нәрсәседер белән барыбер аерыла. Берьюлы бөтен һава дивизиясе белән очу сирәк күренеш.

Менә инде өч төстәге сигнал ракетасы да һавага чөелде. Дежур офицер флажокларын селти. Эскадрильялар берсе артыннан берсе югарыга күтәрелә. Дивизия тулысы белән һавага күтәрелгәч, көз көне кошларның җылы якка киткәнен хәтерләтеп аэродром өстеннән очып үтте дә, истребительләр урнашкан аэродром ягына таба курска ятты. Алар озата барырга тиеш. Бик күп самолетларның тәртип белән тезелеп очуы грандиоз күренеш. Ул бигрәк тә җирдән караганда шулай. Звенолар—эскадрилья, эскадрильялар—полк, ә полклар дивизия хасил итеп оча. Дивизиянең тезелү тәртибе биниһая зур өчпочмакны хәтерләтә. Югарыдан зур чикерткәләргә охшап күренгән истребительләрнең ишле төркеме ашыгыч тәстә өскә күтәрелеп бомбардировщиклар өчпочмагының як-якларына тезелде. Безнең полкны дивизия командиры үзе җитәкли һәм ул төркемнең авангардында оча, ә эскадрильябыз тәртип буенча санаганда—икенче. Шул «тугызлык»ның сул як звеносында безнең ТУ-2 урын алган. Аэродромнан күтәрелеп ерак китәргә дә өлгермәдек, болытлы полосалар очрый башлады. Визуаль карап бару мөмкинлегеннән мәхрүм итүче болытлар «патшалыгы»на килеп керүгә, очкычларның бер-берсеннән җепкә тарттырган кебек ара саклаулары югала. Андый чакта радистларга эш арта, эфир, саклык чаралары күрергә кирәклеге, аерым экипажлар, звенолар, эскадрильялар һәм

полклар бер-берсеннән дистанция ераклыгын арттырырга тиешлеген искәрткән боерыклар белән тула. Болытлы районнар артта калды, Галәветдиннең серле лампасындагы җен тылсымы белән хәрәкәткә китергәндәй, очкычлар кабат тыгыз сафларга җыелдылар. Фронт линиясенә якынлашканны аста янган авыллар, куе төтенгә күмелгән җимерек калалар ачык күрсәтә.

## Американнардан аерылу

Америка генералы безне ачык йөз белән каршылады. Утырырга тәкъдим итте. Янында тылмачы да бар. Ул ике фронтта сугышучы гаскәрләрнең тиздән кушылачагын, Кызыл Армия белән алдан килешенгәнчә, совет хәрби әсирләренең үзләренекенә тапшырылачаклары турында әйтте.

Ана кадәр Вирдаво һәм Цвикаво шәһәре тирәсендәге концлагерьда тотылган әсирләрнең барысын бер урынга—Цвикаво янындагы концентрацион лагерьга тупламакчылар икән. Бу безнең өчен көнелсез яналык иде, чөнки саллы өлешебез 1941 елда ук әсирлеккә төшерелгән һәм алар арасында төрле кеше бар. Өч-дүрт ел элек әсир төшкәннәр күбесенчә хәрби тәртипләрне һәм, гомумән, тәртип дигән нәрсәне онытып бетергән, алар арасында анархия хөкем сөрә. Хәер, бу турыда без икенче көнне, бөркәүле машинага төяп, Цвикаводагы лагерьга алып барып бушаткач кына белдек. Концлагерьның ишегалды бик зур, бараклар да күп. Монда газаплаулар, атып үтерүләрдән исән калган унбиш меңләп кешене туплаганнар. Арадан югарырак дәрәҗәле офицерларны эчке тәртипләр белән идарә итү өчен сайлап куйганнар. Әмма, кагыйдә буларак, старосталарның күрсәтмәләрен тыңлаучы юк диярлек. Аерым төркемнәр үзбаш булып яши, аларның үз җитәкчеләре бар. Андый төркемнәр арасында еш кына «аңлашулар» булып ала, пычакка пычак килгән чаклары сирәк түгел. Әнә шундый куркынычлы җирдә гомеребез өчен калтырап, егерме өченче апрельдән алтынчы майга кадәр яшәдек. Алтысы көнне, көн кызулыгыннан әлсерәп Бобров, Буянов, Бондаренко, Метелкин һәм мин якындагы күлдә су коенып кайттык. Барактагы урыннарыбызга сузылышып яткан гына идек, бер танкист-лейтенант йөгереп кереп:

—Иптәшләр, Җиңү! Әле генә радиодан ишеттем,—дип сөенче алды. Куанубызның чиге булмады, күзләрдәге шатлык яшьләрен сөртә-сөртә кочаклашып, бер-беребезне котладык. Миллионлаган корбаннар исәбенә яулаган бу җиңүдә безнең дә өлеш бар ич.

Союзниклар үзләрендә Җиңү хөрмәтенә зур банкет уздырдылар. Анда без дә чакырулы идек. Американлылар штабында тәрҗемәче булып эшләүче совет лейтенанты банкеттан соң безнең янга килде һәм сер итеп кенә:

—Иртән иртүк мин сезне алырга килермен һәм Кызыл Армия контрольлек иткән территория ягына чыгарга булышырмын. Карагыз аны, башка төркемдәгеләргә белдерә күрмәгез, югыйсә, хәлләрнең катлауланып китүе бар.—Миң тугыз йөз кырык өченче елда фашист әсирлегеннән качып, француз партизаннары ягында сугышып йөргән, күп мажаралар кичергәннән соң союзникларга килеп кушылган лейтенантның без—очучыларга хөрмәте зур иде.

Сигезенче май көнне таң белән, алдан сөйләшенгәнчә, шыпырт кына лагерь биләмәләрен калдырып, әйтелгән урынга килдек. Анда инде кабина түбәсенә эре калибрлы ике пулемет беркетелгән өсте бөркәүле «студебеккер» машинасы көтеп тора иде. Унсигез кеше аның әрҗәсенә менеп утыргач, машина кузгалып китте. Асфальт юл белән Химница шәһәре ягына таба җилдерәбез. Ара якын түгел. Шулай да юлда хәвеф-хәтәр очрамады. Химницага җитәргә алты чакрым кала машина юл читенә чыгып туктады.

—Килеп җиттек,—диде шофер янәшәсендә урын алган лейтенант кабинадан чыгып.—Моннан алты чакрым киңлектәге нейтраль зона башлана, анна-

ры Кызыл Армия чистарткан җирләр. Без бу чиктән кире борылабыз, ә сезгә калган юлны җәяүләп үтәргә туры килер. Тик сак булыгыз, коралды фашист төркемнәренә юлыкмагыз,—дип, лейтенант безнең белән саубуллашканнан соң «студебеккер»ына утырып китеп барды. «Бар инде дөньяда яхшы кешеләр,—дип уйладым америкалыларга хезмәт итәргә калган лейтенант артыннан карап. Без аңа беркем түгел, ә шулай да кыен вакытта хәлебезгә кереп, ярдәм кулы сузарга тырыша, сугыш беткәндә генә, бәхетсезлегебезгә күрә, әсирлеккә төшүебезнең әллә нинди катлаулыклар китереп чыгару ихтималын яхшы чамалый. Ә бит союзниклар үзләре белән сөйләшмичә шундый «мажаралар» оештыруын белеп алсалар, иң ким дигәндә дә хәрби хезмәттән куарга, хәтта хөкемгә тартырга мөмкиннәр. Исән-сау гына йөри күр инде, лейтенант».

Юлда төркем-төркем немецлар очрый башлады. Тик алар коралсыз, әсирлеккә бирелергә барулары, күрәсең. Химницага җитәрәк, тимер юл күпере янында, безнең төркемне ике совет сугышчысы туктатты.

—Туктагыз, урыныгызда калыгыз!—дип боерды алар.—Сез кемнәр һәм кая барасыз? Коралыгыз бармы?—дигән сораулар белән күмеп ташладылар. Шикчел караш белән һәрберебезне баштанаяк күздән кичергәч, элекке совет сугышчылары булуыбызга ышандылар бугай, күпер астына урнаштырылган телефон аппаратыннан каядыр шалтыратырга керештеләр. Аларның өзек-өзек аңлатмаларыннан штабларына булырга тиешлеген чамаладык. Тик тегендә безне күрергә бик атлыгып тормыйлар иде, моның шулай икәнлеген кызылармиячеләрнең кырыс кыяфәтләре күрсәтеп тора.

—Сезгә шәһәр комендатурасына барырга куштылар,—диде иңнәренә сержант погоннары такканы.—Анда менә болай барасы, карта укый беләсезме?—сержант әллә кайдан гына шәһәр картасы тартып чыгарды һәм аның өстенә иелде.—Хәер, очучы халкы картада ориентировканы кемгә караганда да тизрәк таба торгандыр инде.

***

Бондаренко белән Буяновның күзләре сержантның бармагы артыннан урам һәм тыкрыкларны, кварталларны истә калдырыр өчен дикъкать белән картага текәлде. Шулай да без ул көнне комендатурага барып җитә алмадык. Урам тулы техника, төрле гаскәри берләшмә сугышчыларының күплеге хәрәкәтне нык соткарлый. Һәркайда поход кухнялары төтенли. Гармун тарталар, кычкырып җырлыйлар, бииләр. Тамак ягын кайгыртасы булмады: солдат ашын да, боткасын да мулдан ашаттылар. Бер уңайлы урын табып, шунда төн кундык.

Мең тугыз йөз кырык бишенче елның тугызынчы май таңы атты. Бу көн киләчәктә тарихка совет халкының фашистлар Германиясен Бөек Ватан сугышында Җиңү көне булып кереп калачак һәм ул ел саен тантаналы төстә билгеләнеп үтеләчәк. Әлегә басып алынган немец җирендәге немец шәһәре йоклый, кичә кичтән генә шау-гөр килеп күнел ачкан гаскәриләр дә йоклый. Без саклык белән генә комендатураны эзләп урамнардан юлыбызны дәвам итәбез. Юлда очраган патрульләр кем һәм кая баруыбызны тәфсилләп аңлаткач җибәрәләр. Комендатураны эзләп тапканда кояш шактый югары күтәрелгән иде.

Химница шәһәре коменданты полковник Иванцов әйтүенчә, безнең унсигез кешелек төркем хәрби әсирләр эшелоны җыелып беткәнне көтәргә тиеш икән. Бу күнелле хәбәр түгел, чөнки бер ай тоткынлыкта булганнарны кырык бер, кырык икенче елны ук әсирлеккә төшкәннәр белән бер рәткә куюлары яхшыга илтмәячәк. Верховный башкомандующийның әсирләрне сатлыкҗаннар, дип исәпләргә дигән махсус әмере бар һәм аларга карата «Смерш» сугыш вакыты законнарын куллана. Әгәр өч-дүрт ел концлагерьда булганнар белән бер иләктә иләсәләр, озак срокка ГУЛАГ лагерьларына эләгүең бик тә ихтимал. Шуның өчен мона сөенмәдек, көендек. Арадан телгә оста офицерларга Иванцов белән

сөйләшүләрдә бөтен осталыкларын эшкә җигәргә туры килде. Полковник олы яшьтәге кеше, хәлебезгә керде тагын: немецлардан трофей итеп алынган зур гына санитар автомашинасы бирү өстенә, складтан берничә көнгә җитәрлек азык-төлек белән дә тәэмин иттерде. Төштән соң төркемебез автомашинага төялеп шоссе юл буенча Дрезденга таба җилдерә иде инде. Химницадан унбиш чакрымнар киткәч, артыбыздан җинел машинада пехота өлкән лейтенанты куып җитте. Ул лагерьдан Химницага безнең белән бергә килгән һәм немецча бераз сукалаганлыктан, Иванцов аны үзенә ярдәмче итеп алган иде. Өлкән лейтенант күп итеп затлы ризыклар, эчемлекләр китергән, юлдан читтәрәк куаклыктагы яшел аланда тукталып табын хәстәрләргә тәкъдим итте.

—Әсирлектә ачлыгын да, ким-хурлыгын да байтак татыдык, туарылып бер ял итик әле,—диде ул. Шатланып ризалаштык. Тәмләп ашап-эчеп, кичкә кадәр ял иткәннән соң, янә сәфәр чыктык. Өлкән лейтенант безне Дрезденга кадәр озатырга алынды. Тик без ул көнне союзниклар авиациясе бомбага тотып соңгы йортына кадәр җимерә язган бу калага барып җитә алмадык, пехота офицерының машинасы чыгымлый башлап, аның моторында казына торгач, җиргә карангылык инде. Дрезденга җиде чакрымнар ераклыкта ачык кырда кунарга туры килде. Юллар хәвефле булганга, чиратлап икешәр кеше кизүлек иттек.

Таң сызылуга Бобров белән Буянов әллә каян гына газогенераторлы машина табып алып кайттылар. Чәй әзерләп эчкәч, юлга кузгалганчы, азрак тагын черем итеп алырга булдык. Өлкән лейтенант Бобров шул машина эченә кереп ятты, ә сержантлар Метелкин, Мазин һәм мин якындагы чия төбенә сузылдык. Әле йокыга оеп кына бара идем, каты шаулашкан тавышка сискәнеп уяндым. Ни күрим: генераторлы машина дөрләп яна. Сикереп торып шул якка ташландык. Без килеп җиткәндә башкалар ашыга-кабалана ут капкан машинаны янәшә торган санитар машинасыннан читкә этеп азапланалар, бер-ике кеше кабинадан чыгып өлгерә алмаган Бобровны өстерәп чыгару белән мәшгуль. «Ни булды да, ни булды», дибез берни аңламыйча. Аннары белдек: «чуар йөрәкләр» һәркайда табыла, йокысы килмәгән берничә иптәш генератор ярдәмендә санитар машинаны кабызырга уйлаган, арадан берсе автомобильнең артына чыгып, ут ягырга көйләнгән мич капкачын ачкан, ә аннан көлтәсе белән ялкын бөркелгән. Бу хәлләр мизгел эчендә булганга, кабинада йоклап киткән Бобров ишекне ачып җиргә сикерергә дә өлгермәгән. Аның бит-куллары нык пешкән, чиләнеп кызарган тәнендә куыклары кабарып тора. Якындагы торак пункт медсанчастена илтеп салырга туры килде. Сәфәребез уңышлы башланмады, ахыры ни белән бетәр, хәерле булсын. Дрезденга җиткәч, комендатураны эзләп таптык. Анда безгә Беренче Украина фронты штабының бирәдә икәнен әйттеләр, шунда барырга киңәш иттеләр. Урамда беренче очраган подполковниктан сорашып белешкәннән соң фронт штабына киттек. Штаб урнашкан бина комендатурадан ерак түгел икән, машинаны кабызып тормадык, җәяү генә барырга булдык. Өер белән керү килешми, Бондаренко, Буянов, Иванченко һәм тагын бер танкист-лейтенант эчкәре үттеләр, калганнарыбыз тышта калды. Көткәндә вакыт акрын уза, иптәшләрне көтеп инде алҗыган идек—ниһаять күренделәр. Тик алар сөенечле хәбәр алып чыкмады, очучы составка Икенче Украина фронты штабына барырга кушканнар, ә танкистлар монда каласы икән. Һава дивизиясенең кайда урнашуы турында гомумән әйтергә теләмәгәннәр. Хәер, бусы аңлашыла, кулларында американлылар биргән пичәтле кәгазьдән башка берни булмаган кешеләргә кемнең тәфсилле аңлатма бирәсе килсен. Шикле элементлар тирә-якта болай да мыжгыган. Шулай итеп Пилаудан бирле бергә күп михнәтләр кичергән танкистлардан аерылырга туры килде. Бүтән әллә күрешәбез бу тормышта, әллә юк. Язмыш дигәнең кызык инде: көтмәгәндә очраштыра һәм көтмәгәндә генә аерып та куя адәм балаларын.

Машинабыз янында аптырашып басып торганда янәшәбезгә кин җилкәле,

озын буйлы очучы майор килеп туктады.

—Бондаренко, шайтан алгыры, син түгелме соң бу?—дип телгә килде майор кин елмаеп. Бондаренко да аны бер күз ташлау белән танып алды.

—Иптәш майор, нинди җилләр белән?—дип, ул кочагын җәеп майорга таба атлады. Танышлар кочаклашып күрештеләр. Сораштырулар китте. Кырык беренче елны Бондаренко очучылар мәктәбендә укыганда майор аларның укытучылары булган. Күрешмәгәннәренә дүрт ел үтсә дә, бер-берсен тиз таныдылар. Сөйләшә торгач күп нәрсә ачыкланды. Майор безгә Икенче Украина фронты штабын эзләп вакыт уздырмаска киңәш итте.

—Берлин тирәсендә һава дивизияләре күп, сезнең дивизия кергән өченче һава армиясе дә шул тирәдә,—диде ул мәсьәләгә ачыклык кертеп. Майор киңәшен тотып туры Берлинга юнәлдек. Асфальт юл күп урыннарда ватык, шуңа тизлек зур түгел. Берлинга якынайган саен юл кырыенда янган машиналар, хәрәкәтсез тимер өеменә әверелгән танклар ешрак очрый. Әнә немец танкы өстенә үрмәләгән безнең атаклы Т-34, коточкыч алыш күренешен гәүдәләндереп, соңгы талпынуында тынып калган. Агач колга башында такта кадаклап, биш, алты мең һәм аннан да зуррак саннар язылган билгеләр юл янәшәсендәге тәбәнәк калкулыкларда күзгә чалынып кала. Болары фашистлар ашыгыч төстә атып үтергән совет хәрби әсирләренең каберлекләре. Туганнар каберлеге. Күзләргә ирексездән яшь бөялә, тамак төпләренә төер утыра. И-их, каһәрләнгән сугыш, миллионнарча кешенең вакытсыз гомерен өздең, күпме хатыннарны тол, балаларны ятим иттең! Фашизмга беркайчан да аклану булмаячак.

Без Берлинның үзенә кермәдек, әйләнеч юл буенча аның көнчыгыш өлешенә чыктык. Комендатураны тапсак та, вакыт соң булганлыктан, анда кагылып тормыйча, комендатура карамагындагы янәшә бинада төн үткәрдек. Документләрне сорап аптыратмадылар. Үзара киңәшләшкәннән соң, комендатура белән бәйләнешкә кермичә, иртүк кабат юлга кузгалдык. Өйрәнеп җиттек: очраган бер пропуск пунктын кырыйдан әйләнеп узабыз. Югыйсә, хәлләрнең нинди юнәлеш аласын әйтеп булмый.

Риппин дигән шәһәргә җиттек. Монда уналтынчы һава дивизиясенең штабы урнашканлыгын әйттеләр. Үзебезнеке турында берәр хәбәр ишетеп булмасмы? Шундый өмет белән Бондаренко, Буянов һәм күрше полктан тагын бер лейтенант штабка киттеләр. Шактый озак торсалар да, алар аннан күңел җылытырлык хәбәр белән кайтмадылар. Тукталган урында кунарга туры килде. Иртәнге чәй хәстәрләп йөргәндә яныбызга бер очучы офицер килеп, кемнәр булуыбыз, кая баруыбыз белән кызыксынды.

—Бәлки, мин ярдәм итә алырмын,—диде ул. Аңа кыскача гына башыбыздан кичкәннәрне аңлаттык. Дивизиябез штабын эзләп йөрүебезне әйткәч, майор:—Сезнең дивизия Польша җирендә,—дип сөендерде, планшетыннан картасын чыгарып, Польшаның көнбатышындагы бер шәһәр аэродромына төртеп күрсәтте. Болай булгач эшләр күпкә җиңеләя инде, дивизияне тиз табарбыз. Шундый канатлы уйлар белән машинага бензин юнәтеп, тиз арада Риппин шәһәрен ташлап киттек. Тик күңелсезлек тә килеп чыкты. Биш-алты чакрымнар китәргә өлгермәдек, машинаның бер як көпчәге шартлады. Туктап, тәгәрмәч эзләүдән башка чара юк иде. Бондаренко белән Буянов бер якка, Метелкин белән мин икенче якка безнең өчен хәзерге вакытта алтыннан да кадерлерәк булган көпчәк дигән хикмәтне эзләп киттек. Күптән түгел аяусыз сугышлар булып узган урыннарда кыр тулы ватык техника, эзләп ерак барасы да юк. Янмыйча, янтаеп яткан җимерек машиналар да бихисап. Эзләнә торгач, санитар машинабызга яраклы тәгәрмәч юнәтү озак вакытны алмады. Берне генә түгел—икене! Көпчәкләрне машина кучәреннән сүтеп алгач, Метелкин берсен, мин икенчесен тәгәрәтеп, асфальт юл кырында калган машинабыз янына ашыктык. Без кайтканда Бондаренко белән Буянов күренмиләр иде әле. Алар да ике-

сенә ике көпчәк тәгәрәтеп кайтып житте. Шулай итеп машинабызга кирәкле бер тәгәрмәч урынына дүрт тәгәрмәчле булдык. Көпчәк алыштыру озак вакыт алмады. Һәм менә без тагын юлда. Автомашинаның як-якларына кызыл хач төшерелгәнлектән, безне туктатмыйлар, эчтә кемнәр утырганы күренми. Немецлар төзи беләләр шул, СССРда сугышка кадәр ике полосалы юллар, ай-һай, булды микән, анысы икеле, ә менә Германиядә андый асфальт юлларны күп урында очратырга туры килде. Кичкә кадәр хәтсез ара үттек. Төн карангылыгын япканда Биргиндор дигән зур гына немец авылына ял итәргә туктадык. Икенче көнне таң белән кузгалдык. Тик Биргиндордан ерак китәргә дә өлгермәдек, машинабыз бер-ике тапкыр «чах-пох» итеп алды да, сүнде. Бензины беткән икән. Бондаренко белән Буянов бензин эзләп киттеләр. Озак көтәргә туры килмәде, алар ягулык ташучы ниндидер машинага утырып кайтып та життеләр. Бензовоз шоферы яхшы хром курткага, бак тутырып ягулык салырга ризалашкан. Ун-унбиш минуттан кабат асфальт юл буенча жилдердек.

Польшага кадәр чыгарга туры килмәде, көннең икенче яртысында моннан ерак түгел аэродром булуын белдереп, һавага күтәрелүче һәм, киресенчә, жиргә түбәнәюче самолетлар еш күзгә ташлана башлады. Аэродромга өч-дүрт чакрымнар чамасы калгач, каршыга велосипедка атланган берәү очрады. Бу вакыт машинабыз автотрассадан нәни юлга борылган, ә велосипедлы кеше юл бирәм дип, кырыйга чыккан һәм жәяүләп атлый иде. «Чү, бу бит Кураев, әллә күзем ялгыш күрә инде? Юк, ялгыш түгел. Каршыбызга очраган велосипедлы—безнең полк эскадрильясының элемтә башлыгы өлкән лейтенант Кураев иде. Мин янәшәмдә утырып баручы иптәшләремә:

—Егетләр, карагыз әле, Кураев ич!—дип кычкырып жибәрдем. Бондаренко, Буянов, Метелкин мин күрсәткән якка карап, шулай ук Кураевны таныдылар.

—Кураев, иптәш өлкән лейтенант!—дип кычкырып жибәрделәр беравыздан. Кайсыларыдыр кабинаны дөбердәтергә кереште. Шофер янәшәсендә утырган Иванченко белән күрше дивизиядән булган лейтенант аны танымыйлар һәм шуңа күрә машинаны туктатмауларына гажәпләнәсе юк. Машина шып туктады. Ишекне ачып бер-бер артлы жиргә сикердек. Гажәпләнгән Кураев күзләрен киң ачып каршысына йөгерүче кешеләргә төбәлгән. Ул башта ниндидер ят кешеләрнең аның фамилиясен әйтеп кычкыруларына гажәпләнгән булса, таныш йөзләрне күргәч, күргәненә ышанмады булса кирәк. Аңлавыбызча, безне күптән үлгән яки хәбәрсез югалганнар исемлегенә керткәннәр иде. Янына килеп, Александрны төрле яклап кочаклый, үбә башлагач кына, ул моның төш түгел, өн икәнен аңышты.

—Сез исәнмени, сез исәнмени, кадерлеләрем?—дип кабатлады бертуктаусыз, әле беребезнең, әле икенчебезнең иңнәреннән кысып. Ул тавышсыз гына елый иде.

## Яңадан полкта

Кураев, барасы жиренә бармыйча, кире борылды. Санитар машинасы белән полк урнашкан авиашәһәрчеккә кайтып төшкәч, полкташлар аннан ким гажәпләнмәде. Эскадрильядагы элекке дуслар, танышларның шатлануына чик-чама юк иде. Башка эскадрильянықылар да килеп шатлык бүлеште. Күп тә үтмәде, полк командиры сәясәт буенча урынбасары капитан Роганецны һәм эскадрильябыз командиры капитан Лысенконы ияртеп килеп житте. Ике капитан да полкта күптән түгел генә хезмәт итә башлауга карамастан, очучылар арасында зур ихтирам казанып өлгергәннәр. Безнең исән булуыбызга башкалардан ким шатланмадылар. Алар артыннан ук полк адъютанты капитан Дулов һәм штабның башка офицерлары күренде. Дулов нишләптер мине күптәннән үз итә иде, килгән уңайга кочаклап алды:

—Кайттыңмы, улым, менә яхшы булган,—диде аталарча аркамнан сөеп. Ул моны берәү газиз баласыннан күпмедер вакытка аерылып торганнан соң янадан күрешкәндәге кебек кенә итеп әйтте.—Исән булуына ышана идем.

Полк командиры безне штабка чакырды. Урындыкларга тезелешеп утыргач, сүзсез сорау белән аңа төбәлдек. Хәзер язмышыбыз аның кулында, ул ни әйтсә, шулай булачак иде.

—М-да,—дип сузды каршыбызда басып торган подполковник Ударцев маңгаен җыерчыкландырган хәлдә уйланып. Аның борчылуын кәгазь тоткан кулының чак кына калтыравы күрсәтеп тора.—Мин сезне исәндер дип уйламаган идем. Йә, ярый, тормышта төрле хәлләр була. Сөйләгез тәртибе белән барысын да.

Без бер-беребезне тулыландыра-тулыландыра әсирлеккә эләккән көннән башлап полкташлар белән очрашуга кадәр булган вакыт аралыгында күргән-кичергәннәребезне җентекләп бәян иттек. Полк командиры һәм штабка җыелган офицерлар элекке әсирләрнең аңлатмаларыннан канәгать калдылар шикелле. Подполковник Ударцев болай диде:

—Хәлләр тәгаен ачыкланганчы һәм сез яңа экипажларга билгеләнгәнче, полктан читкә чыкмыйча бер ай ял итәрсез, аннары күз күрер.—Полк командиры телефон трубкасын күтәреп эскадрилья старшинасына Бондаренко, Буянов һәм мине мунча керткәннән соң яңа обмундирование белән тәэмин итәргә, паекка куярга әмер бирде. Мунча кереп өсләрне алыштыргач, безгә махсус бирелгән бүлмәдә чиста урын-җиргә ятып, яшь чагында гына була торган тирән йокыга талдык. Ике айдан артык вакыт эчендә бу беренче мәртәбә тынычлап йоклавыбыз иде.

Мең тугыз йөз кырык бишенче елның унсигезенче маеннан без яңадан авиаполкта хезмәттә саналабыз. Шулай булмаса, безне өр-яңадан киендермәсләр, паекка куймаслар, яхшы урын-җирдә йоклатмаслар иде. Икенче яктан карасаң, барлык бу нәрсәләр форма өчен генә эшләнә кебек, чөнки стройга иртәнге тезелүгә йөрмибез, хәрби өйрәнүләрдә катнашмыйбыз, политзанятиеләрдә утырмыйбыз. Билгесезлек күңелләргә тынгылык бирми, киләчәк язмышыбыз ничек булыр, дигән уй бер мизгелгә дә баштан чыкмый. Җитмәсә, ике-өч көн үтәр-үтмәс дивизиянең махсус бүлегеннән особистлар килеп әсирлектә үзебезне ничек тотуыбыз турында сорау алулар башлап җибәрде. Ярар, монысы белән килешеп тә булсын ди, монысы—особистларның төп эше. Эскадрильяда, полктагы кайбер иптәшләрнең «әсир», дип кырын караулары күңелгә тия. Алар моны тел белән әйтмәсәләр дә, ул аларның карашларында ярылып ята. «Бәла агач башыннан йөрми», диләр. Әсирлек газабы теләсә кемгә килергә мөмкин. Анысы кешенең ихтыярыннан тормый. Аннан һәрбер кешегә үзенең нинди шартларда әсирлеккә төшүен турында да аңлатып йөреп булмый. Хурлыклы тамга булып калачак һәм гомерлеккә кимсетү-түбәнсетүләргә дучар итәчәк әсирлек язмышы, аннан котылгач та аң-акылыңны томалый, «син—әсир, син—әсир!» дип чигәңдә тибә, һәр эш-гамәлеңне шул биеклектән торып кылырга мәҗбүр итә. Дүрт ел дәвам иткән канкойгыч сугыш йөрәгемне дүрт мәртәбәгә картайтты, чигәмә бик иртә чал кунды. Әсирлектә чагында иртәдән караңгы төнгә кадәр бер стакан суга, ярты телем ипигә тилмереп йөрүләр; аяк астында күренгән тәмәке төпчегенә үрелүгә җилкә тамырына килеп төшкән сакчы таягы; ачык диңгездәге кораб палубасында унике көн дәвамында карлы яңгырда, тозлы җилләрдә сәләмә өс киеме белән аунаулар—берсе дә эзсез югалмады. Хәер, адәм баласы боларны башыннан кичермәсә, әйтеп кенә ана аңлатып булмый. Ә мин күргәннәрне башкаларга күрергә язмасын.

*Ахыры киләсе санда*

## Эдуард Касыймовның тууына 80 ел

Әдәби эшчәнлеген кыска хикәяләр язудан башлаган Эдуард Касыймов киң катлам укучыларга «Гомер ике килми» романы аша танылa. Әлеге роман автобиографик җирлектәрәк язылса да, шәхес культы тарафыннан кыерсытылган кешеләрнең язмышы сурәтләнә анда.

1930 елның 7 ноябрендә хәзерге Киров өлкәсенең Слободской районы Карино авылында укытучы гаиләсендә туып-үскән Эдуард Касыймовка 1948-1953 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда да, укуын тәмамлап аспирантурада калырга теләгәндә дә күп каршылыклар тудыра әлеге «кара тамга». Бары тик шәхес культының дөрес гамәл булмаганлыгын тану ил күләмендә күтәрелгәч кенә аспирантурада белем алу, диссертация яклау бәхетенә ирешә ул. «Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор» дип аталган темага диссертация язу, балалар дөньясын өйрәнү, үз иту бәлки ана нәниләр өчен хикәяләр язарга да этәргеч биргәндер. 1959 елда аның балалар өчен «Кызыл маяклар» исемле хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. 1962 елда исә «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналында галимнәр тормышыннан алынып язылган беренче күләмле әсәре—«Кояш көн дә чыга» исемле повесте басыла. Әлеге әсәрләре дөнья күргәннән соң, ул 1964 елда СССР (Татарстан) Язучылар берлегенә кабул ителә.

Гаиләсе белән Чулман аръягына—Алабуга каласына күчеп яши башлагач, Э. Касыймов Бондюг химиклары тормышын яктырткан «Чулман—оныклар дәрьясы» дигән дилогиясен («Томан аша», «Һаваларда тургай» романнары) иҗат итә. Биредә ул бер үк вакытта Алабуга педагогия институтында татар әдәбияты фольклоры һәм татар әдәбияты фәннәрен дә укыта.

Тынгысыз күңел һаман эзләнүдә—Чаллы автогиганты калкып чыгып, төрле илдән яшьләр җыела башлагач Э. Касыймов та читтә калмый, язылачак әсәрләренә яңа геройлар эзләп 1972 елда Чаллы каласына күченә. 1980-1981 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы оешмасына җитәкчелек итә. Бу вакытта инде ул шактый гына тормыш тәҗрибәсе туплаган талантлы язучы булып өлгерә. Патриотизмны калку итеп сурәтләргә тиешле еллар булса да, Э. Касыймов үзенең әсәрләрендә сәнгати дөреслектән читкә китмичә, әдәби яктан камил булган күп кенә әсәрләр иҗат итә. «Җир балкышы» исемле романы исә аның зур күләмле соңгы әсәре була.

«Чулман—оныклар дәрьясы» дилогиясе Мәскәүнең «Современник» нәшриятында рус телендә дөнья күргәннән соң, 1978 елда ВЦСПС һәм СССР Язучылар берлегенең махсус премиясенә лаек була.

Татар әдәбиятына лаеклы өлеш керткәне өчен дистәдән артык китап, күпсанлы романнар авторы Э. Касыймов 1980 елда «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Эдуард Касыймов 1986 елның 21 мартында Чаллы шәһәрендә йөрәк авыруыннан кинәт вафат була.



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ РАЗИЛ

## Манарадан Ходай якынрак

Башлангыч мәктәптә без үзебезнең авылда элеккеге мәчет бинасында укыдык. Бу агач мәчет 1921 елда ук салынган булса да, бер якка да кыйшаймаган, таушалмаган, бары тик манарасы гына җил-давыл искән көннәрне, үз язмышыннан сыкранган кебек, ыңгырашып-ыңгырашып куя. Казан өчен, Татарстан, бөтен татар халкы өчен Сөембикә манарасы нинди мәгънәгә ия булса, безнең манаралы мәчет бинасы авылыбыз халкы өчен шул дәрәҗәдә кадерле, изге иде. Егерме беренче ачлык елында авылдашларыбыз аны ничек торгыза алганнардыр, бу могҗиза миңа бүгенге көнгә кадәр ачылмаган сер булып кала бирә. Ә инде аның ыспайлыгына, төзелеш мөкәммәллегенә, архитектура камиллегенә сокланмаган кеше булмагандыр. Каян килгән гап-гади авыл агайларына, мәдрәсә белемле балта осталарына андый маһирлык! Хәзер дә авыл саен мәчет салалар, Татарстанда аларның саны бер мең өч йөздән артып китте бугай инде. Әмма аларның күбесе, Аллаһ йортыннан битәр, түбәсенә торба торгызган сыер абзарыннан әлләни аерылып тормый. Манаралары да бинасына ятышсыз, йә ул иләмсез юан һәм тәбәнәк-тупыйк була, йә завод торбасы сыман чамасыз биек һәм нәзек итеп эшләнә. Төзүчеләргә архитектураның асыл кагыйдәсе—пропорция саклый белү сәләте, гармония камиллеге җитмәү аркасында халыктан тиенләп җыелган акчалар шундый зәвыксыз мәчетләр төзүгә сарыф ителә. Әйткәнемчә, безнең авыл мәчете агач архитектурасының гүзәл үрнәкләреннән саналып, дәүләт тарафыннан саклана торган тарихи һәйкәлләр исемлегенә кертелгән иде.

Мәктәптә укыганда минем иң зур хыялларымның берсе—мәчет манарасының иң очына менеп, тирә-юньне күзәтү иде. Манара ике балконлы булып, өстәге балконга кадәр бормалы баскычтан менеп була. Әмма бу әле манараның өчтән ике өлеше генә, очлаеп килеп, түбәсенә көмеш төстәге ай кунаклаган конуссыман өлешендә баскычмазар юк, анда күгәрченнәр патшалык итә. Күгәрченнәргә керәп-чыгып йөрү өчен иң югарыда кеше башы сыярлык кына тәрәзә дә бар. Минем хыял ничек тә шул ай янына кадәр менеп, әлеге тәрәзәдән дөньяга күз салу иде. Аның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Берчакны мин әнкәйдән: «Мәчеткә манара нигә кирәк?»—дип сораган идем. Ул миңа: «Манарага менеп мөәзин азан әйтсен өченгә, улым. Аннары... манарага менгәч, бөтен авыл күренә, тавыш та ераккарак ишетелә. Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная»,—дип җавап бирде. Бу сүзләр минем күңелемә гомерлеккә уелып калды. Манарага менеп әлеге күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карасам, миңа күрше авыллар гына түгел, Казан һәм Мәскәү калалары, бөтен дөнья, хәтта Ходай Тәгалә үзе дә күренер сыман иде.

Дүртенчедә укыганда барыбер мендем мин ул манара очына. Калай астындагы черек такталарны сындыра-сындыра, кул-аякларны каната-каната булса да, иң өскә үрмәләдем. Күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карагач, әллә инде алдымда

беренче мәртәбә шундый иркен манзара ачылудан, әллә инде манара чайкалудан, күз алларым томаланып, башым әйләнеп китте, күнелгә шом керде. Әйтерсең Ходай Тәгалә рөхсәтсез-нисез үз биләмәләренә кергән өчен шулай акылымны томалый иде. Билгеле инде, мондый нәтиҗәләрне мин соңрак, бераз үскәчрәк ясадым, ә ул чакта кабалана-кабалана манарадан төшкәнем генә истә калган.

Үзебезнең авылда—башлангыч, күрше Шәңгәлчедә—сигезьеллык, Түбән Камада урта мәктәп тәмамлаганнан соң мин башта—Казанга, аннары Мәскәүгә укырга китеп бардым. Авылга кайткан саен әллә кайдан ук иң беренче булып мине мәчет манарасы каршылый торган иде. Әмма ул елдан-ел таушалып, әкренләп бер якка янтаеп бара. Бер кайтуымда аның инде калайларын җил каерып аткан, ае да менә-менә егылып төшәм дип кыйшайган иде. Минем яңа китабым чыгып, ярыйсы гына гонорар алган чак, Казаннан реставратор егетләр алып кайтып, 1979 елның көзендә мәчет манарасын сипләргә тотындык. Ул вакытта район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән яшьлек дустым Рифкат Муллин да ярдәм кулы сузды, авылдашлар да хәлдән килгәнчә булыштылар. Шулай итеп бергәләп манараны торгызып та куйдык. Ай күтәргән көнне бөтен тирә-юнь авыллар җыелышып көч-куәт биреп торганны күрү—минем өчен әйтеп бетерә алмаслык рәхәтлек иде. Дөрес, Казанга кайтуга башта ВЛКСМ Өлкә комитетына, аннары партия Өлкә комитетына чакырып, утлы табада кыздырдылар, идеологик яктан җитлекмәгән кеше икәнлегемне, балаларны коммунистик рухта тәрбияләргә тиешле «Ялкын» журналында эшләргә әзер булмавымны искәрттеләр.

Мәчетебез никадәр матур булса да, рәхимсез еллар барыбер үзенекен итте, агач бина әкренләп тузып, берзаман ярымҗимерек хәлгә килде. Аны сүтүдән башка чара калмаган иде. Әмма сүткәнче авыл осталары аның барлык үлчәмнәрен алып, бизәкләрен фотога төшереп, нәкъ шундый ук кыяфәттәге таш мәчет салырга вәгъдә бирделәр. Озак еллар төзелештә прораб булып эшләгән энекәшем бу эштә башлап йөрүче булды, финанс мәсьәләләре күбрәк минем өскә төште, авылыбыз эшмәкәрләре дә кулдан килгән ярдәмне күрсәттеләр.

Бүгенге көндә авылыбыз мәчете, элеккесеннән дә матуррак, мәһабәтрәк булып, дистәләгән чакрымнан балкып тора. Балчыклы урманың чыгуга минем күз карашым иң беренче булып шул мәчет манарасын эзли башлый. Әгәр манара булмаса, авылымның бөтен яме китәр, хәтта авыл үзе дә бетәр, юкка чыгар кебек тоела миңа. Гомумән, мәчетсез, манарасыз мөселман авылын, татар авылын камил авылга санамыйм мин.

Шушы мәчет манарасы аша иң беренче мәртәбә дөньяның зурлыгын, матурлыгын күрүем, тәүге тапкыр хыялый күккә ашуым бүгенгедәй хәтеремдә, күз алдымда. Ул чакта мин күккә генә ашып калмадым, тәүге кат Аллаһы Тәгаләнең үзе белән очрашкандай булдым. Әле бүген дә колагымда әнкәемнең: «Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная», дигән сүзләре яңгырап тора сыман.

## Минем беренче эшмәкәрлегем

Безнең әткәй озак еллар агроном һәм колхоз рәисе булып эшләде. «Уңыш» колхозының уңышы мул булганга, эшләре яхшы баргангадыр инде, көннәрдән бер көнне аны «Хезмәт Кызыл байрагы» ордены белән бүләкләделәр. Билгеле, безнең гаилә, безнең авыл өчен генә түгел, бөтен район өчен дә заманында зур вакыйга иде бу. Миңа ул чакта нибары җиде-сигез яшь кенә булгангадыр инде, әлеге орденның кыйммәтен аңлап бетермәгәнмендер, аны пионер, октябрят значогы кебегрәк бер нәрсә дип уйладым. Әткәйнең дә аны күкрәгенә тагып, кукыраеп йөргәнен хәтерләмим. Өйдә апалар, сеңелләр белән без аны уенчык итеп уйный идек. Шулай сигез бала чиратлап уйный торгач, ул каядыр юкка чыкты, күпме эзләп, әлегә кадәр таба алганыбыз юк. Документы калды калуын, шуны күрсәтеп, киләчәктә, бәлки, дубликатын алырбыз дип уйлыйм. Еллар үткән саен әткәй-әнкәй белән бәйле һәр нәрсәнең кыйммәте арта бара икән...

Ул елларда орденга иярттеп бүләк бирү гадәте дә булган, ахрысы. Көннәрдән бер көнне безнең ишегалдында ялык-йолык килеп торган чып-чын велосипед пәйда

булды. Билгеле, минем сөенечнең чиге-чамасы юк, бүген «Мерседес» бүләк итсәләр дә ул кадәр үк шатлана алмас идем кебек. Авылыбызда моңа кадәр бер-ике генә велосипед булганга күрә, әлеге бүләкне берничек тә бәяләп бетерерлек түгел иде. Шуңа күрә минем үземә бу велосипедны орден өчен түгел, ә орденны велосипедка ияртеп биргәннәрдер кебек тоелды.

Велосипед утыргычына буй җитмәгәнгә күрә, борын каната-каната ике-өч көндә рам астыннан йөрергә өйрәндем. Җыен бәйрәме көннәрендә бөтен авылны шаккатырып авыл башындагы мәйданга велосипедта барырга иде исәп. Бәйрәм җитәргә берничә көн кала күрше Мәликә апаларга Пермь шәһәреннән кунаклар кайтып төште. Араларында миннән ике-өч яшькә генә өлкәнрәк бер малай да бар иде. Аның белән тиз арада танышып, дуслашып та киттек. Миннән өлкәнрәк булгач, билгеле инде, аның аягы педальгә җитә, рәхәтләнеп утыргычка утырып йөри ала. Әмма әнкәй: «Велосипедны беркемгә дә бирмә»,—дип колакка киртләп куйган иде. Әнкәй дигәннән, әткәй колхоз рәисе, коеп куйган коммунист булса да, әнкәй авылның заманында «кулак» дип аталган хәлле кешеләр нәселеннән иде. Шушы нәсел каны уйнагандырмы, белмим, кинәт кенә миндә алыш-биреш итү теләге уянгандай булды. Ә моның өчен бик кулай сәбәбе дә бар иде. Кайткан көнне үк теге малай (исемен онытканмын инде) кесәсеннән пистолетка охшатып ясалган зажигалка чыгарып күрсәтте. Пистолетын безгә төбәп «черт» итүгә, көпшәсендә ут кабынды. Велосипед шәп нәрсә булса да, мондый хикмәтне исә без—авыл малайларының моңа кадәр төшендә дә күргәне булмагандыр әле. Малай пистолетын чертләткән саен минем күңелдә дә ут кабына, ул ялкын көннән-көн көчәеп, бөтен тәнемә йөгерә иде. Рам астыннан йөрү шактый җайсыз булгангамы, мин инде бераз ялыктыра башлаган велосипедны әлеге пистолет-зажигалкага алыштырырга ният иттем. Ниятемне кунак малайга әйткәч, ул артык сатулашып тормады, зажигалкасын кулыма тоттырды да үзе велосипедка атланып урам буйлап китеп барды.

Билгеле, бу «бик тә отышлы» алыш-биреш хакында мин өйдәгеләргә әйтмәдем. Велосипедны әткәй миңа бирде бит, димәк, мин аның белән теләсә-нәрсә эшли алам дип уйладым. Пистолетны чертләтеп малайларны да куркыткан булдым, чыпчыкларга да төбәп атып карадым. Шулай көне буе туйганчы уйнадым мин аның белән, кич арып-талып пистолетны кочаклап йокыга талдым.

Иртә таңнан торган әнкәй, минем кочактагы пистолетны күргәч, башта куркып калган. Әткәйне чакырып күрсәткәч кенә аның чын пистолет булмаганын аңлаганнар. Билгеле инде, моның өчен миңа әткәйдән шактый ук эләкте. Зажигалканы кире биреп, велосипедны үзебезгә алып кайтырга туры килде. Шулай итеп, минем тәүге эшмәкәрлегем, алыш-бирешем уңышсыз тәмамланды. Әмма моңа һич кенә дә үкенмим, әгәр әткәй-әнкәй ул чакта мине хуплаган булса, бәлки, кемнәрдер кебек гомер буе шулай алтыга алып, бишкә сатып сәүдә кылып йөрер идем әле.

## Туктатыгыз мине

Авылда велосипедта йөрмәгән малай булмый торгандыр. Берничә ел велосипед тәгәрмәче тәгәрәткәч, инде мотоциклга атланасым килә башлады. Мин алтынчы сыйныфта укыган чакта әнкәйнең олы энесе Раиф абый кайдандыр мотоцикл сатып алып кайтты. Бер генә урынлы, артында тимер утыргычлы бу матайга авыл халкы нигәдер «Кәҗә тәкәсе» дигән исем кушты. Элекке хуҗасы шактый туздырып өлгергәндерме, матайның башы ремонттан чыкмый иде. Ярый әле Раиф абый—алтын куллы кеше, сәгать тә төзәтә, чана да ясый, тәгәрмәч тә бөгә, пыяла да кисә, йорт та сала, тимерчелектә дә эшли, хәтта гармун да ясый,—кыскасы, белмәгән һөнәре юк. Мин күбрәк аның тирәсендә кайнарга тырышам, мотоцикл төзәткәндә ачкыч-мазар биреп торам. Моның өчен ул мине соңыннан арттагы тимер утыргычка яисә бак өстенә утыртып урам әйләнә. Ә минем хыял тагын да зурракта, Раиф абыйдан рөхсәт алып үземә рульгә утыруда. Ә андый рөхсәт һаман юк та юк. Велосипедта җил кебек очып йөргән малайга мотоцикл йөртү ни тора инде югыйсә!

Көннәрдән бер көнне Раиф абый матаен ишегалдында калдырып, күрше авылга шабашкага—йорт салырга китте. Бер киләм бабайларга, ике киләм, ә мотоцикл

мине кызыктырып, ымсындырып, үзенә чакырып һаман шул килеш ишегалдында басып тора. Шулай кызыгып йөри торгач, түземем чиктән ашып, матайга утырып карарга булдым. Аяк белән әллә ничә тибеп тә кабынмагач, бакча артындагы юлга чыгып этә башладым. Бер-ике төчкергәннән соң кабынып киткәч, сикереп менеп атландым да тузан туздырып урманга таба юл тоттым. Басу юлларын урап туйгач, матай белән авыл урамына керергә булдым. Күрсәннәр әле авылның кызлары-малайлары минем кем икәнлегемне, имеш. Авыл уртасындагы буа аша салынган тар гына агач күпергә житәрәк каршыма килүче атлы арбаны күреп югалып калдым. Инде нишләргә? Каушаудан тормозга басарга онытып пырылдап күпер башына килеп життем дә, атка бәрелүдән куркып, рульне унга бордым да матаем-нием белән буага очып төштем.

Авыл халкы, жыелышып, мотоциклны багорлар белән буадан күтәреп алдылар.

Шул вакыйгадан соң Раиф абый берничә ел буе мине матае янына якын китермәде. Ә унынчыны бетергән елны (ул чакта без унбер ел укый идек) Раиф абый белән бергә шабашкада йорт салып йөреп, кеше кулыннан тотылган «Иж-Планета» мотоциклы сатып алдым. Анысы да шактый хикмәтле матай булды аның.

Матай һәрчак ишегалдында яисә лапаста тора, миннән башка ана утыручы юк. Әткәйнең матайга исе китми, ул ат жигеп йөри, энекәшем Рәмзил әле бәләкәй, матайда йөрерлек түгел, ана әле ун яшь чамасы гына. Әмма, гөнаһ шомлыгына каршы, ул да мина охшаган булып чыкты. Шулай бер көнне ул иптәш малайлары белән матайны урамга тәгәрәтеп чыгарган да рульгә утырган. Малайлар арттан бераз этеп баруга, минем «Иж-Планета» ярсып алга ыргылган. Велосипед йөртә белгән Рәмзил югалып калмаган, рульне туры тотып, авыл башына таба киткән. Басуны урап янадан авыл урамына килеп кергән бу. Безнең өй янына житүгә матайны туктатырга маташа, әмма газга басудан, рульне борудан башка монын жаен, рәтен белми. Шулай итеп авыл урамнарын бер урый, ике урый, өч урый бу, әмма һаман туктый алмый. Урамдагы шау-шуны ишетеп, мин өйдән чыгып килгәндә, ул артыннан куе төтен чыгарып, жан-фәрманга матайда чабып килә, үзе бертуктаусыз: «Туктый алмыйм! Туктатыгыз мине!»—дип кычкыра иде. Без барыбыз да аптырашта, нишләргә белмичә, авыз ачып тик торабыз. Әгәр шунда бензины бетеп матай үзе туктамаса, бу хәл ничек тәмамланган булыр иде, белмим. Балачакта үземнен дә шундыйрак мажарага юлыкканым булганга күрә, монын өчен энекәшкә артык каты кагылмадым. Бераз үсә төшкәч, ул мотоциклда миннән дә шәбрәк йөрергә өйрәнде, эшли башлагач, иң беренче итеп үзенә матай сатып алды.

## Аучы булдым

Әткәй ягыннан безнең бабайларны элек заманда аучы булган дип сөйлиләр иде. Шуны ишетеп, бер заманны мин дә ауга чыгарга хыялланып йөри башладым. Ләкин иң әүвәл аучыга мылтык яисә тозак ише кораллар кирәк бит. Аларны каян табарга? Тозакка әлләни исем китмәде, булгач-булгач мылтык булсын дип, шуны табу чарасын эзли башладым. Кибеттән сатып алу хакында уйларга да мөмкин түгел, монын өчен, беренчедән, акча юк, икенчедән, рөхсәтсез сина аны кем сатсын ди әле. «Бирәм» дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, көннәрдән бер көнне бабайларнын мунча түбәсендә актарынып маташканда иске-москы арасыннан күгәреп беткән бер мылтык килеп чыкты. «Ватык берданка ул, бернигә дә яраклы түгел»,—дип бабай ана кул гына селтәде. Ә мин үжәтләнеп эшкә тотындым. Башта мылтыкны сүттем дә, озынча ләгәндә керосинга батырып берничә көн тоттым. Аннары ком белән ышкып күгәреген чистарттым. Сынган пружина урынына янасын табып куйдым. Шулай маташа торгач, күгәргән берданка, ниһаять, мылтык төсенә керде. Яхшымы-яманмы, инде мылтыгым бар, ә патронын каян табарга? Бабайның эш кораллары әржәсеннән буш патрон табып, аңа шырпы күкерте төяп тутырдым, ядрә урынына вак кадак кискәләп салдым. Әмма күпме генә тырышсам да, мылтыгым барыбер атмады. Әмма шушы хәлләрдән соң әче телле авыл малайлары мина «Аучы Разил» дигән кушамат тактылар. Гомеремдә бер чыпчык та атып карамаганга күрәдерме, бу кушамат мине бик тә гарьләндерә, шул мыскыллы сүзне

ишетмәс өчен жир тишегенә керердәй була идем. Тора-бара бу кушамат бердәнбер исемемә әверелде, аннан «Разил» сүзен төшереп калдырып, берзаман авылда мине «Аучы» дип кенә йөртә башладылар. Бу кушаматтан котылу чарасын уйлап, төннәр буе йоклый алмый ята башладым.

Әткәй айга берничә мәртәбә ул вакыттагы район үзәге Ширәмәткә райком жыелышларына бара торган иде. Бер баруында ул Ширәмәт базарыннан алагаем олы йорт куяны алып кайтты. Без ул куянга лапас эчендә тактадан бәләкәй генә өй сымак нәрсә әтмәлләп куйдык. Иртән-кичен-көндезен алдына ризык салып, сабый бала караган сыман карасак та, ул яңа жиргә, яңа хужаларга иялəшә алмадымы, әллә берәр чире булдымы, көннән-көн боега барды, тора-бара бөтенләй тамактан калды. Ә көннәрдән бер көнне иртән хәлен белергә дип чыксам, ул кышкы суыктан тораташ булып, хәрәкәтсез ята иде.



Инде нишләргә? «Куянны авыл зиратына кешечә жирләп булмый бит инде, һич югы басуга яисә урман читенә илтеп күмәргә кирәк»,—диде әнкәй. Көн буранлап торса да, жан иясен көнендә жирләргә кирәк дигәнне истә тотып, куянны жилкәгә астым да авыл читендәге урман ягына таба атладым. Ни әйтсәң дә, уникe яшьлек малайны урман ягы шомландыра. Куркуны басар өчен, атмый торган мылтыкны да жилкәгә асып куйган булдым. Ул елларны урманда бүреләр шактый күп очрый торган иде. «Ахмак бүре атмаган мылтыктан да курка»,—диләр бит безнең авылда. Басу капкасын чыгып бераз баргач, каршыма күрше Галиулла абый очрады. Урманнан утын әзерләп кайтуы икән. Минем жилкәдә мылтык белән куянны күргәч, ул: «Ай-һай, зурысын чәкегәнсең, юкка гына «Аучы» дип йөрмиләр икән үзеңне!»—дип тел шартлатты. Мин, нәрсә әйтергә дә белмичә, монсу гына елмаеп куйдым. Урманга житәрәк чанасына коры чыбык-чабык төягән тагын бер кеше күренде. Аръякның күкәй жыючы, әнкәй әйтмешли, теленә шайтан төкергән Ялтер Хәсәне икән монысы. Ул да алагаем олы куян түшкәсен күреп аһ-уһ итте.

Икенче көнне иртән мин авылның чып-чын аучысына әверелеп уянган идем инде. Минем куян атып кайтуым хакындагы хәбәр көне-сәгате белән бөтен авылга таралган, очрашканда инде хәзер миңа мыскыллап түгел, ә нииндидер бер хөрмәт белән «Аучы Разил» дип әйтә башладылар. Тора-бара мин бу куян мажарасын бөтенләй оныттым, бабайның иске мылтыгын да янадан мунча түбәсенә менгереп ыргыттым, аучы булу хыялы да әкренләп юкка чыкты. Мыскыллы сүз дип кабул итмәгәнгә, бөтенләй исем китмәгәнгәме, озакламый авыл халкы да «Аучы» сүзен онытып, мине янадан мулла кушкан исемем белән Разил дип кенә йөртә башлады.

## Ат урлау

Чит кеше белән очрашырга-танышырга туры килгәндә мин гадәттә үземнең кемлегем хакында сөйләп тормыйм, «Алмаз Хәмзин белән бер авылдан»,—дип кенә жибәрәм. Алмаз гажәеп талантлы һәм йөремсәк кеше. Үзе музыкант, жырчы, шагыйрь, сүз остасы,—кыскасы, татарда аны белмәгән кеше бик сирәк. Аннары унбер ел буена аның белән бер партада утыруыбыз, бергәләп жырлап, концертлар куеп йөрүебез, ярыша-ярыша шигырьләр язуыбыз хакында сөйлим. Шушындый кешенең дусты һәм авылдашы булгач, мине дә төшеп калганнардан түгелдер диюләренә өметләнәм.

Алмаз белән безнең михнәтле һәм мажаралы балачагыбыз, яшьлек елларыбыз турында бик тә кызыклы һәм гыйбрәтле кыйсса язып булыр иде. Анысын киләчәккә калдырып, бу юлы үсмерчак елларының бер вакыйгасын гына бәян итәргә уйлыйм...

Минем әткәй, инде әйткәнемчә, колхоз рәисе, Алмазныкы—партком секретаре, алар гомер буе шулай бер-берсенә терәк булып, аралашып яшәделәр. Алмазның әтисе

Наил абый сугышта аягын калдырып кайткан, урам буйлап килгәндә әллә каян ук аның протезы шыгырдаган тавыш ишетелә иде. Мин гомумән сугыштан кайткан кешеләрдән, бигрәк тә аяксыз яисә кулсыз фронтовиклардан бераз шөлли идем. Бәлки, бу курку түгел, ә үземчә хөрмәт итү хисе булгандыр. Аннары, нишләптер, миңа сугыштан кайткан һәр кешенең өендә автоматы яисә пистолеты бардыр кебек тоела иде.

Мин әле бүген дә үземне Наил абыйга бурычлы кеше дип саныйм, аңа рәхмәтләр әйтеп яшим. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, без укуны Зәй елгасы аръягындагы Кызыл Чапчак урта мәктәбендә дәвам итәргә ниятләп, документларыбызны шунда илтеп тапшырган идек. Әле яңа төзелә башлаган Түбән Кама шәһәрендә 1нче урта мәктәп ачыласын ишетеп, Наил абый безнең документларны аннан кире алып, шул яңа мәктәпкә илтеп биргән. Ә Түбән Каманың беренче мәктәбе Алмаз белән безнең язмышта хәлиткеч роль уйнады дисәм, арттыру булмастыр кебек.



Туктале, ниятем бер вакыйга хакында сөйләү иде бит әле... Шулай без Алмаз белән Түбән Камада укып йөрибез, шәһәргә терәлеп торган Актүбә авылында интернатта яшибез, һәр шимбә авылга кайтып, дүшәмбе иртән китәбез. Безнең егет булып килгән, борынга ис керә башлаган чак. «Күрше тавыгы күркә булып күренә» дигәндәй, авыл кызларына күз салу юк, җай чыккан саен күрше авылга йөрергә тырышабыз. Безнең авылга бер иңсәсе белән терәлеп торган Шәңгәлчене күрше авылга санау юк, якшәмбе җиттисә, урман артындагы Иштеракккә юл тотабыз. Җитмәсә, якын дустыбыз Рифкать тә, Алмазның әнисе—безнең беренче укытучыбыз Разия апа да тумышы белән шул авылдан. Ә кызларының чибәрлеге турында әйтәсе дә юк инде! Шулаен шулай, әмма Иштеракккә карурман аша сигез чакрым барасы, аннары төн уртасында сигез чакрым кире кайтасы. Бу араны берничә мәртәбә тәпи-тәпи узгач, моның никадәр михнәтле сәяхәт икәнен чынлап аңладык. Аңлавын аңладык, ә күңел һаман шул авылга тарта бит, каһәр! Чираттагы якшәмбегә авылга кайткач, без, ниһаять, моның чарасын таптык. Әткәй иртә таңнан «Җүләр» исемле үзен-үзе белештерми чаба торган юртак айгырны җигеп эшкә китә, кич арып-талып өйгә кайта. Гадәттә, кичләрен мин Җүләрне аръяктагы ат абзарына илтеп, тугарып кайта идем. Бу юлы да әткәй кашовкадан төшүгә, аның урынына менеп утырдым да... Түбән очка, Алмазларга таба элдердем. Ул мине, сөйләшенгәнчә, баянын күтәреп, капка төбендә көтеп тора иде. Кичке эңгер-меңгердә безне абайлаучы булмады, Җүләр, бер чөңгерүгә үк канатлы атка әверелеп, безне хыялдагы Иштерәк авылына таба очыртып алып китте. Шулай һәрчак җан ярсуы белән ак күбеккә батканчы чапканга «Җүләр» исеме кушканнардыр инде аңа.

Иштерәктә Алмазларның туганнарында атыбызны тугарып калдырдык та үзебез клубка юл тоттык. Барышлый Рифкатьләргә дә кереп чыктык, клубта халык таралганчы, хәлдән тайганчы биедек, җырладык. Аннары кызлар озаткан булып, кышкы авыл урамын кат-кат урадык. Эчләргә суык төшеп, аяклар бозлана башласа да, сер бирү юк. Чөнки без бит андый-мондый малай-шалай түгел, ә колхозның иң атаклы айгырын җигеп, затлы кашовкада утырып килгән Ташлык егетләре! Билгеле, ул атны әтиләргә әйтмичә, урлап киткәнне кешегә сиздерү юк инде...

Төн уртасы җиткәч, безнең күңелләргә дә шом керә башлады. Әле урман аша кайтып, атны тугарасы да бар бит. Әткәй сәгать биштә аны җигеп эшкә китәчәк. Аңа кадәр Җүләргә бераз хәл алып, тамак ялгап, тирен киптереп өлгерергә кирәк. Шундый уйлар белән ишегалдына керсәк, Җүләребездән җилләр искән. Кашовкасы урынында, ә атыбыз юк. Шунда гына без аның баганага бәйләгән йөгәнне өзеп, ачык капкадан чыгып качканын аңлап алдык. Инде нишләргә? Төн уртасында җәяүләп өйгә кайтсаң, кара тавыш чыгасы көн кебек ачык. Атны сорамыйча алып китү, дөресрәге, урлау үзе бер җинаять булса, югалган ат өчен җавап бирүне күз

алдына да китерерлек тугел. Мондый чакта авылга әти-әни янына кайту безнең өчен тәмугка барып керү белән бер иде. Кара кайгыга батып, Иштерәк урамын әллә ничә кат урасак та, атыбыз табылмады. Алмаз белән бүрекләрне батырып кидек тә төн уртасында урман аша унике чакрым ераклыктагы Түбән Камага таба җәяүләп юл тоттык. Мең төрле уйлар уйлап, юл буе сөйләшми бардык. Урман читендәге төрмә биналары янына житкәч, Алмаз ишетелер-ишетелмәс кенә: «Җүләр югалса, безне судка бирерләр микән?»—дип куйды. Мин җавап кайтармадым.

Шушы хәлдән соң без алдагы якшәмбедә авылга кайтмадык. Әти-әни шелтәсеннән, кеше күзенә күренүдән шулай нык курыкканбыздыр инде. Тагын бер атнадан Наил абый интернаттан безне үзе килеп алды. Аннары ниләр булганын сөйләп тормыйм, анысы болай да аңлашыла торгандыр. Ә Җүләргә бернәрсә дә булмаган, Иштерәккә беренче тапкыр гына килүе булса да, ул, адашмыйча, үз аягы белән Ташлыкка кайтып җиткән. Безнең моңа кадәр Иштерәккә йөрүебезне шәйләгән Наил абый икенче көнне үк ат караучы Газиз абыйны кашовка алырга җибәргән.

Шул вакыйгадан соң Җүләргә хөрмәтем бермә-бер артты, тора-бара ул минем якын дустыма әверелде. Бары тик еллар узгач кына мин аның гаҗәеп тә акыллы икәнен, ә үзебезнең ул вакытта никадәр башсыз, дөресрәге, «җүләр» булуыбызны аңладым.

## Затлы баян

Алмаз белән без һәр елны үзебезнең авыл сабан туена кайтырга тырышабыз. Кайткач, ел буе күрешмәгән яшьтәшләр белән очрашырга-аралашырга да җай чыга, өйдән өйгә йөреп бәйрәм итәргә дә туры килә. Сабантуйда (элегрәк безнең якта аны «Җыен» дип йөртәләр иде) Алмаз бигрәк тә көтеп алынган кунак. Чөнки ул җырчы, баянчы, сүз остасы, аннан башка теләсә-кайсы бәйрәмне күз алдына да китереп булмастыр кебек.

Бер елны чираттагы сабантуйга кайтуына әтисе Наил абый Алмазга өр-яңа бик тә шәп баян алып куйган иде. Германиядә эшләнгән бу затлы баянның бәясе дә машина хакы тора дип сөйләделәр. Бүләкне биргәндә Наил абый Алмазның колагына киртләп куйды: «Бу баянда өйдә һәм клубта гына уйныйсың! Сабан туенда яисә урамда шыңгырдатырга иске баяның да бик яраган. Алай-болай ялгыш яңгыр тамчысы төшсә дә, яңа баянның күреге җебеп, рәттән чыгарга мөмкин.»

Шулай да үзләренең капкасы төбендәге утыргычта уйнарга каршы килмәде Наил абый.

Сабантуй көнне иртәнге якта шулай капка төбендә яңа баянын сайратып утырганда без өчәүләп: мин, Рәмзил энекәш һәм Рифкат дустыбыз машина белән Алмаз янына килеп туктадык. Тавышыбызны ишетеп әтисе дә урамга чыкты. Яңа баянны, баянга кушып үзен дә мактый торгач, Наил абыйның күңеле йомшарды бугай, яңа баянны сабантуйга алып чыгарга рөхсәт бирде. Житмәсә, Рифкат: «Сабантуйда да уйнарга ярамагач, нинди баян инде ул»,—диюгә, бөтенләй таралып китте. Без дүртәүләшеп машинага төялдек тә баян уйный-уйный Югары очка, Җыен мәйданына менеп киттек.

Алмаз, һәрвакыттагыча, көне буе мәйдан уртасында, игътибар үзәгендә булды. Ул көнне, әллә кулында өр-яңа немец баяны булганга инде, бигрәк тә илһамланып уйнады, дәртләнеп җырлады, ак күлмәге манма су булганчы биеде ул. Соңыннан агач күләгәсендә авыл җитәкчеләре корган палаткада тамак ялгап, тамак чылатып чыккач, ул тагын баянын кулына алды. Аннары кайсы кайдагы агач төбенә табын корган яшьтәшләр, классташлар, авылдашлар безне берәм-берәм үзләре янына чакыра башлады. Һәммәсенең дә күзенә иң элек затлы баян ташлана, Алмазны тагын уйнарга, җырларга кыстыйлар. Шулай бер-бер артлы дус-ишләрне йөреп чыга торгач, йөрәк хисләребез читлектән чыгып, безгә яшь арыслан холкы керә башлаган иде инде. Ә Алмаз ялындырып тормый, яңа баянны бертуктаусыз тарта да тарта. Малай чакларны искә төшерә-төшерә, кочаклашып җырлый-җырлый безнең йорт турына килеп җиткәч, минем энекәш, Алмазның ай-ваена карамыйча, аны ишегалдына култыклап алып кереп китте. Башта өйгә кереп, әнкәйнең тел йотарлык бәлешен мактый-мактый баянда уйнады Алмаз. Аннары мәҗлес әкренләп мунчаның ял бүлмәсенә күчте. Мин мунча түбәсеннән имән себеркесе алып төшеп, ташка пар

җибәргәндә Алмаз ләүкәдә затлы баян тартып утыра иде инде. Рәмзил белән Рифкат ләүкәне сәхнәгә әйләндереп, бөтен дөньяларын онытып, «Ай гармун, гармун» җырын суза... Татар мунчасындагы эсселеккә чыдый алмаган өр-яңа немец баянынын күреге бер яктан кубып, үлем авазы чыгаргандай уфылдый, аһылдый иде.

Өйгә кайткач, Алмаз әтисеннән нинди сүзләр ишеткәндер, белмим, әмма бу баянны безнең беренче һәм соңгы күрүебез булды. Наил абый, бәлки, аны ремонтлап саткандыр, йә берәр нәрсәгә алышкандыр, анысы безгә мәгълүм түгел. Үзен бүтән күрмәсәк тә, безнең күңелләрдә ул «немец баяны», «мунча баяны», «затлы баян» булып, кызыклы хатирә булып уелып калды.

## Учитель Сәхби

Безнең авылда берничә атаклы кеше бар иде. Шуларның берсе «Учитель Сәхби» исеме белән даны таралган Сәхбетдин абый. (Бу затлы кушамат ана утызынчы елларда мәктәптә укытканда ябышып калган булган.) Ул—авылның атаклы балта остасы, әмма бүрәнә күтәреп кара эш эшләп йөри торган «оста» түгел, йорт-җирнең бизәкләрен ясаучы сәнгать дәрәҗәсендәге чын оста иде. Тирә-юнь авыллардагы иң матур тәрәзә кашагаларын агачтан уеп ул ясаган, иң мәһабәт урыс капкалар да—аның эше, мәчет манарасын торгызганда да Сәхбетдин абыйга ярдәм сорап барырга туры килде. Җитмәсә, әле ул иң нәзберек уен коралы—скрипканы да үзе ясый һәм һәр елны Җыен башланган көнне халыкны үзе артыннан ияртеп, скрипка уйнап урам буйлап уза.

Кызык та, сәер дә кеше иде «Учитель Сәхби». Сугыш вакытында әсирлектә булганга күрә, ул авыл-колхоз тормышына артык катнашмыйча (дөресрәге, аны катнаштырмыйлар), ялгыз гына яши, үз гомерен күбрәк үзе белән генә узгара иде. Хәләл җефете белән нигәдер сүзгә килешкәннән соң, ул өеннән чыгып китеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр озак еллар берьялгызы үз ишегалдындагы остаханәсендә яшәде. Бу остаханә утын яга торган акшарланган мичтән, кечкенә сәке, аш өстәле һәм төп эш урыны—агач верстактан гыйбарәт иде. Хатыны белән бергә тормаса да, ана авыз ачып сүз катмаса да, киемнәре каралгач, ул аларны ишегалдындагы ләгәнгә чыгарып сала, ә тегесе керләрне юып, үтүкләп болдырга өеп куя торган иде. Нигә ачуланышканнардыр, белмим, әмма үпкәләре никадәр зур булса да, алар чынлап аерылышмадылар. Сәхбетдин абый туксан дүрт яшенә кадәр үзе лапас ышыгында яшәсә дә, йорт-җирен, каралты-курасын һәрчак карап, йортына күз-колак булып торды.

Әнкәйнең энесе Раиф абый да немецләрдә әсирлектә иза чиккәнгә күрәдерме, әллә инде икесе дә балта остасы булгангамы, алар бик еш очрашалар, очрашканда сөйләшеп сүзләре бетми торган иде. Әгәр бераз төшереп тә алсалар, әңгәмә башта татарчадан русчага, аннары әкренләп немецчәгә күчә. Күрәсең, алар үзләре генә белгән серләрне кеше аңламасын дип шулай сөйләшә торган булганнардыр.

Авылга кайткан чакта мин гадәттә Яңа урамда юл өстендә яшәгән Сәхбетдин бабай янына сугылып чыгарга тырыша идем. Чөнки аның белән сөйләшүе кызык: ул күпне күргән, күпне белә, аның һәр нәрсәгә үз карашы, дөньяга үз мөнәсәбәте бар. Мин алып кайткан кала күчтәнәчләре белән чәй эчәбез, кайчакта ул дару өчен генә бераз мәен дә йотып куя. Яше туксанны узса да, җөмләсе төзек, фикере төгәл һәм ачык. Аның остаханә-сараенда түр стенага татар кыяфәтле Ленин портреты элеп куелган. Еллар тузаны сеңеп, ул инде шактый саргайган, төсе китә башлаган. Бер кайтуымда мин аннан: «Сәхбетдин абый, без бит инде башка заманда яшибез. Ленин модадан чыкты, мәктәп балалары хәзер аның кем икәнен дә белмиләр. Нигә бу иске портретны алыштырмыйсың?»—дип, ярым җитди, ярым шаяртып сорап куйдым. Ул, миңа бераз сынап карап торды да, авыз чите белән генә елмайды һәм: «Әлегә бу стенага эләрлек кешегез юк бит. Булгач, эләрмен»,—диде.

Саубуллашып китәр алдыннан мин аннан берәр көй уйнавын сорадым. Ул ашыкмый гына үзе ясаган скрипканы кулларына алды да иң яраткан көен—Сәйдәшнең «Хуш, авылым»ын сузып җибәрде. Гүяки бу мизгелдә ул безнең белән түгел, ә үзенең туган авылы, узган михнәтле гомере белән саубуллаша иде.

Икенче кайтуымда Сәхбетдин абый инде мине, кабер ташы кыяфәтенә кереп, авыл башындагы зиратта көтеп тора иде.

**Разил ВӘЛИЕВ**

Ләйсән
Фәтхетдинова

# СУ ЕЛМАЙГАЧ...

ХИКӘЯ

...Алмаганнар. Калдырганнар. Әйтмәгәннәр. Имеш, Диләүзе сорашып йөрергә тиеш булган. Кая булсын инде, җыр ансамбленә! Мәдәният Йортында классташлары арасында "колагына аю басмаганнарга" яңа җыр өйрәтәсе иделәр. Сабантуйга инде! Дилә ничә яшьтән сәхнәгә чыгып җырлап йөри. Юк шул, ансамбльгә алмаганнар. Алты кыз берләшкәннәр дә, җырны сайлап, өйрәнеп үк куйганнар. Бүген ипигә дип кибеткә төшкән иде, шунда белеп кайтты. Классташы Римма сөйләде. Үзе дә "җырчылар" исемлегендә ул. Нишләп белешмәдең соң, кая йөрдең, дигән була. Үзе дә белә бит инде югыйсә Диләнең өч көн Казанда булып кайтканын! Гарьләнде, бик гарьләнде кыз. Бөтен ачуын эченә кысып көчкә түзде. Бар уйлаганын кычкырып, ызгышып китәсе килсә дә, түзде.

Ә ул ничегрәк тезелеп басасыларын да, ничегрәк киенәселәрен дә күзаллый башлаган иде бит! Имеш, үзенең ал тасмаларын һәрберсенә биреп торыр, аякларына ак туфли килешер, бәйрәм рухы өстәр өчен шарлар аласы булыр... Юк инде, Сабантуйга өч көн кала мин дә җырлыйм әле дип соранып йөрмәс. Горурлык дигән нәрсә дә бар бит әле дөньяда! Ул гына да түгел, гарьләнә. Ничек гарьләнмисең инде, бас, кызым Әпипә дигәндә дә көйнең ике җирендә ялгышкан Гөлгенәне алсыннар да, озын халык җырларын да өйрәнеп маташкан Диләне калдырсыннар әле. Ярааар, калдырсалар! Үзләреннән дә шәп итеп берүзе җырлар ул Сабан туенда. Менә карап торырсыз!

Кибеттән кайткач, ярты сәгатьләп бакчаларында утырды кыз. Зур гына су савытлары бар анда. Шул суга карап утырса, ачуы да, арыганы да басыла Диләнең. Әнә, җилнең итәкләре тиеп киткән саен нәни дулкыннар ясап тирбәлә, кояшның һәр нурын үзендә чагылдырып җемелди су. Тукта! Елмайдымы? Тукта, дим! ЕЛМАЙДЫ! Су! Гап-гади су ЕЛМАЙДЫ! Ничек инде? Сумы? Әллә юләрләнәсенме? Точно, китеп барасың син... Юк-юк, елмайды бит! Әллә ничек кенә, көтмәгәндә, җилнең тынып торган чагында(!), дулкыннары белән җыелды да, елмайды! Түгәрәкләнеп килгән күзләре, почыкланып күтәрелгән борыны, җәелеп елмайган иреннәре! Нәкъ шулай, ел-май-ды! Ышанмыйсынмы? Чын әйтәм сиңа, гап-гади, юк, серле һәм җанлы су һич көтмәгәндә күзгә карап елмайды! Елмайды!!! Тәннәр чемердәп куйды. Көтелмәгән елмаю, көтелмәгән җан, көтелмәгән дус! Димәк, җырлый Дилә Сабантуйда! Җырлый! Ничек кенә җырлый әле, Алла боерса!

Ә сунын елмаюы турында Дилә йөгереп кереп иң беренче әнисенә, аннары әтисенә, аннары энесенә сөйләде. Йокыга киткән иденме әллә, әкият сөйләмә инде, дип көлделәр генә. Ышанмыйлар! Алма апасы да ышанмады! Бер өмете дә калмагач, күрше малае Гамилгә сөйләп карарга булды Дилә. Бәлки, ул ышаныр? Әнә бит, гел, бабай тегене күргән дә, моны күргән, дип сөйли торган иде.

Йөгерә-атлый күршеләренә таба китте кыз. Гамил үзе дә капкадан чыгып килә икән.

—Сәлам! Кая барасың?—дип сораштыра башлады Дилә.

—Бармыйм, урамга чыгам,—дип җавап кайтарды Гамил.

—Хе, урамга тик утырырга гына чыгалар димени? Борчак урларга барасындыр әле!

—Китте ди менә, хәзер! Анда тотсалар!.. Штраф түләтә башлаганнар шул!

—Ярар, карале, бер нәрсә сөйлим сиңа хәзер, дип үз хәлен сөйләмәкче итте кыз.

—Җә, сөйләп кара. Берәр гайбәттер инде тагын! Сезнең шул булыр!

Их, ачу китереп тора тагын! Дилә бер мизгел борылып кереп китмәкче дә булды. Тик... бәлки ана да суның елмайганы бардыр, ә?

—Бер дә гайбәт түгел... Карале, ни., синең суга карап торганың бармы?

—Бар, шуннан нәрсә?

—Шуннан шул. Аның сиңа елмаеп караганы бармы?

—Ха-ха-ха! Әйттең сүз, тешләрен күрсәтеп ыржайды менә бая!

—Көлмә әле, мин чынлап әйтәм!—дип житдилек белән дәште Дилә.

—Мин дә чынлап! Ха-ха!

—Беләсеңме, Гамил, бүген мин суга карап утыра идем, име, күземә күренә дип торам, бер жилсез вакытта су, әллә ничек кенә итеп, миңа елмаеп карады! Ант әгәр, гап-гади су елмайды!

Гамил Диләгә бер карады, ике карады, аннары кычкырып көлеп жибәрде, һәм кинәт йөзенә житдилек чыгарды:

—Дилә, карале. Син хәзер, име, көзге каршына барып бас. Авызыңны зур итеп ач та, бар көченә елмай. Аннары имән бармагыңны чигә турысына куй да бераз боргала!—Гамил янадан кычкырып көлеп жибәрде.

Аннары гына аңлады Дилә бу күрше малаеның "житди" сүзен.

—Юләр! Мин сиңа ышанган булам тагы!

—Мин дә шулай дим бит! Юләр тек юләр!—дип үртәп калды Гамил. Дилә исә кире йөгереп кереп китте...

—Сезнең каршыгызда авылыбызның яшь сандугачы Дилә Сөләйманова жырлый! Каршы алыгыз, дуслар!

Чәчләрен ике якка үреп салган да, ал тасмаларын бәйләгән, баш түбәсендә алсу калфак, кулында болыннан яңа жыелган чәчәк бәйләме... Күпереп торган челтәрле итәкләре, жиңнәренә тегелгән чын кебек гөлчәчәкләре, беләндәге бантиклап куелган жемелдәп торучы тасма... барысы да күз явын алырлык! Ә тавышы... колак явын! Көчле дә соң тавышы Диләнең! Мөгаен, авылның әнә теге очына кадәр ишетеләдер, ә! Үзе моңлы итеп жырлый бит, йөрәкләрнең иң яшерен хисләрен дә тартып чыгарырлык итеп жырлый. Бүтән беркайчан да чыгармам, мәңгегә бикләдем дип яшереп куйган уй-хисләрне дә уятып, күптәннән күңелгә керә алмаган бәйрәм хисен таратып жырлый. Әнә, бөтен халык дәррәү килеп кул чаба. Сәхнә алдында биеп торган кунакларның иң нәниенә чәчәкләрен бирде дә, алкышлар эчендә йөзеп кереп китте Дилә. Менә ул жыр ансамбленә ләкмичә калган кыз! Менә ул! Әле үкенерсез булыр, искә алырсыз, безнең арада жырласа, шәп булган булыр иде дә бит, диярсез. Соң шул инде! Сезнең гел бер төрле сикереп торган жырыгызга моның кадәр кул чабучы да булмады ла! Булмады! Сәхнәнең икенче ягыннан төшеп килүче Диләгә нидер әйтергә торган сыйныфташлары яныннан кыз борынын чөеп, келт итеп, тиз генә узып китте дә барды. Менә шулай! Сорашырга иде соң дип йөрмәссез моннан ары. Үзегез килерсез әле. Әйдә инде, безнең белән жырла инде, диярсез...

Бүгенге чыгышыннан бик канәгать булды, сөенеченнән башлары әйләнде Диләнең. Гадәттәгечә, бакча суы янына чыгып утырды. Ял итәргә, киләчәккә йолдыз планнары корырга. Ә су, һаман шул жил итәкләре белән шаяручы су гына бүген нигәдер карамчыл күренә. Әллә күптән алыштырмаганнар инде? Төбенә ләм утыра башлагандыр әле. Тә-ә-к, менә хәзер Диләнең мәктәптә дәрәжәсе күтәреләчәк. Йолдыз була ул! Менә аның каршына Гамил килә. Кулында бер бәйләм гөлчәчәкләр! Әйдә әле, Дилә, бабаемның күргәннәре хакына..., тфү, әйдә әле, Дилә, дуслыгыбыз хакына тагын бер генә жырлап күрсәт әле, ди. Менә бу дәфтәремә имзаңны куйсаң да шәп булыр иде, танылыбрак киткәч, сине тотып булмас, ди. Дилә елмаеп куя да, теге биткә зур итеп автографын сырлый. Нинди жыр гына жырлап күрсәтсен икән соң? Тукта! Тукта, дим! Кайчан гына елмаеп карап торган су каш жыердымы? Әйе! Нәрсә?! Усал итеп карадымы? Нигә? Юк, булмас, юләрләнмә лә! Кайчандыр шундый матур итеп елмайган кояшлы су каш жыерып карады дисеңме? Ачулы итеп?! Сумы? Жилнең тынып торган чагында үзеннән-үзе дулкыннар ясалып кашын жыерды да, түгәрәкләнеп килгән күзләре усал карадымы? Ничек? Ачуланды?.. Әһә, аңлашыла... Йолдыз чирен кешеләр генә түгел, табигать тә яратмыйдыр шул! Чирләмәскә! Дилә! Дилә, дим! Сиңа чирләргә ярамый! Бигрәк тә йолдыз авыруы белән...

# КАПИЦА АТКАН УК

Язмаларымның берсендә мәшһүр галим Эрнест Резерфордның яшь студент белән аның укытучысы арасында туган бәхәстә арбитр сыйфатында катнашуы хакында сөйләдем (№9, 184 бит). Шул чакта ук Резерфорд житәкләгән лабораториядә унөч ел буена фәнни командировкада тикшеренүләр башкарган совет галиме Петр Леонидович Капица турында да сөйләргә булган идем. Әмма аның фәнни ачышлары, физиканың төрле юнәлешләре һәм техника өлкәләрендәге казанышлары турында сөйли башласаң, биографиясен кирпеч кебек калын китап күләмендә язарга кирәк булыр иде. Дөньякүләм танылган галимнең СССРның Фәннәр Академиясенә хакыйкый әгъза итеп сайланудан ун ел элек, 1929 елда ук Англиядә академик итеп сайлануы бик тә гыйбрәтле факт түгелмени? Дөрес, ана үз илебездә дә игътибар аз булмый: ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, СССР Фәннәр Академиясендә үзе оештырган Физика проблемалары институтының директоры, ике кабат Дәүләт бүләге лауреаты. Әмма иң мөһиме шул: Петр Капица әлеге язмамда искә алынган Нильс Бор һәм Эрнест Резерфорд шикелле үк дөньядагы иң абруйлы Нобель премиясе алган иде.

Галимнең репрессиягә дучар булган хезмәттәш галимнәрен курку белмичә яклавы да мәгълүм. Аның булачак академик Л. Д. Ландауны яклап Сталинга, Бериягә, Молотовка язган хатларын хәзер фән тарихы белән кызыксынган һәркем укый ала. Тәгълимати физика белгече академик В. А. Фокны да эзәрлекләүдән П. Л. Капица яклап калган. Чит ил авторларының язмаларында: «Капицадан Джо үзе дә курка иде!», дигән сүзләргә юлыкканым бар. «Джо» дигәне Джугашвилины, ягъни Сталинны аңлата.

Шунысы да игътибарга лаек: нинди генә тикшеренүләргә алынса да, физика һәм техникада яңа юнәлешләргә нигез ташы салган һәм яңа күренешләр ачыклаган Петр Капицаның тәрҗемәи хәлен язучылар аның «алтын куллы инженер» икәнен дә ассызыклап раслыйлар. Латин һәм француз телләрендә «инженер» сүзе иң әүвәл сәләтне, тапкыр зирәклекне аңлата. Бик күп еллар элек галимнең чын-чыннан инженер булганын раслаучы бер вакыйга хакында укып сокланган идем. Бер тәҗрибә үткәрү өчен яңа җайланма ясау ихтыяҗы туа, моның өчен исә бик тә озын һәм бик тә нечкә, өстәвенә буеннан-буена бер үк калынлыктагы кварц җебе кирәк була. Аны каян алмак, ничек ясамак кирәк? Шактый зур коллектив өчен бу хәл итеп булмаслык проблемага әверелә.

Ниһаять, Петр Леонидович, эретелгән кварцка уенчык җәядә киерелеп тартылган укның очын төртеп ала да, аны очырып җибәрә. Тиешле кварц җебе әнә шулай хасил ителә. Һәрчак яңалыкны күрә белү сыйфатына балалар ия. Шундый сыйфатын олыгайгач та җуймаган шәхесләр чыннан да иҗади затлар буладыр, мөгаен.

Шул уңайдан, сугыш елларына туры килгән балачагымдагы кордашларым исемә төште. Авыр эшләрне үз җилкәсенә алган олырак үсмерләр ниләр генә уйлап чыгармыйлар иде, тирес тутырылган авыр арбаны басуда аудару өчен авыш яссылык, ягъни өсте кыеклап киселгән бүкәнгә ныгытылган тактага арбаның алгы тәгәрмәченең берсен күтәртеп җибәрү, физиканы белмәсәләр дә, икенче төр рычаг кулланып авыр печән чүмәләсен өчәүләп кибән башына очыру, атларга эшне җиңеләйтү өчен, урман кырыеннан алып елгага тиклем шугалак туңдырып, кисеп ботакларыннан чистартылган агач бүрәнәләрне елгага тиклем шудырып алып бару дисеңме... Кызганыч ки, авылдашларымның күбесенә сугыштан соңгы авыр елларда укуларын дәвам итү мөмкин булмады. Бәлкем, алар арасыннан да Капица шикелле зирәк инженерлар һәм галимнәр үсеп чыккан булыр иде әле?

**Ким ШАКИРОВ**

## Айдар Җамал



Айдар Жамал (Жамалиев Айдар Марат улы) 1985 елның 15 мартында Казан шәһәрендә дөньяга килә. Әтисе Марат Казанныкы, әнисе Зәйнәп Актаныш районының Табанлыкүл авылында туып-үскән.

Айдар Жамал Казан шәһәренең 71нче татар-рус мәктәбендә белем ала. Мәктәптә укыган елларында ук иҗатка тартыла башлый. Беренче язганнары "Сабантуй" газетасы битләрендә басыла. Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының Татар филологиясе һәм тарихы бүлегенә укырга керә. 2004 елда, икенче курста укыганда, аның шигырьләре, хикәяләре көндәлек матбугат битләрендә дөнья күрә башлый, репортажлары "Азатлык" радиосында эфирга чыга. 2005-06 елларда "Ялкын" журналында хәбәрче булып эшли. 2006 елда ул Сажидә Сөләйманова исемендәге стипендия лауреаты була. 2007 елда шигырьләре "Әллүки" күмәк җыентыгында басыла. Университетны тәмамлагач, Айдар белем алуын аспирантурада дәвам итә. 2007-08 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. Шул вакытта аның "Күкрәгемдә—күкләр..." исемле шигырь җыентыгы, "Динар һәм Гадел маҗаралары яки Сөембикәдә кунакта" дип аталган балалар өчен комиксы дөнья күрә.

2008-10 елларда "Бердәм Россия" партиясенең төбәк башкарма комитетында эшләп ала. Бүгенге көндә Айдар Жамал аспирантурада укуын дәвам итә.

---

*Укучы сүзе*

* * *

Кадерле редакция!

Борчыганым өчен гафу итегез, әмма "Сүнмәс утлар балкышы" исемле гаҗәеп матур итеп бизәлгән һәм бик югары сыйфатлы кәгазьдә нәшер ителгән, бихисап тарихи мәгълүматларга бай китапны укып чыкканнан соң туган фикерләремне сезгә җиткермичә каласым килмәде. Журналның менәнче саны чыгу уңаеннан басылган бу китап чын мәгънәсендә Татарстан һәм татар халкы турында тарихи, сәяси, иҗтимагый тормыш турында иң дөрес энциклопедик чыганак, чөнки китап архивларда сакланган чын дөрес материаллар белән баетылган. Бу китапны укыган кеше тарихны бозып күрсәтергә батырчылык итә алмас.

Әлеге китап—дөнья буйлап таралып яшәүче татар халкына үзенә күрә бер горурлык чыганагы да, без татарлар менә нинди кешеләр дип әйтергә, мактанырга мөмкинчелек бирә. Димәк, халкыбызның киләчәге хакына тырышу-тырмашу, кирәкле эшләр башкару омтылышы да уята инде ул. Рәхмәт!

**Габделхәй НУРИЕВ,**
*Казан*



*Ватан сугышында катнашкан бер төркем язучылар. Алар хәзер безнең арада юк инде... Сулдан уңга—Тихон Журавлев, Мәхмүт Хөсәен, Рәисә Ишморатова, Юрий Белостоцкий, Мирсәй Әмир, Нәби Дәүли, Геннадий Паушкин. Үткән гасырның 70нче еллары.*



*Һади Такташның улы Рафаил Такташ (1936-2008). Сәнгать фәннәре докторы. Үзбәкстанда яшәп иҗат итте.*



*Бөтен дөньяга билгеле мәшһүр биюче, балет артисты Рудольф Нуриевның Казанга килгән чагы. Рәсемдә композитор Әнвәр Бакиров һәм Рудольф Нуриев. 1993 ел.*



*Шагыйрь, прозаик, драматург, хәрби очучы, легендар шәхес Салих Баттал (1905-1995). 1993 елда төшерелгән рәсем.*



*Шагыйрь Әдхәт Синугыл (1935-2004). Казанда, Ташкентта, Кырымда яшәп иҗат итте.*



*Җыелыш залында. Алгы планда—Фәнзаман Баттал, Марат Кәбиров, икенче, өченче рәтләрдә—Радик Фәизов, Заһид Фәйзи, Разим Вәлиуллин. 2003 ел.*

## ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘРЛӘР

***

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Көньяк Уралда эш сәфәрендә булып кайтты. Сәфәр барышында ул, Чиләбе өлкәсе губернаторы Михаил Юревич белән Чиләбе торба прокатлау заводында булды.

Соныннан губернатор резиденциясендә М. Юревич белән булган очрашуда Р. Миңнеханов, Татарстан делегациясе Чиләбе шәһәрен, заманча җитештерүләрне һәм Чиләбе өлкәсенең куәтле потенциалын күрде, дип билгерде. Республика башлыгы губернаторга һәм аның командасына өлкәдәге татар җәмгыятенә булышлык иткәне өчен рәхмәт җиткерде. Очрашуда Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Анда шулай ук килешүне гамәлгә ашыру буенча 2011-13 елларга чаралар беркетмәсенә имза куелды.

Эш сәфәре кысаларында Татарстан Президенты Бөтендөнья татар конгрессының Чиләбе өлкәсе бүлеге активистлары белән дә очрашты. Р. Миңнеханов, оешма активистларын сәламләп, Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы эшчәнлеге Татарстаннан читтә яшәүче татарларның иң актив хәрәкәтеннән берсе булып тора, диде. Ул Конгресс җитәкчесенең нәтиҗәле эшен дә билгеләп үтте. Президент, Татарстаннан читтә яшәүче татарлар үз мәдәниятләрен һәм милли гореф-гадәтләрен саклый алсын өчен, республика төрле яклап ярдәм күрсәтәчәк, дип ышандырды.

Соныннан Президент Р. Миннеханов һәм губернатор М. Юревич Татарстан сәнгать осталары концертын тамаша кылды.

***

Екатеринбург шәһәрендә «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклор коллективлары фестиваленең гала-концертында төрле төбәктән 500дән артык башкаручы катнашты. Анда Татарстаннан да ансамбльләр чыгыш ясады.

Президент Рөстәм Миңнеханов шәһәр губернаторына, Свердловск өлкәсендәге татар җәмгыятенә ярдәм итүләре өчен рәхмәт белдерде. Шулай ук фестивальне оештыручыларга һәм катнашучыларга да рәхмәтен җиткерде. «Түгәрәк уен»ның зур бүләгенә Омск өлкәсенең «Наза» ансамбле лаек булды. Р. Н. Миңнеханов Свердловск өлкәсе «Сардарья» коллективына чит ил маркалы микроавтобус алырга сертификат тапшырды.

## МӘДӘНИ ТӨРЛЕЛЕКТӘГЕ УРТАКЛЫКЛАР

Төркиянең Кайсери шәһәрендә Европа берлеге Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессында Мәдәният һәм мәгариф комитетының чираттагы утырышында Европа төбәкләренең мәдәни, фәнни һәм гуманитар өлкәләрдә алга таба хезмәттәшлек перспективалары тикшерелде.

Комитет сессиясендә рәислек иткән Конгрессның Төбәкләр палатасы Мәдәният һәм мәгариф комитеты башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин мәдәни төрлелекнең Европа өчен дә, шулай ук Россия өчен дә мөһимлеген искәртте.

Утырыш алдыннан Фәрит Мөхәммәтшин Ислам конференциясе оешмасы каршында эшләп килүче Россия Федерациясенең даими вәкиле Камил Исхаков һәм Татарстанның Төркиядәге вәкаләтле вәкиле Радик Гыйматдинов озатуында Истанбулда Ислам тарихы, сәнгать һәм мәдәнияте фәнни-тикшеренү үзәгендә (ИРСИКА) булды.

Республика Дәүләт Советы Рәисе очрашу һәм сөйләшүләр барышында ИРСИКА генераль директоры Халит Эрен әфәндегә Татарстан җитәкчелеге исеменнән тирән ихтирам сүзләрен җиткерде. Абруйлы ислам оешмасы генераль директоры үзенең җавап сүзендә парламент рәисенә ИРСИКА тарафыннан "Татарлар: тарих һәм цивилизация" дигән хезмәтнең бастырып чыгарылуын хәбәр итте.

Ислам фәнни-тикшеренү үзәге җитәкчеләре белән әңгәмә барышында 21 майны Болгарда ислам динен иректе кабул итү көне буларак билгеләү турында Дәүләт Советы ТР Законын кабул итү сәбәпле, ИРСИКАның бүгенге Россия Федерациясе территориясендә ислам динен кабул итү датасы мәсьәләсен өйрәнү турында башлангыч килешүгә ирешелде.

## ТЕЛЕ БАРНЫҢ—ИЛЕ БАР

27-30 сентябрьдә Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының татар этно-мәдәни компонентлы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең V Бөтенроссия съезды узды.

Анда 38 төбәктән 450 милләттәшебез катнашты. Пленар утырышта делегатлар

алдында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Ул милли мәктәптә, мәгариф өлкәсендә бара торган үзгәрешләргә тукталды.

- Әлеге үзгәрешләрнең үзәгендә, әлбәттә инде, укытучы, мөгаллим тора,—диде парламент житәкчесе. Сүз дә юк, педагог, тәрбияче, киң эрудицияле, тирән белемле, инновацион технологияләрне үз иткән, актив тормыш позициясендә торган абруйлы шәхес булырга тиеш! Бу уңайдан Татарстанда педагогның дәрәжәсен югары күтәрү өчен өстәмә чаралар күрелә. Укытучыларның хезмәт хакларын күтәрү, яшь мөгаллимнәрне мәктәптә калдыру өчен матди кызыксындыру күздә тотыла. Республикабыздагы бөтен мөгаллимнәрне дә шәхси компьютер, ноутбуклар, татар телен укыту буенча электрон программалар белән тәэмин итү буенча да махсус акция уза.

Съездда докладлар белән ТР мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, РФ Дәүләт Думасы депутаты, Россия татарларының Федераль милли-мәдәни мохтарияте Советы рәисе Илдар Гыйльметдинов, Ульян өлкәсе мәгариф министрлыгының баш белгече Федосья Улендеева, ТДГПУ ректоры Рәдиф Жамалетдинов һәм башкалар чыгыш ясады.

Алар татар мәктәбен, гомумән, халкыбызның милли-мәдәни үзенчәлекләрен саклап калу, илебезнең төрле төбәкләрендә милләттәшләребез белән эшне тагын да жанландыру, милли педагогик кадрларны әзерләү һәм аларның белемнәрен үстерү турында фикер алыштылар. Съездда каралган мәсьәләләр буенча резолюция кабул ителде.

### ТАТАР КИНОСЫ БАР

VI халыкара Казан мөселман киносы быел мәркәзебездә 15-19 сентябрь көннәрендә үтте. Фестивальнең конкурс программасына 21 илдән 51 фильм тәкъдим ителде. Шуларның 14е тулы метражлы, 17се документаль, 10сы кыска метражлы һәм 10 анимация картиналары.

Шәһәребезнең «Родина», «Мир», «Органик» кинотеатрларында казанлылар һәм килгән кунаклар бу фильмнарны бушлай карады.

Мөселман илләрендә төшерелгән фильмнар арасында аеруча «Бибинур» (режиссеры Юрий Фетинг) дигәне зур уңыш белән барды. Бирелә төп рольне Г.Камал исемендәге театр артисты Фирдәвес Әхтәмова уйнады. Һәм ул фестивальнең иң яхшы хатын-кыз ролен башкаручысы булып танылды. Димәк, татар киносы булачак һәм аның нигезе бар.

### КОНКУРС ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы Муса Җәлил исемендәге республика премиясен бирү буенча чираттагы конкурс башлану турында хәбәр итә. Әлеге бүләк ике елга бер тапкыр, Татарстанның 30 яшькә житмәгән талантлы яшьләренә, шулай ук 30 яшьтән узган аерым авторларга, яшьләр белән эшләүче коллективларга һәм ижат берләшмәләренә тапшырыла. Бу премия сәнгать, фән, мәгариф, тәрбия үсешенә өлеш керткән өчен бирелә. Шулай ук Муса Җәлил исемендәге бүләккә яшьләр эшкуарлыгы өлкәсендә зур уңышларга ирешкән, яшьләр программаларын тормышка ашыручы затлар дәгъва итә ала. Бер премия 100 мең сумны тәшкил итә. Конкурска дигән ижат эшләрен Муса Җәлил исемендәге премия бирү буенча комитетка агымдагы елның 20 декабреннән дә сонга калмыйча юлларга кирәк булачак.

### ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ МИРАСЫ

Казанда ике көн дәвамында «Россия һәм якын чит илләрдә яшәүче мөселман халыкларының рухи мирасы» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция эшләде. Анда танылган ислам белгечләре, Россия, БДБ һәм кайбер ерак чит илләрнең, мөселман уку йортлары вәкилләре катнашты. Алар арасында Ислам дөньясы университетлары федерациясе генераль секретариаты житәкчесе Мостафа Али һәм Марокко патшалыгының Россиядәге илчесе Абделкадыйр әл-Ашхаб та бар иде.

ТР Министрлар Кабинетының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән идарәсе житәкчесе Булат Яһудин: «Шәрекъны өйрәнү һәм көнчыгыш телләрне укыту республиканың берничә югары уку йорты һәм мәгариф үзәкләрендә тормышка ашырыла»,—дип белдерде. ТДГПУ ректоры Рәдиф Жамалетдинов үз чыгышында хөкүмәтнең мөселман мәгарифе традицияләрен үстерүгә аеруча зур игътибар бирүен ассызыклады. «Соңгы елларда без Россия һәм Татарстанның белем бирү һәм фәнни өлкәләрдә төрле мөселман илләре белән хезмәттәшлекне ныгытуның шаһитлары булдык»,—диде ректор. ТДГПУның ислам тарихы һәм мәдәнияте өлкәсендә белгечләр әзерләү мөмкинлеге зур. Безнең уку йорты беренчеләрдән булып Ислам дөньясы университетлары федерациясе әгъзасы булды. Әлеге федерация генераль секретариаты житәкчесе Мостафа Али, борынгы ислам цивилизациясенең башка цивилизацияләр, телләр барлыкка китерерлек нигезе барлыгын искәртеп узды. РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин: «Мөселман халыклары рухи мирасы дигәндә, еш кына тар карашларга юлыгабыз. Ислам цивилизациясенең тирәнгә киткән һәм бай тамырлары ныклап өйрәнүне таләп итә",—диде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Илдус Фәиз дә аның сүзләрен хуплады: «Динне фәнни күзлектән өйрәнү мөмкинлеге туды»,—диде

ул.

Мөселман халыклары рухи мирасы турында сөйләшү секция утырышларында да дәвам итте.

## КЫТАЙДАН ХӘБӘРЛӘР

***

Киләсе елда Кытайда узачак Универсиада вакытында Шэньчженьда Рус-татар йорты эшләячәк. Бу хакта Татарстан Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы хәбәр итә. Күптән түгел министр Рафис Борһанов житәкчелегендәге республика делегациясе Шэньчженьда төзелүче Универсиада объектларын карады. Ике яклы сөйләшү барышында ябылыш тантанасына бәйле мәсьәләләр дә каралды. Мәгълүм булганча, әлеге тантанада Татарстанга Универсиада әләмен тапшырачаклар.

***

Кытайның Хунань педагогия университеты белгечләре Казандагы аерым телләрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләрендә кытай телен дә укытырга тәкъдим итә. Бу турыда ректоратның чираттагы утырышында КФУ ректоры Илшат Гафуров та белдерде. Хунань университеты югары уку йортында кытай теле укытучысы өчен өстәмә ставка булдырган.

## КАМАЛ ТЕАТРЫ УФАДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы Башкортстанда чираттагы ижат сәфәрендә булды. Шушы зур театр бәйрәме башлану белән театр сөючеләрне котларга Татарстан вице-премьеры—мәдәният министры Зилә Вәлиева килде. Гастрольләрне ачу тантанасында чыгыш ясап, ул барлык тамашачыларны да, артистларны да бәйрәм белән котлады. Министр ике тугандаш республиканың төп театрларының ижади дуслыгы уңышлы дәвам итүен ассызыклап, киләчәктә дә шулай булачагына ышаныч белдерде.

Г. Камал театрының Уфага ижат сәфәре уңаеннан Башкортстан вице-премьеры Зөһрә Рәхмәтуллина да котлау сүзләрен житкерде. Аннан соң чыгыш ясаган Г. Камал театры директоры Шамил Закиров, театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры директоры Рәис Исмәгыйлев артистларны да, театр сөючеләрне дә тәбрикләде. Алар Уфага күптән көтелгән күркәм бәйрәм килүен әйттеләр һәм гастрольләрнең уңышлы үтәчәгенә ышаныч белдерделәр.

Казанлылар бу юлы театр сөючеләр игътибарына 9 спектакль тәкъдим итте. Алар арасында "Яшь йөрәкләр", "Курчак туе", "Диләфрүзгә дүрт кияү","41нең арбалы хатыннары", "Дивана", "Тәкъдир", "Мылтык", "Бәби", "Люстра" спектакльләре бар.

Бу сәфәрнең тагын бер үзенчәлеге—гастрольләрне япкан 31 октябрь көнне кунаклар драматург, шагыйрь, жырчы, композитор Зөлфәт Хәкимнең 50 яшьлек юбилеена багышланган бенефис-концертны да тәкъдим итте. Г. Камал театры тамашалары Уфаның Нефтьчеләр мәдәният сараенда күрсәтелде.

## КОМПОЗИТОР КИЧӘСЕ

25 сентябрьдә Сәйдәшев исемендәге Зур дәүләт концерт залында композитор Шамил Тимербулатовның 60 яшьлек юбилеена багышланган музыка кичәсе узды. Анда Александр Сладковский житәкчелегендәге ТР дәүләт симфоник оркестры һәм ТР дәүләт камера хоры чыгыш ясады.

Шамил Тимербулатов—бүгенге көндә актив ижат итүче танылган композиторларыбызның берсе. Аның оркестр өчен язылган әсәрләрендә һәм инструменталь концертларында татар халкының күркәм музыкаль традицияләре гәүдәләнеш таба. Композитор музыкасын фортепианода Асия Корепанова, скрипкада Евгений Балаянц, органда Лада Лабзина, аккордеонда Сергей Антонов, бәрмә уен коралларында Идрис Сабиржанов, жырчылар Мөнир Якупов, Зилә Сөнгатуллиналар башкарды. Концертта Шамил Тимербулатовның хор, солист һәм оркестр өчен "Ялкынлы хәтер" симфония-ораториясе, фортепиано белән оркестр өчен 2нче концерты, скрипка һәм оркестр өчен 1нче концерты, шулай ук аның "Жиңүнең хатын-кыз йөзе" симфониясе һәм фортепиано белән оркестр өчен "Минем Казаным" концерты яңгырады.

Шул кичәдә Шамил Тимербулатовка "Татарстанның халык артисты" дигән мактаулы исем бирелү турында указ игълан ителде. Язучылар исеменнән юбилярны Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин котлады.

## ГЫЙБАДӘТХАНӘЛӘР БӘЙГЕ ТОТТЫ

Казан Ратушасында шәһәрнең ислам һәм христиан дине гыйбадәтханәләре арасында уздырылган смотр-конкурста иң әйбәт дип табылганнары игълан ителеп, аларның житәкчеләренә Казан шәһәре мэры һәм әлеге конкурс комиссиясенең Рәхмәт хатлары тапшырылды.

Тантанага рәислек иткән шәһәр башкарма комитеты аппаратының телләрне үстерү һәм ижтимагый оешмалар белән бәйләнешләр бүлеге башлыгы Ирек Арсланов сүзләренчә, республика башкаласында 177 дини оешма исәпләнә, шуларның 85е мөселманнарныкы, 83е—христианнарныкы, 2се—иудаистларныкы, 1се—кришнаитларныкы, 1се—будда дине тарафдарларыныкы. Ә инде гыйбадәтханәләргә килсәк, Казанда 102 дини объект бар, шуларның 52се христиан монастырьлары һәм чиркәүләре, 47 мәчет, 1 синагога, 1 кришна гыйбадәтханәсе. Шул рәвешле, Казан гыйбадәтханәләр саны буенча Россия Федерация-

сендә беренчеләр рәтендә икән.

### БЕЗНЕКЕЛӘР ТУРЫНДА АКШТА

«Tatar Islamic texts» (Татар ислам текстлары) дигән китап танылган Америка галиме Аллен Франк редакциясе астында «Dunwoody press» нәшриятында чыккан.

Әлеге китапта Исхак Лотфуллин, Габделхак Саматов, Җәлил Фазлыев, Вәлиулла Якупов кебек күренекле дин эшлеклеләренең биографияләре бирелгән. Шулай ук анда авторларның хезмәтләре, аларның оригиналь вариантлары һәм инглиз теленә тәрҗемәсе дә китерелә.

Әлеге китапның АКШта инглиз телендә чыгуы бөтендөнья фәнни җәмәгатьчелеген татар дин галимнәре һәм аларның хезмәтләре белән таныштыруда зур адым булып тора.

### "БАЛАМ ЙОКЛЫЙ..."

Америкада яшәп иҗат итүче танылган композиторыбыз Мәсгудә Шәмсетдинованың өр-яңа җыентыгы чыкты. Америка җирендә дөньяга аваз салган музыкаль җыентыкта М. Шәмсетдинова океан артындагы бишек көйләрен туплаган. Җыентык «Lord Dlow the Mooh Out» («И, Ходаем, айны сүндер, балам йоклый») дип атала. Композитор сүзләренә караганда, бу атама инглиз телендә үтемле яңгырый, чөнки әлеге сүзтезмәләр борынгы инлиз телендәге бишек җырыннан алынган.

Әлеге яңа музыкаль җыентык—«Дөньяның бишек җырлары» проектының икенчесе. 2008 елда милләттәшебезнең «Сиэтл дөньяның бишек көйләрен көйли» дигән хезмәте белән танышкан идек инде. Анда төрле халыкларның кырык өч бишек җыры тупланган иде.

### «КЫЙССАИ ЙОСЫФ»НЫ ДӨНЬЯ УКЫЙ

ТР Милли китапханәсендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы инглиз телендә тәкъдим ителде.

Тәрҗемә авторы—танылган шагыйрь, тәрҗемәче һәм драматург Равил Бохараев.

Кичәдә ТР мәдәният министрлыгы вәкилләре, язучылар, журналистлар һәм әдәбият-сәнгать сөючеләр катнашты.

- Әлеге китап аша XIII гасырда язылган беренче язма татар әсәре турында бөтен дөнья беләчәк,—дип шатлык хисләрен белдерде Р. Бохараев.

Болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы бүген дә иң укылышлы әсәрләрнең берсе булып тора.

Инглиз телендә басылган әлеге уникаль басма Татарстанның тарихи һәм архитектура һәйкәлләрен торгызу фонды һәм республика җитәкчелегенең актив булышлыгы белән дөнья күргән. Поэманы сәнгати яктан Равил Бохараевның автордашы—британ шагыйре Фред Бик эшләгән, ә фәнни киңәшче—фәннәр докторы Нурмөхәммәт Хисамов. Китапны бизәүне оста итеп Петербург рәссамы Азат Миңнекәев башкарып чыккан.

### ЯШЬ ИҖАТЧЫЛАРГА АХУНОВ БҮЛӘГЕ

Арча сәнгать мәктәбендә әдәбиятта, музыка һәм рәсем сәнгатендә зур уңышларга ирешкән укучыларга Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Гариф Ахунов премияләрен тапшыру тантанасы булды. Тантанада катнашучыларны, кунакларны район башлыгы Алмас Назиров сәламләде. Арча районы хакимияте тарафыннан булдырылган бу премия инде икенче ел тапшырыла. Быел аңа биш номинациядә Арча "Нур" балалар телевидениесе, Арча укучылар сарае һәм шәхсән Алсинә Хәбибуллина, Ландыш Вәлиева, Рамилә Шәйхиева, Зилә Галимуллина, Динара Галимуллина, Анастасия Лукоянова лаек булды. Энже Сөләйманова, Илүзә Баһавиева, Ләйсән Купирова, Гөлнур Закировага кызыксындыру премияләре тапшырылды. Бүләк ияләрен язучылар Мөсагыйт Хәбибуллин, Роберт Миннуллин, Фоат Галимуллин, Вакыйф Нуриев, Арчада яшәп иҗат итүче язучы Радик Фәизов, "Ватаным Татарстан" газетасының баш мөхәррире урынбасары Фәния Әхмәтҗанова котлады.

Җыр, музыка белән үрелеп барган бәйрәмдә әдипнең кызы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Наилә Ахунова катнашты. Аннары кунаклар Г. Ахуновның Арчадагы бюстына чәчәкләр салды, аның каберен зыярәт кылды.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен, традицияләрен, татар телен үстерүгә һәм популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Президентының матбугат архивы мөдире—баш белгеч **Хәсәнов Әнәс Хәсән улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

* * *

2010 елның 26 сентябрендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның язучылар һәм композиторлар берлеге әгъзасы, шагыйрь **Вәлиуллин Разим Нәгыйм улы** вафат булды.

2010 елның 2 октябрендә 79нчы яшендә РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, әдәбият галиме-педагог, журналист **Яхин Альберт Гатуф улы** вафат булды.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстан фәне зур югалтуга дучар булды. Танылган тарихчы һәм археограф, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе **Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов** 11 октябрь көнне 77нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

М. Госманов 1934 елның 31 маенда Көнбатыш Кытайда, Голҗа шәһәрендә дөньяга килә. Казан дәүләт университетын тәмамлый. Ул 1960 еллар урталарында ук, XVII-XVIII гасырларда татар телендә иҗат ителгән төп чыганакларны өйрәнеп һәм анализлап, үзен перспективалы тикшеренүче буларак таныта. 1979 елда басылып чыккан «Жучи Олысының XIV-XVI гасырлардагы ярлыкау актлары» монографиясе—Алтын Урданың социаль-сәяси төзелеше турында төрки телдәге төп чыганакны документаль тикшеренү—Урда тематикасы буенча киләчәктәге тикшеренүләр юнәлешен билгели. Әлеге хезмәтне тюркологлар югары бәяли, һәм ул М. Госмановның докторлык диссертациясенә нигез булып хезмәт итә.

Миркасыйм Габделәхәт улы 50 еллык фәнни-тикшеренү эшчәнлеге дәверендә чыганаклар базасын баеткан, шулай ук тарихның конкрет-тарихи проблемаларын эшләүгә ярдәм иткән хезмәтләр язды. Ул Идел һәм Урал буе төрки халыкларының тарихы һәм әдәбияты буенча күп кенә язма чыганакларны фәнни кулланылышка кертте. М. Госмановның күпкырлы фәнни эшчәнлеге заманча татар теле белеменең барлык төп юнәлешләрен: тарих һәм әдәби мирас, археография һәм историография, чыганак белеме һәм иҗади тәрҗемә, тюркология һәм педагогика юнәлешләрен колачлый.

Ул заманча татар археографиясенә нигез салучылардан берсе булып тора. Миркасыйм Габделәхәт улы татар халкының елъязма мирасын эзләү максатында 40тан артык кыр экспедициясе оештырды, шуның нәтиҗәсендә 10 меңнән артыграк кульязма һәм сирәк очрый торган китаплар җыелды. Галим һәрвакыт, иң катлаулы темалар һәм тикшеренү объектларын сайлап, тарих фәне авангардында торды.

М. Госманов тикшеренүче эшен фәнне һәм югары мәктәптә уку процессын оештыручы эшчәнлеге белән бергә үреп барды. Ул Казан дәүләт университетының укыту эшләре буенча проректоры, СССРның совет чорына кадәрге тарихы кафедрасы мөдире, татар халкы тарихы кафедрасы мөдире булды.

1991 елда Татарстан Фәннәр академиясе академигы итеп сайланып, ул аны торгызу һәм үстерүдә үзеннән зур өлеш кертте. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, соңыннан президиум киңәшчесе буларак, аның структур бүлекләрен оештыруда, академиянең гуманитар институтларын үстерү перспективаларын билгеләүдә актив катнашты.

Аның актив катнашында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең башка төбәкләр һәм илләрнең фәнни-тикшеренү учреждениеләре белән элемтәләре җайга салынды. М. Госманов Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш белгечләре җәмгыяте президенты, Россия Фәннәр академиясенең археография комиссиясе әгъзасы булды. М. Госманов Казан шәһәренең мактаулы гражданы исеменә, СССР, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт бүләкләренә, абруйлы фәнни бүләкләр һәм премияләргә лаек булды.

М. Госманов үз эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә галимнәрнең яңа буынын үстерүгә зур игътибар бирүче ачык, демократик һәм интеллектуаль шәхес булды. Фәнгә хезмәт итү аның бөтен тормышының мәгънәсе һәм намус эше иде. Бу аңа укучылары алдында эчкерсез ихтирам, киң җәмәгатьчелектә танылу китерде.

Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның—зур галим һәм гүзәл кешенең якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

**Р. Миңнеханов, М. Шәймиев, Ф. Мөхәммәтшин, И. Халиков, Ю. Камалтынов, А. Гыйльметдинов, И. Метшин, А. Мәзһәров, О. Синяшин, И. Гафуров, А. Коновалов, Р. Мөхәммәтшин, Р. Хәкимов, И. Ибраһимов.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Беренче кар.

*Дүртенче биттә:* язучы **Алмаз Хәмзин**.

# Яңа китаплар





**Нурулла Гариф.** Исем белән җисем арасы. Публицистик язмалар. Казан, 2010.—324 б.

Язучы, галим Нурулла Гариф кин җәмәгатьчелеккә мәгълүм шәхес. Ул ике дистәдән артык китап һәм йөзләрчә фәнни мәкаләләр авторы. Яңа китабына аның соңгы елларда язылган эссе-юлъязмалары, публицистик мәкаләләр, тапкыр сүзләре тупланган. "Һәрберебезнең күңелендә кеше ни өчен яши дигән? дигән сорау ята. Язучы менә шул сораугa җавап табарга тырыша. Эзләнә, уйлана. Тарихка мөрәҗәгать итә",— ди автор. Безнеңчә, автор үз максатына күпмедер дәрәҗәдә ирешкән дә.




**Фәнис Фәтхи.** Көрәшчегә җиңелү юк. Публицистик мәкаләләр. Казан, Татар. кит. нәшр., 2010.—159 б. Тиражы—2000 данә.

Журналист Фәнис Фәтхинең бу китабына татар-башкорт мөнәсәбәтләренә кагылышлы мәкаләләре, Идел-Урал төбәгендә яшәп иҗат итүче талант ияләре белән әңгәмәләре, танылган сәнгать әһелләре турында очерклары туплап бирелгән. Халкыбыз язмышына битараф булмаган һәркем өчен бу китап аерым игътибарга лаек.



Алмаз Хәмзин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)